ISSN 0206—4189

# Казан утлары

8.2001



# Tatarstan Respublikası Prezidentı

## UKAZI

**«Tatarstan Respublikasının xalıq yazuçısı» digən maqtawlı isem birü turında**



Xəzerge tatar ədəbiatın üsterüdəge qazanışları əçen yazuçı **Kamalov Xisam Nuretdin ulına** «Tatarstan Respublikasının xalıq yazuçısı» digən maqtawlı isem birergə.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

Qazan, Kreml', 2001 yıl,
15 iyün.

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2001*

# 8

**(946)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Офыклар артында. *Шигырьләр* ... 5
Факил САФИН. Саташып яткан таң. *Роман (Башы)* ... 10
Газинур МОРАТ. Илемне уйлап килешем. *Шигырьләр* ... 69
Марс ШАБАЕВ. Беренче күргән «тере» язучым ... 74
Әдип МАЛИКОВ. Тылсымлы хатлар *(Яңа әсәрдән өзек)* ... 75
Рөстәм КУТУЙ. Китү. *Шигырьләр* ... 111
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Иван дәдәй. *Хикәя* ... 116
Әнәс ИСХАКОВ. Сагыну көен жырлый күңел. *Шигырьләр* ... 119

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Индус ТАҺИРОВ. Җиңү жиңел яуланмый *(Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәш сәхифәләреннән)* ... 122

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рафаэль СИБАТ. Хәтер һәм мәхәббәт. *Эссе* ... 144
Вахит ХАКОВ. Сүздән чәчәк ясаганда ... 157

**ТАРИХ**

Нурулла ГАРИФ. Халкын олылаган олы галим ... 161
Фаяз ХУЖИН. Болгар цивилизациясе—безнең мирас ... 165
Илнур МИРГАЛИЕВ. Әмир Мамай кем булган ул? ... 170

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

12—Йосыф (Йосыф) сүрәсе ... 174

**ИБРАҺИМ САЛАХОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ**

Ләйлә МИНҺАЖЕВА. Язмыш хатасы микән?.. ... 181

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Мансур ВӘЛИ-БАРЖЫЛЫ. Оя тойгысы ... 185

**NƏNİLƏRGƏ UQIĞIZ**

İlgizər SOLTAN. Şiğırlər ... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Ф. САФИН. Роман «Мнимый рассвет», воспоминания А. МАЛИКОВА «Волшебные письма» *(с предисловием М. Шабаева)*, рассказ З. ЗАЙНУЛЛИНА «Дядя Ваня»; стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Г. МУРАТА, Р. КУТУЯ, А. ИСХАКОВА.
«Публицистика»: статья И. ТАГИРОВА «Победа легко не дается».
«Литературная критика»: эссе Р. СИБАТА «Память и любовь», статья доктора филологических наук, профессора В. ХАКОВА о нюансах татарского языка.
«История»: статья Ф. ХУЗИНА «Цивилизация Булгара—наше наследие» *(с предисловием Н. Гариф)*; статья И. МИРГАЛИМОВА «Кем был Амир Мамай?»
«Коран на татарском языке».
К 90 летию И. Салахова статья Л. МИНГАЗОВОЙ «Ошибка ли судьбы?»
«Книжное обозрение»: М. ВАЛИЕВ рецензирует книгу Ф. Муслимовой «Раны любви».
«Читайте детям»: стихи И. СУЛТАНА на латинской графике.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Ночной вокзал»; писатель Ф. Сафин.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": F. SAFIN'S novel «The imaginary dawn», A. MALIKOV'S memoirs «The magic letters» (with M. SHABAEV'S preface), Z. ZAINULLIN'S story «Uncle Vania», the versece of R. AKHMETZANOV, G. MURAT, R. KUTUI, A. ISKHAKOV.
"Journalism": I. TAGIROV article «The victory is not easy!»
"Literary criticism": R. SIBAT'S essay "Memory and love", V. KHAKOV'S article about Tatar linguistics.
"History": F. KHUSIN'S article "Bulgar civilization is our legacy". (with N. Garif'S preface), I. MIRGALIMOV'S article "Who was Amir Mamay?".
"Life and religion": Koran in Tartar language.
"Commemoratung the 90th Anniversary of I. Salakhov': L. MINGAZOVA'S article "Is that a mistake of fate?"
"Book review": M. VALIEV'S review of F. Muslimova's book "Love wounds".
"Children heading": I. SULTAN'S verses in latin graphic.
The diary of social and cultural life.
In our covers: "Kazan railway station at night"; writen F. Safin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.07.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8151 Заказ А-306
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

# Şigriət
# Шигърият



## Роберт Әхмәтҗан

### ОФЫКЛАР АРТЫНДА

#### Сәйдәшкә

**...Флигельдән чыга. Тора карап**
**нур туфаны тулы дөньяга.**
**Зәңгәр күзләр бага зәңгәр күккә:**
**ак болытлар булып**
**моң ага...**
**И киң дә соң!**
**Күзгә күренми дә**
**моңнар диңгезенең ярлары!**
**Шул диңгездә язмыш дулкыннары**
**актарыла...**
**Гарасаты каплый җаннарны!**
**Әдрән моңы! Гүя симфоник көз!**
**Алтынланган каен чуклары...**
**Өнме соң бу—кочак җәеп килә,**
**татарның бар наемщиклары!..**
**Бәхет түгелме бу? Мажор аккорд!**
**Җирне юып чапкан ташкыннар...**
**Хөрлек җырын күккә күтәрә бит**
**кара урманнарда качкыннар!**
**Җыелып әнә сөрген төпләреннән**
**Җирнең барлык каторжаннары**
**Килә сиңа, Сәйдәш,**
**котлый сине**

---

Роберт ӘХМӘТҖАН *(1935)—шагыйрь, күпсанлы китаплар («Хәтер елгасы», «Таң шәһәре», «Олы юлның җилләре» «Җәяүле күбәләк» һ. б.), популяр җырлар авторы. Ул —Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2001), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Гөлйөземнәр, Батырҗаннарың!..
Бу—син, Сәйдәш,
синең кайтып килеш
йөз яшеңә җиткән көннәргә.
Безгә кызык:
иң беренче булып
кул бирерсең икән кемнәргә?
Килче, бәгырь,
Йөрәк мәйданында
тиңең дә юк,
юктыр көндәшең.
Һәйкәлең дип тарткалашкан ара,
килеп җиткән,
узып киткән әллә
Йөз яшең?!
Тарткалаша татар, өзә алмый
үтерә ул хәтта... яратып...
Ярата ул, син дип үлә!.. Әмма
бердәмлеге җитми
һәрвакыт...
Серем сөйләп, сүз кушасым килсә,
якындагы якын кардәшкә,
ут алырга өмет чырагыма
мин Сәйдәшкә киләм,
Сәй-дәш-кә!..
Аңа булган Халык Мәхәббәте
сыяр мени шигъри тәлгәшкә?
Татарымда миллион йөрәк булса,
һәркайсында—
һәйкәл
Сәйдәшкә!..

## Тол ага

Җәйләрендә—мәтрүшкәләр исе,
Күзләрендә—томан тулгана...
Елдан—елга, елдан—гасырларга
Яна-яна зәңгәр Тол ага.

Күрәсеңдер, ата-бабалардан
Шигъри моңнар тулган елгага.
Телисеңме, теләмисеңме син—
Җырлый-җырлый моңлы Тол ага...

Яшел таулар куенына сыенып,
Зар-сагышын кагып елларга,
Төштә күреп Шатлык үзәннәрен,
Уелып-уелып уйлы Тол ага!

Яз гөлләрен алып кочагына,
Сәлам илтеп елдан—чорларга,
Йолдызларга серен ачмый гына,
Уйнап-көлеп, җырчы Тол ага.

Телисеңме, теләмисеңме син,—
Елап-көлеп моңлы Тол ага.
Җилләр тынып калгач, хәлен сорап,
Кич йолдызлар төшә елгага...

**Ил язмышы аның көзгесендә:
Кайчак—тонык, кайчак—болгана...
Табигатьне, гөлләр сулышын яклап,
Аваз салып чаба дөньяга!..**

**Чулпыларын тагып, кояшларга
Томырылып күксел Тол ага...
Уелып-уелып аккан суына карап,
Тол буенда тора...
Тол ана...**

*

**Кара күздә күкрәп коя,
юкса
җәйләр безгә кире кайтамы?
Кайтсын иде июнь күкрәүләре,
юкә шаулап чәчәк атканы...**

**Бар табигать салкын душ астында,
Ниләр уйлый икән икмәкче?
Болыт явы әллә безнең якны
Атлантида ясап китмәкче?..**

**И, ургылып, урдаланып килә,
актарылып, тонып, әйләнеп...
Әллә шунда гигант шул бүрәнкә
суырып алган бөтен җәйләрен?..**

**Балачагым. Җирнең бер бозавын
бастырыктай елан чорнаган...
Аждаһаны суырып алган болыт
Башбай дигән тирән елгадан...**

**Инде, болыт, бер дә юкка гына
диңгез иттең елга-суларны.
Аждаһалар җирдә үрчи ласа,
суырып алчы, зинһар, шуларны!..**

*

*О вы дубы Камские!*
Г. Р. Державин

**Минем дә шул шигырь язганым бар,
бераз тирләп имән кискәнем...
Шигыренә керткән чал Державин
имәннәрен Имән Кискәнең!**

**Сөзәк ярда леп-леп килә Чулман,
шигырь сөйли бугай Чулман да...
Туган якта ачы баллар күперә,
какланадыр казлар чоланда...**

**Мин сезнеке! Торсын Державинның,
ул морзага бездә кем тигән?!
Үзе әйткәч, «татар» дисәк, ярый,—
онытмыйбыз: кемне кем дигән...**

Бу якларда түбә саламнарын
тузгытканда комлы давыллар,
Патшабикәләргә дастан язып,
Ул яшәгән Патша Авылында!..

Державаның Державины булу
үзе тота алтын утарда!
Бөек шагыйрь аннан гомер буена
«Бакыр бабай» булган татарга...

Бу якларда бөек хатирәләр
тора балкып кояш утыннан.
Шаулый җилдә татар имәннәре,
Җырлап туймый
Шагыйрь тупыллар!..

## Карга каргышы

*(Балачак хатирәсе)*

Баткак ерып, аяк чебиләттек
Бер оч малайлары бергәләп.
Чебигә бит «дару» кирәк тагын.
Мин тупылга менәм үрмәләп...

Ә ботакта—оя—чыбык-чабык
(Ничек кошкай ташып бетергән?!),
Кышны чыгар иде Гыйззи әби,
Шул чыбыкны төяп китерсәң!..

Үрлим, үрлим,
Тезләр сыдырылып,
Якынлашам тәки
ояга!
Мин, кепкамны тешләп,
күкәй җыям,
Берсен куям—
калсын маяга.

Өскә карыйм—
тупыл ябалдашы
Ялт-йолт итә яшел түшәм күк.
Әдикалун исе аңкый аннан...
Аска карыйм—
И, Ходаем,
Очып төшәм күк!

Тик шулчакны кайта хуҗа карга,
Мондый усаллыгын кем белгән?..
Карауллар акырып өскә килә,—
Ләхәүләмне әйтәм
Күңелдән...

Каргый мине...
Төшәм...
Менүләрдән
Кыенрак икән төшүләр!..
Ничек төшәрләрен уйламыйча,
Кыяга да менә кешеләр!?

Шарт...лады да ... ботак!..
Кычытканга
Очып кына төштем
арт белән...

Ә күкәйләр ... исән!
Аларны шул
алып төштем
Кыйммәт хак белән!..

Шуннан бирле... мин
тупылдан очам,
Ярдәм эзләп
күккә тотынам.
Очам һаман
тупыл ботагыннан...
Тик уянып кына
котылам!..

Күз һавасы шундый җиңел, биек!
Бал кортлары оча чүнниккә.
Күз алдында очты алтын богыл
Рәшәләнгән зәңгәр киңлеккә!..

Өнемме соң болар туган җирдә,—
Барысы да безгә дигәнме?
Илһамланып күзгә утлар яна,
Күз ялкыны ялый имәнне.

Сихерләде тоташ! Җирдән ашты,
Күз адашты китеп ялангa.
Чиксезлектә очам, сихерләнеп
Авазларым калды, мине эзләп,
Авазларым йөри аланда...

## Сәфәр алдыннан

*Х. Туфан истәлегенә*

Офыклар артында ни көтә?
Алсу таң, яланнар җил көтә.
Офыкка чакыра сәфәрләр,
йөрәкне сәйярлек җилкетә.

Юл көтә тулпары, баш иеп,
гүя ул тынлыкны тарсына...
Күк һәм җир тоташкан чикләрдән
китәләр тын утлар каршына.

Үпкәле оланнар тирәндә:
безне, ди, аз гына көтмәде.
Ашыкма, күреп кит безне дә,—
яшь моңнар өлгереп җитмәде!..

...Сөйләшеп туймадык таңгача—
төн түгел еллар да җитмәде.
Кумачы, Пәйгамбәр, тулпарың,—
әйтәсе сүзләрем бетмәде...

...Бу мизгел гомердән китмәде

## Факил Сафин

# САТАШЫП АТКАН ТАҢ

РОМАН

*Сталин репрессиясе корбаннары*
*Әхмәтсафа Дәүләтъяров һәм Рабига*
*Сарымсакованың якты истәлегенә*
*багышлыйм бу әсәремне.*
*Автор*

I

Кояш, күгелҗем офык артыннан тәгәрәп килеп чыгарга өлгермәде, көянтәсенә мөлдерәмә тулы чиләкләр асып, үз-үзеннән үтә дә бер канәгать кыяфәттә типчүле вак адымнар белән чишмәдән кайтып килүче буй җиткән көләч кыз сыман чытлыкланып, киң далада анда-санда сибелгән авыл-салаларны пошмас йокысыннан уятып, Сакмар суының ашкын дулкыннары белән уйный-шаяра, күк йөзендә беркем белмәгән һәм белмәячәк тә серле сукмак буйлап Оренбур тарафына юл алды.

Күңелгә илаһи моң, тәнгә дәрман бирүче язгы тымызык иртә иде бу. Дөнья якты нурга төренгән. Җанда гамь кайный. Иксез-чиксез галәмнән иләс төсләр агыла.

Мостафа кояш таң шәфәгын тибрәндереп алган беренче мәлдә үк чыр-чу килә башлаган кошлар белән уянып, иртә намазына хәзерләнә башлаган иде. Ул кемнедер уятмаска теләгәндәй сак кына атлап йөрсә дә, бу бары күңелле алдану кебек кенә, чөнки яшь хатыны Шәмсия тагын да өлгеррәк: моны ул йокыдан уянганда ук сизеп, тоеп алды—хатыны баш төртеп яткан ястык почмагыннан салкынлык бөркелеп торган шикелле. Әйе, Шәмсия әллә кайчан аяк өстендә икән шул, казанда су шаулый, комганга җылы су салынгандыр—сары җиз ләгән эчендә вәкарь

---

*Факил САФИН (1954)—прозаик, шагыйрь, публицист. «Соңгы көз», «Тузганак чәчәге», «Гөлҗиһан» һ.б. китаплар авторы. Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. «Мәйдан» журналының баш мөхәррире. Чаллыда яши.*

рәвештә борынын өскә чөеп яктырып утыручы комган җәнапләре хуҗа кешенең тәһарәт ала башлавын көтә иде.

Мостафа, таң яктысы җәелә башланганда укылган иртәнге намаздан соң, ихата эчендә әвәрә килеп алды, аннан, еллар дәвамында күнегелгән гадәт үзенекен итте: чәй вакыты җиткәнен сиземләп, ак өйгә керергә дип, шактый биек болдыр баскычыннан күтәрелә башлаган иде, ниндидер сихри көч туктатып, ирексездән янбакча ягына борылып карады.

—Бәрәкалла!—диде ул гаять сөенечле мизгелдән сабырлыгын җуя төшеп. Хикмәт дисән дә хикмәт! Гәүдәсе җиненәеп калды, күнел түрен айкап, актарып нидер яндырып үтте, җанын яшь чактагыча ашкыну биләп алды: янбакчадагы алмагачлар шау чәчәккә күмелгән, әйтерсен, кемдер шаярып бакчаны бер төн эчендә ак өрфия белән япмалап алган да, хәзер посып кына ир уртасына җитеп килүче басынкы холыклы хуҗаның бу хәлне күреп, нәкъ шушы рәвешчә әйтелгән «бәрәкалла» дигән аптырау катыш сокланулы сүзен ишетүдән тәм-ләззәт алып, үсенеп торадыр сыман.

Бу аклыкны, матурлыкны сөйләп анлатып кына булмас иде. Мостафа өй ишеген ачарга ниятләгән жиреннән туктап, янә бакча ягына караш ташлады, шушы якты иртә, аклыкка төренеп, күпереп-кайнап утырган алмагачлар анын талымлы җанын кузгатып, ымсындырып җибәрде, моңарчы күргән, кичергән барлык борчулары, кайгы-хәсрәтләр кул белән алып ташлаган кебек юкка чыкты. Карашы көзгедәй яктырып аккан Сакмар өсләтеп йөгереп узды. Аларнын өйләре Сакмар очында, тар урамны кисеп чыгуга—елга яры. Биек ярдан төшүгә, дөнья яралганнан бирле шулай дуамалланып, уенчаклап агучы Сакмар. Шушы урынга нигез корган акыл иясе— киләчәккә карап эш йөртә белгән Дәүләтъяр бабасын һәр намаз саен догадан калдырмый Мостафа.

Каршы яктагы әрәмә, анын артында ук яңа борын төртеп чыккан бәпкәләрен саклап, теләсә нинди җан иясенә кинәт ташланырга әзер ата каз шикелле мәгърур хәлдә торучы урман, урман артында еракта— күк түренә барып тоташкан зәңгәрсу кинлекләр. Ул чиксезлекләрне маңгай күзе белән инләп бетермәле түгел, сәүдә эшләренә керешеп, күпме җирләр, илләр гизде, әмма ир читенә түгел, ил чигенә дә барып чыга алганы юк. Булган Каргалыда олуг затлар, тарих итеп сөйләрлек мәртәбәле сәяхләр! Исмәгыйль баба, утыз өч ел буе илләр гизеп, дөнья айкап кайткан илгизәр җан үзе генә дә ни тора!

Мостафа шау чәчәктә оеп утырган алмагачларга кабат күз төшерде. Күз алмас дәрәҗәдә гүзәллек ташый иде акка төренгән алмагачлардан. Тыныч иртәгә, ил-тәякнең кабатланмас бизәкле манзарасына адарынып шактый торды ул.

Рәхәт чигешле халәтеннән айнып китеп, Мостафа алга омтылды. Иреннәренә тибеп чыккан дымсулыкны иртәнге җил ялмап алдымы, кипшенгән ирене чатнап, алдагы көннәрдә җил-кояш ашап ясалган җәрәхәте әрнеп, үзен сиздереп куйды. Мона игътибар итеп тормады инде ул. «Җүләр баш, баскычка чыгарып куелган бүкәндәй күпме торырга була,»—дип, эчтән үз-үзен битәрләп, өйгә узды, йоклап яткан балаларын уятмаска тырышып, әмма нык, икеләнергә урын калдырмаслык итеп Шәмсиягә эндәште:

—Кая, карчык, җете төстә, кирәкмәгәнгә уралып йөргән чүпрәгең юкмы? Җәһәт кенә табып бир әле...—һм... Теле кибеп, арка үзәге бөгыренә төшеп кычытып алды.

Хатын-кыз да булсын, төпченми-нитми кушканны үтәп тә куйсын ди. Шәмсия ел торып, Мостафанын болай каударланып, бәргәләнүен күрмәгән чибәр хатын, таң калып, беренче мәртәбә иренә тутырып карады, бу караш шундый гаҗәпсенүле иде, хәтта күз сирпеп алган мәлдә озын керфекләре маңгайга ук сикерешеп, сызылып киткән кашын сыйпап төштеләр кебек.

—Нинди жете төс ул тагын? Нинди чүпрәк?— диде ул, гажәпләнүдән тач беркатлы сабыйга әйләнеп.

Мостафа, шуны да аңламыйсың дигәндәй, тавышын күтәрә төште:

—И-и Алла колы, кызыл-мызыл чүпрәк бетмәгәндер ләбаса!

—Кызыл?—дип янә кайтарып сорады хатын.

—Кызыл булгач—кызыл! Яшел дә, зәңгәр дә түгел бит инде!—диде сабырлыгын тәмам җуйган Мостафа һәм бакча як тәрәзәнең чигүле пәрдәсен күтәреп Шәмсиягә ым какты, күр, янәсе, әллә һаман да аңламый изаланасыңмы, Хода бәндәсе.

Шәмсия әсәренеп, тәрәзәгә сарылды, зур кара күзләрен керфек арасына яшерергә өлгермәде, әллә кайдан, тирәннән үк:

—Алмагачлар...—дигән инрәү ишетелде.

Мостафа өчен серле һәм көтелмәгән иде бу аһылдау. Күкләрне дер калтыратып, бөтен тереклекне өнсез калдырып нindидер гайре табигый затның нәгърә оруы шикелле тоелды әлеге авазлар.

Хатын ашкынулы хәрәкәт белән пәрдәне умырып тотып, йөзенә каплады. Шәмсиянең җилкәсе яшен ташы өтеп үткәндәй кинәт куырылып алды. Тәрәз пыяласына бөркелгән уңайга кире кайтып бүлмәне тутырган сулкылдау авазыннан Мостафа үзе дә телсез калып, нишләргә белми тора иде.

Кыланмышын килештермичә, хатын тәрәз төбеннән читкәрәк китте һәм сагышлы тавыш белән телгә килде:

—Ул елны да шушындый матур килгән иде яз...Алмагачлар шау чәчәктә иде, катыкка манчып алган кебек. Ул кошларның сайраулары—зиһеннәрне ала торган иде. Хәерлегә булсын инде...

Мостафа кисәк үрелеп, пәрдәне тарткалап, тәрәзәне томалап ук куйды. Шәмсиянең: «Ул чагында»,—дип сүз башлавы юкка түгел. Беренче ирен, унбишенче елны сугышка китеп, эзсез югалган Фәтхулланы искә төшереп, аһылдый, сызлана иде яшь хатынның бәгыре.

—Күз тимәсен, дим...Чүпрәк бәйләп куярга кирәк...Бигрәк, кеше күзенә чекерәеп кереп торалар...—дип, Мостафа бәрелә-сугыла ишек алдына чыгып китте. Бүгенге иртә, бөтен дөньясы һич кенә дә баягы кебек нурлы, якты тоелмый иде инде аңа...

Шәмсия шушы халәтеннән аерылып бетмәгән хәлдә, күнелендә нindидер шом бар сыман, ире артыннан иярде.

—Сиңа әйтәм,—диде ул зур сер ачкандай.—Бүген таң ике тапкыр атты бит...Нәрсәгә юрарга да белмәссең...Саташып атты таң, саташып...

—Таң саташмый, бәндә саташа. Шайтан таны саташтырды аны. Һем-һем...Вәлкәй хаҗи азанны дөрес әйтмәде. Мин сизеп алдым аны, шуңа иртә намазына үз вакытында тордым.

—Гөнаһлы булган икән Вәлкәй...—Хатынның тавышында сизелер - сизелмәс сөенеч чагылып китте.—Алла каршында да гөнаһ бу, бәндә каршында да, име?

—Ансын бер Ходай белә, аны узып сүләшер хәлем юк. Актүбә ягында кызыллар кыштан калган кибәннәргә ут төрткәннәр. Ансы да башын бутагандыр. Шайтан таңы бу. Яп-якты шәфәкъ уйнап алды бер мәлне офыкта. Тәрәзгә күз төшеп, үзем дә ялгышып сикереп торган идем. Әтәч кычкырмагач, шик керде күңелгә.

—Әтәчкә карап ятсаң...—Шәмсия Мостафаның бу сүзләрен уенга алды.

—Әтәч кычкырмый таң атмый. Вакыты җитмичә кычкырып, дөньяны уятырга Вәлкәй хаҗи түгел лә ул. Искә төшкәндә әйтим, бүген Әхмәтсафа кайтып керергә тиеш, бу әтәчне суярга кирәк. Йончыгандыр бала. Әтәч, мәхлук, үзен көн тугач суясыларын белсә, таңны аттырмас иде дә...—Аның соңгы сүзләрен Шәмсия ишетмәде инде, хатын йөгереп диярлек өйгә кереп бара иде...

Мостафаны монсу уйлар биләп алды.

...Ир-ат кешегә тол калырга язмасын икән. Җир җимертеп дөнья

көткән чакта, бер өер бала-чага белән ялгыз калуның ни-нәрсә икәнен үз башына төшкән кеше генә белә. Гомер иткән хатыны Мәһинур кинәт вафат булгач, Мостафа кая килеп бәрелергә белмәде. Балигъ булмаган биш бала: дүрт улы һәм бер кызын кочаклап япа-ялгыз калды да куйды шул. Туган-тумача, күрше-күлән баштагы көннәрдә кайгысын күтәрешкән булып йөрсәләр дә, һәркемнең үз мәшәкате, үз дөньясы, тора-бара хәлгә кереп йөрүчеләр сирәгәя башлады, ә тора-бара гел беттегә чут. Житмәсә, сугыш бара. Халык өстенә кара хәсрәт булып ишелгән герман сугышының иге-чиге юктыр сыман иде.Хәер бер генә яу да халыкка куаныч китерми ансы, мәгәр шунысын да белә Мостафа—сугыштан кемнәрдер кесә калынайта һәм, шиксез, бу кемнәрдер дигән кемсәләр илбашы-патшалар үзләре үк. Дөрестерме, юктырмы, Мифтах хәлфә әйтә, бер дә сугыш алып бармаган илнең патшасын сантыйга чутлыйлар икән. Шулаен шулайдыр, әмма сугышка кызмаган илдә яшәүләре ожмахка тиң бит. Иле тыныч, казнасы мул, халкы бай—тагын ни кирәк адәм баласына?! Халыкның холкы сәер аның. Рәхәт тормыштан тиз туя—әүвәл үзара ызгыша башлыйлар, аннан патшасына каршы күтәрелә. Коткы салучылары табыла аның. Югыйсә, ил-көннәрнең иминлегеннән кадерлерәк, кыйммәтерәк ни бар дөньяда?! Хәерле булсын, патшаның сугыш дип зиһене томаланган, халыкны ут эченә куа тора.Үзенең кесәсе дә шактый калынайгандыр, яраннарының әйтеп торасы да юк, акча исе килмәсә патшага ешынып та йөрмиләр алар. Тамагын туйдырмасаң дуракмыни ул яран булып йөрергә! Башка мәмләкәт патшалары да өлешсез калмыйдыр, һәркайсы: «җиңгәнче сугышабыз!»—дип лаф орган була әнә. «Бирән нәфесләребез туйганчы халыкның канын түгәбез»,—дигән сүзләре инде бу, безнең телгә күчерсәң. Шулаен шулайдыр да, сугышның бер дә туктарга исәбе юк. Асыл егетләр китә тора, яу кырында югала баралар. Исәпләсәң, Каргалының күпме сөлектәй ир-егетләрен йотты инде бу сугыш.

Тол калдым дип, күпме үрсәләнмә, дөнья көтүдән туктап калып булмый: балаларны аякка бастырып, кеше итәргә кирәк. Дәүләтьярны-кылар көчле нәсел, тармаклы нәсел, ил өстенә нинди генә афәтләр килмәгәндер дә, башлардан ниләр генә кичмәгәндер. Нәсел исән, нигез нык, шөкер Ходайга. Һәр ир—гаилә башы үзенең нәсел терәге икәнен онытмаска тиеш, яшәгән дәверендә нәселен бер башка күтәреп куюга өлгәшергә тиеш, дип уйлый Мостафа. Шулай булмаса яшәүнен ни мәгънәсе, ни яме бар! Үзеңнән соң җиргә нык басып яши алырлык, кодрәтле, денле-иманлы буын калсын! Менә ни өчен яши ул дөньялыкта. Мәһинурның вафат булуы гына һушны-зиһенне алып куйды менә. Малайларның иң зурысы Гомәрханга—унҗиде яшь. Аның өчен борчылмаска да булыр иде, үз көнен үзе көтәрлек зиһенле егет булып үсә. Хезмәтнен ни-нәрсә икәнен әйбәт чамалый, хәләл икмәкне маңгай тире түгеп, кенә табып булганын, эштә чыныгып үскән бала ул. Госманга—ундүрт яшь, монсы, мөгаен, Оренбурдагы Гомәр агайга охшап, укымышлы кеше булып чыгар. Белемгә омтыла, хисләнүчән бала. Әнкәсе вафатын да иң авыр кичерүче шушы, үз эченә бикләнеп йөрергә яраткан улы булмады микән?.. Унике яшьлек Әхмәтсафа барысыннан да аерылып тора. Җебеп торганны бер дә яратмый, ни кушсаң, шуны ялт итеп эшләп куя, әткәсенең кул арасына керә башлавына Мостафаның үзенә караганда ныграк та сөенә бугай әле. Яшенә караганда олырак күренә, ялгызы калып уйланып утырырга ярата. Уйларыннан аерсалар, нәкъ өлкәннәрчә авыр сулап куя да, кушкан йомышны үтәргә йөгерә. Ә сигез яшьлек Әхмәтханга күз-колак булу кирәк тә кирәк. Сәрсән бала, житмәгән җире юк, көн эчендә кузгатмаган нәрсәсе калмый, абыйлары белән шаяра башласа тыярмын димә, аларны җәфалап бетерә. Бердәнбер кыз—иркәләнү-сөелүдән туймый торган өч яшьлек Бибиҗамал, шомырт кара күзле, ут борчасы шикелле терчә кызы исә Мостафаның кайгылы-хәсрәтле көннәрендә иң олы юанычы, шатлыгы, куанычы иде. Дөнья китереп кысты, берни эшләр хәл юк, шушы балаларга үги инәй алып кайтырга кирәк булып чыкты бит менә...

Каргалы борыннан килгән гореф-гадәтләрдән аерылмый. Элек-электән ирләр сәүдә эшендә, патша гаскәрендә казак хезмәтен үтәп гомер үткәргәннәр. Йортның нурын саклау, хуҗалык алып бару хатын-кызлар җилкәсенә өелеп калган. Шуңа күрә Каргалы хатыннары ир хакын хакласалар да, китап кушканча ук гомер буе иргә буйсынып, басылып яшәмәделәр. Алар хөрлеккә омтылучан, айт иткәнгә, тайт диеп торучылары сирәк. Авылда тол калган ялгыз бичәләр булса да, алар шушы хәлләрен артыграк күрәләр: биш бала өстенә килергә ашкынып, ясканып йөрүче юк иде. Мостафаның гөнаһасына кермик, берничә җиргә яучы җибәреп, хәбәр салдыртып караган иде, күнеленә ятыш дип тапкан хатыннар чая булып чыктылар, ахры: «Кеше баласын үстереп, кем рәхәт күргән»—дигәнрәк җавапларын гына кайтарып ирештерделәр яучы корткалар. Мостафа, язмышына күнеп, сабыр итәргә булды. «Язганы чыкмый калмас, өзми-куймый бичәләргә яучы җибәреп, кеше көлкесенә калганчы, көннәр үтә торсын, балалар үсә торсын, шул арада, Ходайның рәхмәте киң, бер насыйбы да чыгып куяр»—дип, үзен тынычландырып яши башлады.

Шушы уйдан анын җаны тынычланып калды, күңелен юк-бар шаукымнар алгысытмый иде инде. Менә шулай тыныч кына яшәп яткан көнендә дөньясы тагын асты-өскә килде. Сәбәпчесе: Шәмсия җибәрттергән хәбәр иде. «Мостафа агай эндәшсә, риза булырыем, дип әйтә, Шәмсия»,—диде, Тайфә карчык беркөнне истә юкта иртүк өенә килеп кереп. Карчык, чигенергә һич тә исәбе юклыгын сиздергәндәй, соңгы араларда яучылардан туеп, алардан да, кабат өйләнү ниятеннән дә бөтенләй ваз кичкән Мостафаны озаклап үгетләргә җыенган шикелле, җиңнәрен сызгана-сызгана түргә атлады. Көннәр көзгә авышса да карчык җинелчә киенгән, шушы хәбәрне ишетүгә бар эшен ташлап өеннән чыгып йөгергән кешегә охшап тора иде. Сулуы капкан, борын тишекләре киерелгән—әйтерсең, йөк аты тарта алмаган авыр арбаны кузгатырга туры килгән бу җан иясенә. Тайфә карчык хәбәрен туп-турыга ярып салгач, бу ир галәмәте кире кагып, эшне бозып куймаса ярар иде дигән кебек, бүлмә эчендә кая бәрелергә белми тулганган җиреннән шып туктап калды да, кызгылт бәбәкләрен тасырайтып Мостафага карап катты. Әлеге хәбәрдән миңгерәүләнеп калган ирнең авыр күз кабаклары челт-мелт итеп ачылып йомылдылар һәм аяк астына ук мәтәлеп шактый тигез идәнне капшап үттеләр, бәхетләренә—бер ярык табып, мәңге күтәрелмәскә дигән ныклы карарга килеп, шунда төшеп чумдылар.

Өй эчен тынлык биләп алды. Иң беренче Тайфә карчыкка җан иңде. Йөзеннән шөбһәле уйлар йөгерешеп үтте. Әйтерсең лә, янына килеп ун туптан атканда да колак яфрагын селкетер тоелмаган шушы Мостафа атлы адәм гөлт итеп кабынып китәр һәм әллә нинди сүзләр әйтеп, карчыкны пыр туздырып өеннән сөреп чыгарыр иде. Тайфә карчык көтелмәгән уйдан куырылып куйды. Югыйсә, Аллаһ шаһит, ул балалар хакын гына хаклап йөри. Әгәренки киресенчә булса, инде керә-керешкә үк ишекне ачып, болдырга аяк басуга, җир ярылып, «эһ» диярге өлгергәнче, ул җәһәннәм чокырына төшеп китәр иде. Хәтта ки япун сугышында һәлак булган изге җанлы картының рухына кылынасы бихисап догаларын кылып бетерә алмыйча казага калдырып, бер гаепсез, изге юлда дип әйтерлек йөргән җирдән юкка чыгар, зәр-зирбизәр булыр иде.

Шөкер, Мостафа күтәрелеп бәрелмәде. Сүзсез генә сәке почмагында иртәнге чәйдән соң җыештырырга өлгермәгән ашъяулыкны яртылаш әйләндереп каплады да, түрдәге зур мендәрләрнең берсенә үрелде. Сизгер карчык, гадәт-йола буенча һәр кергән йортта була торган бу күренешне дәшми-тынмый гына карап тора алмады, Мостафаның җиненнән сак кына тарта төшеп, туктатасы итте:

—Туган, утырып, озаклап сүләшәсем юк та...

Мостафа,ниһаять телгә килде, карчыкны ай-ваена карамый утырырга күндерде.

—Аптыраште калдырдың, Тайфә түтекәем, әйдә, утыр әле, анышып бетеп кенә булмый бит...

—Аяк өсте генә дә сөйләшер сүз түгел шул, наныем.—диде карчык, сөенечен тышка чыгарып түгәргә ашыкмыйча.—Әйдә алайса, бер дога кылыйк,—дип, мендәрнең читенә генә артын терәп утырды да ике кулын кушырып битенә якын китерде.»Ил-көннәр имин, дөньялар мул, ниятләр гамәлгә ашсын, Раббем»,—дип, кычкырып әйтте дә, пышылдауга күчеп жиренә житкереп, аерым бер чырышлык һәм ләззәт белән дога кылды: Тайфә карчык эчке бер сиземләү белән тоеп алды, анын бу йорт бусагасын атлап керүе бушка булмас, Аллаһ боерса. Жир дә убылмас, карты рухына кылынасы догалар да кылыныр, жыясы тәгам жыелыр, эчеләсе чәйләр эчелер болай булгач. Иң мөһиме—монарчы иблис коткысына бирелеп, нәфесенә булышып күнеле тартмаган кемсәләргә яучы булып йөрмәде һәм йөрмәс тә боерган булса.Мостафа янына ул чын күнелдән, ашкынып килеп керде, морадына иреште дә кебек әнә.

—Ялгыз дөнья алып барулары-ы...—дип сузды ул, эш пешкәнгә санап.—Ир-ат кеше хатын-кызсыз гүпчим яши алмый ул. Мәгәр алтын баганакае, дөньякайларның тоткасы булган иреннән калып сынар канат белән балаларны аякка бастыру ялгыз хатыннарга да жинел түгел, Мостафа энем.. Картымның япун жәдрәсе тиеп шәһит киткәненә ун ел, ник бер минут исемнән чыксын менә, ышансаң. Әле ярый, улларым тәүфыйклы, тулыклы булдылар. «Инәй, ни эш бар?»—дип кенә торалар инде жаныкайларым. Картыма охшап, эре сөякле, буй-сынлы булып үсеп алыптай жегетләр булып киләләр, боерган булса.—Карчык, ни өчен килгәнен исенә төшергәндәй, утырган жиреннән Мостафага табан авышты:

—Балалар күзгә-башка чалынмый...

Мостафа авыр сулап куйды. Көттереп кенә:

—Бәләкәчләре йоклый, зурлары дөнья куа,—диде.

Тайфә карчык ирнең сүзен тынлап бетермәстән, үзенекен тезә башлады:

—Маһинурның да Фәтхулласы суга төшкәндәй юкка чыкты бит. Бичараның, ярман сугышыннан бер хаты килде дә шуның белән Аллаһу әкбәр. Шәһит жаны ожмах ишекләрен иң беренчеләрдән булып ачып керсен, кылган догаларыбыз туп-туры рухына житешеп, безне дә көләч йөзләре белән ожмах түрләренә әйдәкләп алып керсә иде. Бикколга яраланып бер солдат кайткан икән, шул килеп әйткән, Фәтхулла белән сугышка бергә кердек, икебезгә бер мылтык бирделәр, мылтык андае, котелок миндәе, агылыйга—тагылый сыман бергәләп чабып барадырыек ярманга каршы, перәме аяк астына туп төшеп шартлады, дип әйтә ди. Шуннан соң бер нәрсә дә хәтерләмим, мине шул кәтилүк кенә саклап калган, мәхлук, тишкәләнеп беткән, үзем белән бергә табиблар гуспителгә илтеп салганнар бер чокырдан табып алып, дип әйтә икән. Ул сугышта исән калучылар аз булган, Фәтхулла да үлгәндер, яралы-мазар булса, бергә булган булырыек, дип әйтә ди. Савыгып чыккач, сораштырдым белүче булмады, урыны жәннәттә булсын, ул үлеп калгандыр дип, шушы хәбәрен әйтеп киткән. Биккол кешесе килеп киткәнгә дә ел үтеп бара. Шәмсияне беләсен, Сакмар очында үз йортлары белән тора. Әти-әнисе ниндидер кизүдән вафат булгач, Фәтхулла йортка гына кергән иде. Үзе—яшь, чип-чибәр, ул эшкә дисеңме, ул төскә дисеңме, илгә гайбәт-мазар чыкмаган.Яшерен-батырын түгел, хатынның тәтесен тарткалап караучылар күп булды. Ни уйлап йөри микән бу бала дип, үзем дә хафага калган чакларым барые. Шәмсия кичә чакыртып алды үзенең янына. Озаклап серләшеп, сөйләшеп утыргач, эчендәге иң соңгы серен ачып салды: «Әбекәем, ялгызыма бик кыен, утыз яшькә кадәр яшәдем якты дөньяда, бер рәхәт күрмәдем. Мостафа агайга сүз тишеп карасак, ул үзенә хәләллеккә алмас микән, ди жаныкаем». Михнәтенә дә, рәхәтенә дә түзәрмен, бер дә башка кешегә күнелем ятмый,—дип әйтте.—Инде, Мостафа туган, миннән эш калмады, соңгы сүз синеке,—дип, Тайфә карчык тынып калды.

Мостафа әлеге хәбәрдән тәмам телсез калган иде. Тол хәлендә озак яшәп булмасын да белә, әмма бу яшьтә яңадан өйләнеп, тормыш көйләп җибәрү уен-муен түгел. Яңадан бер-береңә үзләшергә, бер-береңнең көен көйләргә, чәч-тән исенә ияләнергә, бер җан булып яши башларга кирәк шул. Һич кенә дә бөтен нечкәлекләре белән күз алдына китереп булырлык хәл түгел. Шулай да...Болай карауга, чишелмәслек төен кебек түгел үзе. Бер генә мәртәбә һәм гомерлеккә дип башлы-күзле булып, бер-береңнән холкына, гадәтләренә тәмам ияләшеп беткәч кенә, алма кебек тәгәрәшеп балалар үсеп килгәндә җаның сыман күргән хатыныңны җир куенына тапшырып ялгыз калу...Ай-һай, авыр хәл бу, авыр хәл. Инде дә килеп, яңадан тормыш корып җибәрергә кирәк. Үзеңнән күпкә яшьрәк хатынга ымсыну дөрес булырмы?.. Моңа кадәр уйга да кереп чыкмаган яшь, чибәр Шәмсия белән борчак пешереп булырмы, уй-серләре килешерме? Тайфә карчык белән серләре килешкән килешүен...

Аптырашып утырудан да файда юк. Мостафа—әле генә кырыкның өстенә чыккан, типсә тимер өзәрлек, басса бакыр сытарлык ир. Ялгыз хатынның күңеле ятып, хәбәр салган икән, ни гаебе бар?! Үзең мәңге ул якка аяк атлап бармаячак идең бит, Мостафа, уйла, уйла! Шәмсиягә үрелеп азапланучылар аз булмады булуын, Мостафа җир белән күк арасында йөрүчеләрдән түгел, барысын да ишетеп, күреп яши—чибәркәй нык холыклы булды, илгә-көнгә яман атын чыгармады. Яшәргә дип казгана, көткән дөньясын таратмаска җан-фәрманга тырыша иде. Күпме уйларга була: балаларга әни кирәк. Бигрәк тә Бибиҗамал белән Әхмәтханга әниләренең мәңгелек йортка киткәнен аңлатуы кыен. Көн-таң атса: «Инәй бүген кайтамы?»—дип җелеккә төшәләр. Шушы сораулары йөзгә сары сулар булып ята инде...

Мостафа тәвәккәлләргә булды. Әмма нигәдер Тайфә карчыктан кыенсына , авызын чак кына ачып:

—Кайчан?—Кһм-хм,—дип кенә аваз салды.

Тайфә карчык аның ни әйтергә теләгәнен ярты сүзеннән аңлап, туры караган кояштан нурга тулышкан Сакмар кебек яктырып китте.

...Тайфә карчык әйләнеп кайтканчы Шәмсия ярым караңгы өй эчендә, уйлар камалышында ялгызы бәргәләнде. Хатынның тәвәкәлләп Мостафага атап яучы җибәрүенең башкалар белеп җиткермәгән сере бар иде шул. Бу хакта Шәмсия Тайфә карчыкка да чишелеп тормады.

Соңгы вакытларда ана азанчы Вәлкәй хаҗи каныга башлады. Яучы-мазар аша түгел, туп-туры өенә килеп, үзенә икенче хатынлыкка сорап тинтерәтә, карт шайтан. Олы хатыныннан өч баласы бар, өлкәннәре Шәмсиядән ун яшькә кечерәк булса булыр. Шушы карт йолкыш, бер хатынын ныклап тота алмыйча, көн туса җәнҗал чыгарудан бушамаган Вәлкәй мөртәт бәгыренә төшә башлагач, яшь хатын берничә көн аяк өсте исәңгерәп йөргәннән соң, өч-дүрт төн түшәктә әүмәкләп чыккач һәм түшәге генә түгел, чәч толымнарына кадәр күз яшьләренә манчылып, сыгып алмалы булгач, авылга сүз—мазар таралганчы дип, чыннан да моңарчы читтән генә күз салгалаган, төскә-биткә һич тә Фәтхулладан ким булмаган Мостафага сүз ирештерергә карар кылды.

Ике толның кушылуын бөтен авыл хуплады диярлек. Тик Вәлкәй хаҗи гына каядыр барырга җыенып ишек алдында ат җигеп маташкан Мостафаны күреп алгач, ямьле көннең төсен җибәрде: хуҗаның үзеннән битәр гайрәтле юргасын сискәндереп урам як киртәсенә таягы белән җенләнеп суга-бәрә, күзләрен акайтып авызыннан төкерек чәчте:

—Кеше өлешенә кердең, Мочтай, өлешкә кердең! Мәчеттән килеп хәер-фатыйха алмадың. Никахыңны укыган Мифтах хәлфәгә бәддога ирешсен, кул арты белән дога кылдым үзенә. Их...ялгыштың, Мочтай, ялгыштың...өлешкә кердең...Мәңге рәхәт күрмә, Аллаһның...—дип каһәрли-сүгенә мәчет ягына китеп барган иде.

Бу хакта Шәмсиягә әйтеп, аны аптыратып йөртәсе килмәде, Вәлкәй

хажи хакында ана яшь бичәсе сүз арасында сак кына үзе дә сиздереп алган иде, бу вакыйга ничек кисәк булса, шулай тиз онытылды да. Тик шунсы бар—Шәмсия Вәлкәйне: «Карт шайтан, карт иблис.»—дип өзмикуймый битәрләсә дә, хажи Мостафадан ике-өч яшькә генә олырак, һич тә алай бетәшкән карт түгел иде...

Хатынынын күптән шәһит саналган Фәтхулланы искә алып, жонмай түгеп, елап алуы Мостафаны четерекле хәлгә куйды. Әйтерсен, кемдер анын тез астына сиздерерлек сукты. Хәзер ир, шушы хәлдән сон, берни дә булмаган кебек йөрергә тиеш ди инде. Нинди йөрү булсын, мәрәләү генә инде бу, теге чактагы шикелле жир жимертеп, ашкынып йөрүләр, ай-һай, янадан кабатланырмы?...Ул ни эшләргә белми, кызу адымнар белән ишек алдын урап чыкты. Бераз исенә килгәч, кулларына карап хәйран калды: каян хасил булгандыр, юньләп аңышмады, әллә шул арада Шәмсия кулына тоттырган, әллә каяндыр үзе табып алган, әмма шунсы хак—анын кулында вак-вак теленгән жете кызыл тасмалар пәйда булган иде.

Мостафа бакча капкасын бәйләгән озын сүс бауны кабаланакабалана чишеп, бакча эченә үтте һәм рәхәт аклыкка оеп утырган алмагач ботакларына кызыл тасмалар бәйли башлады. Бу эшне ул ихтыярсыз, ниндидер сөенеч-шатлык хисләрен кичерми башкарды. Иртән башка килгән уй-фикерләр, жанын сафлыкка тиендергән иләс хисләр жилгә очып, таралып беткән иде инде. «Дөрес әйткәннәр картлар,—дип уйлады ул, эше белән мавыга төшеп бераз тынычлангач,— ике тол кушылса—кич йокларга икәү яталар, иртән йокыдан дүртәү уяналар, имеш. Мин һаман Маһинурымны уйлап саргаям, Шәмсия үзенең беренче ире—Фәтхулла дип тилмерә, күрәсең. Юк, истән чыкмый икән ул, жан сөйгән хәләлең, ник анда хур кызы куенында ятмыйсың, һаман күнел түрендә ул, Маһинуры гына...Шуңа күрә Шәмсияне ачуланып та булмый. Анын жаны юк дисеңме әллә! Хәер, бу дөньяда сагышланмый, сагынмыйча яшәп тә булмыйдыр инде. Ни әйтсәң дә, гомер кичүләре кызык нәрсә икән ул, шайтан алгыры. Барсын күрми, кичерми китәрмен димә.

Дөнья дигәнең бер дә тыныч түгел шул. Герман сугышы гына житмәгән, патша галижәнапләре үз тәхетеннән баш тартты да куйды бит. Монсына тагын ни дияргә? Тәхет кадәр тәхеттән үз теләге белән ваз кичкән патша хәзрәтләрен әйтерием инде, шул да булдымы патша, шул да булдымы гамәл? Бераз гына да башы эшләмәде микән бахырның? Ул яраннары, вәзирләре ни-нәрсә карагандыр, ни-нәрсә акыл биргәндер Микулайга. Аларны шул патшанын башы эшләми торганда, акыл бирү өчен, илне бәла-казалардан саклау өчен тоталар түгелме соң? Патша китте дип, тәхет буш тормас, билгеле. Гомер-бакый тарткалаш бара шул тәхет тирәсендә. Тарткалаш кынамы соң?! Сугыш бара илдә. Ата улны, инә кызны белми, туган-туганга, мөселман мөселманга кылыч күтәрә. Ул Лилин дигәненә ни житмәгәндер, халыкны болгатырга. Халыкны аны болгатып кына жибәр, аннан ник болгатканына үкенерсең. Үзе нимеч шпиуны икән.Бер митингәдә Зәки Вәлиди шулай сөйләп торган ди. Анысы башкортларнын патшасы булып куйды тагын. Исең китәр, башкортлар патшасына тәхет кирәк дип, анын гаскәренә меңәрләпмеңәрләп язылган безнең татар жан-фәрманга кан коя. Вәлидинең: «Революция— безнең өчен көтеп алганнан да зур бүләк. Әгәр авыз ачып калсак, ул бүләктән коры калачакбыз, әйдә батыр сугышчылар, гаярь башкортлар, яуга!»—дип бер кычкыруы житкән, бөтен татар дәррәү сикереп торып «Ур-ра» дип кычкыра-кычкыра, сугышка да кереп киткәннәр. Менә сиңа мә, татарлардан торган башкорт гаскәре шул була инде. Борын-борыннан тәхет тынгылык бирмәгән инде бер төрле холыклы кешеләргә. Ханнар-патшалар вафатлары алдыннан тәхетне варисларына васыять итеп калдырган, ана исә әллә нинди юлларын табып, алдан ук хәстәрен күреп йөргән хыянәтче менеп утырган. «Дөньядагы бөтен тәхетләр

телгә килеп, үзләре шаһит булган хыянәтләр хакында хәбәр итсәләр, тарихны өр-яңадан язарга туры килер иде,»—ди Мифтах хәлфә. Лилин пайтәхетне Мәскәүгә күчереп карады каравын, соң анда да шул бер тәхет инде. Тәхет өчен ызгыш-талаш оештыручы иблис үзләреннән алда күчеп килгәндер Мәскәвенә. Айга менеп утырсаң да, тәхеттән калмый ул, иблис. Ходай ни язган. Менә татарларның патшалары бар микән, әллә өлгермәделәр микән әле патшалы булырга. Борынгы дәвердә куәтле патшалары булган татарның, булган. Тик хыянәт һәркайсының башына житеп килгән. Хыянәтне көч-куәт белән дә жинмәле түгел, астыртын, мәкерле эш йөртә бит ул. Шул хыянәтләр аркасында патшасыз да, тәхетсез дә, илсез дә калган инде ул татар. Тагын берәрсе килеп чыгып, үзен татарның патшасы дип игълан итәр микән, Ходаем! Аңа бәләкәй генә булса да тәхет бирер микән Лилин. Бирсә—шыр дивана була да инде. Татардагы хөсетлек, көнчелек ул бәләкәй патшага эшләргә ирек бирерме? Бер дә ышанасы килми. Тәхет өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер безнең халык. Инде шушы афәтләрдән сакла, Ходаем. Аптыраш, уйласаң. Их Микулай, жүләр Микулай!.. Тәхетне башка кешегә бирәләр димени, ә?

Узган ел яз көттереп, ялыктырып килде. Һай авыр да булды инде. Озакка сузылуы гына житмәде, чәчүгә төшкәч тә тоташ яңгырлар башланды. Инде туктады дисәң, тагын Самар ягыннан болыт күпереп чыга, яңгырдан тәмам йончыган дөньяны янә суык тамчылар каезлый башлый. Яңгырлар тынды дип, иркенләп сулыш алып, эшкә тотынырга өлгермәделәр, моңарчы сүрелеп торган яу тагын көчәеп китеп, авылга гаскәрләр килеп тулды. Мәхшәр менә кайда ул. Гаскәрләр үзләре дә ни өчен, кем өчен сугышканнарын белеп бетермиләр. Һәркайсы халык, жир, ирек сөйли. Тик һәркайсы үз каланчасыннан торып халыкны үгетли, үз ягына аударырга тырыша, агай. Әгәр гел митингәләргә йөреп, телмәрчеләрне тыңлап көн уздырсаң, валлаһи дим, аңнар авышып, дин, милләт, иман кебек изге төшенчәләр язгы жебелдек балчыкка уралган утын көле сыман, төсләрен жуя башлар иде. Һәр төркемнең холкы-фигыле, кыланмышлары аеры булса да, сүзләре-шигарьләре—бер. Бу сүзләр ан-зиһеннәрне шулкадәр саташтырып бетерделәр: аларны, әүвәл Каргалы елгасына, аннан Сакмарга агып төшеп, ахырда, Жаек суы дулкыннары арасында тәмамысы юкка чыккан болганчык язгы ерым сулары белән генә чагыштырып булыр иде кебек—төрле авыздан ишетелгән бер үк сүзләр туйдырып бетерде. Халык жир, иген язмышы турында уйлый, болар сүз сөйлиләр. Дутовның ак казаклары халыкны тинтерәтә, аларны кызыл партизаннар дигән ниндидер корама халык алыштыра. Болары бигрәк тә телчән булып чыктылар. Туктаусыз хөррият, ярлы-ябагай мөселман туганлыгы, берләшү дип такылдыйлар, үзләре шул ук мөселман халкын талыйлар, ир-егетләрен көчләп армиягә куалар. Хуш, инде алары авылдан чыгып китеп, котылдык дисәләр, артларыннан, эзләре суынганны да көтмичә, башкорт гаскәрләре кереп тула. Аларның телендә исә— аерымлашу, мохтарият. Ә тынлый торгач, төшенгәч, мәгънә бер үк—берләшик, аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ботарлар, имеш.

Жир, ирек алу өчен нәкъ менә Каргалы халкының алар ягына авышуы кирәк икән. Алар табынган иң шәп шигарьләр тормышка ашсын өчен боларына да шәп, таза ир-егетләр, ашарга азык, киенергә кием, хәтта атларына печән белән фуражга кадәр кирәк, һәм моны да Каргалы халкы бирми, кем бирсен?! Үзләре әрсез тагын, халык биргәнне көтеп торырга жыенмыйлар, ихатага кереп, күзләренә ни чалына, шуны эләктереп алып таялар. Түләү турында сүз дә булу мөмкин түгел, авыз ачсаң, кем булуына карамастан, маңгайга пуля утырту белән генә яныйлар. Афәтле булды унсигезенче ел...

Шул уйлар белән бакчада күпме матавыклангандыр, колагына Шәмсиянең:

—Сина әйтәм, чәйне өч тапкыр янарттым, кер инде,—дигән йомшак тавышы ишетелде.

## II

Кабул итү бүлмәсе ишеген мыштым гына ачып, йомшак адымнар белән кереп килүче Сталинны күргәч, сәркәтип хатын бөрешеп калды. Ул аны яратмый, шадра һәм гомумән, гарип кыяфәтле бу адәм күзенә чалынса, йөзенә нәфрәт ташып чыга. Шул ук вакытта ул аннан шүрли дә. Хатынның мондый карашын Сталин үзе дә сизә, әмма тышка чыгармый, бу юлы да килеп кергән унайга сәркәтипкә көлемсерәүле караш ташлап алган булды, әмма битенә җәелә башлаган якты чаткы тиз арада сүрелеп, аны мәсхәрәле елмаю алыштырды. Сталинның чын йөзе, холкы шушы иде һәм сәркәтип хатын аны шундый ике йөзле булуы өчен күрә алмый да инде. Әгәр Сталин сул як стенага күптән түгел генә элеп куелган зур көзгегә карап алса, үзенә ян белән утырган хатынның бөтен битен тутырып чабышкан нәфрәт дулкыннарын күрер иде. Тик Сталин көзгегә карарга яратмый иде. Хәер, аның бу хатында бөтенләй кайгысы юк, ник кадалып китми шунда.

Рөхсәт-мазар сорап тормастан, Ленин янына үткәнче янә бер тапкыр әле генә Троцкий белән булган сөйләшүен хәтердән янартты. «Стратег табылды!»—диде ул, бу юлы инде чын-чынлап мыскыллы уйларына ирек биреп. Имеш, Куйбышев белән Фрунзе Көнчыгыш фронтта гаять акыллы сәясәт алып барып, Идел-Урал буйларында хәрәкәт иткән каршы көчләрне тиз арада куып таратып бетерәчәкләр; имеш, аларның ин зур уңышы—кичә генә килешмәс күренгән дошман төркемнәрне, әкренләп үз якларына аударып, дошманнан дус ясау сәясәтенә ныклап керешүләрендә. Башкортларның Вәлидов хөкүмәте хәзер совет яклы, бөтен Идел-Урал төбәгендә татар егетләрен кызыл армиягә мобилизацияләү дә искиткеч шәп бара. Араларында үз инициативалары белән гаскәр җыярга керешкән Усманов кебек сәрдәрләрнең булуы бигрәк тә күнелле хәл, имеш.

Троцкийның очлы сакалын чөя-чөя канатланып, хәтта хискә үк бирелеп, вакыты белән бөтенләй сакауга әйләнеп бетеп сөйләшүен Сталин башта көлемсерәгән кыяфәттә, сабыр гына тынлап торган иде. Аз гына уңыштан да шулай сөен инде, җә! Никадәр балалык, никадәр беркатлылык бу бәндәдә. Ун ел буе коры җир күрми дингездә адашып йөзгән моряк ярга аяк баскач бу кадәр үк сөенми торгандыр, ачуым бер килмәгәе. Ахыр чиктә Сталинның сабырлыгы төкәнде, Троцкийның шашына язардай очынуы күңел кайтаргыч дәрәҗәгә житте, моңа чик куярга кирәк иде. Милләтләр эше буенча халык комиссары тыныч, әмма ярсулы тавыш белән теш арасыннан:

—Бәхетсез романтик!—дип ычкындырды.

Троцкий шып туктап, әңгәмәдәшенең йөзенә карады. Сталинның бите буйлап тәртипсез рәвештә кара күләгәләр чабыша иде.

—Бәхетсез романтиклар,—дип кабатлады янә Сталин.—Бухарин, Рыков икътисадта, сез хәрби эштә шушы романтикадан ерак китә алмыйсыз.—Революциядә үгет-нәсихәт, романтика чоры узды. Җиргә төшәргә кирәк. Милләтләр эше бүген иң үзәктә торган мәсьәлә. Әгәр һәркем бу четерекле эшкә уйламый-нитми борын тыга икән, бүгенгә ирешкән азмаз уңышлардан да колак кагачакбыз. Революция һәм милли аерымланута йөз тоткан сәясәт бер-берсенә сыеша алмый торган, хәтта әйтер идем дошмани төшенчәләр. Моны аңлап дөрес бәя бирмәсәк һәм милли төбәкләрдә соңгы чорда гөмбә урынына баш калкыта башлаган «инициаторларны» йөгәнләмәсәк, соңыннан утырып еларга туры килмәгәе дим. Турысын әйткәндә, милли сәясәт белән шөгыльләнүче «белекләләр» күбәйде хәзер...—Сталин, бер авыз ачкач, булган булсын инде дигәндәй, тагын бер-ике төртмәле сүз ычкындырмакчы иде, Троцкий күзендә уйнап

алган зәһәр очкыннарны күреп, иплерәк тонга күчте,—милли төбәкләргә кагылышлы һәр гамәлне төптән уйлап, үзара киңәшләшеп эш алып барсак кына отачакбыз.

—Ансы хак. Киңәшле эш таркалмый...—диде Троцкий. Үзенең эчендә ачуы кайнап түгелергә житеште. «Син, ата иблис, хет бер генә эшенне башкалар белән уртага салып, киңәшләшеп эшләгәнең бармы? Йә бергәләп кабул ителгән карарны үз файдаңа бормыйча каласыңмы?»

—Һәркем юрганны үз ягына тартса, безнең ясаган адымнарыбыз, иң шәп дигәндә дә, бер урында таптану булып калачак.

Троцкий кабынып китте:

—Мин сезне, кадерле иптәш Сталин, нәкъ шуның өчен чакырдым да инде. Сөйләшергә кирәк...

—Алайса әңгәмәне болай дәвам итү яхшы булыр. Вәлидовның советлар ягына чыгуы өчен аз тырышмадым мин. Моны комиссариатта эшләүчеләр яхшы белә. Ә инде татарларга килсәк, Вахитов, Солтангалиевләр янына тагын бер калай әтәч—Усмановның өстәлүен һич тә теләмәс идем. Әгәр алар эздән чыксалар, Вәлидов күрсәткәннәр уен гына булып калачак.

—Моның белән дә килешәм. Әмма бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый һәм кабатлап әйтәм, бүгенге армиябезнең хәле шундый : барлык фронтларда да авыр йөк— татарлар җилкәсендә. Аеруча пехота, артиллериядә шулай. Кайсы гына фронтны алма, сан ягыннан карасак, гаскәриләрнең күпчелеге—Идел буе татарлары. Алар, һич арттыру түгел, революциянең терәге. Шуңа күрә бүгенге көндә Идел буенда төзелеп бетеп килгән Усманов бригадасы полкларына иптәш Куйбышев белән Фрунзе зур өметләр баглый. Минем уемча, монда бераз гына сабыр итәргә кирәк, бригаданы өстәмә рәвештә корал, башка кирәк-яраклар белән тагын да ныгытсак һәм яшь солдатларны ай—ай ярым хәрби осталыкка өйрәтергә мөмкинлек тудырсак, ышанып әйтәм, Көнчыгыш фронт үзенә йөкләнгән бурычны тулысынча ерып чыга алачак. Усмановка ышанып ялгышмаганбыз, оста оештыручы, зирәк егет икәнлеген эштә раслады. Ул бер генә нәрсәне үтенә: әзерлек эшләре тәмамланмыйча, бригаданы урыныннан кузгатмаска һәм фронтка бары тик тулы составта җибәрү. Яшь комиссарның исәбе—оешмас борын бригаданы таркатуга юл куймау. Мин аны яклыйм. Бездә андый эшкә маһирлар табыла ул.—Троцкий хәйләкәр елмаеп Сталинга күз ташлады.—Шулай булганда гына Җаек буйларын тулысынча колчакчылардан һәм калдык-постык казак отрядларыннан арындырып бетерергә мөмкин булачак. Ташкент тирәсендә озакка сузылган сугышлардан соң ял итеп өлгергән Төркстан фронты да хәлләнеп килә. Татбригада сугышка кергән унайга Төркстан фронтының кайбер берләшмәләре Тургай даласына, ягъни татарларга ярдәм итеп хәрәкәт итә башласалар, һичшиксез, Көнчыгыш фронт җәйге компанияне уңышлы башкарып чыгачак. Ул вакытта сезнең көньяк фронтта...

Троцкийның соңгы сүзләре Сталинның йөрәгенә ук булып кадалды. Ул Үзәк Комитет тарафыннан көньяк фронтка җаваплы итеп җибәрелгән кеше буларак, инде кайчаннан бирле Ворошиловның тулы бер армияне Сарысу янында нәтиҗәсез бет туйдырып яткыруыннан гарык булган иде. Башка реввоенсовет әгъзалары айлар буе фронтта, турыдан-туры гаскәрләр белән идарә итүдә катнашсалар, Сталин берничә мәртәбә Сарысу тирәсенә барып кайту белән чикләнде. Ул чакларда Ворошилов белән үзләренчә гаять уңышлы тактик операцияләр дә үткәреп азапландылар, әмма дошман гаскәрләренә мангайга-мангай юнәлдерелгән гади һөҗүм операцияләре меңләгән солдатларны чебен урынына кырдырудан башка берниндн уңыш китермәде. Ворошиловның булдыксызлыгын Сталин эченнән таныса да, реввоенсоветта Троцкий кебек бәндәләр утырганда, ул аны өзгәләүгә юл куймаячак иде. Иң хәлиткеч мәлләрдә кемгә таянырга? Сыналган дусларга—Ворошилов кебекләргә, билгеле. Шуңа күрә ул Троцкийны кискен рәвештә бүлдерде:

—Көньяк фронт үз бурычын артыгы белән үти. Ворошиловка каршы акларның регуляр армиясе сугыша. Көнчыгыш фронттагы, үзегез әйткәнчә, калдык-постык казак бандалары түгел...Димәк, тагын ай—ай ярым вакыт кирәк дисез татар полкларына...

—Иптәшләр шундыйрак фикердә. Күптән түгел анда Калинин булып кайтты. Яна гаскәрләр яхшы тәэсир калдырган. Алдагы операцияләрне планлаштырганда бу факторны исәпкә алырга туры килер.

Сталин, Троцкийдан чыгуга, туры Ленин янына китте. Әгәр Куйбышев үз дигәненә ирешсә, ул чагында...Әйе, Көньяк фронт белән яна бугай Сталин. Бөтен өмет Буденныйның кавалериясендә. Фрунзе, тәҗрибәле хәрби белгеч, ни кыланганын яхшы белә, Көнчыгыш фронтта хәл иткеч җиңүләргә ирешәчәге көн кебек ачык. Троцкий җүләр түгел, дөрес уйлый—революциянең язмышы Көнчыгыш фронтта хәл ителә. Тик революция язмышы гына түгел шул...Бу очракта, аның, Сталинның язмышына да нык сугачак фронтлардагы хәлләр. Ана болай да теш кайраучылар күп. Фрунзены кулдан ычкындырмаска кирәк, аны ничектер Көньяк фронт белән дә бәйләп куярга иде. Бу вәзгыятьтә көньяк фронтны үз сыртында алып чыгарга тырышу ахмаклык булыр иде.Нәкъ шуның аркасында Сталин баш калкыта алмый бит. Очлы сакаллы карт төлке моны да яхшы белә. Әнә ничек астыртын, төче елмаеп карап алды ул Сталинга. Димәк, бер генә юл кала—Троцкийның планнарын челпәрәмә китереп ташларга кирәк...

Ленин кабинетына ул үз-үзенә нык ышанган хәлдә, төпле уй-ният белән кереп китте.

...Ленин шул ук көнне Фрунзега шифрлы телеграмма җибәрде: «Оренбурның нинди кыен хәлдә калганын беләсезме? Шәһәрне саклаучы тимерюлчылар бүген миңнән ике полк пехота, ике кавалерия, һич булмаса 1000 кешелек пехота һәм берничә эскадрон җибәрүне сорыйлар. Ни эшләмәкче буласыз, сезнең планнар ничек? Тиз арада хәбәр итегез!» Икенче телеграмма Көньяк фронтка күпсанлы гаскәр җибәрүне таләп итә иде...

Фрунзе ике ут арасында калды. Татбригаданы ашык-пошык фронтка җибәрүнең җинаятькә тиң гамәл икәнен дә белә, шул ук вакытта Ленин фәрманын да үтәми булмый: әгәр алдагы айларда фронтлардагы хәлләр кискенләшсә, аның үзен бу хәлнең гаеплесе итеп күрсәтергә мөмкиннәр иде. Гаепләү өчен сәбәп ансатның да ансаты—белә торып фәрманны үтәмәдең! Бетте-китте, вәссәлам.

Төзелгәндә үк күп шау-шу, тавыш-гауга тудырган татар бригадасын «эш»тә сынап карарга вакыт җитүен сәбәп итеп, Фрунзе май урталарында Усмановка бер полкны ашыгыч рәвештә Оренбурга озатырга фәрман бирде. Усманов беренче мәлдә баш-аягы белән каршы килде. Бригада әле тиешле сугышчан әзерлеккә җитмәгән дип саный иде ул, ашыгып фронтка китүне һәлакәткә тиңли иде.Иң сәере шул—аны монарчы яклап килгән Фрунзе үзе үк бригаданы таркатуга кереште. Аңлау өчен сәер, бик сәер хәл иде бу....Полк белән бергә, Идел буе татар-укчы бригадасын мең җәфалар чигеп оештырган яшь комиссар Шамил Усманов та фронтка китеп барды. Тылда калган частьлар белән әвәрә килеп ятуга караганда монда кирәгрәк саный иде үзен Усманов һәм болай уйлап һич тә ялгышмый иде...

...Казаннан пароходка төялеп Сызраньга килгәндә, аннан поезд белән Оренбур ягына кузгалып киткәндә дә Усманов үзендә гаять зур җаваплылык тоеп, хисләренә ирек бирмәгән иде. Юлда вакыт бар, аратирә полк составында фронтка баручы артистлар янына гына кереп чыккалый башлады. Аларга карап теләсә ни кадәр хисләргә бирел, гаепкә алучы юк. Артист халкы кайда да артист булып кала, ике дөнья бер моржа, унайлырак урын тапсалар, дөньяларын онытып ду китереп репетиция ясый башлыйлар. Җитмәсә, артистлар арасында яшь, чибәр кызлар

да бар. Егетләре кызларга егылып гашыйк булып та куйганнар, һәркайсының үз кайгысы—«үз мәгъшукасын» башка чит-ят күзләрдән саклап калу. Ни әйтсәң дә, егетләр дә төшеп калганнардан түгел, кызлар өчен алар арасында гаять зур конкуренция бара, телләре телгә йокмый, авызларыннан кошлар очыралар инде, тынлап барсаң. Әмма бу хәлләрдән кызык табып йөрергә җай юк, вакыты ул түгел шул.

Шамил Оренбурга якынлашып килүләрен күңеле белән тоеп бара иде, алгы вагоннан паровозга табан үтте һәм мичкә күмер ташлап мәш килгән кочегарга орынмаска тырышып, иң алга ук килеп басты.

Оренбур...Аның балачагы, үсмер еллары үткән серле кала...Күпме хыялларына канат булды Оренбур, күпме ашкынулар, тетрәнүләр кичергән шәһәр ул. Үсмер чагында радио белән җенләнеп, китап, журналлар актарып никадәр йокысыз төннәр үткәргәнен исенә төшереп тәненә рәхәт җылылык йөгерде, иреннәренә елмаю кунды. Ыспай, зыялы кыяфәтле, яна фуражкасы астыннан тыенкы гына чыгып торган бөдрә чәчле бу егеткә елмаю бик килешә иде. Хәрби киеме дә гәүдәсенә ятышып тора. Яшерен-батырын түгел, артистка кызлар ул килеп керсә бөтенләй әллә нишләп китәләр, ятлаган сүзләрен оныталар, биегәндә ялгыш китереп басып иза чигәләр.Үзләре астан гына комиссарга яндыргыч караш ташлап өлгерәләр. Их, тыныч вакыт булса...Шамил белер иде яшьлекнең кадерен. Аның йөрәге сулкылдап куйды.

Ул Оренбур ягыннан күзен алмыйча, күңеленнән шәһәр белән бәйле истәлекләрен барлый башлады.Ә бит Оренбурдан соңгы мәртәбә китүенә бер ел вакыт үтмәде. Үткән ел күпме михнәтләр күрсәтте аңа бу шәһәр һәм шәһәр тирәсендә барган сугышлар. Дутовчылар гаять мәкерле һәм аяусыз иде шул. Ә кызылларның таркау гаскәрләре кылган гамәлләрне күздән кичерсәң, чәчләр үрә торыр. Теләсә каян җыелган партизан отрядлары, ни теләсәләр шуны эшләп, халыкның нәфрәтенә дучар булып, бөтенләй абруйсыз калып, хур булып беткәннәр иде бит ул чагында. Аңа Сызраньда оештырган отряды белән унсигезенче елның февраленнән җәйгә кадәр бу тирәләрдә авыр сугышлар алып барырга туры килде.Аерым партизан отрядларын берләштереп, көчле бер йодрыкка тупламакчы иде ул, тик алай җиңел генә хәл ителә торган нәрсә булып чыкмады ул эш. Һәр отряд командиры үзен Наполеон кебек хис итә, гел үзенекен генә алга сөрә. Шуның аркасында күпме тәртипсезлекләр, ярамаган гамәлләр кылынды бит.

Әле дә исеннән чыкмый, шулай, җәй башларында, аның янына томырылып бер үсмер килеп керде. Аның артыннан ашыгып атлаучы абзый да пәйда булды. Абзый малайны читкәрәк этәреп, алгарак үтте.

—Мин Гомәр Дәүләтъяров булам,—диде ул, үзе белән таныштырып. Ул мәгънәле итеп Усмановка карап алды: янына кем килгәнен чамала инде, дигәнрәк фикер салынган иде аның сүзләренә. Абзый көттереп тормыйча, бу хакта әйтеп тә бирде.— Мондагы һәр укымышлы, зыялы белән бергәләп милләт өчен күп эшләр башкарган адәм булам. Менә бу егет,—диде тынычлана алмый урынында таптанып торучы үсмергә ым кагып,—Каргалыдан, Әхмәтсафа исемле. Миңа энекәш тиешле. Ул күңелсез хәбәр алып килгән, тиз генә аңлатып булса...

—Нинди хәбәр ул?—диде Усманов яшенә караганда күпкә ныклырак тавыш белән.

Сүз башлаганда бу яшь кешегә бер дә ышанычы юк иде Гомәр абзыйның, инде андагы житдилекне, тәвәккәллекне күреп алгач, эченә җылы йөгерде, йөзе балкып китте.

—Мин инде ике-өч кешегә барып бәрелдем, мәсьәләне Усманов кына хәл итә алыр дип, синең янга җибәрделәр. Эш шунда—Каргалыда кызыллар бер төркем егетне җыеп, дезертир дигән булып, үзләренчә судмәхкәмә оештырып маташалар, ди. Әхмәтсафа китергән хәбәр шул икән.

Абзыйның бөртекләп аңлатуын сабырсызланып көтеп торган Әхмәтсафа ашыгып өстәп куйды:

—Стенага терәп атабыз, диләр. Авылдан беркемне чыгармыйлар. Холыксыз кыланалар, атарлар да. Анда минем абыем Госман да бар. Тайфә әбинең улы Хәлфи абый, тагын...

Усманов, күп сөйләшергә урын калдырмады. Отыры ачуы чыгып, сукранып алды:

—Ну шушы Хәйбрине! Бу көннәрдә ул йөри иде Сакмар аръягында. җүнләп сугышканы юк, халыкның канына тоз салып йөрүдән башканы белми.

—Әйе, әйе, Хәйбри исемле командирлары. Бар кешене тотак иттеләр. Беркемне чыгармыйлар авылдан.

—Ә син ничек чыга алдың?—дип, кызыксынып-сынап сорады Усманов.

—Каргалы зур авыл бит, абый.Тишек-тошыкларын болай гына томалап бетермәле түгел,—диде малай олыларча житдилек белән.—Мине Дәүли абзый Сакмар аша чыгарып, Кушкүл чатына каләр китереп куйды. Ат белән...Ул кире борылды, егетләргә бер-бер бәла була күрмәсен дип, авылга чапты. Мин Гомәр абзыкаем янына йөгердем менә...

—Һм...Хәйбрине авызлыклап, арт сабагын укытып кайтмый булмас, алайса.

Ул ишек аша кемгәдер кычкырды:

—Федор, отрядыңда ничә кеше калды?

—Иртән егерме атлы, кырык пехота иде,—дип берәү көттереп кенә жавап бирде.

—Безгә атлылар житә. Сугышчыларыңны жый, хәзер үк Каргалыга юл чыгабыз. Анда Хәйбри үз тәртибен урнаштырып йөри икән.

—Тагын нинди мөгез чыгарган инде?

—Мин аңа халык арасында аңлату эшләре алып барып, отрядка егетләр жыеп кайт дип фәрман биргән идем. Ул ансат юлын тапкан—егетләрне жыеп ала икән дә, атам дип, куркытып, отрядына китереп куша. Жайлы бит...

—Атар да. Сакмар буендагы бер авылда теге атылган егетләр шул Хәйбри эше. Аның ише кешегә мылтык түгел, очлы таяк тоттырасы да түгел. Күптән кыжрап йөри—бер-икесенең мангаена жәдрә утыртсаң, «отрядыңа яз, абзыкаем» дип,халык безгә йөгереп кенә киләчәк, дигән сүзләрен күп тыңладык бит инде.

Боларны ишетү Усмановның үзе өчен дә күңелле түгел иде, Хәйбрине мондый эшкә чыгарып жибәрүенә үкенеп куйды.

—Әй, шушы дуамал холыкларын!—Усманов ашыгып урыныннан торды, биленә тагылган кобурасын капшап алды да чыгу ягына атлады.

—Ярый, Гомәр абзый, сүз бозау имезә, без юлга кузгалдык. Ә мин сине беләм бит, кибетенә китап алырга йөри идем...

—Әйтәм аны...Күргән дә сыман...—дип, аптырап сөйләнеп калды абзый.

Усманов көлемсерәп Әхмәтсафага эндәште:

—Син, егет, үзең белгән сукмактан кайта тор. Без күпер аша барабыз. Хәйбринекеләр син үткән кәжә сукмагыннан атлылар килеп чыгуын күрсә, этем белсен, аңышып тормыйча, чүкеп тә куярлар.

Әхмәтсафаның тамырларында кан уйнап алды. Аның да Усманов отряды белән бергә гөрс итеп Каргалыга кайтып керәсе килә иде. Күрәсе иде Хәйбрине, каршысына Усманов килеп баскач, ни-нәрсә сөйләнеп азапланыр микән? Тик болай хыялланып, вакыт үткәреп торуы өчен үзен битәрләп алды: житешсә генә ярар иде Усманов абый. Хәйбри дигән имансыз командир бер-бер хәл эшләргә өлгермәсә генә ярар иде. Иң яраткан Госман абыйсының да гомере кыл өстендә калды. Әгәр Усманов отряды килеп өлгерсә, шатлыгы эченә сыймас, ул бит гаять зур эш башкарды! Күпме егетнең гомерен саклап калды. Шушы уйлар эчендә, Гомәр абзыйсына «рәхмәт» әйтергә дә онытып, бүлмәдән чыгып йөгерде.

Усмановның кечкенә отряды килеп кергәндә, авылда мәхшәр купкан иде. Яна мәчет диварына Хәйбри башкисәрләре унлап егетне тезеп куйганнар. Хәзер алар зур эш башкаргандай халык алдында кәпрәеп йөргән Хәйбридән соңгы боерык, фәрман көтәләр иде.

Авыл урамнарын дер селкетеп, кинәт чабышып килеп кергән атлыларны күреп, Хәбри бер каушап калса, килә-килешкә ат өстеннән җиргә сикереп төшеп, җилләнеп каршысына килеп баскан комиссар Усмановны күреп, яңа гына әтәчләнеп йөргән командир кисәге бөтенләй мәлҗерәп төште.

—Тагын ни майтарасың, Хәйбри?—диде Усманов үтә канәгатьсез тавыш белән.

—Ни бит, иптәш Усманов...Бераз агарту эшләре алып бармыйча булмый, кызыллар отрядына язылам дип торучы юк. Шуңа, мин әйтәм...

—Аңлашылды, халыкны агартмыйсың син, канга батырып йөрисең! Күрәсеңме, халык сиңа нинди нәфрәт күзләре белән карап тора. Үзеңнең борыныңнан ары бернәрсәне дә күрмисең, ахры, син. Корал бит ул, егеткәем, акыллы кулга эләксә генә илгә, халыкка файдага эшли. Синең ише дуамал җанга корал биреп ялгышканбыз без.

—Миңа ни...Фәрман үтәм йөреш. Йә кайсыгыз минем кадәр гаскәр җыйды отрядка?

—Бүген бауга тагып алып кайтасың, ике-өч атнадан коралларын ташлап, качып, таралышып бетәләр. Шул булдымы эш?

—Бәтәч, иптәш комиссар, ансын инде сез үзегез карагыз. Тәрбияләгез, агартыгыз, качырмагыз. Шул да булдымы революцион тәртип!?.

—Бөтен хикмәт тә шунда инде. Хәйбри, революцион тәртип дисең икән, ул синең үзеңнән башланырга тиеш. Кара инде киеменә—башында казак папахасы, аягында башкорт читеге, өстендәге гимнастеркаң каешланып каткан. Үзең командир саналасың.

—Көлмә инде, иптәш Усманов. Монда үзеңне карарга вакыт бар, ди.

Усманов ачуын яшерми, сөйләвен дәвам итте:

—Солдатларыңны күр, революция солдатларымы алар, әллә юлбасарлармы? Аерып алмалы түгел. Хәзер үк отрядыңны җый, үзләрен тәртипкә китерсеннәр, ә мин халык белән сөйләшеп алам,—дип Усманов, яңа мәчет янына тезелеп баскан, башларын аска иеп, сүзнең ни белән бетәсен тын да алмый көтеп торган егетләргә таба борылып, кутәренке тавыш белән:

—Нәрсә, бөрешеп басып торасыз?—дип кычкырды.—Барыгыз, өйләре-гезгә йөгерегез, әти-әниләрегез хафаланмасын. Кызыл гаскәрләргә көчләп алып китү булмаячак!

Шушы сүзне ишетүгә, егетләр дәррәү урыннарыннан кузгалып, күз ачып йомганчы, җыелган халык арасына кереп югалдылар. Сафта ике егет кенә басып калды.

—Сез ни көтәсез?

Егетләрнең берсе алгарак чыгып, каушый төшеп сүз башлады:

—Рәхмәт, иптәш командир...Хәйбри-җанкыярны акылга утыртуыгыз өчен мең рәхмәт...Мин Тайфә карчык малае, Хәлфетдин. Безне атарга алып чыгалар дигәч, инәй-карчык йөрәге тотып егылды. Өйгә кайтып, аны юатып киләсе булыр. Өйләргә таралганчы сезгә сүзебез бар иде.

—Тыңлыйм.

—Без менә Мочтай...әй лә, Мостафа абзый малае Госман белән уйлаштык та, сезнең отрядка язылысы иттек.

Усманов өчен Тайфә карчык кем дә, Мостафа агай кем—ул кадәр әһәмиятле түгел, ә егетләрнең үз теләкләре белән отрядка кушылырга теләүләре бик мөһим иде. Дулкынланудан аның йөзенә алсулык йөгерде. Ул бер читтә ризасыз кыяфәттә басып торган Хәйбригә ачулы караш ташлады.

—Дөрес уйлыйсыз, егетләр. Вәзгыять шундый, чормада ятып та,

печән кибәне астына яшеренеп тә Рәсәйдә барган хәлләрдән качып котылып булмый.—Аның сүзләрен шым гына тыңлап торган Госманның йөзенә кызыллык йөгерде, ул нәрсәдәндер оялган сыман башын түбән иде. Усмановның күзеннән шаян чаткылар сибелде.—Нәрсә, егет, кыек атып туры тигездемме әллә?

—Өстенә бастыгыз, дисәң дә була, иптәш комиссар, ул егетне чормадан өстерәп төшердек,—дип сүзгә кысылды Хәйбри.

Усмановның йөзе житдиләнде.

—Синең кыланмышыңнан җәһәннәмгә качардай булырсың, Хәйбри...

Монарчы дәшми торган Госман телгә килде.

—Кемгә ышанырга белмәссең, кем килсә, шул үз гаскәренә куа. Бертуган абыем Гомәрхан әнә Муса Мортазинның полкына язылган иде. Кызыл гаскәргә дип, озак та үтмәде, Мортазин башкортлар ягына чыккан, диделәр. Шулай булгач кемгә ышанырга соң?

—Әйе, андый ялгышлык булды. Ул көннәрдә аңлашу житмәде. Хәзер Мортазин да, башкортларның башка частьлары да кызыллар белән күмәкләшүгә каршы түгел. Безгә һич тә аерымланырга ярамый.Шушы чорда татар-башкорт мөселманнары файдасына нәрсә дә булса эшләп өлгерә алмасак, соңыннан үкенергә туры киләчәк. Сугыштан соң батырлар күбәя. Тыныч тормышка күчеп, милләт ягын кайгырта башласак: « Без фронтларда кан койганда, сез, мөселманнар үзара талашып, ызгышып яттыгыз, хәзер ни-нәрсә таләп итмәкче буласыз»—дип, көләчәкләр генә. Шуңа күрә революциядә жин сызганып катнашырга кирәк дип саныйм. Безнең язмышны үзебездән башка беркем дә хәл итәргә тиеш түгел. Минем большевиклар сафына басуым, кызыл гаскәр туплап, ак казакларга каршы сугышуым нәкъ шуның өчен дә. Моны мин генә түгел, сез дә шулай аңласагыз иде. Ул чагында Хәйбриләрдән качып чормада ятасы урынга, революцион гаскәрләрнең иң алгы сафына килеп кушылырсыз. Шуларны аңлаган хәлдә минем отрядка кушылырга ниятлисез икән, рәхим итегез, бер каршылыгым да юк.

—Рәхмәт, рәхмәт,—диештеләр егетләр, комиссарның үзләре белән шулай дустанә сөйләшүенә сөенеп.

—Рәхмәтне миңа гына түгел, штабка нәкъ вакытында килеп житкән жегеткә дә әйтергә онытмагыз,—диде ул, елмая төшеп.

Усмановның сүзен ишетеп, тарала башлаган халык тукталып, тагын жанланып алды.

—Кем, кайсы жегет турында сүз бара?—диде бер агай.

Мактана төшеп, тамак төбе белән икенче абзый сүзгә кушылды:

—Минем малай, Әхмәтсафа...Дәүли Кушкүлгә кадәр ат өстендә озатып куйды. Тәки барып житкән, эзләп тапкан бит, шайтан алгыры. Әнә үзе дә әйләнеп кайтып килә,—дип, үтә дә житди кыяфәттә ашкынулы адымнар белән мәчеткә табан килүче үсмергә күрсәтеп.

—Мочтай малае икән...—диде бая сорау биргән агай канәгать тавыш белән.—Үткер күренә, «каеш»ныкылар икәне атлавыннан ук сизелеп тора.

Әхмәтсафа жыелган халыкның, команда буенча дип әйтерлек, дәррәү үзенә табан борылып каравына кыенсына төшеп, әтисе янына килеп басты. Мостафа улын башкалардан аралап алырга теләгәндәй, нык итеп жилкәсеннән кочаклап, башкалар ишетерлек итеп улын мактап алды:

—Маладич, улым! Госман абыеңны йолып алдың бит тәки.

—Хәлфетдин абый кая соң?—дип, беркатланып сорап куйды Әхмәтсафа.

—Барсы да исән-имин. Өйгә йөгерделәр әнә.

Мәчет янына жыелган халык, шушы шөбһәле һәм чарасыз үткән берничә сәгать эчендә тәмамысы арып-алжып беткән иде, тоткын егетләр азат ителгәч, «бу тирәдә чуалуның кирәге калмады, бәладән баш-аяк» дигәндәй, тарала башлады. Усманов шактый талчыккан Әхмәтсафага кулын сузды:

—Булдырдың, егет икәнсен!—Халыкның алны-артны карамый аралуын күреп, мәчет баскычына сикереп менде һәм кулын өскә күтәрде:

—Җәмәгать, таралмагыз әле!

Авыл агайлары, «бусы нәрсә инде тагын?» дигәндәй сәерсенеп, теләр-теләмәс кенә кире борылдылар, сагайган карашларын яшермичә Усманов тирәсенә елышып, ярымтүгәрәк ясап бастылар..

—Җәмәгать, бер житешеп килгәч, гәпләшеп тә алыйк инде,—диде ул, уенын-чынын кушып. —Шушы гүәрдин сыман егетләргә карап тордым да, уйлап куйдым. Ярый, без китәбез, иртәгә, әйтик, ак казаклар килеп керер, егетләр алардан да котылып калыр, тагын ике-өч көннән башкорт жайдаклары кереп тулыр авылыгызга. Һәркайсы үзенчә мобилизация, ягъни солдат җыйнау турында карар игълан иткән. Без дә Ленин фәрманы буенча, гаскәр җыябыз. Татарларны инде апрель аеннан бирле кызыл армиягә язу бара. Шундый хәлләр...Ничек саклап калырсыз соң алга табан егетләрегезне? Ә бит мобилизациядән сәбәпсез читләшкән кеше дезертир булып санала, ә сугыш чорында дезертирны, үзегез беләсез...

—Менәтерәк шунсын аңлап бетереп булмый да инде, иптәш-әфәнде командир. Әллә аңлата белүче юк, әллә үзебезнең баш юка,—дип сөйләнә-сөйләнә алгарак чыкты бер агай. Ул, тел төбендә хикмәтле фикер ятканны искәртергә теләгәндәй, сакал-мыегын учы белән нык кына сыйпаштыргандай итеп алды.—Килүчеләр күп ансы, һәркайсы мөселман исеменнән сүз йөртә. Безгә инде, яшерен-батырын түгел, татар, башкорт дип өйрәнмәгән. Мин үземне кем дип тә белмим, татармы, башкортмы, фаразан?.. Тфү-тфү, әйтмәгәнем булсын, күзем чәчрәп чыкса да, денем белән, иман-вөжданым белән теләсә кайда үземне мөселман дип раслый алам.

—Без дә мөселман бригадасы,—дип аны җөпләде Усманов һәм ялгап алып китте.—Катлаулы мәсьәлә бу. Нәкъ шуның аркасында Вәлидовчылар белән аерымлану килеп чыкты.

—Анысы кем тагын?—дип сорады арадан берәү.

—Башкортларның патшасы,—дип җавап кайтарды аңа Мостафа, белдекле рәвештә.

—Ишкәннәр икән...

Сорау бирүченең әлеге сүзләреннән көлешеп алдылар.

Усманов кызуланып:

—Әйе,—диде,—барыбыз да мөселманнар. Шунысын гына онытмаска кинәш итәм: мөселман дөньясы катлаулы, хәтта каршылыклы да. Барлык диндәшләребез өчен җавап тотасы килми, әмма Идел-Җаек арасындагы төбәкләрдә яшәүче татар, башкорт халыкларына берләшергә кирәк. Безне Солтангалиев кебек юлбашчыларыбыз шуңа өнди. Үзегез күреп торасыз, көчкә көч белән генә каршы торып була. Кем рәхәт күрсәтте сезгә? Патшамы? Ак казаклармы? Әллә Вәлидов рәхәт тормышка чыгарыр дип уйлыйсызмы? Алай булмый ул җәмәгать. Берләшүдән гайре башка чарабыз юк. Без, әгәр милләт булып яшисебез килә икән, шушы юнәлештә кичекмәстән хәлиткеч адымны ясарга тиешбез. Киләчәккә карап эш итәргә өйрәник, җәмәгать...

—Быелның—ярингәсе, таңдагының ахирәте бар,—диде арадан берсе.—Булырның бавы озын шул аның, туганкай. Тормышның көе китте, тозы чамалы нотыклар тыңлап яшәүләре ялыктырды инде.

—Дөрес. Дутов та Идел-Җаек арасында учредилка мәмләкәте дип, сезнең башыгызны бутап йөри әнә. Башка коткы салучылар аз түгелдер. Аңа кушылган Вәлидов халыкны юк-бар нәрсәләргә ышандырып, Дутов белән берләшергә чакыра, житмәсә.

Моңарчы Усмановны тыныч кына тыңлап торган калын кашлы адәм дөрт итеп кабынды:

—Алар берләштеләр, сез дә кушылыгыз! Вәссәләм бит инде шуның белән. Үзем—түрдә, сүзем үрдә дип кенә сүләнәсең, агай-эне. Берләшәсе килгәнгә беркем дә комачау ясамый. Ник сузасыз?

—Дәүли дөрес сукалый.Ун дәрвиш бер келәткә сыя, ике патша бер

кыйтгага сыймас дигән борынгылар. Патшалар кубәйгән саен жир тарая.

Усмановның бирешергә исәбе юк иде.

—Алар ни өчен берләштеләр соң? Төп идея—Татар-Башкорт республикасы төзүгә каршы берләштеләр бит алар, ягъни берләшүгә каршы берләшү булып чыга. Ләкин Дутовка, әгәр аның уй-нияте тормышка ашса, Вәлидов кирәкме, башкорт мәмләкәте кирәкме? Юк, кирәк түгел. Урыс монархиясенә, ягъни урыс патшасына ант эчкән Дутов мөселман өчен бармагын да селкетмәячәк. Ә көрәшкә өндиләр. «Көрәш» сүзе матур сүз, тик ни өчен көрәшкәнне белергә кирәк. Әнә Сакмарга карагыз, ничек дәртләнеп, ашкынып ага ул! Мин үзем Оренбурда туып, шунда үскән, укып белем жыйган кеше. Яз көне бозлар актарылганда бигрәк матур, ямьле була иде Сакмар. Тик ярдан карап торганда гына матур. Шул актарылган елгага кереп карагыз әле. Исән калырсызмы? Сезнең башны әйләндереп йөрүчеләр дә шулай, матур сөйлиләр, ә эчтәлеге бер—шул сүзләргә ышанып ташкынга кереп китсәгез, берегез дә исән чыга алмаячаксыз.

—Сине уздырганы юк иде сыман...Бигрәк шома сиптерәсең. Ат сөртенми жир танымас, ир сөртенми ил танымас, әйтүе генә жинел, дөреслекне бер Ходай белә,—диде Дәүли, бер дә Усманов белән килешәсе килмичә.

—Мактавыгыз өчен рәхмәт.Телгә ансы кесәгә керешле түгел,—диде Усманов,ак тешләрен күрсәтеп елмаеп.—Яшермим, максатым—мөселман гаскәрләрен жыеп бер йодрыкка туплау. Яулар кичкән кеше буларак әйтәм, бердәм һәм кулында коралы булган халык белән генә хисаплашалар. Кулга корал алгансың икән, ни өчен яуга керүенне бел. Сәгать сукты, мөселман халкына азатлык яулап алырбыз, бабайлар монарчы гасырлар буе хыялланган ирекле дәүләтебезне торгызырбыз. Оренбурда төзелгән мөселман батальоны комиссары буларак әйтәм—көч безнең якта, халык безнең якта. Без—жиңәчәкбез!

...Кисәк әче итеп паровоз сызгыртып куйды. Усманов хәтирәләреннән айнып китте. Мәзәк хәлдә калганын да шәйләп алды— үзе дә сизмәстән, йодрыгын күккә чөеп жибәргән хәлдә тора икән бит! Ул артка борылып карады, күреп калучы булмаганмы. Күзгә кеше-фәлән чалынмагач, тынычлангандай булып, штаб урнашкан вагонга керергә кузгалды. Оренбур якын, инде бик якын иде...

## III

Әхмәтсафа өлкәннәрнең сөйләшүен тынлап бетермәде, өйләренә ашыкты. Шулай да Дәүли абзыйның акыллы һәм көчле Усмановка каршы төшеп маташуын өнәп бетермәде. Көчле булмас ди сина! Хәйбри аны күргәч, шәлперәеп, шәрә бүре хәлендә калды. Каргалы никрутларын (әткәсе сүзе) котылгысыз һәлакәттән йолып кала алуына малайның түбәсе күккә тигән иде. Баш өстендә өерелеп йөргән болытлар да, Жаек буеннан кисәк-кисәк исен куйган салкынча жил дә аның бу күнел күтәренкелеген баса алмады. «Өлгердем бит! Госман абыйны коткарып калдым, шөкер»,—дигән уй аны күкнең жиденче катында йөртә иде. Ул хәзер атлап барган, озакка сузылган яңгырлардан тәмам жәфаланып, изерәп беткән сукмак та, әйтерсең, Оренбурның таш түшәлгән юлларыннан ким түгел. Малай арыганын онытып киртә буйлап сузылган сукмактан йөгерә-атлый, йөзе кояштай якты, бүселеп торган көнгә дә исе китми—бүген бәйрәм, чын бәйрәм иде аның өчен.

Шул уйлар белән барганда Ишан мәчете тыкрыгыннан капыл каршысына Вәлкәй хажи килеп чыкты. Уңны-сулны искәрми кайткан малай барган шәпкә хажига бәрелә язып, соңгы чиктә сукмактан читкә каерды. Үзе исә әллә шүрләп, әллә уйларыннан айнып бетә алмый:

—Һәй-лүк!..—дип, сөрән салганын сизми дә калды. Әйтерсең, киң дала буйлап сарык көтүе куып бара.

Үсмердән мондый кыланмышны, бернинди аратага сыешсыз пырдымсызлыкны көтмәгән Вәлкәй хажи шыр җибәрде бугай, кулындагы кәкре саплы таягын сөнге сыман күтәреп, Әхмәтсафаның күкрәгенә китереп төртте.

—Мәлгунь, күзенә бәрәнге үскән нәләт, артыңны кыргычлап, борыч белән уасы нәмә, ни уйлап шакмак күзеңне киереп ачып мәчет әһелияте өстенә килеп менәсең, ә?!—дип чинап җибәрде ул.

Әллә тагын Әхмәтсафа аны почмакта юри саклап торып, шулай куркытырга уйлаган. Малай чынлыкта шүрли төшкән иде, шундук теленә килгән беренче сүзләрне әйтергә өлгерде:

—Хәерле көннәр булсын, азанчы бабай!..

Бу сүзләргә Вәлкәйнең ачуы отыры көчәеп кенә китте.

—Мөселманча, китапча сәлам дә бирә белмисең, йолкыш. Мифтах хәлфә бозган нәмәкәйсеңдер инде. Әссәламәгаләйкүм, хажи хәзрәтләре, диген, атың коргыры.

Азанчы дөрес әйтә иде. Каргалы—тирә-якта гына түгел, бөтен татар-мөселман илендә барыннан да бигрәк үзенең мәчет-мәдрәсәләре, диндарлары белән дан тоткан авыл. Чулман, Җаек буйларында яшәүче укымышлы һәр мөселман изге сәфәр—хаҗга барырга уйласа, сәфәрнең нәкъ менә Каргалы аша үтүен хуп күрер иде. Озын һәм билгесез юлга чыгар алдыннан ике-өч ай мондагы абызагай—гыйлем ияләре хәзрәтләрдән, хаҗ сәфәрендә булып кайткан тәкъвә картлардан бу изге эшнең низам-кануннары хакында озаклап һәм тәфсилле аңлатмалар алалар. Хаҗ турындагы белемнәрен арттырып, кирәгенчә төшенгәннән соң гына Каргалыдан кубып китәләр иде. Тик, ни гаҗәп, дини йолаларга, гореф-гадәтләрнең какшамас кануннарыннан бер мыскал читкә авышмаган Каргалыга да берзаман, иске тәртипләрнең үтәлешен ныклы күзәтүдә торкан абызагайлар уенча, җәдитчелек дигән нәмәхрәм мәктәпчелек үтеп керде. Иң беренче Гомәр Дәүләтьяров сәбәпче булды моңа. Ул, яшьтән үк үз көнен үзе күрә башлаган зиһенле сәүдәгәр, Оренбурга күчеп, шәригатькә ярашмаган эшкә тотынды. Иң беренчесе, шөкәтсез озын чәчле, җилбәзәк кыяфәтле, әмма үз якларына үтә дә зирәк сукалаучы мөгаллимнәр, нәширләр белән дуслашып алды. Авылга чат ябышып яткан яшьләрне шәһәрдәге мәдрәсәләргә гыйлем эстәргә барырга күндерде. Ул гына житмәде, Каргалыга—хак мөселманнар, «икенче Мәккә» дип атап йөрткән шанлы салада җәдитчә мәдрәсә ачтыруга ирештеләр. Гомәр Дәүләтьяровны, аның тарафдарларын кадими имамнар егълый-егълый каргасалар, җәдитчеләрне яклаучылар да аз түгел иде. Озак та үтмәде, бөтен мөселман дөньясын үзләренең диндарлыклары белән шаккатырган Каргалы шәкертләренең аннарын саташтырырга әллә кайдан Мифтах атлы хәлфәне табып китерделәр. Анысы бигрәк тә үҗәт булып чыкты: мең дә бер каршылыкны җиңеп, янау-куркытуларга, туктаусыз һөҗүмнәргә карамый җәдитчә укытуны оештырып җибәрде. Шулай итеп, гасыр башында, Каргалы имамнарының гасырлар буе бөртекләп җыйган абруе сизерәп төшкән мендәр сүрүе кебек сыпыла башлады. Шәкертләрен әйт, күрәсең, халыкта дини белемнәр белән рәттән дөньяви белемнәргә дә омтылыш шул кадәр көчле булгандыр—хәзрәтләренең бәддогаларына, янау-куркытуларына керфекләрен дә селкетмәгән кыяфәт белән, һич икеләнмичә Мифтах хәлфә ягына авыша башладылар. Җитмәсә, авылда кызлар мәктәбе ачылды. Монысына нәсел-тумышлары белән Каргалы кешеләре саналган Хөсәенов байлар тырышты. Аларга ярдәмгә алтын приискалары хуҗасы алтынчы Закир Рәмиев килеп кушылды. Гомергә күрелмәгән хәл, әлеге мәктәпкә Оренбур, Троицк кебек шәһәрләрдән үсмер кызлар җыелды. Сусаса да сусар икән халык белемгә!

Авыл картлары, мулла-имамнар да бирешергә теләмәделәр. Тырышлык куеп йөрүләре бушка китмәде тагын, кызлар мәктәбен яптырганнар

иде яптыруын. Тик дөньялар буталып китте, Оренбур байлары янә ачтылар мәктәпне. Менә шулай кадимчеләр белән тарткалаша-өзешә түнтәрелеш дәверенә килеп керделәр Каргалы җәдитчеләре.

Әмма кадимчеләр Дәүләтьярныкыларны җай килгән саен каһәрләүләрдән, сәбәпле дә, сәбәпсез дә битәрләүдән туктамадылар. Әйтерсең, Каргалыга үтеп кергән җәдитчелеккә генә түгел, ә дөньяның астын-өскә китергән түнтәрелешнең дә төп гаепләре шушы тынгысыз нәсел кешеләре иде. Һәр эшнең башында алар йөргән кебек, нәкъ менә алар таяк белән болгата кырмыска оясын. Вәлкәй хаҗиның котыруы да тикмәгә түгел, кинәт каршысында пәйда булган әлеге үсмер дә Мочтай малаена охшаган, туп-туры күзгә карап торулары, гөнаһсыз көлемсерәве гел этисенеке икән.Теле телгә йокмый, әҗәткананың:

—Әйе, Вәлиулла бабай, Мифтах хәлфә шәкерте мин,—дип, чатнатып ярып салды, тоз күз. Үзләренә шайтан гыйлеме өйрәтеп яткан хәлфәсе белән горурланган да төсле. Их дөньясы бозылды, ачуым бер килмәгәе, дип уйлап, эчтән сызып куйды Вәлкәй хаҗи. Әлгәре чорлар булса...

—Нинди бабай булыйм мин?—дип, рәнҗеп кычкырды ул ярсулы тавыш белән үсмергә.—Бар, бар юлыңда бул, малай актыгы! Шул Мифтах хәлфә бозып бетерде сезне. Шаккатырсың, ник кирәк авыл баласына җәгърәфия, хисабы ник кирәк. Акча булса, аңсын гына саный беләсең аны. Урысча укытуны сөйләп тә торасы юк, диннән яздыруга тиң гамәл, гөнаһ шомлыклары...—дип тезеп китте ул, үсмернең корт чагудан качкан кебек өйләре ягына элдертүенә игътибар итмәстән.—Дөньясын урыс акылы бутады инде. Ерак китәрсең менә урыс акылы белән. Кайчаннан бирле болганалар, әле илнең тынычланырга исәбе юк...

Өйләре турына житәрәк Әхмәтсафаның каршысына бер-берсе белән узыша-узыша ике бала йөгереп чыкты. Болар—энесе Әхмәтхан белән сөйкемле сеңлесе Бибиҗамал иде. Иркә кыз килә-килешкә абыйсының тезләренә сарылды:

—Олы абый китәм әйтә,—диде ул сабыйларча тәтелдәп.—Миңа мәми алып кайтам әйтә.

—Кая китә Госман абый?—дип, аңыша алмый, Әхмәтханга карап сорау бирде ул.

—Сугышка китәргә жыена...—диде Әхмәтхан, борынын мышкылдатып.—Хәлфетдин абый да кызылларга язылган.Ул да китә...

Абыйсына сөйләп бетерергә ирек бирми, Бибиҗамал күргәнишеткәннәрен җилгәрә башлады:

—Әйе, абыкай, Хәлфи абый да китәм әйтә. Инәй елый, китмә әйтә.

Әхмәтсафа аптырап тагын Әхмәтсафага карады. Энесе һушлы бала, көттермәде:

—Тайфә әбиләргә барганыек. Барып керсәк, инәй Хәлфи абыйны кочаклап: «Ике аягыңның берсен дә атламыйсың, син киткәч мин нишлим?»—дип үкереп елый. Хәлфи абый әйбәт бит ул, өйдәге бөтен эшне ялт иттереп кенә тора. Шуңа инәй җибәрәсе килми аны. Госман абыйга бер сүз дә әйтмәде. «Үзең беләсең инде,»-дип кенә куйды әнә. Тайфә әби өйдә юк, югары очтан кызлары килеп алып киткәндер инде.

Энесенең бу хакта сүз озайтуын теләми иде Әхмәтсафа. Җитмәсә, тел бистәсе сеңлесе янында. Үги инәйнең Хәлфине калдырырга теләгәнен сизенә иде ул. Тик Госман абыйсының армиягә язылып китәргә җыенганы турында әткәсе бер сүз дә әйтмәде. Әллә Госман абыйсы өйгә кайткач кына шундый карарга килгәнме? Әткәсе, бер хәбәрсез, комиссар Усмановка мөкиббән китеп, һаман ул сөйләгәннәрне тыңлап тора микән мәчет янында?..

Ул сеңлесен күтәреп алды да, Әхмәтханга дәште:

—Хәзер үк әткәйне алып кайт. Ул яңа мәчет янында булырга тиеш.—Аннан шыпырт кына,—Инәй белән Хәлфи абый турында сөйләнмә, ярыймы,—дип тә өстәде.

Әхмәтсафа сеңлесен күтәргән килеш ишек алдына үтте. Каргалыда ишек аллары бик ук киң түгел. Мостафа агайның ишек алды, башкалардан аермалы буларак, шактый иркен. Ихатада саман кирпечтән салынган кара-каршы ике өй. Берсе—гадәттә балалар йоклый торганы кече өй, икенчесе—акбур белән агартылганын, олы өй дип йөртәләр.

Госман кече өйдә, мич буендагы бүкәндә, нindидер гаеп эшләгән кеше сыман башын түбән иеп, үз уйларына йотылып утыра иде. Энесе белән сеңлесе кайтып керүгә куанды, ахры, йөзе бераз яктыра төште.

—Әткәй кайтмадымы?—дип сорады ул сүлпән генә.

—Әхмәтхан алып кайта хәзер...Сине коткарам дип чапкан булам мин, ә син...—дип үпкәләгән тавыш белән Әхмәтсафа сүз башлаган иде, Госман әкрен генә урыныннан күтәрелеп, энесе янына килде һәм аның кулыннан Бибиҗамалны алып күкрәгенә кысты.

—Шулай кирәк, энекәш...

—Хәлфи абый да китәргә җыена икән.

Госман хәсрәтле көлемсерәде.

—Китәр, китми кая барсын...

—Инәй китмәскә үгетли икән дә...

Нигәдер риза булмыча, Госман чыраен сытты.

—Бу ут борчалары барып та кайтканнар икән,—дип ул сеңлесен сак кына идәнгә төшерде. Бибиҗамал шуны гына көткән кебек ишектән чыгып тайды, аңа ни, уйнарга гына булсын. Госман, әһәмиятле хәбәр әйткәндәй, кулын энесенең җилкәсенә салды.—Бөтен хикмәт тә шул Хәлфетдиндә, энекәш. Бүген мин аның белән нык кына сөйләштем. Йә икебез дә армияга язылабыз, йә мин сине бәреп үтерәм, дидем. Тик син моны беркемгә сөйләмә. Үзең бел дә май кап. Килештекме?!

Әхмәтсафа берни аңламый, инсәсен җыерып куйды.

—Нигә алай әшәке әйттең Хәлфи абыйга!—диде ул, Госманның дуамал сөйләшүен өнәмичә.—Хәлфетдин абый булмаса...Сез бит гел читтә йөрисез.Әткәй дә кайтып керми. Дөньяны инәй белән алар алып бардылар.

—Юк сүз бозау имезә.Менә сугышлардан исән-имин әйләнеп кайтыйк, син дә исәя төш, бер иркенләп сөйләшеп утырырбыз икәү генә. Хәзергә мин әйткәнне тыңла. Бу хакта беркемгә дә тишмә. Сер булып калсын.

Җилләнеп әткәсе кайтып керүен күреп, икесе дә тын калдылар.

—Ни уйлап чыгардың син, бала?—диде Мостафа агай өйгә кергән уңайга. Тиз кайтудан аның сулышы киселә, көч хәл белән генә тын ала, аһылдап сәкегә килеп утырды.

Госман аптыраулы, мескен кыяфәттә әткәсенә күтәрелеп карады.

—Болай булмый бит инде,—диде ул, йөзендәге кызыллыгын куарга теләгәндәй кулы белән йөзен сыпырып.—Үзең уйла, әткәй, өй чормасында күпме качып ятарга була? Оренбурда яшәү тагын да куркынычка әйләнде, өйдә ятышлы түгел—балалы өйдә бур тормас, ди. Барыбер табып алачаклар. Кайсы як килсә дә күзләренә чалынасың икән, дезертир дип, атып кына үтерәчәкләр. Ичмаса, үз теләгең белән бер якка кушылсаң...Инде егерме яшь мина, аңла әткәй...

Мостафа агай тирән уйда дәшми торгач, әкрен генә:

—Инәгез кайда?—дип сорады.

—Тайфә карчыкларда...—диде теләмичә генә Госман.

—Бар, улым, Әхмәтсафа, алып кайт әле инәнне...

...Тайфә карчык өенен болдыр баскычына аяк басуга, Әхмәтсафаның колагына үги әнисенең еламсыраган тавышы ишетелде:

—Юк, Хәлфетдинкәем, уйлама да! Син китеп мин нишлим? Телисең икән, әйдә икәүләп җәһәннәм аръягына олагабыз. Ялгызымны гына калдырма,— дип өзгәләнә иде Шәмсия әнисе.

Хәлфетдин нидер быдырдый, аның сүзләре аңлашылмады.

Үги әни аны тыңлап та тормады, сулкылдап елап җибәрде:

—Ә мин...Нигә үзең турында гына уйлыйсың?..

Өйгә генә сыймыйча, тышка ук ишетелеп торган бу тартышның серен хәзер бөтен тирәнлеге белән чамалый иде инде Әхмәтсафа. Йортка үги әни килеп ике еллап чамасы үткәч, әтисе үзләренә хезмәтче егет алды. Ул—Тайфә карчыкның бик тә сүз тыңлаучан, акыллы һәм чибәр улы Хәлфетдин иде. Аны балалар да яратты, тора-бара шуны сизенде Әхмәтсафа—егетне үги әнисе дә үз итте, ахрысы.

Әтиләре кыш буе юньләп өйдә тормый, дала ягына тире-яры җыярга чыгып китә, өйдәге бөтен эш элек Гомәрханга өелеп кала иде. Соңгы елларда сәфәр йөрү куркыныч була башлады дип, аннан соң эшкә өйрәнә торсын дигән уй белән дә әтисе Гомәрханны да үзе белән юлга алып чыга башлады. Госман исә Оренбурда, Гомәр абзый кибетендә пыр тузып сәүдә эшенә өйрәнә.Кыскасы, өйдәге мал-туарны карау бер Шәмсиягә генә калганлыктан, Хәлфетдиннең хезмәтче булып килүенә иң нык сөенүче дә, әлбәттә, үги әнкәсе иде. Хәлфетдин дә тиз ияләште. Кайбер чакларда, әгәр малайлар тыңламый башласалар, үги әни аларны Хәлфетдингә әйтү белән генә куркытып тыя иде:

—Карагыз аны, малайлар, тагын сугышсагыз, белегез, Хәлфетдин абыегызга әйтеп, колагыгызны бордырам! Болай булса, әткәгез кайтканчы, өйне ишеп төшерәсез сез.—Үзе астан гына яратып Хәлфетдингә карап ала.—Әле әткәгез кайчан кайта...—Шәмсия әнинең тавышында әллә өмет, әллә өметсезлек чагылып китә. Хәлфетдин сәер генә тамак кырып куя.—Кайтып керсә дә өйдә тора алмый ул...—Бу сүзләрне ул Хәлфетдинне юатырга теләгәндәй әйтә.—Артын сәкегә терәргә өлгерми, Дәүли агай килеп җитә, тагын казакълар арасына барып, сөйләшеп кайткан, тире төяп җибәрергә көтеп кенә торалар, ди. «Дәүлинең, сүләшүен әйтерием,—ди Мостафа,—барсаң, ай буе тире җыелганын көтеп ятарга туры килә,»—дип, сукрана-сукрана тагын чыгып китә.

—Байларга ни, кеше генә булсын куалап йөрергә. Беләләр бит, Мостафа абзый китә икән, буш кул белән кайтмый,—дип сүзгә нокта куймакчы була Хәлфи.

—Өйдәгеләрнең нишләве, ничек көн итүе ике ятып бер төшенә дә керә микән, юкмы?! Ярый инде, акылына килеп, сине хезмәтче итеп алды...—Соңгы сүзне әйткәндә аның йөзе тулышып, алсуланып, үги инәй тагын да чибәрләнеп китә. Мондый сөйләшүләр башта Әхмәтсафа алдында булгаласа да, соңрак алар икесе генә, ниндидер үтә яшерен серләре бар кебек чыш-пышка күчә башладылар, яннарында Әхмәтсафа пәйда булса, сүзләре шундук өзелә, Хәлфетдин исә, май ашаган мәче шикелле, мыштым гына бу тирәдән сызу ягын карый иде.

Дөньялар болганып, яшьләрне көчләп армиягә ала башладылар. Үткән ел гаскәргә алынудан качып йөргән берничә егетне Сакмар буена чыгарып атып та киттеләр кызыллар. Бүген комиссар Усманов, күзен дә йоммый, янә дә дезертирлар табыла икән, судсыз-нисез атабыз дип куркытты. Госман шактый вакыт чормада качып ятты. Тик әллә бөтен җиргә җитә торган Әхмәтхан аның кайдалыгын белеп алып, «сер» итеп кенә өч яшьлек Бибиҗамалга әйтеп өлгергән. Берзаман Бибиҗамал дөнья яңгыратып үкерә башлады:

—Олабкай янына менгерегез! Олабкайга барам!— «Олабкай» дигәне —»олы абзыкай», ягъни Госман була инде.

Нихәл итәсең, кызый җиңде, абыйлары ярдәмендә чормага үрмәләп менә башлады. Госман сеңлесе өчен җанын ярып бирергә әзер, моны сабый күңеле тиз сизеп алды, аның янынан төшми дә башлады диярлек. Ул гына да түгел, берәр нәрсәгә ачуы килсә, бу түгәрәк йөзле, сары чәчле курчак кебек кызчык, абыйсын шаштырыр дәрәҗәгә җиткереп, чорманы тутырып дулый башлый иде:

—Әйтәм, әйтәм!.. Качып ятасың, урамдагы мылтыклы абыйларга әйтәм. Мине яратмасаң, кычкырам!

Госман, ахыр чиктә, түзә алмады, чормадан төшеп, таныш-белешләрдә кунып йөрде. Тик бу эш тагын да хәвефлерәк: үз өеңдә

дезертир качырып яткыруны беркем дә өнәп тормый. Әгәр көннәрнең берендә, кемнәрдер килеп, өйләрендә яшеренеп ятучы су сөлеге кебек егетне тапсалар, йорт хуҗасына ни-нәрсә буласын кем белә...Саклангланны саклармын дигән бит Ходай. Госманның хәле болай да мөшкелләнеп бара иде. Бүген исә Сакмар буенда язгы ташу ярга чыгарып аткан бүрәнәләрне җыеп мәшәләнгәндә, аны кызыллар килеп эләктерде.Ни булса шул булыр, исән калырга язса, үзем теләп, китәм кызыллар ягына дип, ныклы карарга килгән иде. Әмма үзе генә түгел.Ул чормада ятканда, Шәмсия белән Хәлфетдин арасында нидер булганын сизеп алган иде. Хәлфинен, кеше-кара күрмәгәндә, әрсезләнеп Шәмсиягә үрелгән чакларына да шаһит булды. Кулга алынганнарны каравыл йортына җыйдылар башта. Иң ахырдан Хәлфетдине дә китереп яптылар. Беркөнне аның мактанган кебек: «Сәндерәдә урын ясадым, эт белән килеп эзләсәләр дә тапмалы түгел,»— дип сөйләнгәнен ишетеп калган иде. Ходайның амин дигән чагына туры килмәгәндер, килеп капкан бит әнә. Моңа Госман сөенеп тә куйды. Аннан ис җыйгач, башкалар ишетмәслек итеп, Хәлфетдин белән ачыктан-ачык сөйләште. Хәлфетдин күтәрелеп бәрелмәкче иде дә, Госманның сабан тәгәрмәче кебек зур, түгәрәк йодрыгына, киң күкрәгенә, тәвәккәллекнең теге ягына чыккан карашын күреп, тиз суынды...

...Яшь хатын, Әхмәтсафаның тып итеп килеп керүен күреп, Хәлфидән читкәрәк тайпылды. Шулай да, үземнекен әйтеп бетереп калыйм дигәндәй, такылдап алды:

—Кире булсаң да булырсың икән,—диде ул, җан ачысы белән.—Бу шаукымнар үткәнче сәндерәңдә генә ятарсың. Курыкма, этем дә белмәс. Тайфә әби терелгәнче, ашарыңа үзем илтеп йөрермен. Шушы саташуыңны гына чыгарып ташла башыңнан.

Хәлфи астан Әхмәтсафага сөзеп карап алды.

—Тынычлан, сине эзләп килеп тә життеләр. Озакламый өйлә намазы...Хәзер үк китәм дигән кеше юк бит әле. Өйләдән соң гына, диләр...

## IV

Унтугызынчы елның язы үткән елгының нәкъ капма-каршысы булды. Апрель урталарында ук җир өлгереп, сукага чыктылар. Май урталарына Каргалы халкы чәчүләрне төгәлләп, күп эшләрен бетереп килә иде инде.

Бу ел сәүдә җәһәтеннән әллә-ни уңышлы булмады. Дәүләтъяр нәселе борынгыдан бирле казакъ яклары—Тургай суы буендагы далага сибелгән авыллардан тире-яры җыеп, Оренбур, җай чыккан башка шәһәр-калаларга илтеп тапшырып көн күрде. Шуңа күрә аларның нәсел кушаматы да «каеш» иде. Әлеге кәсеп белән соңгы дәвердә җиң сызганып Мостафа гына шөгыльләнде. Кәсеп артык төшемле түгел, әмма жирне туфан басмаса, казакъ ягында мал бетмәс, тотрыклы эш санала,тормышлары да кеше алдында бөтенләй ким-хур булырлык та түгел иде.

Ибе килсә, җәбе килми, Мостафа хатын рәхәтен генә күрә алмады. Маһинур унган, миһербанлы иде дә, көтмәгәндә вафат булды. Яшь хатыны Шәмсиягә никтер үзенең күңеле ятып бетми. Югыйсә, бөтен Тургай далаларын айкап чыксаң да, Сакмар буйларын инләп йөрсәң дә, ахыр чиктә, көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып ала торган бичә түгел. Шәмсиянең үз куенына килеп керүе Ходайның иң зур бүләге саналырга тиеш тә бит, юк, нәрсәдер тота Мостафаны. Ул аннан һаман тартына, ачылып бетә алмый, шуңа күрәдер инде, назга, иркәләүгә сусаган хатынга көткәнен бирә алмый иде. Ничек дип әйтергә, Мостафа әле ир уртасы кеше, куәт тә, дәрт тә житә юкса, әмма хатынны бөтен барлыгы белән үзенеке итеп тоя алмый. Ике арада ир белән хатын арасында гына була ала торган ышаныч юк. Ышаныч...Менә нәрсә житеп бетми иде Мостафага. Әгәр тормыш иткәндә бер-береңә, ышаныч юк икән, димәк, тормыш та

юк дигән сүз. Ни гаҗәп, Мостафаның торган саен үзенә карата суына баруына Шәмсия һич тә борчылмый кебек. Эчендә утлар дуласа да, сиздермәскә тырышуымы шунда.

Тора-бара шуны сизде Мостафа—ул өйдә чакта сүрән генә йөргән яшь хатын, ире сәфәргә җыена башласа, гел үзгәреп бетә. Йөзе яктыра, йөгерек адымнар белән кече өйдән олы өйгә яки киресенчә күчеп-чыгып йөрүләрендә, балалар белән сөйләшкәндә, Мостафа белән үзара мөгаләмәсендә дә пошамангa төшерерлек серлелек тоела иде. Андый чакта хатынның аңлый алмаудан гаҗиз калып, күңеленә әллә никадәр вәсвәсә тула. Бүген бичәсе тагын сәер холкын күрсәтеп алды. Тик бу юлы ир яшь хатынны аңлады кебек һәм, ни гаҗәп, шул минутта ук аңа җиңел булып китте. Шәмсия сугышта үлеп калган ире—Фәтхулласын оныта алмый, бичаракай. Күр, ничек өзгәләнә, ничекләр генә дә юатырга белмәссең. Дөресен әйткәндә, бу хисләр, шушындый ук кичерешләр Мостафага да ят түгел—Маһинуры кинәт күз алдына килеп, бәгырьләре киселеп куйган чаклар азмы әллә?

Уллары үсеп җиттеләр, таралып та баралар. Гомәрхан белән Госман кызыллар ягыннан сугышып йөриләр, исән генә була күрсеннәр берүк.Госман белән бергә яуга киткән Хәлфетдин озак та үтмәде,качып кайтты әнә. Үткер егет булып чыкты, шайтан.Моны аңа сер итеп кенә Тайфә карчык чишкән иде. Тик кайда качып ята торгандыр, анысын әйтә алмый Мостафа. Тирә-юньдә гаскәр мыж килеп йөри, аны үзендә хезмәтче итеп тоту турында уйларга да ярамый. Бәхетенә, Әхмәтсафа үсеп килә. Ундүрт яшь инде аңа, чын егеткә әйләнеп бара. Уртача гәүдәле, киң җилкәле, бөркет карашлы егет булачак ул. Чәчү чорында Мостафаның күп эшләргә кулы да тимәде хәтта.

Чәчүләр тәмамланыр көннәрдә Дәүли бай килеп керде. Дәүләтъяр нәселенә кагылышлы шәҗәрә агачының көчле ботакларыннан саналган кеше ул. Әхмәтсафаны казакъ далаларыннан мал куып алып кайтырга көнлекче итеп яллап китте.

—Эш сорап, тупсамның ишеген төшермиләр,—дигән иде ул.—Халыкка эш кирәк, берәү дә көнлекче ялларга атлыгып тормый...

—Аягың тәпердәмәсә, авызың чәпелдәми,ансы...Дөньяларның рәте китте шул. Үзем дә ай ярым казакъ арасында йөреп кайттым, үнәргән эшем булмады,—дип зарланып алды Мостафа.

—Дөньясы тынычланганны көтеп ятсаң, бөтенләй кәяләп бетәрсең. Сәүдә хәле шундый, Мостафа туган, өстәп тормасаң, гомер буе җыйганны бер җәйдә туздырып бетерергә була. Госманны әйтәм, әрәм иттең гаскәргә язып. Сәүдә эшенә кулы килешә иде. Гомәрхан абзыйның кибетенә кергән саен кызыгып чыга идем. Шөкер ди идем, Дәүләтъярныкылардан тагын бер төпле сәүдәгәр җитешеп килә ди торган идем. Кайтып керсә, эшләре җайлы барган берәр сәүдәгәрнең кызына өйләндереп тә җибәрсән!.

Мостафаның бу сүзләргә күңеле булды. Шулай да сер бирәсе килми:

—Һи-и, Дәүли абзый, тумаган колынның билен сындырып куймыйк тагын,—дигән булды.—Әле үзе ни дияр! Чәче сәүдәгәр кызыныкына бәйләнсә, сәүдәгәр кияве булыр...

—Алай димә, Мостафа!—дип кырт кисте Дәүли.—Нәселенне чүплисең килмәсә, егеткә тиңен табып бирергә кирәк. Үз тиңен таба алмаган кеше, иртәме, соңмы—үкенә ул. Тик ул вакытта терсәкне тешләргә соң була инде. Егет кешене озак буйдак йөртү дә килешми.Башлы-күзле булгач, тагын да иҗтиһад кылып тотыначак сәүдәгә. Һай-ли, иҗтиһад итмәсәң, булмый ул.

Мостафаның кәефе килеп, ипле тыңлап торуына инангач, үгезне мөгезеннән әләктерергә карар кылды:

—Әйтәм бит, халык бик килә эш сорап. «Ни бит, кем, туганкайлар,—мин әйтәм,—булмый, алдан ук вәгъдә иткән кешеләрем бар»,—дип, күбесен кире бора торам. Әхмәтсафаны алам көнлекчегә, каршы килмәсәң ...

Мостафа, күрәсең, уйланып озаграк торгандыр инде,монарчы

өлкәннәрнең сүзенә катышмый, сабыр гына тынлап торган Әхмәтсафа телгә килде:

—Барыйм, әткәй. Узган ел бер мәртәбә Актүбә ягыннан мал куыштым иң, эш рәтен беләм,— дигәч, каршы килмәде, түләү шартын килешеп, Дәүли белән кул сугыштылар.

Мостафаның исәбе буенча, Әхмәтсафа кичә өйгә кайтып керергә тиеш иде. Яңа көн туды, һаман күренми малай.Аның эче поша, бүген көн әллә ничек башланып китте шунда...Алмагачларына күз явын алырлык жете кызыл тасмалар бәйләп бетереп килгәндә, Мостафаның башыннан нинди генә уйлар чабышып үтәргә өлгермәде тагын. Менә шул чагында Шәмсия аны чәйгә чакырып чыкты да инде...

...Иртәнге чәйдән кузгалырга өлгермәделәр, өй ишеген киереп ачып Дәүли килеп керде. Керә-керешкә, кәефенең көр булуына ишарә, гөлдер-гөлдер килә башлады:

—Кара әле, дим, Мостафа туган, бу чәчби кызың кемгә охшап шулай тынгысыз, ә? Атны турыгызга туктатырга өлгермәдем, күктән яшен ташы китереп орды дип торам, синең кызың икән, арбага сикереп тә менде. Кай ара йокысыннан торган—кай ара урамга чыгып йөгергән!—Дәүли, йөзендәге елмаюын жыеп тормастан, шушы сүзләрдән соң гына кычкырып сәлам бирәсе итте—Әссәләмәгәләйкүм, Мостафа туган, бәрәкәтү вә рәхмәтуллаһ.—Ул арада сәкегә капчыктай гына авып төште,—Аллаһ тәгалә хәерле тереклек бирсен,— дип, дога кылырга тотынды.

Мостафа хәл-әхвәлләр сораша-сораша чынаякка чәй койган арада, Дәүли яңалыкларны тезеп тә чыкты.

—Шөкер, Мостафа туган. Әле кичә, караңгылар төшеп килгәндә, малларны алып кайтып житкерделәр жегетләр. Ну, Мостафа туган, Әхмәтсафаң чырыш икән, бер дә башкалардан калышмады. Бер сарыкны расхудка чыгармыйча, кайтып життеләр бит.—Аннан нигәдер мал куучыларны мактаудан тыела төшеп, сүзне икенчегә борды,—Һи-и, гел шул тирәдә кайнаштым үзем. Бала-чагага ышансаң, жүләр...Үзе юкның, күзе юк, Мостафа туган. Таныш казакълар да ярдәм итте. Юкса, кая мондый мәхшәрдә исән-имин кайтып житү. Менә генә бер жирдә сугыш кабынып китә, аны әйләнеп узасың, нәкъ каршыда туп гөрселдәргә тотына. Көтүне кая куарга белми аптыраган көннәр аз булмады.. Ничек итсәм иттем, тәки исән-имин кайтарып житкердем малларны. Акча, сәмән дим, күктән яумый. Сәфәргә кузгалыр алдыннан дус-ишләрдән бурычка жыйдым сәмәнне. Кичә кич, өйгә кайтып аугач та күзгә йокы керми, төне буе исәпләп чыктым. Йөрәктә кара сөлек утыра, Мостафа туган.Чыгым керемне басып китә.

Мостафаның, дөресен әйткәндә, Дәүлинең керем-чыгым дигән нәмәрсәсендә артык эше юк. Туган тиешле кешенең сәүдә эшләренә битараф булудан түгел, әлбәттә.Ул «брат братның көтү көткәненә рад» дип йөрүчеләрдән түгел.Кичә үк кайткач, Әхмәтсафа кайда икән? Шул уй борчый иде аны.

—Иртүк тордым да, тукта мин әйтәм, Мочтайга кереп чыгыйм...

Күз алдында үз исемен бозып сөйләшүне өнәмичә, Мостафа кашын жыерып, сынап Дәүлигә карап алды. Бу карт төлке нәрсәдер майтарырга азаплана иде үзенчә.

—Синең малай Гомәр абзыйларда кунам, дип китте, малларны урнаштыргач. Өйгә кайтып кергәнме, юкмы, белмим.—Хужаның карашыннан Әхмәтсафаның өйгә кайтып кермәвен чамалап, тагын да жанлана төште.— Маллар аек аръягында, касапчылар ягында калды,—дип сүзгә ачыклык кертеп алды.

—Арыгандыр инде, балакай...

—Арыган дип, алай артык ашыктырмадым мин аларны, үз көйләренә генә йөрттем...— Дәүли кесәсеннән акча янчыгын чыгарып яны белән Мостафага борылып утырды да, озаклап кәгазь акча кыштырдатырга

керәште. Анын битенә сыек алсулык йөгерде, мангаена тир бәреп чыкты. Санауны тәгәлләгәч, тәвәккәл кыяфәт белән Мостафага акча суздьг.

—Алып куй әле шуны, Мостафа туган. Әхмәтсафаның хезмәт хакы булыр бу. Бигайбә, менә саный башласаң, шулай бит ул, һич тә баштагы исәп барып чыкмый. Бераз киметергә туры килер инде, туганкай, авырга алма. Үзең дә әйткәнең бар, елларның бер дә рәте юк бит... Мостафа, ничарадан бичара төстә, акчаны алып, ашъяулык астына шудырды. Дәүли исә чынаяктагы чәен шопырдатып чөмереп бетерде һәм ничек тиз керсә, шулай чыгып та китте.

Мостафага шуннан соң гына аң керде. Дәүлигә Әхмәтсафа кайтып кергәнче исәп-хисапны өзеп кую яхшырак иде. Мостафага нәрсә сөйләсә, шул дөрес. Чын эшнең кыйммәтен мангай тирен түгеп, үзе эшләгән кеше генә белә бит.Борынгылардан калган сүз бар: йорт сатучы янына килсәң, иң элек сора—бу йортны үзе салып кергәнме, әллә әткәсе төзегән өйне сатарга җыенамы егет? Әткәсе төзегән йорт булса, курыкмыйча сөйләшергә була, егет йортны үзе житкерсә—якын да килмә, ана өйнең һәр чөенең ничек кагылуы мәгълүм, бәясен дә сорый беләчәк инде ул!

Киртә башына үрмәләп менгән Бибижамал, әткәсен күрүгә, сөенеченнән кош тоткандай:

—Әткәй, кара әле мин кайда мендем!—дип ике кулын да җибәреп, киртәгә аяк үрә басарга маташа башлады. Мостафа тиз генә барып, кызын киртәдән йолкып алды, аның җылы ак муенын үзенең чал кырә башлаган сакалы белән кытыклый-кытыклый, өйгә атлады. Кыз чырык-чырык көлә, Мостафага да рәхәт булып китте.

Кергәч, акчаны санап карады. Дәүли сөйләшкәннең яртысын калдырып чыгып киткән икән. Күз аллары караңгыланды. Баш миен кайнатырлык эссе кояш астында йөзләгән мал тоягы туздырган тузан өермәсен ярып, озын чыбыркысын шарт-шорт шартлата-шартлата әле бер якка, әле икенче якка юргалаган Әхмәтсафаның арыган йөзен, кояштан, жилдән кипшенеп, яргаланып беткән иреннәрен, кылган, шырпыдай каткан әрем сабакларын, чәнечкеле үләннәрне ерып йөреп җәрәхәтләнеп беткән, әрнүе үзәккә төшә торган кан саркып торган аяк үкчәләрен аермачык күргәндәй булды. Җанын тирәннән үк өтеп—яндырып үткән нәрсә күкрәгенә төер булып килеп утырды. Рәнжүе зиһенен томалардай булса да, күтәрелеп бәрелмәде тагын. Малайның исән-имин кайтып житүе зур куаныч иде. «Баш исән булсын, калганы табылыр»,—дип, үз-үзен юатып тәрәзәдән Оренбур ягына күз салды.Ул якларны күгелҗем рәшә сарып алган. Кисәк сискәнеп китте: Каргалыга илтүче юл буйлап нииндидер атлылар килүен шәйләп алды. Болай тәртипле төркем булып гаскәриләр генә йөри...

«Баш исән булсын ла»,—дип, кычкырып ук әйтте ул янә бер тапкыр. Әмма бу юлы әлеге сүзләр ачыну хисе белән йөрәк түреннән саркылып чыктылар. Дәүли саранланды-ы...Үзе өчен түгел, Әхмәтсафа өчен әрнеде аның йөрәге. Саранлыкка килгәндә, дөресен әйтсәк, аларның нәселенә хас нәрсә инде. Ни хәл итәсең, Мостафа үзе дә кысынкырак булырга тырыша иде сәүдә эшендә.

* * *

...Ун-унбиш көн ачык далада учак ягып, иптәшләре белән алмаш-тилмәш черем итеп төн үткәрүләр, кояш белән кузгалып, туктаусыз «һай-һу»лап мал куа-куа алга барулар тәмам йончыткан иде Әхмәтсафаны. Оренбурга житеп, малларны урнаштыргач, төнгә каршы Каргалыга кайтып тормаска булды. Гомәр абзыйларына ничек килеп кергәнен дә, урын салып биргәнче, инде йокы базарына китеп баруын да җүнләп хәтерләми бугай. Шул ятудан, кояш күтәрелгәнче тора алмый ятты. Әйтерсең, кемдер рәхимсез тукмап ташлаган—аяк-кулларны кыймылдатып булмый,

күз керфекләре эренләп ябышып беткән. Кузгалып китеп, ныклап юынгач кына кеше рәте керде аңа.

Гомәр абзый ашыкмый ашап утырган Әхмәтсафага үз итеп карап алды. Кай арада үсеп җиткән диген! Кулыннан эш килер егеткә охшый Мостафаның бу малае. Үсмернең хәленә кереп, дәшәсе итте:

—Вәйт, агай, кара чутырга әйләнгәнсең син, ә!?. Өеңә кайтып керсәң, ай-һай, таный алырлар микән? Әллә соң, мин әйтәм, берәр атна шәһәрдә калып, көч җыеп аласыңмы?

Әхмәтсафа, йөзендәге җитдилеген җуймый, башын чайкап куйды. Шушы аз гына хәрәкәттән дә муен тирәләре әрнеп сызлый башлады. Бөтен тәне җәрәхәттән торадыр сыман тоела иде аңа хәзер.

—Юк инде, Акабыкай (Ак абзыкай дигәне) өйгә кайтам,—диде ул иреннәрен сак кына кыймылдатып.

Гомәр абзый көлеп җибәрде.

—Каргалы кичә үк күчә башлаган диләр иде, тизрәк кайта күр, бөтенләй Сакмар артына күчеп бетмәсен.—Аннан җитдиләнә төште,—кайтырсың, Алла колы, кая ашыгасың? Ашаганнан соң бераз ял ит. Бездә сиңа ярашлы кием бетмәгәндер, өс-башыңны алыштыр, бөтенләй сәләмәгә әйләнгәнсең, җегет кеше шулай буламы? Онытма, без—Дәүләтъярныкылар! Кеше күзенә чәчрәп керергә яратмасак та, ил-көн алдында ким-хур булып йөрүне дә хупламыйбыз. Шөкер, нәселдә бер генә адәмнең дә юк-бар эш белән йөреп вакыт уздырганын, исемне дегеткә буяп йөргәнен күргән юк,—дип, Әхмәтсафаны олы якка әйдәде.—Кер әле монда. Әбүгалисина мәгарәсе булмаса да, ис китәрлек нәрсәләр бар монда,—дип, бүлмә диварына беркетеп ясалган китап киштәләренә күрсәтте.

Бүлмә салкынча, бераз караңгырак иде, эссе кояшта тилмереп, җек күргән тәннәр иркен сулыш алган кебек булды.

Гомәр абзый бүлмәгә ут элде, киштәдән бер китап алып, аның битләрен актаргалады да, Әхмәтсафага күтәрелеп карады:

—Гаяз әфәнде Исхакыйны беләсеңме?

Әхмәтсафа, нигәдер каушый төшеп, ләкин үз-үзенә ышанып җавап кайтарды:

—»Сөннәтче бабай», «Теләнче кызы» ...дигән нәсерләр язган кешеме?

Хуҗаның йөзе яктырып китте.

—Күз тимәсен, Мифтах хәлфә сезгә төпле белем биреп ята түгелме соң?! Әйе, Гаяз әфәнде әсәрләрен санап киттең син. Мишәр егете ул. Бер нәрсә уйлап, сүз әйтә икән, шул сүзеннән үлсә дә кайтмый инде. Холкы аркасында күпләргә ярап бетмәсә дә, милләтне алга, тәрәккыяткә җибәрү өчен аннан да күп эшләгән әдип юктыр...

—Тукай, Әмирхан, Ибраһимов, Рәмиев?..—дип, сораулы карашын әңгәмәдәшенә төбәде Әхмәтсафа.

—Исең китәр!—хисләнеп кулын өскә күтәрде Гомәр абзый.—Шушы сәләмә киемгә төренгән егет кисәге әдәбиятымызның бинниһая якты йолдызларын санап чыкты.—Син аларны укып беләсеңме, әллә болай, ишетепме дигәндәй?

Әхмәтсафа, кинәт калкынып куйды һәм көтелмәгән ачык тавыш белән шигырь укый башлады:

...Әрни-әрни ләгънәт әйтәм,
Тискәре бу дөньяга.
Мин мәхәббәт нуры дим, ул
Аерылу шәмен яга...

—Әфарин, балакай! Әйтеп бак, кем булыр әлеге тетрәткеч юлларны язган шагыйрь?

—Сәгыйть Рәмиев,—диде Әхмәтсафа. Ул инде үзен имтихан вакытындагы кебек хис итә иде. Җавап тотучы халәтенә керешеп, уй-фикерен бер нәрсәгә—әдәбияткә туплады. Яшереп торасы юк, ул нәсер, шигырь язучыларга сокланып бетә алмый, аларны гайре табигый адәми

затларга саный иде. Аның өчен иҗат, шагыйрь, әдип кебек төшенчәләр изге, ул әдәбиятка мөкиббән иде. Моны Гомәр сәүдәгәр дә сизеп алды, ахры. Сәгыйть Рәмиевнең шигырен ишеткәч, кош тоткандай, сөенеп, әңгәмәдәш табылуына канатланып, сүзен дәвам итте:

—Әйе, энем, әдәбият кешегә күп акыл бирә. Аны дөрес итеп кабул итә белергә кирәк. Менә Сәгыйть әфәнде адәм баласының дөнья белән каршылыкка керүен, уй-хисләрендә алдануын ни рәвешле ярып салган. Зиһеннең үзәгенә үтеп керә, җанны актарып ташлый бу шигырь юллары. Ә бит шагыйрь дөрес әйтә, алданабыз, һай, ничек кенә алданабыз әле гомер кичкәндә. Без алданабыз, ә дөнья бездән көлә генә. Чөнки аның мәңге какшамас кануннары бар. Иң үкенечлесе, алдануларданн сабак ала белмибез, сихерләнгән кебек, һаман бер үк тумгаккә киләбез дә абынабыз, киләбез дә абынабыз. Сабак ала белмәгән халыктан да кызганыч кавем юк. Җәбер-золымнан башы чыкмый аның. Әле генә син санап үткән әдипләребез милләтне менә шушы гарип халәттән чыгармак булып талпыналар да инде. Аларны белү, әсәрләрен уку, уку гына түгел, язганнарының асылына төшенү һәр татар баласына мәртәбә өсти. Аңлавымча, Мифтах хәлфә сезнең зиһеннәргә шуны салырга тырыша. Тик әдәбиятымыз зур безнең, син санап үткән әдипләрдән башка тагын бөекләремез бихисап. Бу хакта белү кирәк, житеп киләсен, нәкъ акыл җыя торган чагың. Мәрҗани хәзрәтләрен беләсенме?

—Ишеттем...

—Ишетү генә аз, һай, бик аз, энем. Мөселманга намаз фарыз булган кебек, татар шәкертенә Мәрҗани хәзрәтләрен белү фарыз. Тагын бер карт әдибебез бар —Риза Фәхретдин хәзрәтләре...

—«Сәлимә» дигән нәсерен укыдык,—диде Әхмәтсафа, куана төшеп. Аның белексезләнеп бер дә Гомәр абзыйсын рәнҗетәсе килми иде.

—Рәхмәт төшкере, димәк ки, Риза хәзрәт иҗаты белән азмы-күпме таныш инде син. Мин кайсы әдип белән сөйләшсәм дә, гел әйтә киләм: «Әдәбиятымызда Риза Фәхретдин хәзрәтләрен читкә алып куеп булмый.»—дим. Яңа әдәбият дип шаулап йөрүчеләр күп ул, ә Риза хәзрәт бер «Сәлимә» әсәрен генә язса да, мәңгелеккә кереп калыр иде тарихымызга. Менә ул кайда бөеклек, менә ул кайда милли рух, халык тормышын эченнән үк аңлау, аны шәкертләремезнең башына сеңдерерлек куәт белән яза алу. Укы, энем, Дәүләтъярныкыларга, әйтмәсәм дә булмады, гомер бакый «каеш» булып, касапчылык, тире-яры белән генә эш итәргә димәгән, гыйлем юлы белән дә бару фарыздыр...

* * *

Каргалыга кайтырга чыккач, Сакмар тавыннан төшеп, күпергә якынлашып килгәндә дә Әхмәтсафаның башында Гомәр абзыйның хикмәтле сүзләре бөтерелә иде. Алар җилкетә, алга әйди, үсендерә, шушы сүзләрдән соң яшәүнең мәгънәсен чамалаган сыман булды, күңел түреннән җанны ымсындырып ниндидер яктылык өермәсе үтте. Уйларына йотылып бетеп барганда, каршысына әллә каян гына Тайфә карчык килеп чыкты.

—Әхмәтсафа балакаем, син икәнсең әле. Таный алмыйча йөдәдем. Тау сыртында каршыга килүче бер гәүдә күренгәч тә, кем булыр, мин әйтәм, бу хәтле пошмый гына атлаучы. Хәзерге кешене белмәссең, карчык-корчык дип тормас, мин әйтәм, кулымдагы төенчеккә күзе кызып, Аллам сакласын, бер-бер хәл кылмагае дип, әрәмә арасына кереп, посып тордым.—Тайфә карчык, сер әйткәндәй, бөкрәя төшкән гәүдәсен як-якка боргалап, якын-тирәдә чит кеше юклыгына тәмам ышанып беткәч кенә, Әхмәтсафаның күлмәк җиненнән чак кына эләктереп, үзенә тарта төшеп, яңа хәбәр әйтеп салды:

—Балакаем, әле генә олы юлдан авылга мылтыклы гаскәр кереп калды. Кызыллар булса кирәк. Мин башта олы юлдан барадырыем,

аларны әрәмә арасына качып үткәреп җибәрдем дә, шушы кыска юлга төштем. Мәгәр, алда баручы башлыклары узган ел малайларны армиягә алып киткән адәмгә ошаганые. Хәлфетдин белән Госманны әйтәм. Гомеркәе булгач, Хәлфетдин Ташкентка барырга чыккан жирдән пуездан төшеп калган. Госманнан бер-бер хәбәр юкмы?

—Юк иде әле, Тайфә әби. Китте дә батты. Әткәй борчылып, төн йокылары йоклый алмый инде. Мин киткәч кенә хәбәр бирмәсә...

—Шәмсияне күргән ием, хәбәр-мазар булмады ди. Рәхмәт инде, Шәмсияне әйтәм, хәлне белеп кенә тора. Әле бүген дә аңа ышанып калдырдым өйне. Үзем Оренбурга, олы кызым янына барып кайтырмын дип юлга чыкканыем.—Тайфә карчык, сүзенең кереш өлеше тәмамлануга сөенгән кебек, тагын як-ягына җәһәт каранып алгач, күнелен кыздырып торган серен әйтеп ташлады,—Хәлфетдин абыеңны әйтәм, лапастагы сәндерәдә качып ята хәзер. Госман ясаган иде яшерен урын. Сандык инде, сандык. Булса да булыр икән шулай эшкә оста кеше. Әрәмнәр булмаса ярар иде балакай. Котларым очып тора, дус бар, дошман бар, берәрсе тишеп, каптырып алмасалар ярарые Хәлфетдинемне. Алай күргән-белгән кеше юк сыман әлегә. Безнең өй, шөкер, хәллерәк бәндәләрнең ихаталары арасына кысылып, күзгә-башка артык бәрелеп тормый. Аннан шул бәләкәй генә йортта имәндәй таза жегет качып ята дип кем уйлый инде,иеме, улым?.. Хәлфетдин үскәндә и шаярып җибәрә торганые, балакаем. Атасыз үскән малай тынгысыз була бит ул. Йөрәгем урынымнан куба торганые инде, саманнан корыштырган стенага ялгыш килеп бәрелеп, йортны ишеп төшерер дип. Алла саклады инде, исән була күрсен. «Сине сагынып кайттым, инәй, сагынуга түзеп булмый икән»,— ди, наныем. Госманны әйтәм, кайларда, нинди михнәтләр чигеп йөри торгандыр...

Әхмәтсафа, Тайфә карчыкның озакка сузыла башлаган сүзеннән ялкып, кузгалмакчы булган иде, карчык каударланып каршысына ук төште:

—Туктап тор, улым, бер генә сүзем калды. Хәлфетдинне әйтәм, сәндерәдә бер-бер эш белән мавыгып китмәсен дим. Балта сабы юнып азаплана иде. Зинһарлар өчен, кайтышлый сугылып кит, хәбәр сал, авылда солдатлар барын белеп торсын дим...

Тайфә карчыкның гозерен үтәргә вәгъдә биреп, Әхмәтсафа авыл ягына ашыкты.

Моннан бер ай чамасы элек Каргалы тирәсендә кызыллар белән колчаклар арасында көчле сугышлар булып алган иде. Бер карыйсың, авылга аклар килеп тула, икенче карасаң, өйдән-өйгә кереп ихатада ни бар, шуны туздырып авыл буйлап кызыл афәт уза. Алар бигрәк тә пырдымсыз кыландылар. Качкын, дезертир, яшеренеп ятучы ак солдатлар юкмы дигән булып, өйдән-өйгә йөриләр, күзләренә чалынган , берәр нәмәрсә күнеленә хуш килсә, хуҗага «эһ» дияргә ирек куймыйча, алып чыгып китәләр. Алар өчен Алла да юк, мулла да юк, исереп үзара бәйләнешәләр, хатын-кызларга ябышалар, кыскасы, авылда монарчы күрелмәгән мәхшәр ясадылар. Берничә кызыл солдат Әхмәтсафаларнын да өенә кереп, әйбер-караларын туздырып чыгып китте. Ул көннәрдә Әхмәтхан авырып, урын өстендә ята иде, бер кызылармееңц кылтайган кыяфәт белән, малай өстендәге юрганны штык белән генә алып чөймәкче иде, әллә чамалап бетермәде, әллә нияте үк явызлыкта булганмы, штык Әхмәтханның култык астына кадалган. Авыру малай куркудан дөнья бетереп кычкырып җибәрде:

—Әткәй, мине үтерәләр!..

Әхмәтханнын үзәк өзгеч кычкыруын ишетеп, ишек алдында калган солдатлар, Мостафа агайның үзеннән дә алда өйгә атылып керделәр. Өлкәнрәк солдат, командирлары булды микән, сәкедән идәнгә атылган малайның култык астыннан шаулап чаптырып аккан канны күргәч, үз-үзен белештермичә, бер гаепсез кыяфәттә торган жаһил коралдашынын

якасыннан эләктереп алды һәм ярсулы тавыш белән, малай ягына ым кагып:

—Синен эшенме бу?—дип ысылдады.

Командирның ачуын да, көчен дә бер юлы сизеп алган солдат, эшнең зурга китәргә мөмкин икәнлеген чамалап юхаланырга тотынды. Әйтерсең, бер ни дә булмаган, йөзенә җәелгән җүләр елмаюын баса төшеп, сөйләнгән булды.

—Мин дип...Ялгыш эләгеп китте инде, бала-чага аяк астында урала бит. Искәрмәстән сикереп торып, штыкка төртелде.

Ул арада өйгә әтиләре атылып килеп керде. Идәндә канга батып яткан Әхмәтханны күргәч, йөзенә мәет аклыгы йөгерде.

—Нишләттегез баланы, бәдбәхетләр!—дип ачыргаланды ул, яртылаш һушын җуйган Әхмәтхан тирәсендә ни кылырга белми бәргәләнеп. - Улыкаем, ни булды? Кайсыгыз кул сузды балага?!—дип кычкырды ул, курку-мазарны онытып, сүзсез калган солдатларга.

Командир, Мостафага игътибар итмәстән, үз солдатларына җикерде:

—Марш моннан! һәр өйдә шулай вакыт үткәрә башласагыз, кайчан фәрманны үтәп чыгарсыз? Марш, марш, алдагы өйләргә. Ә син,—ул Мостафага дәшә иде,—дөнья җимереп йөрмә, мондагы хәлне үзең бел дә, вәссәләм. Яшь ит тиз үрер, мә, бәйләштереп куй,—дип әллә кесәсеннән, әллә патрон сумкасыннан ак марля кисәге чыгарды. Янәшәсендә өнсез басып торучы Әхмәтсафага тоттырды.—Дулама абзый, өең тулы бала-чага, соңгы малаең түгел...—дип, ярым ачык ишектән бәреләсугыла тышка атылды.

Әхмәтхан күп кан югалтты ул чакта. Авырлык белән генә савыгып килә һәм Әхмәтсафа мал куарга ялланып чыгып киткәндә урын өстендә ятып калган иде.

Өйдә хәзер нишли торганнардыр. Госман абыйсыннан һаман хәбәр килмәве һич тә яхшы түгел шул. Җитмәсә, Хәлфетдине тагын...Искәрми калып, кызыллар кулына төшмәсә ярар иде. Инде Әхмәтсафа белә—шома сөйләсәләр дә, кызыллар килеп керсә, авылга бигрәк күп бәлаказа китерә. Алар авызыннан туктаусыз сибелгән ирек, җир бәхетле тормыш кебек сүзләрне тыңлый башлагач, әллә соң, чыннан да, бәхетле, матур тормышка чыгу өчен шундый аяусызлык, беркемне дә җәлләмәү, беркем белән дә хисаплашмау кирәк микән? Эссе дала кояшы астында мал куып, әлсерәп, хәлдән таеп егылыр чиккә җиткән чакларда, шундый уйлар да килгәли иде ана.

Әмма бер гөнаһсыз сабыйның канын коюны ул берничек тә аңлый да, аңлата да алмый иде.

...Ул авылга килеп кергәндә Яна мәчет тирәсенә халык җыйнала башлаган иде. Әүвәл өйләренә кереп чыгасы килсә дә, Тайфә карчыкның үтә пошаманга төшеп әйткән сүзләренең тәэсире зур булдымы, урам чатыннан күренеп торган акшарлы биек йортка, ягъни үзләренә табан түгел, тыкрык түренә посып утырган Тайфә карчык өенә борылды.

## V

Мөселман полкының Оренбурдагы беренче төне тыныч үтте.Иртәнге аштан соң, гаскәрләрнең ничек урнашуларын, кәефләре кай чамада икәнлекләрен белү максатыннан, Усманов полк биләмәләрен урап чыгарга уйлады. Киенеп бетәргә өлгермәде, кемдер сабырсызланып ишек шакыды һәм рөхсәт көтеп тормастан, каерылып ишек ачылды.Бусагада Еникеев күренде. Ул полкта культура-агарту эшләре өчен җаваплы. Кичә соң ятуына карамастан, таң тишегеннән аяк өстендә, шәһәрне саклаучы гаскәрләрнең үзәк штабында булырга өлгергән. Усманов үзенә буйсынган командирның аннан алда житешүенә бераз күңеле кителсә дә, сиздермәде. Мондагы командование Еникеевка артистлар белән концерт

кую эшләрен башлап җибәрергә фәрман бирергә өлгергән. Кинәшкә Усмановка йөгергән— монысы өчен комиссарның күңеле булды, әлбәттә. Оренбурны саклауны оештырган җирле хакимият әле полк командирлары белән танышып өлгермәде, кемнең кем икәнен белеп җиткерми, шуңа күрә, кичә төштән соң шәһәргә килеп кергән бер полк гаскәр аларны канатландырып җибәрсә дә, шундук үгезне мөгезеннән эләктерергә телиләр, килгән гаскәрләрне үз кул асларына алып, монда кем өстен, кемнең фәрманы белән эш итәргә тиешлеген аңлатырга маташалар, ахры.Кемнең кемгә буйсыну мәсьәләсе гаскәрләр өчен үтә мөһим һәм әгәр вакытында хәл итеп өлгермәсәләр, четерекле нәрсәгә әверелергә мөмкин иде. Мәсьәлә җитди, аны тиз арада хәл итәргә кирәк тә, тик Оренбурдагы иптәшләр үзләренчә уңай юл тапканнар: күзләренә кайсы командир чалына, нинди дә булса ашыгыч фәрман биреп, аның тиз арада үтәлүен таләп итәләр, кемнең кем икәнен белегез, янәсе. Теләсә ничек тупланган партизан отряды белән эш итәләрмени?! Юк инде, туганкайлар, каршыгызда регуляр кызыл гаскәр тора, тәртипкә күнә башларга туры киләчәк.

Усманов бу хәлнең буласын алдан чамалаганга, елмая төшеп, Нигъмәтне тынычландырырга кереште:

—Фәрман икән—фәрман, үтәрбез. Тик алар әйткәнчә ашыгып түгел. Артистларының программасы белән танышыйк, шунан соң аны полк штабы расларга тиеш. Беренче чыгыш артистлардан җаваплылык таләп итә. Кайда, кемнәр алдында беренче мәртәбә сәхнәгә чыгалар, тамашачы аларны ничек кабул итәчәк? Болары да мөһим. Үзәк штабка үзем барып, барлык мәсьәләләрне хәл итеп кайтырга туры килер. Бу хакта полк командиры да уйлана, штаб утырышында үз сүзен кистереп әйтәчәк дип уйлыйм. Оренбурдагы иптәшләрнең зиһеннәре таралып китте бугай. Кем нәрсә куша, шуны үтәп йөрергә, без монда йомышчы малайлар командасын алып килмәдек. Регуляр Кызыл Армия частьлары, ягъни Беренче татар укчы полкы килүен тизрәк төшенсәләр, яхшы булыр иде.

Әлеге сүзләр Нигъмәт Еникеевның күңеленә ятты. Усмановка карап, көр тавыш белән өстәп тә куйды:

—Үзем дә шушы карашта торам, иптәш комиссар.

—Яхшы. Алайса киттек. Иң элек штаб урнашкан вагонга кереп чыгыйк,—дип, Усманов эре-эре атлап чыгарга юнәлде. Нигъмәт бер читкә тайпылып, аңа юл бирде.

Полк командиры шәһәрне саклаучы үзәк штаб вәкилләре белән кичә очрашкан икән, мондагы вәзгыять хакында шактый хәбәрдар булып чыкты. Бу тирәләрдә күптән түгел генә колчакчылар белән сугышлар булып узган. Хәлиткеч бәрелеш Каргалы авылы тирәсендә булган. Сугыш сугыш инде, халык өчен дә эссез калмаган. Күп кан коелган, йорт-куралары зыян күрүчеләр дә байтак. Уйланырга мәҗбүр иткәне— авыл халкы кызыллар килүгә риза булмыйча, җыен үткәреп маташкан. Гаеп, билгеле, кызылларның үзендә. Дорфа кыланганар, талаганнар, туздырганнар, көчләгәннәр...Гаеплеләргә тиешле җәза бирәсе урынга, командирлар аларны яклау юлына баскан.Бу хәл халыкны отыры котыртып җибәргән. Хәзер шушы гөнаһны юуу мөселман полкы өстенә төшә икән. Актүбә ягына чигенгән колчакчылар теләсә кайчан Оренбурга яна һөҗүм башларга мөмкин. Тылда кызылларга ачулы, шәһәргә биргесез зур саланың булуы полк командирын борчуга салган иде. Өмет бар—полкта үткән яз Каргалы халкы алдында аз-маз гына булса да абруй казанып өлгергән Усмановның булуы, җитмәсә, полк белән бер бригада артистларның да килүе үзәк штаб җитәкчеләренең күңеленә дәрт өстәгән икән. Үзәк штаб киңәшен тотып, артистларга тәүге концертны Каргалы халкы алдында күрсәтергә фәрман бирелде.

Бригада солдатлар озатуында Каргалыга кузгалды. Үз араларында Усмановның булуына труппа кызлары сөенеп туя алмыйлар иде. Кызлар-

ның барысы да диярлек ана гашыйк, ул үзе дә жебеп йөри торганнардан түгел, кызларга караш ташлауга ук коңгырт күзләрендә шаян очкыннар уйнап ала. Ат өстендә ипле, көяз утыруларын гына күр син аның! Комиссарның кызып киткән чакларын күргән кызлар аннан бераз шүрлиләр, шулай булса да аның кайбер чакта бөтенләй малай-шалайга әверелә язып үзләре тирәсендә бөтерелә башлавын көтеп кенә торалар. Һәр репитициягә диярлек килеп, артист халкына хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тырышуыннан да разый иделәр. Шуна күрә дә Каргалыга килеп житкәнче колонна өстендә көлешү, шау-шу тынып тормады.

* * *

Әхмәтсафа авылга кайтып кергәч аруын онытты. Әнә бит—күнеләндә малайлык шаяруы уянып, Тайфә карчыкларга урам як капкасыннан түгел, ә читән белән лапас арасындагы аралыктан мәче кебек шылт иткән тавыш чыгармый үтте. Урам яктан керә калса, качып-посып йөри торгач Хәлфетдин шактый шомарган, «Кемнең кем икәнлеген аяк атлавыннан чирек чакрымнан таныйм,»—дип мактанганы да бар, бәлки Әхмәтсафаны танып та алыр иде. Таный калса, кызык булмый инде ул. Үсмернең күзе очлы— авыл эргәсендә сугыш барган куркыныч көннәрдә, үги әнкәсе Шәмсиянең яшертен генә Хәлфигә берничә мәртәбә ашарга илтеп кайтканын күреп калган иде. Бу хакта аннан башка беркем дә белмәде бугай, хәтта әтисе дә бихәбәр йөрде, ахрысы.

Әхмәтсафа да сак кына лапас эченә үтте. Салкынча лапас эченә кергән унайга шаяртасы килү теләге сүрелә төшеп, әкрен генә сызгырмакчы булды. «Ан бул, Хәлфи, без килдек,» имеш. Әмма ирен арасыннан ул көткән «фью-үү-ү» чыкмады. Хәтта үкенеп куйды: кипшегән ирене чатнап ярылып, әрнеп сызлый башлады. Ул барысына кул селтәп, лапас түренә, Госман абыйсы кайчандыр осталык белән, кеше күзенә чалынмаслык итеп ясаган сәндерә тарафына ике-өч адым атларга өлгермәде, шып туктап та калды. Сәндерә ягыннан тыенкы көлү, чыш-пыш тавышлар ишетелде. Үсмер сагаеп калды. Хәлфи үз-үзе белән сөйләшеп, көлеп жүләрләнеп ятмый торгандыр бит инде, ачуым бер килмәгәе? Булса да булыр, елга якын шулай кешедән кача-поса жан асрый бит ул. Чордашлары бер якка да кушылмый йөрделәр-йөрделәр дә, болай кан калтырап яшәгәнче, ни язган булса шул булыр дип, йә аклар, йә кызылларга кушылып, сугыш юлларына кереп югалдылар. Хәлфи бирешми, әнә: «Инәкәемне сагынып кайттым,»—диде дә, вәссәләм, яшеренеп ята бирә. Хәлфине кызганып куя иде Әхмәтсафа. Үткән ел, атылудан исән калгач, әллә сөенечтән, әллә һушларына килә алмый әнкәсе Тайфә карчыкның ай-ваена карамый, тәвәккәләгән иде ул. Башка егетләргә: «Кызылларга язылабыз, малай, болай йөрсәк, куяннар урынына чүкеп бетерәләр безне,»—дип кызып-кызып сөйләнеп торганын да ишеткән иде.Тик шунсы гажәп тоелды, Хәлфи бер сүз әйткән саен, дөрес сөйлим микән дигәндәй, Госманга күз салып ала иде...Үги инәй Шәмсия егетнең ниятен белгәч, Әхмәтсафа үз күзләре белән күрде, Хәлфинең муенына сарылып, канъяшь койды...

Сәндерәгә тар баскыч сөялеп куелган. Үсмер бер арата күтәрелмәде, монарчы колагына кермәгән сәер аһылдаулар ишетеп, тукталып калды. Юк, бер дә Хәлфинең ялгыз эшсезлектән, эч пошудан ыңгырашып, аһваһ килеп ятуына охшамаган бу. Татлы, тансык, көтеп алган рәхәт чигүгә тартым авазлар ишетелә монда. Ул сабырлыгы бетеп, бер тында өскә үрмәләп менде һәм тартма рәвешендә эшләнгән сәндерәнең читенә килеп сарылды...

Күз аллары караңгыланып китте. Күзенә чалынган күренештән Әхмәтсафа телдән язып тора иде. Калаклап куйганнар диярсең, кире сикереп кенә дә төшеп китә алмый, сәндерәгә менеп үк тә житә алмый. Тартма читенә ябышты да калды. Сәндерәдә үги әнкәсең һәм Хәлфине

шәйләп алды ул. Шәмсия шулай кисәк пәйдә булып, үзләре өстенә капланган кара чутыр кеше затын күреп, өстендә яткан Хәлфине чөеп кенә җибәрде. Әхмәтсафаның кулына үги әнкәнең шәрә боты тиеп китте, битен ялмап алган итәк җилен тоеп алды. Хатын «аһ» итәргә генә өлгерде, нидидер көч аны үсмер аша биеккә үк чөеп җибәрде дә, тагын бер аһылдап алган арада, лапас эченә дөбердәп килеп тә төште. Җилләнеп, шашып урыныннан сикереп торган шыр шәрә Хәлфетдин, аптыраудан бөтенләй кыяфәтсез калган бәндәдә Әхмәтсафа чалымнарын шәйләп, селтәнеп торып үсмернең күкрәгенә китереп төртте. Әхмәтсафа түбәнгә очты. Ул исен җыеп, мәрәләп аягына күтәрелгән арада, кай арада күлмәкыштан киеп өлгергән диген, шаулап Хәлфи сикереп төште һәм тәмам аңгыраеп калган Шәмсияне күтәреп торгызды:

—Авыртмадымы, җаным?.. Ник лапас келәсен элеп кермәдең инде?— диде ул тонык тавыш белән.—Сикерәләр димени. Кем дип белдең, ул хәтле...—ул ачу белән Әхмәтсафаның инсәсеннән эләктереп алды. Үсмернең күлмәге аерылып чыкты. Хәлфи еламсыраган тавыш белән аңа укталды:

—Ни калган сиңа монда? Нәрсә дип йөрисең? Болай да кешелегем калмады...Хәзер нәрсә була инде? Йә?

Нәкъ шушындый ук сораулар үги инәйне дә газаплый иде, ахры, ул чайкала-чайкала түргә табан берничә адым атлады һәм лапас почмагына башын төртеп үкси башлады.

—Бар икән күрәселәр...Адәм хуры булдым би-ит. Язга чыккач ук әйттем мин сиңа, китик, күзебез кай якка карый, шул якка чыгып китик, дип әйттем...Үги балалар багып кем рәхәт күргән?..— Хатын кайчандыр Хәлфи белән булып алган бәхәс-сөйләшүләрен исенә төшереп такмаклый иде.

Ярым караңгы лапас эчендә дә Хәлфинең тирләгән, кызарган йөзен аермачык күрде Әхмәтсафа. Егетнең исә үз хәле хәл. Кызганыч итеп бер тын хатын ягына карап торгач, авыр сулап телгә килде. Егет һушлы, бу очракта иң беренче хатынны акылына китерергә кирәк иде. Әкрен генә сүз башлады:

—Кирәкми, Шәмсия, юкка яшь коймa. Әхмәтсафа малай-шалай түгел, барсын да аңлый. Шулай бит, энекәш!—Ул нидидер кыргый, ярсулы караш белән үсмергә төбәлде. Әлеге караштa: «Әгәр монда күргәннәрне кемгә дә булса житкерсәң...»— дигән янаулы мәгънә ярылып ята иде. Егет хәтәр җилләнеп тагын Әхмәтсафага ябырылды. Үсмер исә һич кенә лапастан чыгып таю җаен таба алмый, Хәлфинең киң күкрәге ишекне томалап торган кебек.

Шәмсия эшнең тагын да аянычрак борылыш аласын сизеп, кисәк хәрәкәт ясап итәген тарткалап алды һәм әчке бер ярсу белән Хәлфигә дәште:

—Тиясе булма! Барысына да мин үзем гаепле. Мине ни эшләтсәң дә эшләт, тик аңа кул күтәрмә!

Хәлфи башын сәер чайкап, ишек яныннан читкә тартылды.

Шәмсия тагын «аһ»ылдап алды.

—Кабыргам сынды бугай...—диде ул, үкенүле тавыш белән.— Сәндерәдән егылып кына төштем бит. Исәр димә инде мине. Күрәчәгем булгандыр, бүген бер дә аягым тартмаган иде...

Бу сүзләрдән Әхмәтсафа шуны аңлап алды: димәк, үги инәй монда башка көннәрдә дә булгалый икән. Ул әле һаман, берни аңламаган сабый сыман, башында бөтерелгән сораулардан гаҗиз калып тора иде. Ни калган аңа монда, нәрсә эшләп йөри ул Хәлфи янында? Хәлфиен әйтерим, ник җенләнә ул кадәрле?..

Хатын исә вәзгыятьне үз кулына алып, хәлне бераз йомшартырга тели иде. Әхмәтсафаның күңелен табарга теләгәндәй, сөйләнә бирде:

—Кинәт баш очымда кара чутыр бер нәмә күренгәч котым очты. Җен дип торам. Болай да куркып яткан...кешегә сон...—Ул тынычланып

житә алмый әле. Теленә ни килә, шуны сөйләп, эшне бозып кую ихтималын сизеп алды. Ипләп кенә сүзне башка якка бора башлады.— Коймак пешергән ием. Дәүли абзый : «Әхмәтсафа бүген кайта,»—дип кереп әйткәч. Хәлфетдин абыена да илтеп кайтыйм, мин әйтәм. Кайчаннан бирле жылы аш күрмәгән кеше бит.

Хәлфетдиннең дә йөзе яктыра төште. Һи-и Шәмсия, хәйләкәр хатын! Борчакны пешерә болай булгач.

—Ни булган соң әле монда, әйеме үскәнем? Хәлфетдин белән сөйләшеп...утырган жирдән, искә-санга алмый торганда килеп чыктың бит. Кеше күрмәсен дип, Хәлфетдин мине үз янына суырып кына алды.

—Ыгы-ы...—Хәлфетдин сөенеп көлеп куйды.—Шулай булды инде. Куркыта бит инде. Бу хәлләрне оныт, Әхмәтсафа энекәш. Ни күрсәң шуны дөньяга сибеп йөрү егетлек түгел ул...

—Юк инде, нишләп кешегә сөйләп йөрсен!—дип, юхаланып алды Шәмсия.—Балалар арасында иң акыллысы, иң яратканым шушы Әхмәтсафа. Төшкән көннәремдә, өйдәге чисталык, тәртипкә исем киткән иде. Өйне жыештырып, карап торучы—ул булган икән.

Үги инәй, кабыргасы авыртуын да онытып, сөйли дә сөйли. Ничек тә Әхмәтсафаның күңелен күрергә тырышуы үзенчә.

Хәлфи тәмам тынычланды дияргә була.

—Шәп егет булып үсә, энекәш,—диде ул баштагы дорфалыгы өчен гафу үтенгәндәй.—Әле өенә кайтып кергәнме, юкмы— минем хәлне белешергә килеп житкән. Түлке, энекәш, болай тавыш-тынсыз, мәче кебек өскә килеп кермә бүтән. Ни булмас дисең?..

—Кайчан кайтып кердең соң?—дип төчеләнүен дәвам итте Шәмсия.— Өйгә кердеңме, әткән өйдәме?

Әткәсен телгә алгач, Хәлфетдин, бөрешеп калды. Хәлфи белән Шәмсиянең көтмәгәндә калган кыен хәлдән чыгарга маташып әртистләнеп торулары күңел болгаткыч тәэсир ясый иде. Шушы яшь хатынга ышанып йөргән әткәсенең зарлы карашын күргән кебек булды. Шушындый авыр, аңлаешсыз заманда көткән дөньясын пыран-заран китермәскә тырышып йөрүче әткәсе, миһербанлы, нечкә күңелле әткәсе кызганыч, бик кызганыч тоелды аңа.

Үги инәй, кулын күкрәк тирәсеннән алмый, тагын бер мәртәбә Хәлфигә яндыргыч караш ташлады:

—Ишетсең колагың, тырнак очы белән чиртәсе булма Әхмәтсафага!— диде ул һәм жавап көтмәстән, лапас эченнән чыгып йөгерде.

Шәмсия чыгып киткәч, Хәлфетдин бөтенләй басынкыланып калды. Әхмәтсафа гәүдәсе базык булса да, көч-куат ташып тора. Хәлфетдиннең исә кайчаннан сәндерәдән төшкәне юк. Эшсезлектән, хәрәкәтсезлектән тәне сизерәп бара. Үсмер алдында бая харап кыланган булса да, бергә-бер чыкканда Әхмәтсафа тиз генә бирешердәй күренми. Нәкъ шуны искәрткәндәй, Әхмәтсафа артык коелып төшмичә генә сүз башлап азаплана әнә:

—Кызыллар килгән авылга. Яңа мәчет тирәсендә кайнашалар. Шуны әйтеп китим дигән идем дә...

Хәлфи сагаеп калды.

—Ни эшләргә соң миңа, энекәш? Бала-чага түгел икәнеңне беләм, дөресен әйтәм, Шәмсия белән...

Әхмәтсафа, жүләр сатма, дигәндәй, кинәт алга тартылды.

—Беләбез!—диде ул нәфрәт белән. Госман абый да белә...Бу хакта онытасы килә иде. Сез һаман хыянәт юлында икәнсез.

—Миңа бит, аралар ничек булып бетте...диде уфтанып Хәлфи.

—Имансыз булдың, Хәлфи.—Үсмернең бу жирәнгеч затка абый дип дәшәсе килмәде.—Икегез дә,—дип тә өстәп куйды.—Әткәй кызганыч...Сез—аның намусын таптаган хайваннар.—Әхмәтсафа торган саен кыза барып, чын-чынлап һөжүмгә күчте.—Ни кыланганыгызны әткәй белеп алса, икегезне дә балта белән тураклап өячәк!

Хәлфи аклануга күчте:

—Мостафа абзый юаш күренә шул. Шәмсия шуңа күрә ашкынды да инде. Ничек булгандыр, үзем дә сизми калдым, энекәш, шул хатын тәки аздырды бит.

Хәлфинең үзен гөнаһсыз итеп, бар гаепне үги әнкәсе өстенә өяргә маташуын тыңлап торуы җирәнгеч иде. Әхмәтсафа өздереп, кире уйламаслык итеп, соңгы сүзен әйтте:

—Бүген үк кит син! Авылны пычратып йөрмә моннан соң да. Син эшләгән кабахәтлекне иң соңгы адәм актыгы да эшләми.

—Кая китәргә?—Әхмәтсафаның болай усаллануыннан Хәлфи гел аптырашта калган иде.—Кая китим мин, ә?

—Һич тә булмаса, әнә кызылларга ияреп кит. Берәр җиргә барып чыгарсыз әле.

Әхмәтсафа сүзем бетте дигәндәй, борылды да лапастан чыгып китте. Ишек алдында яп-якты, дөньяны кояш яндыра иде.

Хәлфетдин шул көннән авылдан юкка чыкты. Аның кая киткәнен беркем дә белмәде.

* * *

Бер ел буе Госманнан хат-хәбәр көтте Мостафа. Узган яз улының өзек-төтек әйтелгән сүзләреннән кызылларга язылып, яуга китәргә җыенуын белгәч, атай кешенең миен мең төрле уй, мең төрле сорау яндырып үткән иде. Каршы килеп нишли ала, хуплап-үсендереп тә тора алмый.Гомәр абзыйның гел кабатлый торган сүзе бар: «Әйбер затлырак булган саен аны югалту куркынычы да күбрәк була. Кеше дә шулай.»—ди торган иде ул. Госман зиһенле, тәүфыйклы, игелекле бала иде, нүжәли шулай суга төшкән кебек кенә юкка чыгар? Ачыта, Госманны уйласа бик ачыта йөрәге Мостафаның. «Юк!»—дип, кистереп әйтәсе калган да, булдыра алмады шул. Адәм баласы әнә шул, вакытында, кирәк чагында юк дип әйтә белсә, күп бәлаләрдән котылып калыр иде дә... Безнең халык арба тәгәрмәче күчәреннән чыкмыйча, каза киләсен чамалап өлгерә алмый. Югыйсә ара-тирә күчәр башындагы чәкүшкәгә күз салыштыргалап кына бару кирәк тә соң. Күрәкарау дими ни дисең. Менә хәзер җир тырмап еласаң да, Госманны кайтарып кертеп булмый өйгә. Җәл егет, җәл. Исән генә була күрсен. Кемнең кадерлесе булсын ул анда? Кызыллар да шул, чынны ялганга, ялганны чынга авыштырып кына йөриләр, ахыры. Элек Рәсәйдә кешенең кадере юк иде, кызылларның да кеше кадерен белүләре шикле. Күп нәрсәнең беркайчан да кадере булмый. Рәсәйдә нәрсә күп? Кеше, әлбәттә! Иң кадерсезе дә кеше җаны, кеше гомере булачак, димәк. Кол тәхеткә менсә, ил ләхеткә керер дигәннәр.

Бүген Каргалыга ниндидер гаскәриләр килүен күреп алгач, күңелендә яшерен өмет чаткысы сызылып үтте. Иртүк күнеле урыныннан купты. Сәбәпчесе—ап-ак чәчкәгә төрелгән алмагачлар булса да, күрәсең, бу алгысынуның тагын бер хикмәте бардыр. Сәбәпсез җил дә исми, ди китап. Әллә нинди ятышсыз адымнар белән кайтып кергән хатыны Шәмсиягә артык игътибар итмәскә тырышты ул. Иртән яшь аралаш: «Фәтхулла сугышка киткән елны да...» диеп, үкси-үкси ишек алдына чыгып китүен исенә төшереп, йөрәге кукрәк читлеген умырып атардай булып талпынып алган иде. Аның әле һаман урынына утырып бетә алганы юк.

Нинди гаскәр керде микән авылга? Анысы кызыллар булуына иманы камил. Зур эшләр майтармакчылар бугай, соңгы араларда авылга еш киләләр, халыкны җыеп, митинг ясап яңа хөкүмәтнең ярлы-ябагайга бүләк итәчәк бәхетле көннәре турында гәп куерталар. Хәлле кешеләргә ни-нәрсә күрсәтер микән бу хөкүмәт? Тәхетне ныклап үз кулларында тота башлагач күренер инде анысы. Бик тә тәхеткә хуҗа булып аласы килгән кемсә хакында кемдер әйткән: тәхетне төлке кебек эләктереп алды, тәхеттә бүре сыман кыланды, ахыр чиктә, эт үлеме белән үлде,

дигән. Бәлшәвикләр шулайрак кыланалар менә.

Мостафа тагын үткән ел, Госман белән аерылышкан мәлдә ул гел бер сүзне тәкрарлады:

—Ашыкмыйсынмы, улым, ашыкмыйсынмы?

Госман башын түбән иеп, салынып төшкән кулларын кая куярга белми, әле кушырып, әле сәер генә угалаштырып, бу адымны үзенчә нигезләп азапланган иде:

—Булмый, болай, әткәй. Яшәү түгел, җәһәннәмгә әйләнде тормыш. Качкын хәлен аңлый торгансыңдыр, яхшылыкка алып бармый икән. Башта да җүнле уй юк. Хәл итәргә кирәк...

Мостафа улының яшь тибеп чыккан күзләренә карап, тирән сулыш алды да, фатыйхасын бирде:

—Хәерле булсын. Бер син генә түгел инде, балакай. Аллаһ ташламасын, шул гына...

...Авыр сөйрәлеп Әхмәтсафа кайтып керде. Ул нигәдер бик күңелсез иде. Нигәдер күлмәген кулына урап тоткан. Аның мондый төшенке кыяфәттә кайтуын Мостафа артык арганнан күрде, ял итсен, хәл алсын дип, борчымаска булды. Башка вакыт булса, Мостафа улыннан кайсы якларга барып чыгуларын, уртак танышлардан кемнәрне очратуын, ул якларда нинди хәбәрләр ишетүен тәфсилләп сораштырыр иде, бүген аңа вакыт табылмады. Әхмәтсафа көттереп тормады, авылга кызыллар килүен, араларында үткән ел Госман абыйсын гаскәргә яздырып алып киткән Усманов дигән комиссарның да булуын хәбәр итте. Моны ишеткәч, Мостафа каударланып чыгып китте. Шәмсия берни булмагандай, Әхмәтсафаны чәйләп алырга чакырды. Үсмер күзенең агы белән үги әнкәсенә карап алды да, әткәсе артыннан чыгып йөгерде.

Әткәсе кай арада Яна мәчет янына килеп житкән диген: Усмановны эзләп тапкан, монарчы эчен тырмап торган сорауларын да бирергә өлгергән икән. Усманов әткәсен тынычландырырга тырыша. Үткән ел хәлләр шәптән булмаган икән, Каргалы егетләре, аннан тормаган сәбәпләр аркасында, төрле фронтларга озатылганнар. Госманны яхшы хәтерли комиссар.

—Кирәк чакта ипле, кирәк чакта тәвәккәл иде улыгыз. Акыллы егет, тиз генә юкка чыкмас. Хәбәре килер, сабыр ит инде, абзый,—диде ул гаепле сыман, күзен аска төбәп.

Гаеп дип әйтерлеге шул—ул Оренбурдан киткәч, Мәскәүгә барып татар-мөселман укчы бригадасы төзү артынан йөргән, шул чагында күп егетләрне Көньяк фронтка озатып өлгергәннәр. Госман да шунда эләккән булырга тиеш. Инде бригада төзелеп бетеп килә икән. Үткән елдагы кебек, егетләрне өстенә солдат киеме кигән унайга, кулына винтовка тоттырып, сумкасына бер уч патрон салып ут эченә кертеп җибәрү булмаячак, дип ышандыра комиссар бүген кызыл гаскәргә язылырга ниятләгән яшьләргә. Әхмәтсафа күзе белән Хәлфетдинне эзләде. Яшьләр арасында Хәлфи юк иде.

Үз теләге белән язылучыларны Усманов нигәдер: «Гаскәргә «күңелле» булып язылучылар»,—диде. «Нинди «күңелле» булсын инде алар?»—дип үз-үзенә сорау бирде Мостафа. Аптыраганнан язылa яшьләр, башны алып кая олагырга белмәгәннән. Әмма жанга ятышлы булганы шул: комиссар кат-кат әйтте, яшьләр сугыш һөнәренә өйрәнми торып, окопларга җибәрелмәячәк! Башта Самарага, аннан бәлки Казанга ук, әле төзелеп бетмәгән I нче татар-мөселман укчы бригадасы карамагына китәчәкләрен аңлатты. Комиссарның ипле сөйләшүенә егетләрнең янәшәсендә торган Мостафаның күңеле булды. Әйтерсең, әлеге егетләр арасында аның Госманы да бар...

—Берүк, шулай, син сөйләгәнчә булсын инде, туган. Яп-яшь егетләрне мылтык та тота белмәгән килеш яуга җибәреп, аларны чебен урынына кырдырудан ни файда хөкүмәткә?—дип аның сүзен җөпләп куйды.—Дошман дигәнең дә акылсыз түгел, кемнәр белән алышканын белеп керә яуга.

—Дөрес, абзый. Дошман белекле, зиһенле икән, безгә дә ахмак булу ярамый. Дошман көчле икән, без тагын да көчлерәк булырга тиешбез. Башында акылы булган кеше дошманыннан күп акыл җыя ул.

Усманов, гади авыл агаеның шулай үзен җөпләп торуына кәефе килеп, кулын-кулга «чалт» итеп сугып куйды. Аның күзендә яшьлек очкыннары уйнаклап алды.

—Мин яшь совет властен яклап, байтак сугышларда катнаштым,—дип мөрәҗәгать итте ул егетләргә.—Сез әле тәвәккәлләргә генә җыенасыз. Дөрес эшлисез! Ахыр чиктә, барыбыз да бергә, эшче-крестьян илендә яшәячәкбез. Үзең корал тотып яклыйсың икән, дәүләт ун мәртәбә кадерлерәк булыр. Бергә булыйк, туганнар! Татар-мөселман исеменә тап төшермик!

Усманов үз телмәреннән үзе хисләнеп китте. Аны тынлап, яктырып басып торган Мостафаның кулын җәһәт кенә эләктереп алды һәм нык кына кысып куйды. Андагы дәрт, кайнарлык, үз-үзенә ышануны кул кысуыннан да чамаларга була иде.

—Тагын сәгать ярымнан безнең артистлар авыл халкына концерт куялар,—дип дәвам итте Усманов.—Менә сәхнәне генә әзерләп бетерсеннәр.—Ул яңа мәчет каршындагы мәйданның каршы ягына төртеп күрсәтте. Анда гаскәриләр кайнаша, үзләренчә сәхнә ясап маташалар иде. Чаршау элеп куйганнар, аның артында кемнәрдер мәш киләләр. Әхмәт-сафаның күнелен кыбырсытып куйганы шул, чаршау артыннан хәрби киемдәге ике кыз чыгып, шул тирәгә җыелган бала-чагалар янына килеп, нидер сорашкан булып кыландылар. Бүгенге концерт өчен нидер кирәк иде, ахры. Яшь кызларның чытлыкланып кына йөрүләре булдымы бу—Әхмәтсафага караңгы, әмма зифа гәүдәләренә искиткеч ятышлы иде солдат киеме. Кызларның да гаскәриләр белән йөрүләреннән таң калган күнелен иләс уйлар җилкендерде. Яше житсә, бүген үк кызылларга язылып гаскәргә китәргә әзер иде ул. Ярый әле Хәлфи күренми, ана харам мондый кызлар белән бер сафта йөрү. Үзе дә сизми калды, кай арада әткәсе янәшәсенә килеп баскандыр.

Усманов, Әхмәтсафаны күреп алгач, аның инсәсенә кулын салып, шаяртып куйды:

—Мин бу егетне беләм бит! Үткән ел Хәйбри отряды эләктереп алган егетләрне үлемнән йолып калган иде.— Усманов авыр сулап, каядыр, дала якларына карап, сагышланып өстәп куйды,—Хәйбри юк инде. Сезнең авылдан киткән көнне үк далага, Дутовчыларга каршы чыгып китте үз отряды белән. Сабыр итәргә, өстәмә көчләр килгәнне көтәргә кушкан идек, тынламады. Партизанлык көчле иде шул анда, шул очрашу соңгысы булды...Дутовчылар белән беренче бәрелештә үк казаклар тураклап бетергән үзләрен. Каргалы егетләренең бәхете булгандыр, шушы егет килеп житеп, хәбәр салмаган булса...

Әхмәтсафа, комиссарның сүзләреннән тетрәнеп китте:

—Каргалыдан да егетләр кушылган иде бит ана,— диде ул ачынып.— Госман абый да кушылмаса... —Ул Усманов белән әткәсенең сөйләшкән сүзләрен ишетеп өлгермәгән иде.

—Алар исән-сау калдылар ул чакта,—диде Усманов үсмерне тынычландырып. —Егетләрне Хәйбригә бирмәдем. Яшермим, тарткалашып караган иде. Егетләрне Казанга исән-сау илтеп житкергән идем лә...

Әхмәтсафаның тезләренә Бибижамал килеп сарылды.

—Китмә, абыкай, жибәрмим,—дип үзенчә такылдады дүрт яшьлек кызчык,—Китсән, мин дә елыйм, инәй дә елый...—Ул узган ел Госман абыйсын озатып калуын онытмаган икән, бүген Әхмәтсафа абыйсы гаскәргә китә дип үрсәләнә иде.

Әхмәтсафа, көлмәк итәге белән сенлесенең борын тирәсен җыештырып алды да, Бибижамалны кулына күтәреп, әткәсенә карады:

—Кайтыйк инде, әткәй. Госман абыйны белгән-күргән кешеләр юк икән монда.

— Тамаша карарга килегез,—дип, Усманов артистлар ягына атлады.

...Әхмәтсафа Яна мәчет янына килеп җиткәндә концерт башланган иде инде. Матур тавышлы бер ир-егет, сүз дә юк, артисттыр, кайнарланып декламация сөйли:

...Җаек суы—яман су,
Ага бик шәп һәм ярсу;
Себереп түк дошманны,
әй булмасын ямансу.
аек суы бик тирән,
Яз җыела кар суы,
Дошман шунда себерелсә,
Басылыр йөрәк ярсуы.

Шунсы кызык, бу шигырьне укыганы бар иде Әхмәтсафаның. Кызыллар калдырып иткән гәзиттән иде бугай. Авторын да белә—Галиәсгар Камал. Артистның шартка яраклаштырып, шигырьне укыганда «Идел» сүзе урынына «аек» дип алыштыруын да чамалады. Әхмәтсафаның хәтере шәп, шигырь «Актык йомрык» дип атала иде.

Сәхнә тирәсен яшьләр, бала-чага сарып алган, Әхмәтсафа аптырабрак тора иде, аның каршысына йөзенә шатлык хисләре йөгергән Усманов килеп басты.

—Нәрсә, егеткәем, урын да калмаганмы?—диде ул шат тавыш белән.—Халык җыелыр микән дигән шик бар иде күңелдә, шөкер, килгәннәр бит,—диде ул үсмергә күптәнге танышы белән сөйләшкән кебек—Шик күңелгә вәсвәсә сала бит ул. Вәсвәсәле күңелгә исә шайтан керер оялый.—Ул шулай сөйләнә-сөйләнә Әхмәтсафаны кулыннан җитәкләп диярлек сәхнә алдына алып китте.—Сиңа гына урын табарбыз, ни дисәң дә син инде безгә булышлык күрсәтеп өлгергән егет. Гаскәргә «күңелле» булып язылучыларга берничә урын әзерләдек, шунда утырып карарсың концертны.

Үсмер егет үзенә булган игътибардан кинәт кыюсызланып, комиссарның чакыруын кабул итмәгәндәй, читкәрәк каерды.

Усманов йөзендәге елмаюны сүрелтми, йомшак, тик боеручан тавыш белән Әхмәтсафаны туктатты:

—Нилектән болай халыктан шүрлисең? Онытмасаң, узган ел сине күтәреп алырдай кыланды Каргалы халкы. Синнән дә хөрмәтле кеше юк иде авылдашларың алдында.

Шунда гына Усманов үсмернең берүзе булмавын искәреп алды. Аның кулына асылынган Бибиҗамалны күреп, көләсе итте:

—Нинди чибәр кыз ияртеп йөрисең?—дип сорады ул, кызчыкның чибәрлегенә соклануын яшермичә.

—Сеңлем,—диде Әхмәтсафа, сүзне тизрәк түгәрәклисе килеп. Һаман да кешеләрнең игътибар үзәгендә булып тору унайсыз иде аңа. Якынтирәгә җыелган яше-карты көяз комиссарның шулай үз итеп Әхмәтсафа белән сөйләшүенә исләре китеп карап торалар иде.

—Кызыйның исеме ничек була?—дип, Усманов сөйкемле кызның бөдрәләнеп торган коңгырт чәчләреннән сыйпап алды.—Абыйсын ярата икән, кара әле аңа ничек тагылган.

—Бибиҗамал,—дип, чатнатып әйтеп салды кызчык.

Абыйсы аны кулына алды.

—Бибкәй-кыз икә-ән,—диде Усманов сузып.—Мондый сөйкемле кызга килешә икән Бибкәй исеме,—дип кабатлады ул. Шушы көннән башлап, Бибиҗамал исемен онытылыр да, үзен Бибкәй дип кенә атап йөртә башлаячакларын кыз әле бөтенләй белми иде. Ул яп-якты зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, сабыйларга гына хас үтә ышанулы тавыш белән сузып кына сорау бирергә дә өлгерде:

—Абый, бүген кемнәрне үтерергә килдегез?

Усманов бер мәлгә югалып калды, шулай да үз-үзен кулга алып, елмайган кыяфәтен югалтмыйча, бармагын иреннәренә китерде:

—Тс-с-с,—дигән булды.—Без беркемгә дә тимибез, сенлем. Дошманнарны гына куабыз. Кирәкми алар безгә, китсеннәр.

Кыз бер теле ачылгач, туктап калырга исәпләми иде инде, бәләкәй бармагын сәхнә ягына төртеп, тәтелди бирде:

—Дошманнар әнә тегендә, шуларны куарга кирәк. Китсеннәр, иеме, абыкай?..

Абыйсы җавап биреп тормады. Үзенә баш кагып, кырт борылып киткән Усмановка нидер әйтмәкче иде, кире уйлады, алдагы урыннарның берсенә барып чүмәште. Бибкәй абыйсы алдында боргаланып утырды-утырды да, нәни йомшак кулын аның муенына салып, изрәп йоклап китте. Әхмәтсафа бар дөньясын онытып, сәхнәгә төбәлде.

Ул арада сәхнәгә Усманов сикереп менде.

—Җәмәгать,—диде, сөйләсе сүзләренең бик тә мөһим булачагына басым ясагандай, уң кулын алга суза төшеп, бер мәлгә тын калды.—җәмәгать,—дип кабатлады ул, үзе тудырган киеренкелекне йомшарта төшеп,—Менә насыйп булгач, тагын сезнең авылга килеп чыктык. Бу юлы инде мин сезнең каршыда регуляр кызыл армия вәкиле, Казанда оешкан I татар-мөселман укчы бригадасының иң әзерлекле, иң булдыклы, кыю сугышчылардан торган полкның комиссары буларак чыгыш ясыйм. Кызыл фронтта партизанлык чоры бетте. Дошманнарга каршы барган аяусыз яуда төп сүзне оешкан кызыл армия гаскәрләре әйтәчәк. Милли бригаданы оештырырга рөхсәтне совет хөкүмәтенең олы җитәкчеләреннән алдым. Ышанам, алар азатлык яуларында сынатмаслар. Әле май башында гына Казанга иптәш Калинин килгән иде. Безнең частьларны карап, безнең ни-нәрсәгә яраклы икәнлегебезгә бәя биреп китте. Татар-мөселман бригадасы Михаил Иванович Калининга ошады. Кем белми, әйтеп китим, ул Мәскәүдә, Кремльдә Ленин белән янәшә эшләүче большевик. Яшереп тормыйм, Мәскәүдә дә төрле түрә бар, әмма Калининга ышанырга була. Эшче арасыннан күтәрелгән кеше. Менә аның киңәше белән, безне Оренбур ягына, колчакчыларга каршы сугышырга җибәрделәр...

Халык шаулашып алды. Усманов аларның тынычланганын сабыр гына көтеп торды. Инде сүзне Каргалы халкы үз күзләре белән күргән, башларыннан кичкән вакыйгаларга борды.

—Күреп торасыз, дошман мәкерле һәм яхшы коралланган булуга карамастан, кызыл армия ныклы адымнар белән алга бара. Дутов казаклары сезнең канга да аз тоз салмагандыр...

Арадан берсе ачык итеп әйтеп ташлады:

—Безнең канга кызыллар күбрәк тә тоз салды әле.

—Булгандыр, сугыш чоры, кемнең кем икәнлеген сорап торыш юк. Мин фактларны гына китерәм. Дутовны кызыл гаскәр сугышчылары янадан мәнге Оренбур далаларына аяк басмаслык итеп, арт сабагын укытып җибәрделәр.

Халык тагын шаулашып алды. Чөнки Дутов гаскәрләре арасында Каргалы егетләре аз түгел һәм мондагы кайбер кешеләргә Усмановның авызыннан чыккан әлеге сүзләрне тыңлап тору җинел түгел иде. Моны оратор үзе дә сизеп алып, уң кулын тагын кисәк алга сузып җибәрде. Әхмәтсафа беренче күргәндәй, комиссарның кыяфәтенә күз салды. Һәрвакыттагыча, коңгырт бөдрә чәчләре кызыл йолдызлы фуражкасы астыннан килешле генә чыгып торалар. Өстенә кигән хәрби киеме уртачадан югары буена шулкадәр килешә, халык аның сүзләренә караганда, сөйкемле сөягенә карап кына тына төште, ахры.

—Тагын да ары китсәк, Вәлиди төзегән башкорт гаскәрләре совет хөкүмәте ягына чыкты. Хәзер бергәләп акларга каршы сугыш алып барабыз. Башкортларның үзләренең хөкүмәтләре бар, безнең татарларның да аерым дәүләте, үз гаскәре булыр. I нче татар-мөселман укчы бригадасы төзелү моңа ачык дәлил. Дөньяда барган хәлләрдән артта сөйрәлергә тиеш

түгел татар халкы,—дип дәвам итте Усманов. Анын карашы Әхмәтсафа алдында изрәп йоклап киткән сабый—Бибкәйгә төртелеп, туктап калды. Бер тын сүзсез торгач, бүген генә кызыл гаскәрләргә язылган егетләрне күздән кичерде.—Менә бүген бернечә егетегез кызыл гаскәргә «күңелле» булып язылып китә...

—Ихтыярый-мәҗбүри,—дип төзәтергә өлгерде кемдер.

Аны да төзәтүче табылды:

—Теләк белән,—диде кемдер.

Усманов монын ише нәрсәләргә игътибар итмәгәндәй, сүзен янә бер кат кабатлады:

—«Күңелле» булып. Хайваннар гына теләккә килә. Без— кешеләр, күңел, хис белән эш итәбез. Әле карап торам да, сабый кызчык Бибкәй турында уйлыйм. Хатын-кыз мәсьәләсе милләт өчен иллә мөһим мәсьәләгә әйләнде, җәмәгать. Хатын-кызга әйбер, йортка калым китерүче мал итеп караудан азат булырга тиешбез.

Кемдер хихылдап көлеп куйды.

—Уен түгел, җәмәгать. Әйе, бүген хатын-кызлар кол хәлендә. Алар хәтта тормыш корып җибәрү, белем алу мәсьәләләрендә дә искелектә хөкем сөргән гаделсез кануннарнын корбаны булып яши бирәләр. Ә бит алар да үз язмышларына үзләре хуҗа булырга хокуклы. Хәтта нәни Бибкәй дә бүгеннән үзен кеше итеп тоярга тиеш. Үсеп житкәч үзе теләгән гаилә тормышы корсын ул. Мәхәббәт ирегә булырга тиеш түгелмени, ә? Бүгенге көннең төп шигарләре: «Хатын-кызга ирек!», «Бетсен коллык—бетсен хурлык!» икәнлеген инде күпләр аңлыйлар. Менә шунын бер мисалын күрсәтәсебез килә. Бүген Каргалыга беренче сәхнә карлыгачларыбыз—биюче кызлар Мөкаррәмә Әсфәндиярова, Камилә Мәжитова иптәшләрне алып килдек. Бу уналты яшьлек кызлар коллык пәрдәсен ертып ташлап, кадими туганнарының каршы төшүләренә, һичнинди ай-вайларына карамый кызыл гаскәрләргә мәдәният хезмәте күрсәтүчеләр сафына кушылдылар. Өйдә, дүрт стена арасында якты дөньяны күрергә мәхрүм кызлар, хатыннар шулай ук үз ирекләре өчен көрәшә башласыннар, тигез хокук дауласыннар. Милләтнең Жанна д'Арклары, Софья Ковалевскаялары, Мария Ермолаевалары булсын! Безнең милләт башка халыклардан ким түгел.

—Хатын-кызга ирек бирсәң, ишәрсең ишәк чумарын,—диде берәү ачулы тавыш белән.—Әле болай да кулдан ычкынырга тора алар, иблис токымнары. Коткы салуы гына ансат...

Әлеге сүзләрдән агайлар янә бер шаулашып алдылар, тик бу шаушу нигәдер күңелле төс алган сыман тоелды.

—Иптәш Еникеев, концертны дәвам итегез,—диде Усманов һәм сәхнәдән төшеп, Әхмәтсафа янындагы буш бүкәнгә килеп утырды.

Комиссарнын үз-үзен тотышы да, сөйләү куәсе дә Әхмәтсафага ошый иде. Баягы хисләр янә уянды: үзенең дә жиңү артыннан жиңү яулап баручы кызыл гаскәрләр сафына басып, яуда булмаган чакта шулай концертлар карап, солдат гомере үткәрәсе килә башлады.

Ул арада күңелләрне жилкетеп скрипка, мандолина авазлары ишетелде, мәйдан өстендә дәртле бию көе яңгырый башлады. Көй башламы уйналып бетер-бетмәс сәхнәгә милли киемнәрдән ике кыз атылып килеп чыктылар һәм житез, жинел хәрәкәтләр белән биеп тә киттеләр. Тамаша-чылар арасында кызларның бу гамәлләрен хупламаучы сүзләр ишетелгәләп алды:

—Бәндәдән курыкмасалар, Ходайдан курыксыннарые, бәдбәхетләр, ни кыланалар бит, ә? Дөньялар бозылды...—диде бер агай.

—Кызлар гына түгел, бичәләр азына башлады. Барып чыктык инде туганнар...

—Әйтмә дә генә инде. Бөтен халык алдында арт сикертеп йөргәннәрен күрсәләр, ата-аналары нишләрләрие микән бу иблисләрнең? Таралышыйк, җәмәгать, яшьләрнең азынганы гына житмәгән, боларны карап утырып, үзебез дә гөнаһлы булабыз!

Шулай да мыңгыр-мыңгыр килеп утыручылар аз иде. Арада кызлар-

ның биеп йөрүләрен килештермәүчеләр булса да, авыл агайлары һич кенә дә концертны ташлап кайтып китергә ашыкмадылар. Ул гына да түгел, аерым бер ләззәт һәм канәгатьләнү белән сылу кызларның сәхнәне ду китереп, табан асларыннан ут чыгарып биюләрен тамаша кылып утыра бирделәр. Гүзәллек каршында акылы булган кеше гөнаһ уйлап утыра димени...

Кызларга карап әсәрләнгән Усманов, бер заман әллә онытылып китеп (һәрхәлдә, тамаша кылучылар шулай кабул иттеләр) әллә шулай алдан сөйләшеп куелганмы, урыныннан кубып, сикереп сәхнәгә менде, күз ачып йомганчы сәхнә уртасына килеп басты, көй уңаена гәүдә-инсәләрен ятышлы гына уйнатып торды да, кызларга кушылып, килешле хәрәкәтләр белән биеп тә җибәрде.

—Ике титигә бер әтәч, әйттерә генә,—дип, хихылдап алды бер абзый.

—Әтәчләре бер кетәк, титиләре генә аз икән шул,—диде аңа каршы икенчесе.

—Шаярма,—дип сүзгә кушылды өченче агай, белдекле тавыш белән,—әллә син ул титиләр теләсә кайсы йолкыш әтәчкә эләгә дип белдеңме? Түрәләрдән артмыйлар алар. Япун сугышында күрдек инде, кызлар барые, шәфкать туташлары диләрме, түрәләрдән узып бер солдатка да тәтемәде алар.

Концерт беткәч, артистлар җиһазларын олауга төяргә керештеләр. Усманов отрядына кычкырып фәрман бирде:

—Барыгыз да атларга! Яңа гаскәргә язылучылар—олауга утырып барасыз—кузгалдык! Алга!

Усманов концертның уңышлы үтүенә сөенеп бетә алмый иде. Тагын берничә көннән аның полкы дошманга каршы яуга куылып кертеләсен дә, каршы килүенә карамастан, полкны иң авыр участокка куеп, бернинди яклаучысыз калдырачакларын да, беренче бәрелешләрдә үк казаклар тарафыннан тар-мар китереләчәкләрен дә белми иде. Каргалыдагы концерт полкның тәүге һәм соңгы җину булачагы башына да килми, ул үзен бу мизгелдә бөркеттәй хис итеп Оренбурга кайтып бара иде.

* * *

...Көне буе авызына бер валчык ипи капмаса да, нигәдер ашыйсы килмәде. Әхмәтсафа кече өйгә кереп сәкегә капланды, авырлык белән генә кабат күтәрелеп, баш астына кечкенә мендәр ташлады да күзен йомды. Бүген булып узган хәлләр бер-бер артлы башыннан кичеп, аның талчыккан җанын тагын да газаплыйлар, җанга яңа әрнүләр генә өстиләр иде.

Шулай күпме яткандыр, урам якта гадәти булмаган тавышлар ишетеп, күзләрен ачты. Өй эченә карангылык инеп килә икән, димәк, Әхмәтсафа йокымсырап киткән. Сагаеп, мендәрдән башын күтәреп тыңлана башлаган иде, атылып өйгә әткәсе килеп керде.

—Кем бар өйдә, торыгыз! Янабыз, пужар! Каргалы очына ут капкан, әйбер-караны чыгарып өлгерик,—дип әллә нинди ят, калтыравык тавыш белән кычкыра-шаулый ничек тиз килеп керсә, шулай ук җәһәт кенә чыгып та китте.

Әхмәтсафа абына-сөртелә урамга атылды. Һаваны тутырып «Янгын, пожар»,—дигән авазлар янгыраса да, урамда кешеләр аз күренә, чөнки һәркем үз ихатасында чабыша. Каргалы халкының янгын мәсьләсендә тәҗрибәсе җитәрлек, авылда янгын чыкмый тормый. Мондый җилле көнне, камыш япкан түбәле саман йортлардан торган урамны ярты сәгать эчендә ут ялмап кына алачак. Шуна күрә, һәркем үз йортын коткарып калырга тырыша. Инде өйне саклап калып булмый икән, дөнья көткәндә җыйган әйбер-карасын, булган малын ут авызына калдырмаска омтылырга кирәк бит.

Ут чыккан йорт үзләреннән ерак түгел иде. Кыш буе Мифтах хәлфәдә бергә укыган сабакташы Кәримнәр йорты давыллап яна. Ут беркемне дә аяп тормый, инде алар йортыннан күрше-күләнгә җәелә. Һаваны торган саен төтен болыты каплый. Җил янган камыш учмаларын дулата-дулата авыл буйлап тарата, Әхмәтсафаларның йорты януы да котылгысыз иде. Әтисенең ачыргаланып кычкыруы, шушы куркынычны сизүдән иде.

Каршысына җан-фәрман чабып килүче Саттар белән Әбдерәшитне күреп, Әхмәтсафа дус малайларның каршысына төште. Белә, беркемнең дә сөйләшеп торырга вакыты юк, шулай да кызыксынуны җиңеп булмый. Саттар белән Гаптери аның яшьтәшләре, сабакташлары. Әхмәтсафаны күргәч үзләре дә бер тынга тукталасы иделәр.

—Кәримнәр яна, малай.—диде Саттар—яшенә караганда җитди сөйләшә торган үсмер.—Солдатлар торганые алар өендә, шулардан тәмәке урлап калган. Бүген, ничектер җай табып, өй артларында, алабута арасында тәмәке тартырга маташа икән, әнкәсе килеп чыккан өстенә.

Әхмәтсафа, «өстенә чыгу» дигән сүзләрне ишеткәч, Таифә карчык лапасында булган хәлне исенә төшереп алды.

—Кәрим, куркудан тәмәке кабызырга сызган шырпысын өскә чөеп җибәргән. Бәхетсезлеккә каршы, янган шырпы түбә камышына килеп төшкән. Әнкәсе аңыша алмый торганчы, түбәгә ут үрләп тә киткән. «Күз ачып йомганчы төреп кенә алды ут»,—дип елый Бәдәр апа.

Әхмәтсафа Саттарның сүзен тыңлап бетерә алмады, өйдән әткәсенең ачулы тавышы ишетелде:

—Әхмәтсафа, дим, кая олактың? Әйберләрне чыгара башла кече өйдән! Апайларыңны Таифә карчыкка җибәр, ут алар ягына бармый. Өске урамнан урап үтсеннәр. Тиз бул, әй малай актыгы!

Ул ихатага йөгереп кергәндә, әтисенең дә, үги инәйнең дә күзенә ак-кара күренми иде. Ишегалды уртасына әйбер-кара чыгарып өелгән. Әгәр ут килеп җитсә, бу йорт кирәк-яракларының исән калуы икеле, ә ат җигеп, әйберне арбага төяп илтеп булмый: быел яз башында ук колчакчылар Мостафаның сәүдәгә йөри торган ике шәп юыртагын алып чыгып киткәннәр иде. Атлыдан атсыз калганнар иде, хәзер йортлыдан йортсыз итмәкче була язмыш аларны...

Әхмәтсафаның сизенүе дөрескә чыкты. Янгыннан алар бик аз гына әйбер-караны саклап кала алдылар. Ут кемнең кем икәнен тикшереп тормый, каралты-кураны рәттән ялмап килеп, аларның йорт-җирләрен дә көлгә, күмергә әйләндерде дә куйды.

Уйлау сәләтеннән мәхрүм калган Мостафа агай, гаҗиз калып, кара күмергә әйләнгән алмагач кәүсәләренә карап, гел бер үк сүзләрне кабатлады:

—Һай, алмагачлары, һай, шау чәчкә генә ие бит... Әле иртән генә ап-ак иделәр. Язмаган икән, язмаган икән балакайларымны алма белән сыйларга...—Һаман төтенләп утырган йорт нигезеннән урый да, тагын бакчага үтә, тагын шул ук сүзләрне кабатлый иде:—Һай, алмагачларым, һай шау чәчкә генә ие бит...

...Икенче көнне Мостафа агай кемнәндер арык кына ат алып торып, янгыннан ни хикмәт белән исән калган арбага уттан саклап калырга өлгергән әйберләрен төягәндәй итеп, Таифә карчыкның курчак өедәй кечкенә йортына күченделәр. Җәй көнендә йокларга да уңайлы булыр дип, вакытлыча «яшәү» өчен Әхмәтсафага лапастагы сәндерә эләкте. Үсмер, әтисенең гаҗәпләнүенә каршы, шул ук көнне Госман абыйсы ясаган сәндерәне туздырып атты да, анысына караганда күпкә кайтыш, әмма үз куллары белән ясалган булгангадыр инде, йоклау өчен бик ипле күренгән сәндерә әмәлләп ташлады. Ул бу эшне аеруча җилләнеп, эчке бер ярсу белән башкарды...

## VI

...Янгыннан соң бер ел үтеп китте. Шушы ел эчендә йорт төзеп керербез дигән хыял тормышка ашмый калды. Янгыннан соң ук Мостафа агай авырып китте.

—Бәхетне аны күп эзләдем, улым,—диде ул, беркөнне Әхмәтсафаны үз янына чакырып китереп.—Кеше күпме генә казганса да үзе теләгәнчә бәхетле була алмый икән. Шунысы да бар—без үзебез уйлаганча бәхетсез дә түгел. Урталыкта яши адәм баласы. Ике нәрсәгә туры карап булмый икән, кояшка һәм үлемгә. Тере килеш мәет булып яшәүдән Ходай сакласын. Укырга кирәк сиңа улым. Гомәрхан абыең эшкә дәрт иде, исән-имин кайтса, ул югалмас. Госман укымышлы егет, затлы егет иде. Югалтудан куркам аны...Нәселне вакламаска кирәк улым, Дәүләтъяр нәселен балкытып торган йолдыз бул син. Укуың әйбәт булды, унны-сулны аера беләсең. Кемгә ияргергә, кемнән качарга кирәклеген дә чамалыйсындыр. Денсез чукына, уйсыз үкенә.Башыңны күтәреп йөр, шул чагында гына күренә күктәге йолдызлар.Йолдызга карарга өйрәнмәгән кеше төнлә дөрес юл таба алмаячак. Яшәүләре авыр бу дөньяда. Кайбер чакта яп-якты көн дә төн сыман тоела. Менә шулай, улым, якты көндә адашудан саклан.Күтәрә алган кадәр генә йөк күтәрергә өйрән. Күтәргән атка йөкне өяләр аны. Чамасын белмәсәң, көлкегә калырсың. Кеше яши-яши данга, дәрәҗәгә өлгәшә. Берзаман үзенең кем икәнлеген, тамырларын оныта башлый. Ходай биргән зиһенең, укып җыйган белемең чиген үтеп, белексезлек ягына чыкма. Үзенә бернәрсә дә булмас, тик башкалар өчен дә куркыныч кешегә әверелерсең. Шундый заман килде, хәзер комсызлар, әрсезләр өскә чыга. Комсызлык бирәүләрнең зиһенен томалый, бирәүләрнең күзен ача—болганчык суда ни-нәрсә эләктереп калырга мөмкин икәнлеген белеп алганнар алар. Комсыз, әрсез кешеләрдән ерак йөр. Бер кешенең дә маңгаена кылган гөнаһлары язылып куелмаган. Ихлас кеше үзен гөнаһлы дип уйласа, башкаларга акыл биреп тә тормас, гел тәүбә юлында йөрер иде. Акыллы бул, улым. Үзеңне генә акыллыга чутлама, башка кешеләрнең дә акыллы икәнлеген онытма. Башка адәмнәрнең акылын күреп, шул акылны үзеңә ала алсаң, яшәүләре күпкә җиңел булыр...

...Ул төнне Әхмәтсафаның күзенә йокы кермәде. Керфекләренә йокы эленеп, инде онытылып китәм дигәндә, баш миендә, янә уйлар өермәсе кузгала иде. Ана быел җәй унбиш яшь тулды. Хәзер ул егет инде. Оренбур каласына, «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга чыгып китәчәк ул. Яна хөкүмәт мәдрәсәне укытучы-мөгаллимнәр хәзерли торган уку йорты итеп үзгәртте.

Әхмәтсафа ике җәй рәттән Сакмар буйлап сал агызды. Башка эшләргә караганда төшемле эш санала ул. Салны Оренбурдагы агач эшкәртү заводына илтеп тапшырасың да, исәп-хисап ясала. Мостафа агай авырып киткәч, янгыннан соң тиз генә мантып булыр кебек тоелмый иде. Өй салу турында әлегә уйлыйсы да юк, тормышны рәткә кертергә кирәк иде. Шуңа күрә сөенә-сөенә эшләде ул. Сал агызу белән турыдан-туры житәкчелек иткән подрядчик Гариф аны башта эшкә алырга да теләмәде. Янгыннан соң күпләр янадан өй торгызырга ниятләп, эш юллап, авылдагы байлар, кәсепчеләр тирәсендә бөтерелеп алдылар, тик авыл өстеннән әллә ничә мәртәбә үткән афәт-сугыш гарасатлары унтугызынчы елның язында дулаган янгыннан һич кенә дә ким түгел иде. Авылның чын байлары, дөнья күргән хәлле сәүдәгәрләр акларга ияреп, әллә кайларга китеп югалдылар. Совет хөкүмәтенә яраклашып үз эшен оештырырга омтылучы кәсепчеләрнең, сәүдәгәрләрнең әле авылның һәр мохтажына ярдәм итәрлек көче дә, теләге дә юк. Чөнки борынгы сәүдәгәрләрнең мохтажларга хәйрия ярдәм күрсәтүе, зәкәт бирүе аларның абруйларын бермә-бер күтәреп, сәүдә эшләренә дә унай йогынты ясый иде. Аякка басып килгән яна байларның игелекле эшләренә бирәү дә

игътибар итми. Шулай булгач, ник дип әле алар үз малларын унга-сулга таратырга тиеш ди?...Киресенчә,халык арасында сүз чыгып, ЧК килер дә, бар мал-мөлкәтенне туздырып, талап китәргә дә күп сорамас дип куркалар иде. Каза күрүчеләр саман кирпечтән өй корыштырып, гаиләләренә вакытлыча куыш булуына куанып, шунда гомер сөрә башладылар. Дөньялар тынычлангач, сәвит хөкүмәтенең авыр тормышлы кешеләргә күзе төшәр, тормышларын рәтләргә ярдәм итәр дип уйлаучылар иде алар. Өметсез шайтан, сәвитчеләр ике сүзнең берендә «ярлы-ябагай мәнфәгате» дип, кабатларга яраталар ич. Күпләр һавадагы торнага ышанганчы дип, калага барып эшкә урнаштылар. Мостафа агай авылда калып, үзе ижтиһад итеп, тормышын аякка бастырырга уйлады. Бердәнбер таянычы—улы Әхмәтсафаны, туганы Дәүли ярдәме белән подрядчик Гарифка, сал агызучы итеп урнаштырды. Сөйләшкәндә Гариф, эшләгән өчен хезмәт хакына өйлек бүрәнә бирергә вәгъдә итте, бераз акчалата да түләргә булды. Әхмәтсафа буйга калку булмаса да, тырыш һәм эшкә үҗәт егет иде. Сал агызучыларга авыл халкы аеруча ихтирам белән карый, бу эш теләсә кемнең кулыннан килми: ашкынып аккан Сакмар буйлап әллә кайлардан сал куу, әйтсән, әйтмәсәң дә уен түгел шул. Ул шулай егетлек бусагасыннан атлап керде.

Гариф—сугышлардан исән-имин кайтып, үз эшен оештыра башлаган, озын гәүдәле, сүзгә дә, кыланмышларында да тупас һәм аяусыз адәм. Мостафа агайга беренче җәйдә үк унбиш бүрәнә бирергә булган иде. Вәгъдәсез булып чыкты: Әхмәтсафа ике җәй ал-ялсыз сал агызып йөрүенә карамастан, эш өчен тияр әҗерен бирмичә, һаман алдагы елга калдырып килә. Быел, көзгә табан Әхмәтсафа түзмәде, Гариф белән бераз сүзгә килеп алды. Теге мыскыллы рәвештә:

—Сиңа төс түгел ул йорт салып керү, үләттән калган нәрсә,—дип битәрләп ташлады.—Саманнан кирпечләр әвәлә дә, өегез йорт, юк бүрәнә, моннан соң ымсынып та йөрмә?—дип, ярга килеп төртелгән сал буйлап, як-якка чайкала-чайкала чабулап китте.

Башыннан аягына кадәр ләмгә батса да, җиңү алар ягында иде. Шуңа күрә Гарифның җикеренүенә артык әһәмият бирмәде. Гариф дулаганнан гына салны борып агым уртасына чыгарып булса икән. Сакмарның җайсыз борылышында, елга уртасында гомер-бакый шулай кукраеп утыручы ак ташка килеп бәрелеп, ярга килеп сыланды сал. Бәхетсезлеккә каршы, салның койрыгында Әхмәтсафа ничектер үзе генә калып, ишкәкне нәкъ вакытында кирәгенчә чумдырып-каерып ала алмый калды. Җитмәсә, аның чираты да түгел, сүз тыңлап, бер егетне алыштырып кына баскан иде. Суеласы көнен белсә, әтәч танны уятмас иде, ди әткәсе. Шул тыңлаучанлыгы аркасында ишетте дә инде яман сүзне Гарифтан. Әткәсе дөрес әйтә, юк дип әйтә белми ул. Теге егетнең дә әллә ни йомышы булмаган, тәмәке көйрәтеп аласы килгән. Бу урында ишкәккә һәрвакыт ике кеше баса иделәр, Зариф абзый—«Килеп житә алмый калдым,»—дип аклана әнә...Агачлар начар беркетелгән булып чыкты. Бер араның бавы түзмичә шартлап өзелде, сал тарала башлады һәм агачлар котырып аккан Сакмар иркендә, бер-берсе белән ярыша-ярыша аекка табан юл алдылар. Җаекка житсәләр, аларны тотып алырмын димә инде. Әхмәтсафа, башкалар искә килеп өлгергәнче, салкын суга ташланды, кулында озын саплы авыр багор, шул багор белән бүрәнәләрне яр читенә этеп чыгара, исәбе—ничек тә агачларны бер-берсенә каршы төшереп, аларның үз иркендә агуына комачаулык итү иде. Һәр салда өч-дүрт егет була, Әхмәтсафалар салында Гариф белән дүрт кеше иде. Эшнең хәтәр икәнен башкалар да тиз аңлап алдылар, Әхмәтсафаның җан-фәрман агым белән көрәшеп матавыклануы аларга көч өстәде бугай, сәгать ярым азаплангач, агачларны тын култыкка җыйнап, салның исән өлешенә япсартып бәйләп, ныгытып куйдылар. Шулай да берничә агач, агым иркенә буйсынып, түбәнгә таба— аекка төшеп китте. Аларны тотарга тырышу исә, салны бөтенләй туздырып, юкка чыгаруга бәрабәр иде.

Эш тәмамлангач, шушы агачлар өчен Әхмәтсафага бәйләнде Гариф. Бу хәлгә таруда салчы егетләрнең һәммәсенең нинди дә булса гаебе бар, алар дәшми торуны хуп күрделәр. Зариф салчылар арасында иң өлкәне һәм тәҗрибәлесе, Әхмәтсафаны яклап авыз ачкан иде, Гариф аның да гаебен яхшы белгәнгә, ачу белән аңа бер генә карап алды, Зариф шым булды. Подрядчы исә торган саен котырды, Әхмәтсафаның якасына килеп ябышты:

—Атың коргыры, йоклап бардыңмы әллә?—дип, йодрыгын егетнең борын төбендә уйнатты.

Әхмәтсафаның арыган, яңагы суырылып эчкә кергән. Өстеннән шыбырдап су ага, Гарифка каршы әйтү теләге бөтенләй юк иде. Гариф аның саен котырды:

—Синдәй җебегәнне шушы эшкә алган мин җүләр. Малай-шалай эшеме инде, сал агызу, йә?—Бу юлы ул Зарифка эндәшкән булды. —Әйт, Зариф, суга ташларгамы бу җүнсез малайны! Күпме агачны аекка агызып юкка чыгарды бит, ә?—Ул ачынган тавыш белән, тагын бер-ике сүз өстәде дә, Әхмәтсафаны сал өстенә аркылы-торкылы ташланган агач өеменә этеп җибәрде. Егет хаксызга рәнҗетелүдән болай да коелып төшкән иде.Каршылык күрсәтмәүнең әҗере шул булды, аягы каядыр эләгеп, «эһ» итәргә өлгермәде, бүрәнә аша очып, Сакмарның ләмле су читенә барып төште.

Моңарчы гаепле төстә торган Зариф түзмәде, йөгереп диярлек Гариф янына килеп басты:

—Тиясе булма!—диде ул янаулы тавыш белән.—Әгәр ул булмаса, ярты сал агып бетәрие, ярый ул каушап калмады...Күрериең агачларны, Әхмәтсафа булмаса!

Зарифның көтелмәгән кыюлыгыннан башкаларга да җан керде. Гариф шундук шиңеп калды.

—Егетләр, ахмак булмагыз!—диде ул, аларга шикле караш ташлап.—Миңа гына кирәкме әллә? Эш пешсә, сезгә дә начар түгел. Кесә тутырып акча аласыз...

Шул чагында Әхмәтсафа телгә килде.

—Кайчан бүрәнәләрне бирәсең? Сөйләштек бит!

Гариф тагын ярсып маташса да, Зариф барында яңадан егеткә ягыла алмасын аңлап, сүгенә-төкеренә, Әхмәтсафаны мыскыллап әйткән баягы сүзләрен кабатлады.

—Төс түгел сиңа бүрәнә!—диде ул, яр читенә килеп баскач.—Карагыз аны, кич житкәнче агачлар урынында булсын. Ә юкка чыккан агачларны, син егеттән,—Әхмәтсафага ачулы караш ташлады,—түләтәм, белдеңме, ачык авыз!

Менә шушы вакыйганың үчен алдымы, әллә шундый җай гына көтеп йөргәнме, Мостафа агайның кат-кат өенә барып йөрүенә карамастан, Әхмәтсафа белән исәп-хисапны тулысынча өзмәде Гариф. Тукран кебек һаман бер сүзне кабатлады:

—Алдагы елда күз күрер, алдагы елда карарбыз...

Эшләп-эшләп тә җүнле сүз ишетмәгәч, Әхмәтсафа, Гариф сыман кеше хезмәте кулланып, әрсезләнеп, алдау-йолдау юлы белән баеп калырга омтылучыларга ялынып йөрмәскә кирәклегенә инанды. Андыйларны күрә алмый башлавын да тоя иде. Шушы инану аның киләчәк юлын билгеләде дә инде. Ярый теге чакта Зариф абзыйсы ярдәмгә килгәч, Гариф чигенде. Тик барыбер этлеген эшләде—тиешле хезмәт хакын түләмәде. Йодрык уйнатып Гарифны да, аның кебек кеше канын эчәргә омтылган яңа сәвит байларын да җиңеп булмаячак. Беләктә көч бар ансы. Шушы ике җәйдә җилкәләре тагын да киңәеп, җиргә нык басып йөрүче егеткә әйләнсә дә, аның да, аның сыман яшьтән эштә ватылган башка үсмерләр-нең дә хаклык өчен көрәшкә чыгарга хәлләреннән килми иде. Бер генә юл кала—белем алырга, ярлы-ябагай яшьләргә берләшергә кирәк. «Беләге юан—берне егар, белеме булган—меңне егар»,—ди иде Мифтах мөгаллим.

Әхмәтсафа еш кына комиссар Усмановны искә ала. Ул әйткән: «Бергәлектә—көч», дигән шигарне иптәшләренә кабатлый. Авылда яшьләр берлеге төзеп мәш килделәр. Әхмәтсафа монда да башлап йөрүчеләрдән иде.

—Берләшергә кирәк. Яна тормыш корабыз дип тотынганбыз икән, беренче эш шул булырга тиеш,—дип чыгыш ясады ул ялкынланып.—Каргалы халкын читтән берәү дә килеп якты тормышка чыгармас. Сәвит байлары да баш өстебезгә кояш яндырмас. Әүвәл яшьләр бер йодрыкка берләшергә тиеш.—Яшьтәшләре анын оста сөйләвенә биһуш китеп утыралар. Ә ул сөйли дә сөйли.—Шунсыз алга барып булмый. Салнын таралганын күргәнем бар. Искә килгәнче, агачларны агым бөтереп кенә алды. Аек суына килеп эләксәләр, бетте диген, тиз арада җилле-давыллы дингезгә агып төшәчәкләр. Дулкын иркендәге аерым-аерым бүрәнәләрнең алдагы язмышын Ходай үзе генә белә... Безнең дә язмыш шундый...

Мифтах мөгаллимдә дүрт ел дәвамында хисап, җәгърәфия, әдәбият, урыс теле укып белем алган егет әтисенең кинәшен тотып, хәлфәсенең фатыйхасын алып, җәй урталарында ук «Хөсәения»гә документларын илтеп кайткан иде. Аңа авылдаш егетләрдән берничәсе иярде. Укырга керү дигәч тә, җиңел генә түгел икән: шартын китереп имтихан да алдылар хәтта. Белемнәренә карап кемне—хәзерлек сыйныфларына, кемне башлангычның кайсыдыр баскычына укырга алдылар. Әхмәтсафа, бераз урысчасы сынату сәбәпле, хәзерлек сыйныфынын икенче баскычына кабул ителде. Һәрнәрсәгә үткер Саттар Ишбулдинның башлангыч сыйныфка кабул ителүенә барсы да көнләшкән кебек булдылар.

Аларны Әхмәтсафа тиз суытты:

—Саттарның ничек тырышып укуын барыбыз да беләбез. Көнләшеп торасы юк, шушы бер ел эчендә ике еллык сыйныф белемен үзләштереп, Саттар дусны куып җитү бурычы тора безнең алда. Шундый заман—бер ел хәл итә кеше язмышын. Ашыгырга кирәк безгә егетләр, ашыгырга. Өлгерми калсак, кемгә үпкәләрбез?

Моңарчы читтәрәк торган Пәрваз иреннәрен бөрештереп, каршы төшеп маташты:

—Кая куасың безне, Әхмәтсафа? Боерган булса, укырга да өлгерербез, яшәргә дә.

Чыннан да, кая ашыга соң әле Әхмәтсафа? Җаны кая ашкына анын? Бу хакта төптән үзе дә уйлап карамаган иде булса кирәк. Пәрвазның сүзләреннән сүрелә төшеп, бая әйткән фикерен ныгытып куярга омтылды:

—Ак ташка бәрелеп таралган сал хәлендә калуыбыздан куркам. Шул гына...

Күрер күзгә малайлыклары да чыгып бетмәгән үсмерләрне берәр өлкән кеше, йә, мәдрәсә ишек алдында үтеп-сүтеп йөргән мөгаллим-хәлфә читтәнрәк күзәтеп торса, зурларча сөйләшеп торуларына сөенер идеме, әллә сәерсенер идеме—белгән юк. Белем алырга шундый җитди, уйлы егетләрнең килүе имтихан алучыларны да җилкендереп җибәргән иде.

...Әхмәтсафа һаман йоклап китә алмый иде әле. Күз алдына кара бәрхет түбәтәй кигән, чандыр гәүдәле, һәрвакыт ачык йөзле Мифтах хәлфә килеп басты. Аннан сабак алулары җан рәхәте иде.

Уку дигәннән, Әхмәтсафа, Каргалыда Мифтах хәлфә җәдитчә мәктәп ачып, балаларга сабак бирә башлаганчы да, өч-дүрт ел Вәлкәй хаҗидан сабак алып йөргән иде. Сабак дисәң, хәтерең калыр. Вәлкәй хаҗи биргән сабак-дәресләрдән Әхмәтсафа нигәдер ләззәт тапмады. Мәчет каршындагы мәдрәсәгә килеп керүгә, борынга тынчу ис килеп бәрелә. «Һәфтияк»ләрне ачып, өйгә бирелгән дәресләрне хәлфәгә әйтә башларга өлгермисең, ул, сабакны өзеп, эшне өлкән шәкертләргә бирә дә, үзе йә берәр сәүдәгәргә аш мәҗлесенә, йә җеназага-фәләнгә дип чыгып китә. Авыл зур, унбер мәчет булса да, муллаларга, хәлфәләргә эш табылып кына тора. Аларның мәҗлес ише нәрсәләрнең берсеннән дә каласы килми. Хәлфә чыгып китүгә,

мәдрәсәдә дәрес бирүнең ысулы үзгәрә. Өлкән шәкерткә тагын биш-алты «ярдәмче»—куштан табыла. Юк кына сәбәп табып, кечерәк шәкертләрнең аркаларына чыбык белән «шелек» сугып, күңелләрен басалар. Китә елашу, китә ызгыш—чыда гына.

Шундый бер «шелек» сугу вакытында, Әхмәтсафа дусты Габдрахман белән, малайлар аны Әптри дип кенә йөртәләр иде, букчаларын алып, мәдрәсәдән чыгып тайдылар.

Яз көне иде. Якты көнгә килеп чыккач, малайлар үзләрен бәйдән ычкынган кәҗә бәтиедәй хис иттеләр. Кыш буе тынчу мәдрәсәдә ятудан аксылланып калган йөзләренә шаянлык, мутлык төсмерләре җәелде, аяклар үзләреннән-үзләре Сакмарга, әле кайчан гына дәү-дәү бозлар актарылып-кайнап аккан елгага таба йөгерделәр. Киртә, читән буйларында әлегә кояш нурларына бирешми маташкан кар ята. Башка вакытта булса алар иркенләп кар атышлы уйнап алырлар иде, бүген исә вакыт юк, үтә әһәмиятле нәрсәне күрми калабыз дигәндәй, йөгерә-атлый Сакмар буена җилдерделәр. Язгы ташу ел саен тар гына күперне үзе белән ияртеп алып киткәч, бердәнбер кичү чарасы—паром кала. Малайлар ак-кара күрми нәкъ менә шушы паром борынын китереп төртә торган сөзәк яр буена, Каргалы халкы әйткәнчә—пристаньга юнәлделәр.

Авыл читенә чыгуга малайларга гаҗәеп манзара ачылды. Сакмар елгасы шундый тулышкан, шундый гайрәтләнгән елга җәйрап яткан дингезгә әйләнгән иде. Малайлар җәй көне ат саклап йөргән бер-бер тугайның гына кинлеген дә өлкәннәр өч-дүрт чакрым булыр дип сөйлиләр иде, ул тугайлар су астында калган. Әрәмәдәге кайбер куакларның башлары гына су өстеннән тырпаеп тора. Елга еракта серәеп торган усак урманына кадәр җәелгән. Тыелгысыз су ташкыны агачларга бәйләнә-бәйләнә, аларны үзенең салкын һәм кызгану-фәләнне белмәгән ярсу дулкын-канаты белән кыйный-кыйный аекка актарылып-бөтерелеп ага. Ара-тирә, моңарчы кай җирләрдә посып ятканнардыр, куе-кучкыл су өстеннән күксел-ак пароход сыман, галәмәт дәү боз тавы агып үтә.

Авыл читендәге сөзәклектә мәхшәр. Монда малайлар бөтенләй белмәгән яклардан килгән йөзләрчә олау Оренбур ягына чыгу өчен атналар буе паром көтә. Аргы яктан да шундый ук олаулар, атлар, кешеләр шәйләнә.

Малайлар олауларны читләтеп үттеләр. Якын елышмавың хәерле, чөнки Каргалы элек-электән үзенең угрылары, ат караклары белән дан тоткан авыл. Кем булсын: малай-шалаймы, яшьләр яки өлкәннәрме, олауларга якынлаша башласа, ачулы-янаулы тавыш ишетелә башлый. Әллә кайдан, ерактан урап үткән сыман тоелганнар иде, малайларга каршы бер адәм чыкты.

—Малай актыклары, таегыз моннан! Көшегез-көш, Каргалы чәүкәләре! Туйган инде сезнең ише ыбыр-чыбырдан. Йөккә җилләре генә тиеп китсә дә, зыян салалар, мур кыргырлары. Әнә бер хәерсезе йөк бавын кисеп, нәрсәдер актарып азапланган.—Елга ягыннан һәрдаим исеп торган салкынча-дымлы җилдән бите кәшәләнеп беткән йөкче нык кына сүгенеп куйды.

Ана атна буе җүнләп йокы күрмәүдән иңке-миңке йөргән икенче йөкче кушыла:

—Берүк сак бул, агай-энэ. Үткән ел шушы Каргалы кичүендә мин ярты олау малымнан колак кактым. Юлдашларым таныш-әшнә адәмнәрие, юкса, алар да искәрми калганнар.

—И-и туган, йокы белән үлем бер, ярый, бөтен малына каз мае сөртмәгәннәр...

—Йокы дип, бер күзем ачык, бер күзем ярым йомык, черем итү инде. Үзем күреп торам, ике адәм килеп, йөкне актаралар, шуларга кычкырып кына булмый. Оеп тик ятам, әллә чын хәл, әллә саташам мин әйтәм. Һушка килеп, сикереп торган идем, кая ул, тегеләрдән җилләр искән.

—Угры сине көтеп тора, ди.

Олаучыларны тынлап торуы рәхәт тә, монда буталып йөрергә вакыты ул түгел. Малайлар күнегеп беткән инде, мосафирларның үзләренә карата

коры кыланып, читкә тибәрүләренә артык исләре китмәде. Үз юллары—юл, пристань ягына теркелди бирделәр.

Монда да кызык. Елга агышын басып, шау-шу килә халык. Кемдер чиратын югалткан, кемдер хәйләгә керешкән: хәрәмләшеп паромга алданрак үтмәкче була. Теге як ярга барып төртелгәч тә, тынычлык юк. Инде хәзер жай гына паромнан чыгып китә алмыйча тарткалашалар. Бусы—үзе бер тамаша. Тик малайларның моны тамаша кылырга вакытлары юк та юк инде. Үзләренә яхшы таныш паромчы Зариф абыйның паром ярга туктаган унайга, көчле ыргым ясап жиргә сикерүен, паром бавын күз ачып йомганчы «пристань» итәгендәге юан тәбәнәк баганага бәйләп-нығытып куйганын карап, сокланып торырга була ансы. Зариф абыйлары яшь, таза, көчле шул. Соклансаң да була! Яр буенда бераз юангач, букчаларын якындагы жимерек күпер араталары астына яшереп, ерак түгел кузна уйнаучы малайлар янына йөгерделәр. Карангы төшә башлаганчы уйнап, хәлдән таеп, язның бу көнен шулкадәр күңелле, мәгънәле үткәрүләренә сөенеп, күпер буена килсәләр, акылга сыймаслык хәл—күпернең теге калдык өлеше биек ярдан аска, болганып аккан Сакмарга жимерелеп төшкән дә киткән...Киткән икән китә бирсен, әмма Әптери белән Әхмәтсафаның китап, грифель тактасы тутырылган букчаларын да үзе белән иярткән күпер!

Хәлнең мөшкеллеген чамалап, телсез калган Әхмәтсафага карап, Әптери такмаклап алды:

—Бетте баш, малай, өйгә кайтып керде юк!—диде ул, еламсыраган тавыш белән.—Сабактан качканны хәлфә әткәйгә әйтми калмый, болай да эләгә иде, әгәр букчасыз калуны да белсә-ә...Ярачак ул мине...

Әхмәтсафа, әтисенең беркайчан да кул күтәрмәгәнен белгәнгә, артык чәпчемәде. Әткәсе еш кабатлый торган сүзләрне әйтеп, Әптерине юатырга тырышты:

—Баш ярылып, күз чыкмаган...

—Сиңа рәхәт, син жүләр, дигәндәй... Атан тырнак белән дә чиртми бит сезгә. Минем әткәй холыксызлансамы?!. Юк, син теләсә ни эшлә, мин бүген өйгә кайтып тормыйм,—диде Әптери, ныклы карарга килеп.—Бабайларда кунам, иртәгә, төштән соң әбекәй илтеп куяр әле өйгә. Әткәй әбекәйдән шөлли, ул булганда дөнья жимерми.

Каргалыда холыксыз кешеләр аз түгел. Дуамалланып әллә-ни майтарып ташлаучылары да бар. Шулай, көннәрдән бер көнне, бер абзый арып-талып капка төбендә ял итеп утыра икән. Күршесе моннан сорый: «Ул кадәр ни эшләр бетерден, тынын-көнең беткән?»—ди икән. Абзый, башын сыпыргалап, бик зур эш эшләгән кебек жавап кайтарган: «Өйдәге бөтен әйберне жимереп, талкан иттем, бераз ял итәм дә мичне сүтәм...» Баксаң, агайның бәләкәй малае кәлүшенә пес иткән икән. Шунын ачуын алган, имеш. Әптеринең атасы да шундыйрак дуамал холыклы адәм иде. Ярачак ул Әптерине, малай дөрес әйтә.

—Мин башка бармыйм, сабакка!— диде Әхмәтсафа.—Озакламый сабанга төшәләр, кыр эшләре башлана...

—Шуннан?—диде Әптери, өлкәннәрчә сөйләшергә маһир Әхмәтсафаны бүлдереп.—Сабак бетмәс борын сине кем мәдрәсәдән алсын?

—Башкаларныкы бетмәгәндер, безнеке бетте инде.— Әхмәтсафа көлеп, ярга якынрак килде. Шаулап аккан Сакмарга карап уйланып торгандай итте дә, көйләп жибәрде:

Китте букча суга агып,
Йөрмим сабакка барып...

—Бәет чыгарырга оста икәнсең син...

—Кичә әткәй янына кәкре Бәдри килгән иде. «Көнлекчегә бер малаенны биреп тор әле, Мостай кордаш»,—ди. Әткәй әйтә: «Гомәрхан белән Госман үземә кирәк, минем дә аз булса да жирем бар бит»,—диде.—«Әхмәтсафаны жибәрермен»,—дип вәгъдә итте. Вәт шул, иртәгә үк Бәдри абзыйга көнлекче булып китәм.

—Син...күнлекче?—дип аптырый төшеп сорау бирде Әптери.—Көчең житәр дип уйлыйсыңмы?—Әптери күзен чепиләндереп Әхмәтсафага карап алды. Карашында дустын җәлләве ярылып ята иде.—Әткәй мәнге күнлекчегә бирми мине...

—Аның урынына чыбык ашата...—диде үчекләшеп Әхмәтсафа. Үзен бер дә бәләкәй малай итеп күрсәтәсе килми иде аның. «Эшләп кеше үлми, ныгый гына»,—ди әткәсе. Әйтсәң әйтмәсәң дә Бәдри абзыйга ярдәмче бер малай кирәк бит. Үзе гарип, балалары юк. Нишләсен ул, Әхмәтсафага да риза булып тора. Вак-төяк эшкә ул ярап тора, кисәкле эшкә башкаларны яллар. Монда мәсьәлә букчаларның юкка чыгуында бит әле.—Аның эше кара көзгә кадәр бетми инде. Көзгә кадәр кемнең кайда букча югалтуын кем исендә тотсын ди? Тик Бәдри абзыйның бер яман гадәте бар: эшли торасың, ул бәйләнеп теңкәгә тия. Үткән ел күнлекче булып Госман абый йөреп алган иде. Кичә әткәй әйтте: «Юкка-барга малайга бәйләнер булсаң, чамала, киләм дә алып кайтып китәм, гаеп итештән булмасын»,—диде. «Юк, юк, күзнең агы белән дә карамам»,—дип, антлар эчте Кәкре Бәдри. Менә күрербез инде, ни кыланыр...

Әхмәтсафа, сүзендә торды. Шул көннән башлап мәхәллә мәдрәсәсенә бармады. Бәхетенә каршы, көзгә Оренбурдан Мифтах мөгаллим килде. Вәлкәй хажи Әхмәтсафаны Мифтах хәлфәгә бирүгә нык каршы булды. Имеш, Мифтах хәлфә малайларны деннән яздырырга, урыс итәргә килгән. Мостафа агай бирешмәде, дөнья булгач, белемнәренең барысы да кирәк, дип, улын җәдитчә мәктәккә, Мифтах мөгаллим кулына тапшырды.

Таңны сискәндереп, әтәчләр кычкыра башлады. Төн буе төрле уйлар уйлап, җәфаланып беткән Әхмәтсафа йокыга китеп кенә маташа иде, үги әнкәсенең яңгыравыклы тавышы ишетелде:

—Тор, Сафа, әнә Саттарлар җыенып, капка төбенә килеп басканнар инде.

Әхмәтсафа үз-үзен белештермичә сикереп торды, «ә» дигәнче түбәнгә төшеп, юынырга ашыкты.

Шәмсия шаркылдап көлеп җибәрде:

—Юри генә әйттем. Саттар белән Әптери әле жиденче төшләрен күреп яталардыр. Торгач торгансың икән, тиз генә капкалаштыр да, мал асларын тазартып куй,—дип, чиләкләрен шалтыратып урам коесына суга чыгып китте.

Бу иртә Әхмәтсафаның балачагы белән хушлашу таңы иде...

## VII

«Хөсәения» дәге тәртипләргә ияләшеп китү башта кыен булды. Күнел гел авыл ягына тарта, ә монда һәр нәрсә хәлфә-мөдәррисләрнең рөхсәте белән генә эшләнә. Әхмәтсафаны үзе кебек хәзерлек сыйныфы шәкертләре торган бүлмәгә түгел, ә өченче каттагы, аңа караганда бераз яшькә өлкәнрәкләр бүлмәсеннән урын бирделәр. Монда электән килгән гадәт буенча, һәр нәрсә санлы, ягъни номерлы иде. Әхмәтсафа да уникенче санлы ятакта йоклый, ашханәдә уникенче урынга утырып ашый, сыйныфта аның партасы (бу яна сүзгә ияләшә алмый интекте) шулай ук уникенче иде. Авылдаш малайлар—Саттар, Габдерахман-Әптери, Хәмитләрдән аерыласы килмәгән иде килүен. Хәер, яна бүлмәдәшләренә дә тиз ияләште. Бер ягында—Шарлык ягы егете, инде бу мәдрәсәгә өченче «кыш»ка килгән (ул уку елын шулай «кыш»лап саный иде) Сәгыйть; стена буендагы ятакта—юантык гәүдәле, иренәре дымсуланып, бүселебрәк торганы Мәҗит исемле егет китап актаргалап ята иде. Сәгыйть Агишев—сөйләшергә ярата торган, жор телле, якты йөзле шәкерт. Мәҗит аның капма-каршысы. Кем ни әйтсә—шуның белән бәхәскә керергә генә торган әтәч холыклы, төртмә телле егет. Аңа йомышын төшмәсен, ник дәшүенә үкенерсең. Калган шәкертләр белән

тиз дуслашты ул. Мәжиткә ишарәләп, Сәгыйть берничә төртмә сүз дә ыргытып алды:

—Дөньяда мокытлык дигән чир бар, Әхмәтсафа. Бу чирдән Әбүгалисинаның тыйб китабында бер дәва да күрсәтелмәгән. Димәк ки юк андый дару. Ни өчен ышанып әйтәм, чөнки мокытлар ул чакта да булган. Даруы табылса, тыйб китабының беренче битенә үк язып куяр иделәр. Әбүгалисина галиҗәнаплары. Мокытка Ходай үҗәтлекне өеп биргән. Син караны кара дисең, ул ак дип сикереп тора.

Мәҗит бу сүзләргә бәйләнергә теләп, кисәк кенә кулындагы китабын бер читкә ыргыткан иде, нидер уйлап, астан гына Сәгыйтькә карап алды да, кире ятагына ауды.

Ишек янында тагын бер ятак бар. Ансы әлегәчә буш тора— хуҗасы килеп житмәгән икән.

Уку башланып, берничә көн үтүгә, шәкертләргә «Хөсәения» дигән атаманы онытырга куштылар: алар укыган белем йорты мәдрәсә булудан туктап, Көнчыгыш халык мәгарифе институты итеп үзгәртелгән, имеш. Озак та үтми, мәдрәсәдә дини йолаларны—намаз уку, ураза тоту, гает көннәрe үткәрүне тыйган фәрман язып элделәр.

Бер көнне, фәрман эленгән дивар яныннан үтеп барганда, Сәгыйть тукталып калды һәм шыпырт кына әйтеп куйды:

—Мине монда өйдәгеләр мулла булырга дип җибәргәннәр иде, хәерле булсын, бөтенләй динсезгә әйләнеп кайтам инде. Вәт нинди замана килде безгә, дустым,—диде ул, хәсрәтле көлемсерәп.—Рәхәт бит, мин сиңа әйтим, иртән комган тотып, тәһарәт-мазар дип, чабулап йөрисе юк, казыйларның әрләвен ишетеп торасы юк. Каршы төшкән адәм заты да күренми тагын, әйтерсең, шуны гына көтеп торганнар. Кешене диннән биздерү бик җиңел икән, иманлы итү генә кыен бәндәнe.

Яннарыннан сөйләшеп,басынкы көлешеп, үзләренчә чикылдашкан булып кызлар үтеп китте. Сәгыйть, кызларга ым кагып алды:

—Болары оҗмах кошлары була инде.—Ул мәзәк кенә күз кысып алды.—Мин мәдрәсәгә килгән елны бу бинада эзләре дә юк иде. Шәһәрдә аерым кызлар мәктәбе бар иде. Әдәби кичә үткәргән чак та, кызларны кунакка дәшик дисәң, хәлфәләрнең күзләре маңгайга менә иде. Ә кызлар белән танышасы килә, малай. Шуңа күрә әдәби кичәләргә Кәрван-сарайга йөрдек башта. Анда Бабич агай шигырьләр укый иде, ай-вай, вәт галим кеше иде ул.

—Хәзер кайда соң ул?—диде Әхмәтсафа, Бабич турында сүз чыккач, кызыксынуын яшермичә. Шәехзадә Бабич исемле шагыйрь турында аларга Мифтах хәзрәт бик илһамланып сөйли иде. Әхмәтсафаның соравыннан Сәгыйть күңелсезләнеп калды. Кемнәндер шикләнгән сыман, тирә-якка каранып алгач, пышылдап диярлек:

—Үткән ел кызыллар тотып алганнар аны. Башкорт хөкүмәтенә эшләгән икән ул. Башта башкорт хөкүмәте совиткә каршы булды, аннары кызыллар ягына чыкты. Бабич тотакка эләккән вакытта башкортлар совит ягында инде. Темәстән ни эш беләндер кайтып килгән Шәехзадә агай, кызылларга тап булгач, тимәсләр дип ышанган. Качып-нитеп тормаган, прәме алларына килеп чыккан. Тегене тотып алганнар, җәзалаганнар, ахырда, ат койрыгына тагып йөрткәннәр. Һушын җуйгач, атып үтергәннәр.

Каршыларына йомшак басып килүче Мәҗитне күреп, Сәгыйть сүзнең юнәлешен үзгәртте:

—Мәҗит, сиңа «кәтүк»ләрдән сәлам!—дип, баскычтан үзләре яшәгән икенче катка күтәрелүче кызларга күрсәтте.—Берсе бигрәк синe сорап өтәләнде инде, әллә Пәрвaз булды шунда. «Мәҗит кая, күренми?»—дигән була. Үзенең күзләре ут яна. Нәрсәдер бар монда, мин әйтәм. Хәбәрең тизрәк сиңа житкерим, дим. Юкка сорашмыйдыр, мин әйтәм.

Мәҗит исә китмәгән төсле, кулын селтәде:

—Эһем... «Кәтүк»ләр кайгысы ди монда. Менә хисаптан сабак әзерләп йөрим. Һич баш житми, ике поезд кара-каршы чыга да, берсе кызулап

китә, берсе нигәдер әкренли шунда. Ничә сәгатьтән очрашалар, имеш. Очрашмасалар, ник дөмекмиләр...Ник кирәк инде ул мина? Минем паровоз буласым юк, ләбаса!—дип, кемгәдер бәлаләп, үпкәләп, хәлфәләр бүлмәсенә табан китеп барды.

—Желегенә үтәләр анын, өстәмә дәрескә чакырып,—диде Сәгыйть.— Югыйсә, белмәгәне, күрмәгәне юк, ә хисапка башы житми.

Әхмәтсафанын күнелен кызлар кузгаткан иде. Мәжитнең хисапка үтмәгән башы кайгысымы монда! Ул янә кызлар турында сорашасы итте:

—Ә «кәтүк»ләр дигәнең— кемнәр инде алар?

Сәгыйть көлеп жибәрде.

—Ну, жегет, борынга ис керә башлаган синең. Сала баласы димәссен,— диде, шаяртуыннан канәгатьләнү кичереп.—Кызларны без шулай атыйбыз. Бик тере үзләре. Шүредәге кәтүкләр кебек житезләр, буйга да таманча гына, тулы, таза тәнлеләр. Чак кына кул сузсаң, яшь боландай читкә атылып, чабып китәргә генә торалар. Житмәсә, бар эшкә сәләтлеләр, ул кичәләрдә күрсәң, малай... Иннек-кершәннәр ягып жиффәрәләр, мин сиңа әйтим...Башта—калфаклар, аякта—читек, өстә—бәби итәкле күлмәкләр, прәме, күзләр камаша. Сәхнә уенына хирыслар. Мандолина, пианино уйнап, декламацияләр сөйләп жиффәрәләр, малай... Кичә булган көннәрдә бер генә егет тә үз акылында түгел инде. Һуштан яздыралар, өндә килеш төштә шикелле йөрисең. Төне буе шул кызларны уйлап, саташып чыгасың.— Аннан, елмаеп, Әхмәтсафага күз кысты.—Менә укулар көйләнеп, шәкертләр белән дуслашып-үзләшеп бет әле, үзең дә шул «кәтүк»ләр тирәсендә чуала башларсың, бик мут егет күренәсең. Бәләкәй буйлы жегетләрне кызлар ярата бит. Мусаны күздә тотып әйтүем. Үлчәп баксаң, буйга сина караганда да тәбәнәк иде. Шул бәләкәй генә Муса «кәтүк»ләр тирәсендә йөри торгач, «орчык»ка әйләнде тәки. Кызлар үз иткән егет болай да бер башка үсә ул, мин сиңа әйтим. Һәй, елгыр малай иде Муса. Кызлар сагынып үләр инде. Быел укуга килми ди...

—Ә нишләп килмәскә уйлаган соң ул?—дип сорады Әхмәтсафа.— Аның Муса исемле шәкерт турында ишеткәне бар иде. Әллә ничек, үзен күрмичә үк, күңелне жәлеп итә торган исем иде бу. Серле тоела иде Муса атлы егет. Серле нәрсәне тотып карыйсы, жан иясен күрәсе килә бит инде.—Кайсы яктан иде? Кыргыз-кайсак якларыннан түгелдер ич?

—Мостафадан ул, безнең якташ,—диде Сәгыйть. Муса исемле шәкертне дус күрүе, аның исемен аеруча яратып, үз итеп әйтүеннән сизелеп тора иде.—Шигырьләр дә чыгара. Бабич кебек зур шагыйрь булмакчы. Булыр, нишләп булмасын?! Аңа әдәбияттан Шәриф Камал кебек әдипләр сабак биргән. Безгә генә ул...Әллә нигә быел хәлфәләр пошаманда йөргән сыман. Күп укытучылар мәдрәсәдән киткәннәр. Шуңа аптырап йөрүләре микән?..

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә үз бүлмәләренә килеп керделәр. Сәгыйть астарсыз, жәймәсез буш караватны күрсәтеп:

—Шушында йоклый иде Муса...—диде. Сагыну хисләре тышка ук бәреп чыкты.—Менә бусы да аныкы...—дип, карават башындагы жыйнак кына сандыкка күрсәтте.—Быел әтисе үлгән аның, шуңа килеп житә алмады...Абыйсы Ибраһимны күргән идем беркөнне. Ул «Мөхбир» дигән гәжиттә эшли иде. Аптыраулы кыяфәттә. «Авылга китәргә туры килер, әткәй вафат бит минем.—ди.—Энекәшләрне, сеңелкәшләрне карау минем өскә калды,—дип күз яшьләрен сөртеп алды. Нечкә күңелле егет икән, Муса да шундый иде. Муса соңрак килә, болай булгач. Ну шәп уйный иде мандолинада. Бик тә килештерәләр иде Гайшә белән сәхнәгә чыксалар.

Әхмәтсафа ут борчасы сыман житез, чибәр Гайшә Мөхәммәдиева дигән кызны күреп белә иде инде. Сәгыйть дөрес такылдый торгандыр. Шундый кызның күңелен яуларлык булгач ни, шәп егеттер ул Муса. Кайсы кыз күңеленә охшамаган егет белән сәхнәгә, халык алдына чыгып бассын ди!

Сәгыйть Мусанын ятагына моңаеп карап торды да, артистларча килештереп шигырь укый башлады:

Янгырат илне, алынга чык, себреп ил тапларын!
И уян ил, бу синен инде уяныр чакларын!
Барча хаклык, барча шатлык дөньясы алда әнә!
Әйдә омтыл шул тарафка, анда алга юл ана!

Үзенә әсәрләнеп карап торган Әхмәтсафага, күзен кысып алды да, янә Муса ятагына ымлады:

—Бу декламацияне Муса язган иде. Менә бит, ничек әйтә!..

—Бабичтан ким түгел...

Сәгыйть илһамланып шигырь укый башлаган мәлдә бүлмәгә килеп кергән Фатыйх Сәгыйтов, үзен һәрнәрсәдән хәбәрдар дип санаучы һавалы сыйныфташлары, бердән, Сәгыйтьнең кыланмышын килештерми, икенчедән, Әхмәтсафаның сүзен өнәмичә, иреннәрен бөрештерде:

—Ни нәрсәсе бар инде бу шигырьнең? Бабич, имеш... Инде дә килеп, Тукай хәзрәтләре, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев белән дә чагыштыр алайса. Хәзер һәркем—мөхәррир, һәркем—бәет чыгара. Сәгыйтькә төбәп ике юл шигырь укып алды:

Гаҗәп түгел сабый-илә сабыйлык,
Гаҗәптер әмма гамәлдә габилык.

—Әһә,—диде мәгънәле рәвештә Сәгыйть.—Җегетнең түбәтәй асты бөтенләй үк буш түгел—Дәрдмәнд сүзләре аша безне ангыралыкта гаепләп ташлады әнә. Тик шуны онытма, Фатыйх: Мусаның беренче тәҗрибәләре генә бу. Шәриф абзый аңа зур өмет баглый. Төхфәт Ченәкәй дә олылый үзен. Синен шуна ачуың килә, әйеме?..

Мәҗит: "Таптың ачу китерер нәмә!"—дип мыгырданып алды. Бүлмәдәге ничә шәкертнең ник берсе аны яклап сүз әйтсен. Моны сизеп, отыры ачуы чыкты. Зәһәрләнеп бүлмәне бер әйләнде дә, тагын кемгә бәйләнергә белми, бүселеп чыгып китте.

Сәгыйть, Фатыйхның кыланмышына игътибар итмәстән, Әхмәтсафага борылды:

—Ә син үзең шигырь язмыйсыңмы?

—Юк,—диде Әхмәтсафа көлемсерәп.—Бәет чыгармасам да, яттан шигырь сөйләргә яратам, Мифтах мөгаллим үзе дә әдәбиятны яхшы белә иде, белгәнен безгә дә өйрәтергә тырышты.

Сәгыйть шуны гына көтеп торган диярсең. Икеләнергә урын калдырмый, Әхмәтсафаны кыстый башлады:

—Әйдә, малай, сөйләп җибәр әле берәр шигырь, ач күңелне!

Әхмәтсафа ялындырмады, шигырь укый башлады:

Сызла, сызла, сызла күңлем,
Сызла бер туктамыйча.
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Сәгыйть, елмаеп, кулын Әхмәтсафаның җилкәсенә салды һәм кайнарланып дәвам итте:

Сызла, сызла, син мәхәббәт
Ялкынын гөлләр яса,
Мәңге хәсрәт һәм кара төн
Елларын көннәр яса!..

—Әфәрин, туган! Их, шушы мәлне Сәгыйть хәзрәт Рәмиев үзе күрсә!.. Синең белән яшәргә була.—диде ул, Әхмәтсафаның җилкәсенә кагып.— Әдәби кичәләр башлансын гына, шиксез, сәхнәбездә балкыячак-сың әле! Урын түрдән булыр. Тагын ни гамәлләр беләсең? Ходай бер биргәнгә өеп бирә бит ул...

Әхмәтсафа, мактаудан күңеле булып, тиз генә аяк киемен салып ташлады. Куллары белән идәнгә таянып, аягын төпә-төз өскә күтәрде һәм, барсын да шаккаттырып, җинел генә кулларында йөреп китте. Моны физкультура

дәресләрендә һаман да шул Мифтах мөгаллим өйрәткән иде.

—Булды, житте, малай,—диде Сәгыйть, кулларын шапылдатып.—Синең кебек маймылланучы юк иде әле бездә.—Ул шаркылдап көлеп жибәрде.—Чын артист икәнсең!

Берничә көн үткәч, монарчы хәзерлекнең беренче сыйныфында йөргән Әхмәтсафаны, керү имтиханнары вакытында әйтелгәнчә, икенче сыйныфка күчереп куйдылар. Ул—Гайшәләр укыган сыйныф иде. Үзләрен-нән алдагы сыйныфларда кызлар булмаганга ирәйгән сыман, Гайшә һәм аның ахирәтләре үзләрен иркен, хәтта хужаларга тоталар иде дисәң дә хата булмас. Беренче тәнәфестә үк, иптәш кызын житәкләгән Гайшә, әле сыйныфташларына ияләшеп житмәүдән кыенсыныбрак торган Әхмәтсафа каршысына килеп басты.

—Дустым,—монда укучы кызлар да, егетләр дә бер-берсенә шулай эндәшергә күнегеп киткәннәр иде—ишеттерделәр, оста итеп декламация сөйлисең икән, аннан гимнастик күнегүләр ясарга да маһир диделәр...

—Кем әйтте?—диде Әхмәтсафа, Гажәпкә калып.

—Сүз иясе белән йөрми...

Ул каршысында чытлыкайланып торучы Гайшәнең тел төбен аңлап бетерми иде әле. Ә менә Гайшәнең иптәш кызы...Кызга бер караш ташлау белән Әхмәтсафаның йөрәге жилкенеп куйды. Озынчарак алсу йөзенә, им өчен генә дигәндәй, бераз гына сипкел сипкәннәр шикелле. Шундый сипкелле кыздан да сөйкемле кыз юктыр дөньяда! Кыз үзе дә озын керфекләре арасыннан егеткә бер караш ташлап алган булды. Битендәге алсулык куера төште. Кыз егетнең карашын тотып алып, оялган рәвешле күзләрен түбән текәде.

Гайшә, үзе әйткәнчә, малай-шалай белән аралашып өйрәнгән, Әхмәтсафаның күнел түрендә мизгел эчендә уйнап алган хис өермәсенә исе дә китми, сөйләвен белде:

—Үзешчән сәнгать түгәрәге эшен яңартып жибәрәбез, дустым.—Акыл сатып та алды.—Монда кыш буе таракан симертергә килмәдек, мәгърифәт нуры жыярга килдек. Үзебез йөрмәсәк, бер нәрсә дә китереп бирмәсләр безгә. Менә Заһидә,—ул янәшәдәге кызга жинелчә генә терсәге белән төртеп куйды,—матур итеп жырлый. Бии дә белә...

Заһидә, кашларын жыерып: «Нигә әйттең инде?»—дигәндәй, назлы тавыш белән сузып:

—Гайшә-ә!—дигән булды. Бу сүзләр ахирәтенә кисәтү ясаган кебек яңгырады.—Әле бит...

—Бетте, бетте,—диде, Гайшә көлеп.—Нәрсә жебеп төштең әле Әхмәтсафа алдында? Егетләр күргәнең юкмы әллә?

Тегесе бөтенләй оялып, читкә тартылды.

Гайшә бу хәлгә бик канәгать иде бугай, Заһидәнең беләген тагын да кысыбрак тотты:

—Менә парлашып сәхнәгә килеп чыгарсыз әле, шәкертләрнең күзләрен яндырып! Киләсе атнада түгәрәк эшен башлап жибәрәбез, беренче утырышка Шәриф агай белән тагын берничә кунак чакырабыз. Сез... —Әхмәтсафа белән Заһидә кире уйламаслык итеп әйтәсе килә иде аның. Тавышында катгыйлек чаткылары пәйда булды. —Сез быел концерт-тамашаларны алып баручы булырсыз! Үткән ел кичә саен алып баручы эзләп хәлдән тая идек...

Шушы көннән башлап Әхмәтсафаның күңеле әллә нишләде. Заһидәне гел күреп торасы килә. Үзе генә сизеп бетермәгән: монарчы аның жаны йокымсыраган булган икән бит. Хәзер жаны уянып, дөньясын яктыртып, ямьләндереп жибәрде.

## VIII

Кышкы каникулдан Әхмәтсафаны Оренбурга әтисе үзе китереп куйды. Туры мәдрәсәгә төшермичә, Гомәр агаларына алып китте.

Сирәк кунакларны Гомәр абзый шатланып каршы алды. Шулай да

аның күнеле тыныч түгеллеге күренеп тора иде.

—Сәүдә эшләре кәяләде, Мостафа туган,—диде ул, кунаклар чәй эчәргә утыргач. Мостафаның да йөзендәге сүрәнлекне шәйләп алгач, сүзеннән өзелеп калды.

Мостафаны аңларга була. Гомер буе тире-яры белән эш иткән адәм ич ул. Соңгы елларда бөтенләй сәүдәдән читләшеп калды менә. Шуңа пошына, үз-үзен эчтән кимерәдер, бахыр. Ул гына җитмәде, өйләре янып көл булды, бусы да зур каза. Гомер иткән хатыны үлеп, яңадан өйләнеп, аякка басып кына килгәндә афәткә тарыды шул. Каргалыда янгыннар чыгып торды инде ул моңарчы да. Гомәр үзе дә шаһит, уникенче елгы янгында халык ут-эссегә чыдый алмагач, Сакмарга кереп тулды. Ике сәгать эчендә авылның яртысы янып бетте. Тагын хафаландырганы шул— Мостафаның яуга киткән улларыннан хәбәр юк, ди. Ата кеше моңа да борчыла... Гәҗитләр караштырганда Гомәрнең күзенә чалынды, Усманов төзегән гаскәрләр хәзер Бохара, Хива ханнары белән алышта икән. Гомәрхан белән Госман шунда барып эләккәннәрме, башка җирдәме?.. Исәнме алар, үлеме?.. Кем дә белми. Шушы нәрсәләр Мостафаны тәмам сындырып бетергән булса кирәк. «Бирешкән энекәш, нык йончыган»,—дип уйлады Гомәр.

Әмма Гомәр абзый уйлаган сәбәпләр җитди, бик җитди булса да, Мостафаның эчен тырнаган, йөрәген әрнетеп торган тагын бер сәбәп бар иде—ул Шәмсия..

...Бер көнне Шәмсия ис китәрлек яңалык житкерде:

—Фәтхулладан хәбәр килгән, исән икән,—диде ул, иңрәүле тавыш белән.—Теге Биккол адәмен җир йотсын! Фәтхулланың үлгән хәбәрен китереп, бөтен зиһенемне алды. Җанымны кыйды бит, җанымны кыйды. Үзе дә инде. Ничә еллар хат язмый торды. Менә хат җибәргән. Себердә аклар белән эшне бетердек, озакламый кайтып җитәм, дигән...—Шәмсия сүзен әйтеп бетерә алмады, үксеп елап җибәрде. Мостафа аяк астындагы идәннең кай яккадыр шуыша башлавын тойды. Өй эчендә сүстән бау ишеп маташа иде, кулының җегәре бетеп, яртылаш ишелгән бау идәнгә шуып төште. Хәзер инде аның ни аты юк, ни сәүдә эшләре алып барырга җай бирми бу хөкүмәт—бау ишеп, шуны каладагы бер артельгә тапшырып, көнне-көнгә ялгап яткан мәле иде. Ул беренче мәртәбә шулай текәп, озак кына карап торды Шәмсиягә. Кем җиткергән аңа бу хәбәрне? Фәтхулланың үлде хәбәре килгәненә биш еллап бит инде. Герман сугышына киткән кеше ничек Себергә барып эләккән дә, ни рәвешле аклар белән эшне бетергән ди? Дөрес сөйлиме Шәмсия?!. Әллә Мостафа белән җаннары беркеп җитмәгәнне аңлап, шушы сәбәп белән араны өзү, өйдән чыгып китү җаен карыймы? Ул исәңгерәп, аптырап озак торды. Шәмсия Хәлфетдин юкка чыккач шактый көйсезләнеп йөргән иде. Үртәлеп, хафага төшеп айлар үткәрде. Инде беразтынычланды кебек иде, менә сиңа мә, тагын бер хәбәр. Хәлфетдин өчен Шәмсиянең нигә ул кадәрле эчтән януын, ут йотуын аңлап җитмәсә дә, Фәтхулланың әлеге хәбәре тормышны бөтенләй эздән чыгарасы көн кебек ачык иде. Болай да башны кая куярга белми йөргән чак иде шул. Эшләр әнә кайсы таба бара—авылда гына ничә комитет, ничә совет. Мал-мөлкәтенә хуҗа булып булмый, барсы да советта исәптә. Балаларына да совет хуҗа ди. Бала туса, муллага исем куштырганчы, советка барып баланың исемен яздырып кайтырга дип, әйткәннәр ди. Хатының да үзеңнеке түгел икән инде, әгәр бераз әфсен-төфсеннәп, камчы белән хәләл җефетеннең җеннәрен качырып алсаң—беттең дигән сүз. Совет килеп, аерып та куя. Хәер, Мостафа беркайчан да моның ише белән шөгыльләнмәде, аңа мондый куркыныч янамый кебек. Ну инде әгәр бабайлар ысулы белән җәмәгатенне акылга утыртсаң, хәлләр бөтенләй икенче төс алырга мөмкин. Әйтик, шуннан соң хатының авылдагы хатын-кызлар комитетына чыгып йөгерде, ди. Комитет—советка ишеттерә. Озак та үтми, өенә хәтәр бер комиссия килеп керә. Әгәр комиссия «өшкерү» эшләрен чамадан артык дип тапса, ир кисәген мылтыклы солдатлар озатуында төрмәгә

үк жибәрергә дә күп сорап торыш юк. Бәс, шулай булгач, Шәмсиягә: «Фәтхулла исән»,— дип алдашуның нигә кирәге бар? Теләсә болай да чыгып китә. Мостафадан курыкса, сәвит яклавына исәп тота ала. Ирләрнең генә бер хокуклары юк менә. «Китәм»,—дисә, каршы төшеп булмый...Алай түгел икән шул. Янында йөргәндә генә кадерен тоймаган Шәмсиянең. Хатын ана үз аягы белән килеп кергән мал сыман тоелды, ахры. Андый малның кадере булмый бит. Менә инде икенче мәртәбә шундый тойгы кичерә: беренче тапкыр унтугызынчы елның язында, алмагачлар чәчәккә төренгән иртәдә бар күңелен айкап ташлаган иде шушы сүз. Инде менә бүген... «Фәтхулла» дип авызын гына ачкан иде, Мостафа коелды да төште. Унтугызынчы елны, ул көнне авылда янгын чыккан иде. Бу юлы инде ут Мостафаның йөрәгенә капты. «Фәтхулла исән...Димәк, кайтып керәчәк ул көннәрдән бер көнне. Ни дип җавап бирер?.. Шәмсия ни кылыр? Шушы минутта ана Шәмсиядән дә кадерле кеше юктыр сыман тоела башлады. Булганда гына кадере беленми икән, югалта башласак...

Шәмсия элек тә Фәтхулланың инде олыгаеп барган әти-әнисен, ягъни биатасы белән бианасын ташлап бетерми иде. Таба ашы пешерәме, гает көннәре буламы, йә башка бәйрәмме—тәмле ризыктан калдырмый иде аларны. Фәтхулладан хәбәр алгач, көн саен диярлек Каргалы очына—башта килен булып төшкән йортка китеп югала. Шунсы бар, бер чакта да Бибкәйне үзеннән калдырмый, әллә ниләр сөйләшә-сөйләшә көлешеп чыгып китәләр, күтәренке күңел белән кайтып керәләр. Мостафаның ут йотып йөрүе әллә бар Шәмсиягә, әллә юк. Хатынның күңелен башта ук табарга тырышмавының әҗере инде бу, дип, Мостафа тешен кысып булса да түзде, эчендә кайнаган ярсуын тышка чыгармады. Хәер, өйдә кара тавыш кубарып ни кыласың? Әле бит бу хакта юньләп сөйләшкәннәре юк.

Мостафа һич кенә уйларыннан айный алмый. Әйтерсең, менә шулай уй эчендә изаланып утырыр өчен килгән Оренбурга. Үз-үзен җинеп, уйларын куып, тиз генә кире кайтмаслык итеп олактырып бетерә алмады тәки. Һаман шул Шәмсия сәбәпче. Урыннына купкан җанын янә бер нәрсә борчый—ул да булса, соңгы вакытларда Әхмәтсафага кырын карый башлады Шәмсия. Исен китәр, башка хатыннар артык сәвитләшеп барганда, Шәмсия ничектер, моңарчы күзенә артык бәрелми иде, үтә диндарланып китте. Әхмәтсафа турында сүз чыкса, Мостафага бәйләнә башлый:

—Динсез, имансыз булып үсә ул малаең!—ди ул, зәһәрләнеп.—Анда Оренбурда «Хөсәения» мәдрәсәсе дигәннең иседе калса да, җисеме калмаган икән. Яшьләрне җыеп, урыс ясап яталар икән хәзер. Кеше арасына керер хәлем юк, абыстайлар, ил карчыклары күземне ачырмыйлар. Мостафага әйт, күрә торып, баласын диннән яздыра, диләр. Авылда яшьләр котыра, кәмсәмүл төзибез дигән булалар. Төзерләр, төземи сон—саман сугып, өй житкереп керәсе түгел бит. Әхмәтсафа кайтса, шулар белән мәш килә. Дәүлине ак йортыннан куып чыгарган сәвит. Шул йортны яшьләр ызбасы иткәннәр. Кайткан саен, шунда кичә-мичә оештырып, декламация сөйләп, яшьләрне котырта, юлдан яздыра, дип, сөйлиләр. Яшьләр ызбасы түгел ул, имансызлар ызбасы! Син ичмасам, Әхмәтсафа белән нык кына сөйләшәсе урынга, шуның кыланмышларына бер кәлимә сүз әйтмисең,—дип колак итен ашый.

Мостафа ай—ай ярым эчендә танымаслык булып үзгәргән хатынын тынычландырмакчы булып маташа:

—Дөньялар гел башка бит, карчык. Әхмәтсафаны тыям дип, өйдә бикләп яткырып та булмый. Элекке тормыш кайтса икән дә...Юк инде, кайтмас. Илне нигезеннән үк җимерделәр. Мин кәсептән колак кактым, Әхмәтсафа шушы тормышка җайлаша алмаса, нишләрбез соң без?.. Безнең нәсел гомер-гомергә сәүдә кәсебендә булган. Мәчеткә тиешле садаканы биреп бардык. Мулла-хәзрәтләр тел-теш тидермәде безгә, иман юлыннан язасыз дип әйтмәде, Ходайга шөкер. Әхмәтсафа да динсез булмас, яшьлек чор үтәр, эзгә төшәр ул. Яшь чакта була инде ул. Әле хәтеремдә, яшьлектә, никрут булып йөргән чакта, олы хәзрәтнең өй турыннан кич җырлап үткән идек:

Турыгыздан жырлап үттек,
Ачуланма, хәзерәт.
Яшь чактагы җүләрлекне
Беләсен бит әзерәк.

Иртәнге намазда әткәйгә шелтәләп кенә әйткән хәзрәт. Тавышны зурга җибәрмәде тагын. Элек тә яшьләр шулай хикмәт чыгарып куялар иде. Әхмәтсафа да бу шаукымланып йөргән ташлар... Менә Гомәрхан, Госманы кайларда, хәбәр-хәтерләре юк. Сугышлар да бетеп бара бугай, илгә кайтучылар ишәйде, юк, малайлардан хәбәр, юк кына...—дип, сүзгә нокта куйган иде ул чакта Мостафа. Шунсы кызык, әлеге сөйләшүдән соң Шәмсиянең диндарлыгы да чигә төште...

Әмма сизеп тора, Шәмсиянең Әхмәтсафага карата булган карашын үзгәртеп бетерә алмады. Нигәдер Әхмәтсафа да Шәмсиягә якты чырай күрсәтми. Моны Әхмәтсафаның яшьлегенә аударып кына да бетереп булмый. Мостафа аңлап бетерә алмый иде. Күрәсең, элекке елларны, ул озаклап өйдә тормаган чакларда, бу ике Ходай бәндәсе арасыннан кара мәче узган да, инде һич кенә дә бер-берсен кичерә алмыйча иза чигәләр. Берсе карый, берсе сабый, әмма бер-берсенә юл куймыйлар гына бит. Әхмәтсафа ипле холыклы болай карап торуга. Шәмсия егеттән күрә бугай гаепне. Мостафа егетне битәрләргә ашыкмады. Гаеп табасың килсә, әүлиядән дә табарга була торгандыр аны. Кешене болай гына динсезлектә гаепләп тә булмый. Кем динле-иманлы, кем кяфер, кем туры юлда, кемнең кыйбласы дөрес—боларны бер Ходай гына белә. Башкаларны имансызлыкта гаепләгән кеше беренче чиратта үзе денсез-имансыз түгел микән әле? Боларны Шәмсиягә әйтеп тормады инде Мостафа...

Чәй эчеп бетергәнче Мостафа шулай үз уйларына чумып, Гомәр абзыйның сүзләрен колак тирәсеннән шудыра биреп тик утырды. Гомәр абзый берара Мостафага күз ташлап алган иде, тегесенең уйлары белән бу өйдән шактый ерак җирләрдә йөргән аңлап, хәсрәтле генә көлемсерәп куйды. Моны сизеп алган кунак, башын түбән иеп, сансызлыгы өчен гафу үтенгәндәй итте.

Әхмәтсафа чәен эчеп бетереп, өлкәннәрне көтеп тормастан амин тотты да, түр ягына чыгып, ниндидер китаплар актара башлады. Гомәр абзый белән Мостафа агай, өстәл яныннан кузгалмадылар. Чын әңгәмә яңа башланып кына килә әле. Алар еш очраша алмыйлар, очрашсалар серләре килешә иде монарчы.

—Егетне укытырга кирәк,—диде Гомәр абзый. Мостафа өйдәге хәлләрне сөйләп бирмәсә дә, нәкъ кирәкле җиргә китереп басты. Һаман да үги әнкәсе каршы килсә, Мостафа Әхмәтсафаны бер-ике ел көнлекче итеп йөртү ягын да уйлап куйган иде.—Егетнең үзенә дә әйттем, дөньялар ничек кенә болганса да, барыбер безнең нәсел арбадан төшеп калмады, иҗтиһад иттек. Патшага да ярадык, санатка да ярадык, сәвит белән дә телгә килмәскә кирәк. Мин шулай уйлыйм. Шунсы бар, сәвит башта халык дип күп шаулады шаулавын. Хәзер башкачарак сайрый. Сәвитнең төп таянычы—ярлы-ябагай, имеш. Йә, әйт, әгәр иҗтиһад итә торган булса, гыйлемле, мәгърифәтле булса ярлы, гидай булып йөриме бәндә?

Мостафа «юк» дигәндәй, башын чайкап куйды.

—Үзең йөрмәсәң, Ходай китереп бирми инде,—диде ул әкрен генә.—Шунсы гына эчне тырный—яшьләрне мәчет-мәдрәсәләрдән читләштереп, диннән аерып, хөкүмәт ни-нәрсә уйлый икән? Имансыз бәндәләр белән тормыш корып булыр дип саташа микән? Без сәүдәгәрләр, дингә ябышып ятмасак та, шөкер, иманнан язмадык ансы.

—Сәүдә ул, Мостафа туган, пәйгамбәрдән калган шөгыль. Бер надан: «Шайтан башка, җен башка,»— дип әйткән, ди. Большевиклар тәүге нәүбәттә мөселман дип гаскәр тупладылар, хәзер мөселман дигәнне инкарь итеп, эшче-крестиян дип кенә җибәрәләр әнә.

Мостафа сүзгә кушылды:

—Мөселманнарны бергә туплап, кызыл гаскәр оештырып йөргән Усманов дигән адәмнең сөйләгәне истә. «Без— большевиклар... Мөселманнарга һәръяклап ирек бирү өчен көрәшәбез,»—дип әйтә иде ул.

—Хәйрулла хәлфәнең малае инде ул,—диде Гомәр абзый көлемсерәп.—Әткәсе укымышлы, белдекле хәлфә иде, улы коммунсит булды да куйды. Әнә Бохара якларын пыр туздырып йөри икән хәзер. «Диннең оясын тар-мар итәбез!»—дип язганнар гәҗиткә.

—Бохарага ук барып җиткәннәр, диген. Коммунист белән большевиклар дигәннәре ничегрәк соң аларның? Кайсы яхшы, кайсы начар безнең өчен? Дингә кайсы каршы?

Гомәр абзый йөзен чытып куйды да, җитдиләнеп җавап бирде:

—Ике чабата бер кием, Мостафа туган. Халыкны гомер иткән диненнән яздыру өчен Ленин-мөртәт икенче дин—большевизм динен уйлап тапты. Хәзер халыкның аңына шушы алласыз динне сеңдерәләр. Бутала халык, кыйбласын югалта. Иң куркынычы шул. Бер мәртәбә динен, иманын сата икән бәндә, аның белән теләсә нишләп була. Ленин моны яхшы аңлый, шуңа күрә, әнә син бая әйткәнчә, яшьләргә каныкты да ул. Ил буенча яшьләр төркемнәре төзелә. Гәҗитләрдән укып барам—унышка ирешәләр дә булса кирәк. Кабат әйтәм, Әхмәтсафа дөрес аңларга тиеш,—ул түр якта утырган егеткә төбәп, сүзен дәвам итте,—гыйлемлелек бер нәрсә, әмма иманга хилафлык китерәсең икән, моны бер нәрсә белән дә аклап булмаячак. Дәүләтъяр нәселе бу якларга Нократ Иделе тирәсендә көн иткән җирләреннән кубарылып, чукындырудан качып килеп чыккан. Өлкәннәрдән калган хәбәрләргә караганда, борынгы бабаларыбызның берсе Казан артындагы Арча төбәгендә сәет булган. Сәет инде ул—димәк пәйгамбәрләребез Мөхәммәд нәселеннән дигән сүз. Менә без нинди нәсел!—Гомәр абзыйның тавышында горурлык чаткылары бар иде.—Бүгенге ыгы-зыгы үтәр ул. Ил имансызлык юлыннан китсә—алда халыкны афәт көтәчәк. Бу афәт бүгенге яшьләр өстенә ишелеп төшәчәк. Әгәр шушы түнтәрелеш чорында халыкның җаны, рухы имгәтелмәсә, дин-иман зәгыйфьләнмәсә, бәлки киләчәккә өмет калыр, рәт чыгар андый илдән.

—Әле ансы кайчан булыр?.. Син әйтә башлаган идең, Гомәр абзый, шул нәрсә күнелдән китми генә бит: ярлы-ябагайга таянып илне алга алып барып буламы, җә?

—Дөрес, туганым. Ярлы-ябагай—булганны әрәм итәргә, бирсәң алып, бирмәсәң талап көн күрергә маһир. Гәҗитләр язганны укып, шаклар катып утырам инде. Солтангалиев дигән кеше, Ленинннан фатиха алып, башкорт, татар авылларыннан мәҗбүриләп икмәк җыя икән. Борын төбендә язгы чәчү. Үткән ел, үзең беләсең, елы әйбәт килсә дә, безнең яклардан зур яулар үтеп, игеннәрне басуы-басуы белән юкка чыгардылар. Көлтәгә куйган игенне ут төртеп харап итеп бетерделәр, адәм имгәкләре. Кызыллары—акларга калмасын дип, аклары— кызыллар кулына эләкмәсен дип тырыштылар. Инде шул ут—давылдан калган икмәк өлешен дә тартып алалар хәлле крестьяннан. Ярлы—ябагайга аңа нәрсә: амбары юк, амбары була калса, анда им өчен икмәге юк. Җәй буе тамак ялына кешегә эшләп гомер үткәргән бит ул. Хәллерәк хуҗалыкларны талыйлар Солтангалиев гаскәриләре. Продразверстка дип атала ул хикмәт. Инде ике ел крестьянның башын күтәрергә ирек бирми шул хөрәсәннәр. Кеше талап көн күрергә маташкан бәндәләрне хөрәсән дими, ни дисең?..

—Прод...продра...

—Продразверстка,—дип, кабатлады Гомәр агай.

—Тел сындырмалы, иеме?.. Хәлле кеше бөлсә, ярлы-ябагай да ачтан интегәчәк бит,—диде Мостафа.—Хөкүмәт шуны белмиме?

—Бәлки, беләдер дә... Бәлки, акыллары җитмидер. Татарның ярарга тырыша торган яман гадәте бар. Урыс хөкүмәте икмәк җыярга куша, вәссәләм. Ул үзе татар, башкорт авылындагы хәлне килеп карамаган. Урындагы түрәләргә ышана ул. Мондагы хәлне Солтангалиев аларга караганда биш мәртәбә яхшы белә, ә бит урыс җырын җырлый, имеш: татар—

башкортның амбарын, гаскәр белән килеп, чистартып алып китә. Язга ничек чыгар халык, җәй ничек булыр, иген унармы? Ансын кем уйларга тиеш микән?.. Крестиян халкы зирәк бит ул. Хәлле, булган хуҗа, беркайчан да соңгы капчыгын чыгарып селкемәде, елдан—елга мая калдыра килде. Иң афәтле елда да, әле исемдә, моннан утыз еллар элек корылык булды, илгә ачлык килде. Татар, башкорт шул маясы аркасында кырылып бетмәде. Патшадан ярдәм булмады диярлек, үз байларыбыз коткарып калды халыкны.

—Ходай сакласын инде,—дип, җөпләп куйды аны Мостафа.—Бу хөкүмәтнең кыланганнарын карап торам-торам да, йөрәкләр җу итеп китә. Өметле түгел сыман... Бер дә эчкә җылы йөгерми, Гомәр абзый.

—Сәүдәгәрләребез кайсы кая таралып бетте,—диде Гомәр абзый һәм түр яктан бер китап алып чыкты. —"Торгово-промышленная Россия" дип аталган, 1899 менә бу китапка сәүдәгәр буларак мине дә теркәп куйганнар иде,—диде ул, нәкъ баягыча ачы көлемсерәп. Китапның каурый кыстырып куйган битен ачып, кычкырып укып күрсәтте.—Давлетъяров Гумер, дигән, Оренбургский уезд, дигән,—Сәет бистәсеннән дип күрсәтелгән. Менә безнең сыман урта кул сәүдәгәрләрне дә бөртекләп җыйдылар элек...Кая хәзер безнең сәүдә йортлары? Тартып алдылар...—Гомәр абзыйның күзеннән яшь атылып чыкты.—Мин халыкка аң-мәгърифәт бирәм дип, күпме китап, гәҗит тараттым бушка. Һәр кибетемдә китап сата торган бүлекләр оештырдым. Минем эшнәләрем Гаяз хәзрәт Исхаков, Галимҗан Ибраһимов, Рәмиевлар иде. Кая ул вакытлар? Ни өчен шәкертләр хәзер бер китап алырга тилмереп йөри? Мин инде карт кеше, яшьләр нишләр? Кая менә бу китапта күрсәтелмәгән шөһрәтле Хөсәеновлар, Кильдияновлар, Динмөхәммәтовлар?.. Гобәйдуллиннар, Әҗемнекеләр кая китеп беттеләр? Кая аларның мал-мөлкәтләре? Рәмиләр алтын приискаларын хөкүмәткә биреп котылмакчылар иде, ни булып бетте? Хәзер Дәрдмәнд—атаклы миллионер, шагыйрь кая барып бәрелергә белми каңгырап йөри...

Мостафа эндәшмәде.

—Юк, туган, бу юл белән барып булмый.—диде Гомәр агай әрнеп.—Малны талап, әрәм-шәрәм итеп түгел, булганны саклап, халыкны тагын да мөлкәтлерәк, маялырак итеп кенә ил алга бара ала. Шулай булмаса, синең сүзең дөрес—өмет юк...

Мостафа, Гомәр агайның әрнүле сүзләреннән соң, гел бетереште кебек. Йөрәгенең иң түрендә ярсулы хисләр кайный, җаны бәргәләнә. Гомәр абзыйсы да авыр уйлардан ялгызы кыйналып яшәп ята икән бит. Ни дип юатырга аны? Юк шул, юатыр, тынычландырыр сүз таба алмый ул.

Гомәр абзый янә сүз башлады:

—Ил-көн алдында йөз аклыгы булырлык гәҗит—мәҗмугаларыбыз бар иде.. Кая китте «Вакыт», «Шура» кебек мәҗмугаларыбыз? Аларга алмашка ни чыга? Тәгәрәп үләрсең, «Юксыллар сүзе», «Мөхбир»...Кемнәр эшли андый гәҗит-мәҗитләрдә, кемнәр нәшир итә? Җыен гидай, җыен надан гәҗит чыгару эшенә керешге хәзер. «Юксыллар сүзе»н сөйләп йөреп халыкның аңы үсәрме, юкмы?—Үзенә үзе җавап та бирде.—Тамчы да үсми. Безнең мәҗмугаларыбызда мәртәбәле, шөһрәтле галимнәремез эшләде. Халыкка мәгърифәт нуры тараттылар алар. Шуларны укып-үгрәнеп халыкка аң керде, иҗтиһад итеп, җир эшенә, сәүдә эшенә күңел бирә башлады, татарның башкалардан ким булмаганлыгын расладык, кеше арасына кердек. Ә бу хөкүмәт нишли? Хәлле крестиянне юксыллар рәтенә төшерә. Шул да булдымы һөнәр?!.

Әхмәтсафа өлкәннәрнең сөйләшүләрен, бигрәк тә Гомәр абзыйның рәнҗүдән кызарып-бүртенеп хәзерге хөкүмәтне тиргәвен килештермичә, аның сүзләренә үзенчә бәя биреп утырды. Күп сүзләрнең үзенә карата әйтелгәнен, аның хәтеренә салып куярга омтылып сөйләнгәнен дә аңлый иде ул.Мифтах хәлфәнең шәкертләренең җавабыннан риза булмаган чакларда шаяртып әйтә торган сүзе бар: «Дөрес!..—ди ул, кистереп. Бер тыннан соң өстәп куя,—ләкин алай түгел ул...»

Өлкәннәр һич кенә дә хәзерге зур үзгәрешләрнең асылын аңлый

алмый һәм аңлый алмаячак та дип уйлый иде ул. Каникулга таралыр алдыннан институтка губкомнан вәкил килеп: «Әле революция яңа башлана!»— дип, чыгыш ясаган иде. Аның сүзләре аңлаешлы иде, ичмаса. Бөтен кеше дә тигез, бәхетле яши икән, моннан кемгә зыян?.. Йә әйтегез, начар сүзләрме бу? Бөтендөнья эшчеләре, бүгенге әңгәмәдә еш янгыраган ярлы-ябагайлар көрәшкә кушылып бетсәме?! Яңа инкыйлап кирәк! Аң, җан инкыйлабы. Шул чакта гына илдә яңа тәртипләр урнаштырып булачак. Яңалыкка һәрвакыт каршы чыгучы табыла. Әле дошманнарны тар-мар итеп, бөтен дөньяда пролетариат диктатурасы урнаштырасы бар. Институтка партия—совет курсларында дәрес бирүче укытучылар да килеп йөриләр. Бигрәк тә Заһид Шәркый кебек ихластан яңа тормыш өчен янып йөрүчеләрнең чыгышлары йөрәккә май булып ята. Яңача яшәүнең никадәр матур, шатлыклы һәм хөр булачагы хакында сөйләп, институт шәкертләренең күңелләрен җилкендереп китәләр алар.

Гомәр агай белән әткәсе Әхмәтсафаны тора салып инкыйлапчы булып китте дип уйлыйлар икән—ялгышалар. Иске тормышның бар «ләззәтен», «рәхәтен» үз җилкәсендә татымадымы ул?!. Янгыннан соң өйсез калып, Таифә карчыкның тавык кетәклеге кадәр йортында иза чигүләрен исенә төшереп, йөрәгенә кан сава. Әтисе: «Дөньяның тоткасы—сәүдә эше!»—дип йөрде моңарчы. Сәүдә гөрләп бармаса да, бөтенләй гаиләне ким-хур итмәде ул. Ил-көннең тынычлыгы киткән иде, сәүдә эшенең дә көе китте дә куйды. Димәк, бу юл ышанычсыз булган. Җирләре аз, булган кадәресеннән дә уңыш җыеп алып буламы, юкмы—елның ничек килүенә карый. Өлкәннәр моны Ходай кулында диләр. Аларның гаиләсе авыр тормышта яши хәзер. Кемгә дә ярдәм сорап барышлы түгел: элекке сәүдәгәргә ярдәм кулын сузам дип торучы булмаячак. Дөрес яшәмәгән әткәсе. Кәсепчелек итүнең дөмбере менә кайчан килеп чыкты. Югыйсә, үз көчләре белән тормыш иттеләр. Моңа күз йома яңа хөкүмәт. Аңлашылып бетми бетүен. Яңа хөкүмәт дигәннәре дә авылдашлары бит. Кечкенәдән байларда ялланып эшләде. Эшләгәненең әҗерен ала башласа, кимсетелүләргә дучар булуын кычкырып сөйләп йөрсенме инде?.. Сөйләсәң, сөйләрлек бар ансы. Подрядчик Гарифта ике ел рәттән сал агызуын әйтсенме? Өлкәннәр белән беррәттән авыр бүрәнәләрне күтәрүен искә алса әле дә бәгыре сулкылдап куя. Юеш бүрәнәләрне заводка озатуы җиңел түгел иде. Әхмәтсафа башкаларга караганда ике-өч мәртәбә артык эшләп ташлый иде. Шулай булса да, эшен килештермәгән булып, Гарифның үзенә кырын каравын, өй салып керү өчен утыз бүрәнә бирергә тиеш булып та, берсен дә бирмичә, һаман киләсе елга калдыра килүен, шуның өчен үги әнкәсе Шәмсиянең егетне булдыксызлыкта, ә әткәсе Мостафаны кеше белән уртак тел таба алмауда, сөйләшә белмәүдә гаепләп, өйдә тавыш чыгаруларын искә төшерә дә, бүгенге вәзгыятьтә Гомәр абзыйның сүзе түгел, ә Заһид Шәркыйның бәхетле киләчәк хакында сөйләгәннәре өскә чыга иде. Киләчәк хакындагы сүзләр егетне җилкендерә, аңа канатлар өсти. Көнлекче булып та, казакъ якларыннан тире-яры җыеп, сәүдәгр исеме күтәреп йөреп тә мантып булмаячак. Илдәге һәр нәрсәгә хуҗа булып алсак кына, өметле һәм ышанычлы юлга чыгарбыз. Ул чагында инде ярты елга бер күргән туганың белән сөйләшергә сүз тапмый көне буе зарланып, өметсезлек сазлыгына батып, җәфа чигеп утыру булмас. Бик тә өметле сыман тоела аңа киләчәк. Алда—аларны якты еллар көтә! Шуларны белә торып, ничек күңелсезләнеп утырасың, ди?! Ул татлы хисләр иркенә бирелеп, киләчәк хакында хыялга чумды...

*Ахыры бар*



## Газинур Морат

### ИЛЕМНЕ УЙЛАП КИЛЕШЕМ...

### Типке

Мин—кешеләр арасында
Адашып йөргән малай—
Җитәкләп киләм уемны,
Уем, гүяки, маэмай.

Әле алга ыргыла ул,
Әле борыла артка.
Әле өрә, әле ырлый,
Әле чабудан тарта.

Әле җиргә ятып ауный,
Әле текәлә күккә.
Һаулый башласа, башына
Кешеләр тибеп үтә.

Юатам үзен: сабыр бул,
Каударланма, дим, алай.
Кешене исеннән түгел,
Хисеннән таны, маэмай.

Эт типкесендә йөрсәң дә,
Иленә илермә син.

---

Газинур МОРАТ *(1959) —шагыйрь, публицист. «Мин дөньяны тыңлыйм», «Җир хәтере», «Түбә» һ. б. шигырь китаплары авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

Кешеләр тотып, үзеңә
Борынчык кидермәсен.

Ил типкесендә йөрсәң дә,
Тибәреп булмый илне.
Ул үзе дә—нәкъ синең күк—
Муенчак кигән инде.

Мин үзем дә—нәкъ синең күк,—
Типкедә йөргән малай—
Илемне уйлап килешем,
Уем, гүяки, маэмай.

## XX гасырга эндәшү

Нинди әрсез дөнья—
Гүя ямьсез хатын.
Ә син шуның белән
Бер ятакка яттың.

Бер табактан булды
Җыйган тәгам-ашың.
Бер үк газап чиктең,
Бер үк йолдыз ачтың.

Бер мунчага йөрдең,
Бер ләүкәгә мендең.
Бер табага салып
Кыздырдылар телең.

Бер үк тимер кыршау
Кыса барды башың.
Бергә гүргә иңдең,
Бергә күккә аштың.

Ә ятакта инде
Ауный яңа гасыр...
Безнең гомер, әйдә,
Бәет булып калсын.

## Останың китүе

Йомычка кебек кыела,
Чәер күк эри көннәр...
Вакытның тәрәз йөзлеген
Иртәгә ясар кемнәр?

Тәрәз уемы шикелле
Уелган безнең чикләр.
Иртәгә туфан калыкса,
Нух көймәсен кем сипләр?..

## Дәрдемәнд кабере

*Сүнеп, вәйран булып мәгъмур тияклэр,*
*Җир астында тезелде ку сөякләр!..*

Дәрдемәнд

Кара йөзләр кабат ил өстенә
Кызыл бурзайларын өстергән.
Империя дигән каток узган
Бакый йортның таптап өстеннән.

Җилләр генә түгел—
Зилзиләләр
Юган эзне... юган хәтерне.

Ярый әле Вакыт отып калган
Шигърендәге һәр юл-сәтырне.

«Комлар» гына түгел—
Кубарылып
Ташлар күчкән... кабер ташлары...
«Ку сөякләр» түшәп ил багына,
Илгәсәрләр җирне ашлады.

Илдә калган Гариб...
Байгыш Сагыш
Тоткандыр шул... илдә туңса да...
Шагыйрьләрнең язмышлары уртак—
Бай булса да, гидай булса да.

## Мономах бүреге

*Марсель Галигә*

Алтын Урда!
Азмы алтыннарың
Әверелгән ятлар күркенә.
Бүркең булса, бүре баласын да
Салып йөртер идең бүркеңә.

Син—курганнар кебек яланбаш шул,
Ялган баш шул безнең чорга да.
Бүрегеңдә, әнә, каракошлар
Ике башлы бала чыгара.

## Нигез

Сыркыдыда сыктап торганым бар
Хәйрүш әзи Такташ нигезендә.
Шайтан таяклары шыбырдашты:
—Бу нигездә калдык тик без генә.

Казанымда кузлар йотканым бар
Күктән сөрелгәннәр эргәсендә.
Шагыйрь булып ташлар ыңгырашты:
—Без һаман да тәкъдир төрмәсендә.

Тәкъдир булып туфрак пышылдады:
—Язмышыннан узмас берегез дә.
Нигезеңне саклап калыйм дисәң,
Күкләр белән кирәк берегергә.

## Төнге әверелеш

Икәү яккан учакмыни—
Чатыр-чотыр төн яна.
«Кемнәр ярын кемнәр сөймәс
Бу вафасыз дөньяда»,—
Дип җырлаган җилле чаклар
Бар иде бит безнең дә...

Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә.

Керфекләрең йомылганда
Дертләп куям, сискәнеп.
Сулышыңнан ишетелә
Җилбәзәк җил искәне.

Күкрәкләрең гүя гөрзи,
Кулың гүя айбалта.
Шүрәледәй шәрә шәүләң
Йөри дивар буйлата.

Таш диварга сеңә бара,
Сыза бара сурәтең.
Икәү яккан учак кебек
Шыпырт кына сүнә төн.

Карашыңда—таң салкыны,
Өши барам, өшәнә...
Һәрчак шулай: шом баса, әй,
Яшьлек искә төшә дә.

Җилле чаклар, тиле чаклар
Бар иде бит безнең дә.
Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә...

## Интернет

Санаклыны гына санлый дөнья,
Таный дөнья, аңлый... аңлаша.
Кырын ятып илләр чөкердәшә,
Безгә—кызык, безгә—тамаша.

Ил-халыклар лөгать-тел алмаша,
Аңлашканга иңә бәрәкәт...
Дөнья белән тынышырга була,
Ут-күршеләр белән—мәрәкә...

## Диптих

### 1. Картлар йорты

Дөнья кадәр сагыш сыйган монда,
Дөнья кадәр кайгы сыенган.
Дөньялыкта сый-тәгамең калса,
Шөкер, Ходай өзми сыеннан.

Дөнья көтеп арган карт-корының
Исе китми монда юк-барга.
Сагыш эчеп сусауларын баса,
Кайгы йотып ята йокларга.

Ә балалар
дөнья
куып
уйный
Дөнья дигән сары йортларда.

## 2. Җиһангирлар кәрт суга

—Сезгә дә булсын тамаша,
Безгә дә булсын кызык,—
Чыңгыз хан белән Бонапарт
Кәрт суга кызып-кызып.

—Ә син, Леонид Ильич,
Торма кызыкны бозып.

—Бөек җиһангир кылычын
Бик җиңел димсең әллә?

—Тузны да каплый алмагач,
Король түгел син,—кәрлә!

—Ә син, Гайсә, чәпчемә,
Үзең дә безнең хәлдә.

—Дөньясына баш булгач та,
Ник баса икән нужа?

—Олуг казый әйтеп бирсен:
Кем бу җиһанда хуҗа?

—Башөсте, Корыч бабай,
Хөкемең чыгар, давай...

## Йөзьяшәр карт сүзе

Бу дөньяда яши-яши
Мин тик шуны аңладым:
Кешедән көшел коела,
Ком коела аннары.

## Берәүгә

Буең озын, уең кыска,
Алдашасың хәйран оста.
Бар булмышың белән лаек
Бу илдә син һәрбер постка.

Шуңа да син бик көрсенмә,
Утыра бир көрсиеңдә,—
Дөрес булыр ялганың да,
Үрчи торыр яраның да.

Син хаклыдыр: йә, бу илгә
Хак сөйләгән тинтәк нигә?

Син хаклыдыр: илдә, димәк,
Ишәйгәндер синдәй имгәк...

* * *

Кошлар китә кәрван-кәрван—
Агачлар елап кала.
Без китәбез берәм-берәм—
Уйланып еллар кала.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

## БЕРЕНЧЕ КҮРГӘН «ТЕРЕ» ЯЗУЧЫМ...

*1951 ел. Минзәлә педагогия училищесында укып йөргән чаклар.*

*Безнең үзебезгә күрә әдәбият түгәрәгебез дә бар. Житәкчебез—Мөхәммәт абый Гарифуллин. Ул үз заманында, әле сугышка кадәрле үк, Казан дәүләт педагогия институтында Сибгат Хәкимнәр белән бергә укыган, аның белән тулай торакта бер бүлмәдә яшәгән, үзе дә шигырьләр язгалаган, әдәбиятка үлеп гашыйк кеше иде.*



*Көннәрдән бер көнне ул класска гадәттәгедән дә артыграк елмаеп, балкып килеп керде. Мөхәммәт абый кергәндә гел шулай елмаеп керә иде, ә бу юлы йөзендә ниндидер серлелек тә бар төсле тоелды. Әлеге серен озак саклый алмады ул, өстәл янына килеп баскач, әйтеп салды:*

*—Укучыларым, беләсезме, Минзәләгә «Яшь сталинчы» газеты хәбәрчесе шагыйрь Әдип Маликов килгән бит,—диде.*

*Минем инде Минзәләнең «Ленин байрагы» газетында берничә хәбәрем, хәтта бер-ике шигырем дә басылган иде. Урынымнан ничек сикереп торганымны сизми дә калдым:*

*—Мөхәммәт абый, чакырыйк аны түгәрәк утырышына!—дип кычкырып җибәрдем.*

*Мөхәммәт абый, гадәтенчә, сабыр гына елмаеп җавап бирде:*

*—Ул кадәр каударланма, Шабаев. Чакырырбыз, килер...*

*Килде Әдип абый безнең түгәрәк утырышына. Әллә ни калку булмаган, юкарак кына чәчле бер кеше икән. Пинжәгенең күкрәк кесәсе өстендә бер орден-медаль планкасы да бар иде шикелле. Бәхеткә дигәндәй, ул сугышны Ерак Көнчыгышта—Сахалинда үткәргән. Японнарга каршы торган икән.*

*Мөхәммәт абый исемнәребезне әйтеп безне таныштырып чыкты. Газиз Мөхәммәтшинга килеп җиткәч, Әдип абый:*

*—Ә-ә, беләм! Гали Хуҗиев синең бер хикәяңне «Үсү юлы» альманахына тәкъдим итте. Көт, чыгар,—диде.*

*Без, әлбәттә, Газизгә кызыгып карап куйдык. Мин исә, исемемне әйткәч, торып бастым да бер шигырь укыдым бугай...*

*Әдип абый безнең белән бик гади генә сөйләште, хатыны Саҗидә апаның Вахитов исемендәге урта мәктәптә тарих укытканын да әйтте. Мин, ничектер, аңа бераз көнләшеп карап утырдым: менә бит нинди бәхетле кеше, сугышлардан исән-сау әйләнеп кайткан, ә безнең әтиләр ятып калды, кайта алмады шул... Әтиемә багышланган «Сине эзлим» дигән поэмам күңелемдә шул чагында туа башлагандыр, мөгаен...*

*Әдип абый безгә юка гына «Атаудагы хисләр» дигән китабын да кыстырып килгән икән, шуннан берничә шигырен укыды. Сахалин... тайга... японнар белән сугыш сулышы...*

*Язучы Әдип Маликов белән танышу шулай башланып киткән иде. «Уза гомерләр, аккан су кебек...», шагыйрь әйтмешли. Без танышканда аңа әле утыз гына яшь булган икән! Ә хәзер—сиксән... Алар артыннан без дә картаеп киләбез...*

*Әдип Маликов аннары Минзәләдән Әлмәткә күчеп китте. Аңа кадәр әле ул, «Литературная газета»да Константин Симоновның Муса Җәлил турында мәкаләсе басылып чыккач, шагыйрьнең Минзәлә педучилищесы бинасында политруклар курсында укып йөрүе, аның Мөхәммәт абый Гарифуллин белән дус булуы, аларда кунгалап та калуы турында зур гына очерк та язып бастырган иде. Ә мин—сугыш чорында әле авыл малае—Минзәләгә бер базарга килгәч, ничектер, Муса Җәлилне дә күреп калган идем. Салкын кыш көне. Базар яныннан чаңгыларда бер төркем сугышчылар үтеп китте. Халык: «Арттагысы Муса Җәлил... Муса Җәлил...»—дип пышылдашып калды.*

*Әдип Маликов күңелемә шулай бик иртә кереп, аннары Казанда очраша башлаганчы, әйбәт, кешелекле шәхес булып яшәде. Аның сабырлыгы-тыйнаклыгы сокландыра иде. Аның беренче мәхәббәте Сажидә Сөләйманова да талантлы шагыйрә булып танылды. Без аны рус шагыйрәсе Анна Ахматовага тиңли идек. Ни кызганыч, ул бик иртә вафат булды—нибарысы илле дүрт яшендә.*

*Ул вакытларда мин инде Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир булып эшли идем. Әдип абый Сажидә Сөләйманованың каты авыру килеш хастаханәдә язган соңгы әсәрен—»Гөлбадран» повестен күтәреп килде: «Чыгарыгыз инде, Марс»,—дип үтенде ул. Без ул повестьны шул елда ук чыгарып та куйдык.*

*Сажидә Сөләйманова бик талантлы шагыйрә иде. Аның таланты Әдип Маликовка да тәэсир итми калмагандыр. Алар—ике иҗатчы—бер-берләренең әсәрләрен укышып, бер-берләренә ярдәм итешеп яшәделәр. Әдип Маликов та «Яшьлек утравым» дигән повесть-истәлеге, «Туган як җиле» кебек шигырьләр-поэмалар китабы һәм башка әсәрләре белән үзен танытты.*

*Әдип Маликов һәрвакыт тыйнак, әмма үз дәрәҗәсен белеп, түбәнлеккә төшми торган язучы булды. Ул синең күзеңә бер тутырып карый да, шуннан бөтенесе дә аңлашыла.*

*Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, «Почет билгесе» орденлы язучы Әдип Маликовка сиксән яшь, дидек. Лаеклы-мактаулы озын гомер бу!*

*Әдип ага, сине «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре исеменнән чын күңелдән котлыйбыз һәм иҗатыңда яңа уңышлар телибез!*

**Марс ШАБАЕВ**

# Әдип Маликов

# ТЫЛСЫМЛЫ ХАТЛАР

ЯҢА ӘСӘРДӘН ӨЗЕК

Казанга килүемә өч ел да узып киткән. Кичләрен, энем белән Бауман урамы буйлап йөргәндә, утлары балкып янган тәрәзәләргә карап узабыз. «Их, шуларның ник берәрсе безнеке түгел икән?!»—дип уфтанып куйган чаклар еш була иде. Якты дөньяга үз тәрәзәңнән карый алу—шуннан да зур бәхет юктыр шикелле иде ул чагында.

Мин Татарстан радиосында балалар өчен тапшырулар редакторы

идем. Татарстан Язучылар союзы рәисе Әхмәт Ерикәй телефоннан мине кабинетына чакырды. Мин, фатирга чират житкән икән дип, ашыга-ашыга шунда чаптым.

—Мәскәүгә, Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга җибәрмәкче идек сине,—диде ул акрын гына, җайлап кына.—Кави Нәҗми, Газиз Иделле дә шул фикердә, квартирга чиратың сакланыр. Анысын үзем күзәтеп торырмын...

1949 елның август ахрында булды бу сөйләшү.

—Соң бит инде, Әхмәт абый, имтиханнар беткәндер...

—Сезнең өчен соң түгел. Ватан сугышында булганнарны имтихансыз алалар,—дип аңлатты ул,—әмма иҗат конкурсы үтәргә туры киләчәк. Поэмагызны, шигырьләрегезне җыеп китерегез үземә. Урта мәктәп аттестатын да. Газиз Иделле шигырьләрегезне бүген төнлә үк тәрҗемәләргә булды. Иртәгә Мәскәүгә очам...

Бу сөйләшү бераз кытыгыма тиде. Ничек инде үземнән башка гына язмышымны хәл итәргә җыеналар болар?! Ләкин, ни генә дисәң дә, минем башка чарам юк иде. Әле горурланырга кирәк, рәхмәт әйтергә кирәк моның өчен, дип уйладым. Дөньяда бердәнбер әдәбият институты бит!

—Быел Татарстанга көч-хәл белән бер урын бирделәр,—диде Әхмәт Ерикәй ахырдан.

—Рәхмәт сезгә, Әхмәт абый!

Киләчәгемне дә кайгыртып куйды ул:

—Техникум дипломында бер төп фәннән «уртача»гыз бар икән. Ярты елга кадәр стипендия билгеләмәсәләр, литфондтан ярдәм итәрбез...

* * *

Сау бул хәзергә, синдә җылы почмагымны, якты тәрәзәмне таба алмаган Казаным. Яңадан очрашканга кадәр, рухи төбәгем!

Егерме сигез яшемдә ВУЗ студенты булачакмын. Әйе, безнең буын күп нәрсәгә соңга калып кына иреште шул...

* * *

Соң булса да уң булсын.

Мәскәүгә килеп төшкәч, Тверь бульварын эзләп таптым һәм челтәрле чуен капкадан Әдәбият институты ишегалдына барып кердем. Биек чаганнар, бер дә исләре китмәгәндәй, сабыр гына каршы алдылар. Ике катлы «Герцен йорты» эчтәрәк булып чыкты. Тәрәзәләре зур, якты. Алар, ничектер, күнелне үзләренә тартып тора иделәр.

Икенче сентябрь иде бу. Тәнәфескә чыгарга звонок бирделәр бугай, ишегалдына берәм-берәм дә, төркемләп тә студентлар чыга башлады. Кызып сөйләшә-сөйләшә, папирос көйрәтергә тотындылар. Берән-сәрән кызлар да күренә. Алары да тарта. Кайсысы кулларын бутап, шигырь укый, кемдер ораторлык итә. Күмәк көлү авазлары ишетелеп куя. Хәрби киемнәрен салмаган егетләр дә шактый күп. Пехотачылар, дингезчеләр, хәтта очучы формасындагылар да бар. Эчемә җан керде. Үз туганнарымны күргәндәй булдым. Бу егетләр белән уртак тел табуы авыр булмаячагына ышанып, сөенеп куйдым.

Институт ишегалдына таба атлаганда, арадан берсе:

—В нашем полку прибыло, значит...—диде.

Шул ук ярым хәрби мине икенче каттагы канцеляриягә кадәр озата керде. Андагы ачык йөзле, кызыл иренле дамалар, телеграмманы күрүгә, бер авыздан:

—Котлыйбыз!—диештеләр.

Шул арада бер чибәре:

—Хәзер мин сезне... нче аудиториягә озатам,—дип, култыклап та

алды,—профессор Реформацкий лекциясенә рәхим итегез, Эдип Маликович!

Юл унаеннан өстәп тә куйды:

—Конкурсны әйбәт үттегез, рәхмәт!

Өнемме-төшемме дип торам. Бәй, бик тиз булды ич әле бу. Кем кемгә рәхмәт әйтергә тиеш соң әле?! Болай зурлап каршыларлар дип һич өмет итмәгән идем. Армиягә кадәр Уфа һәм Казан ВУЗларына барып та, башымны түбән иеп, кире кайтып китүләрем исемә төште. Мин ул чагында үземне мескенрәк хәлдә хис иткән идем. Кем әйтмешли, Мәскәү—Мәскәү инде ул!

Аудоториягә кергәч, мина студентлар шунда ук буш урын да табып бирделәр. «Сезнен өчен сакладык»,—дип тә куйган булдылар.

Зур портфелен күтәреп, кечкенәрәк буйлы, гади генә киенгән күзлекле берәү кафедра янына узды. Реформацкий дигәннәре шул икән. Аудоторияне күзлек аша бер капшап алуга, ул карашын мина юнәлтте:

—Ә-ә, яна иптәш! Кайсы яктан буласыз?—дип, учка тотарлык кына сакалын сыйпаштырып сорау бирде.

—Казаннан!—дигән сүзне ишетүгә, яныма килде, кул биреп күреште.

—Казан Фәнни-тикшеренү институтында минем бик якын дустым бар,—диде ул, шатлыгын яшермичә,—телче-галим, профессор Латыйф Җәләйне беләсезме? Минә шул. Хатлашып торабыз...

Аны белгәнлегемне әйткәч:

—Менә мин «Введение в языкознание» дигән бик четерекле фәннән лекцияләр укыйм сезгә,—дип куйды,—ярдәмчем булырсын.

Бөтен студентларнын күзе миндә иде. Һәркайсынын йөзендә кызыксыну билгесе: Максим Горький исемен йөрткән, дөньяда бердәнбер дип даны чыккан Әдәбият институтына яна студент килгән бит. Житмәсә, татар егете. Дөрес, бу институтны сугышка кадәр 1940 елда Габдрахман Әпсәләмов тәмамлап чыккан булган. Ләкин ул Казаннан түгел, Мәскәү пропискасы белән яшәгән.

Институтта беренче уку көнем менә шулай башланып китте.

* * *

Студент тормышы бөтенләй башка икән. «Атым юк урамда, кайгым юк буранда», дигән кебегрәк йөрисен. Ике кулына бер эш—уку. Эдуард Асадовка гына бик кыендыр укуы. Ике күзе дә дөм сукыр. Юан жеп белән тарттырып, күз урыннарына кара күн түгәрәкләр бәйләнгән. Шулар өстеннән кара күзлек тә киеп куйган үзе. Тәнәфескә чыксан, коридорда ин күп сөйләүче шул. Студентлар аны уратып алалар. Кайчакта шунда профессорлар да тукталып тора. Хатыны Наташа бер читтәрәк студент кызлар—Маргарита Агашина, Юлия Друнина һәм тагын кемнәрдер белән гәп кора. Ара-тирә Эдуардка күз салып куя. Алар сугыш башланганчы ук бер-берсенә гашыйк, әле өйләнешмәгән пар булганнар. Эдуард фронтка киткәч, хатлашып торганнар, кавышырга сүз куешканнар.

Асадов сугышта авыр яраланып, ике күзсез калгач, Наташа аны хәрби госпитальдән эзләп таба, шунда вакытлыча медсестра булып эшкә керә. Сонышнан бергә тормыш корып жибәрәләр, парлап, әдәбият институтына укырга керәләр. Алар һәрвакыт култыклашып йөри, берни булмагандай, уен-көлке белән сөйләшә. Дөньяда гүя алардан да бәхетле кеше юк, диярсен. Лекция вакытында Наташа конспектлар язып бара, ә Эдуард бик игътибар белән тынлый. Анын хәтере яхшырак икән. Радиодан ишеткән шигырьләрне шунда ук отып кала, диләр. Үзе дә шигырьләр яза.

Студентлар дөньясына кереп киткәч, менә шундый танышлыклар башланды.

Унны бетереп килгәннәргә ике дөнья—бер моржа. Яшь тайлар кебек, уйнаклашып, сикергәләшеп йөриләр. Үзләре бик күпне белә, чукынганнар. Бәхәскә дисән—аларга куш.

Ә сугыш күргәннәр—басынкы, күбесе үз эчләренә бикләнгән. Өзелеп

калган укуны өр-яңадан башларга кирәк бит. Лекцияләрне тыңлый белү—үзе бер һөнәр. Уйларың сине әллә кайларга алып китә. Сугыш кырында ятып калган полкташ дусларың күз алдына килеп баса...

Янәшәмдә утырган Федор Сухов сугышта рота командиры булган. Ярты Европаны фашистлардан азат итешкән. Ә үзе турында һич кайгырта белми. Өзлексез тәмәке тарта. Тулай торагында бернинди режимсыз яши. Йокысының да, ашау-эчүенең дә рәте юк. Ботинка баулары кыска, өзелеп бәйләнгән, өстән генә ике тишеккә эләктергән. Чалбары үтүкләнмәгән булыр. Атнага бер генә кырына. Матур әдәбиятны уку программасы буенча түгел, үзенә ни якын—шуларны гына укый. Яратмаган лекцияләренә бөтенләй йөрми.

Безнең курстагы биш студент кызның берсе әйтеп тә куйды:

—Эх, Федя, минем кулыма эләксәңме, тәртипкә китерер идем инде үзеңне...

Хөрмәт итәләр аны кызлар, нәрсәсендер яраталар, сөйләшеп, күңелен табарга тырышалар. Артык гади, сабый кебек эчкерсез бәндә ул күршем Федя Сухов. Бер ротада хезмәт иткән, исән калган полкташларыннан еш кына хатлар алып тора. Ял көннәрендә шуларга җавап хатлары язып утыра. Ә кызлардан хат килми, ахры.

Институтның тулай торагы Переделкино дигән поселокта. Сәгать ярымлык юл. Әмма Мәскәүнең үзендә яшәп укуга ни җитә! Андый бәхетле җаннар байтак икән: Польша, Болгария, Венгрия, Төньяк Корея һәм тагын кайлардандыр килгән студентларны шул илләрнең илчелекләре башкала үзәгендә урнаштырган. Ә берничә кызга һәм сугыш инвалидларына институт ишегалдындагы йорттан урын тапканнар.

Без фәкыйрьләргә җәяүләп тә, троллейбуска утырып та, электричка белән дә—барасы да кайтасы, кайтасы да барасы... Әле Переделкинога килеп җиткәч тә, үргә каршы тагын унбиш минут атлыйсы. Түз генә, йөрәгем!

Бу урын язучылар шәһәрчеге икән. Мин Тренев дачасында урнаштым. Анда биш бүлмәдә унбишләп студент яшәп ята. Беренче танышым—Төньяк Осетиядән килгән яшь шагыйрь Григорий Гагиев булып чыкты. Ун сыйныфны алтын медаль белән тәмамлаган. Хискә бирелүчән, саф күңелле кешегә охшый. Хетагуров исеме теленнән төшми. Аның күп шигырьләрен яттан белә икән. Хәтеренең шундый яхшы булуына хәйран калырлык. Ә безнең ише солдатларның элек ятлаганнары да коелып беткән. Шулар кайгысы булды мыни?!

Ял көнне без аның белән язучылар шәһәрчеген карап йөрдек. Күренекле рус язучыларының оясы шушында икән лабаса! Леонид Леонов, Всеволод Иванов, Александр Фадеев, Николай Погодин, Илья Сельвинский, Борис Пастернак, Маргарита Шагинян... Әллә йөзләп язучы яши икән биредә!

Фадеев дачасы безнең тулай торакка урам аша гына. Әйе, «Разгром», «Последний из Удэгэ», «Молодая гвардия» кебек атаклы әсәрләрнең авторы, СССР Язучылар союзының генераль секретаре күршебездә генә яши. Зәңгәргә буялган ике катлы агач йорт. Биек койма аша, ак каеннар арасыннан челтәрле балконнары күренеп тора.

—Әйдә, койма ярыгыннан карыйбыз,—диде Жора, балаларча беркатлылык белән. Ә мин, картлач, шуңа риза булдым. Эчтә кечкенәрәк күл күренә, фонтаннары атып тора. Күлдә пар аккош йөзеп йөри. Үрдәкләр чумышып уйный. Алгы ишектән ак чәчле, мәһабәт гәүдәле берәү килеп чыгуга, курсташым:

—Үзе!—дип тел шартлатып куйды. Ә мин кинәт телсез калдым. Унҗиде яшеннән Сучан партизаны, аннары бригада комиссары Александр Фадеевның кайнар вакыйгаларга бай тормыш юлы, Уссури тайгалары күз алдыма килде.

—Киттек моннан тизрәк!—дидем мин курсташыма.—Әлләни уйлаулары бар...

Без Фадеев дачасын узып, җәйрәп яткан зур күл янына барып чыктык. Тирә-юне яшеллек белән уратылган. Нинди генә агачлар үсмидер монда. Яр буенда чылбырлы көймәләр дә байтак күренә. Аргы башта балыкчылар учак ягып җибәргән.

Гагиев Переделкинога август урталарында ук килеп урнашкан. Шул вакыт эчендә ул бер афәтле хәлгә дә тап булган. Ике көн тоташ койган яңгыр артыннан көчле ташу әлеге буаны алып киткән икән. Башта моннан берничә чакрым ераклыктагы Буденный дачасындагы буа ерылган, ди. Көчле су ташкыны аннары биредәге дамбаны күпере белән бергә агызып киткән.

Ин «кызыгы» шунда булган: Буденный күк атына атланып, атлы сакчылары белән бергә ташу артыннан куа килгән. Переделкино поселогына бәла-каза килмәгәе дип хафаланган, күрәсең. Ул көнне Переделкино кешеләре болыннарда, әрәмә araларында сөзелеп калган симез карп балыкларын җыеп йөргәннәр.

—Җыегыз, җыегыз!—дип рөхсәт биргән Буденный,—уха ашарга мине дә чакырырсыз...

Легендар маршал солдатлары бер көн эчендә дамбаны да, күперен дә, элеккесеннән дә шәбрәк итеп, торгызып та куйганнар. «Фадеев күренгәнче өлгертегез буаны»,—дигән Буденный.

* * *

Көннәрнең берендә, тәнәфескә чыккач, кемдер артымнан килеп, күземне каплады:

—Кем, таныйһыңмы?—дип сорады ул, башкортча гына.

Башымны борырга теләсәм дә ычкына алмадым. Куллары каты да, көчле дә булып чыкты. Шуннан ул үзе каршыма чыгып басты, мине кочаклап алды.

—Бәй, «Тальян моңы» ич!—дидем мин, исеменнән алда, аның шундый әсәре буенча куелган спектаклен хәтерләп.—Саумы, Габдулла!

—Әсәрен исеменнән алда йөрсә, шәп ул,—диде Әхмәтшин, күңеле булып, шунда ук татарчага күчеп.—Йә, хәлләр ничек?

Аның ут кебек янып торган сихерле кара күзләре миңа төбәлде. Уртача буйлы чандыр гәүдәсендә яшерен көч ташып торганын әллә каян сизеп була. Без сөйләшеп киттек.

1948 елда Башкорт академия театры Казанга гастрольләргә килгән иде. Репертуарлары бик бай, башлыча музыкаль әсәрләр куелды. Арада иң шөһрәт казанганы «Тальян моңы» спектакле булды. Билетларны алыпсатарлар театр каршында биш бәягә сатып йөрде. Бу әсәр радио буенча да трансляцияләнде. Әхмәтшин безнең эш бүлмәсенә кереп, озак кына сөйләшеп тә утырган иде. Ул чорда радиода эшләүче Гамир Насрый белән фронтташ дуслар булып чыктылар. Уфа пединститутында укыган икән.

—Пединститутта укыганда, алай-болай, Сажидә Сөләйманова дигән кызны очратмадыңмы?—дигән бер көтелмәгән сорау ычкынды телемнән.

Габдулла кинәт миңа текәлеп:

—Әллә танышыңмы?—диде. Һәм шунда ук сүзен дәвам итте:

—Алай-болай гына түгел, хәтта бергә танцыларда очрашкан булды. Егетләргә «алай-болай» бик исе китми иде. Горурлык димме...

Мин Сажидә белән авылдашлар икәнемне әйттем.

Дәрескә керергә кыңгырау чылтырады, сөйләшеп бетерергә ирек бирмәде. Габдулла пединститутта укыган җиреннән бирегә икенче курска килеп кергән булып чыкты. Ул күрше аудиториягә кереп китте. Ә икенче тәнәфестә Габдулла Сажидә турында бер мәзәк тә сөйләп алды.

... Институт кичәсендә Сажидә сәхнәгә биергә чыккач, туфлиенең бер үкчәсе төшеп кала. Зал «аһ!» итә. «Ни булыр икән?» дип уйларга да өлгермиләр, кыз туфлиләрен салып, оча-куна носкидан гына биергә тотына. «Бис!» кычкырып кул чабалар үзенә.

Әхмәтшин сүзен кызганычлы тавыш белән очлап куйды:

—Бер айлык ипи карточкасын биреп алган туфлие булган икән бит бахыркайның...

Син нинди икән хәзер, Сажидә? Чамалавым буенча, быел соңгы курста укыйсың булыр. Аннары каядыр китеп югалырсың, үзенә тиң пар табарсың. Кайда гына йөрсәң дә, бәхетле була күр, карлыгачкай—житез кошкай. Күңелемнән мин шуны тели идем аңа.

* * *

Кемнәр генә укымый бу институтта! Йөз иллеләп студент арасында һәр республиканың диярлек үз вәкилләре бар. Туган илнең кечкенә бер кисәге, тере өлгесемени: үзара төрле телләрдә сөйләшәләр, гореф-гадәтләре дә төрлечә. Һәркайсы үзенчә горур. Әмма дуслык хисе барысы өчен дә уртак. Сугыш ялкыны аша узган солдатлар арасында ул хис аеруча көчле икән.

Институт ишегалдындагы тулай торакта яшәүче ике студентка игътибар иттем. Алар игезәкләр шикелле, һәрвакыт бергә булалар. Тик өс-башларында гына аермалык бар. Исем-фамилияләрен, кемнәр икәнлекләрен дә белеп алдым. Берсе—Михаил Кильчичаков, чем кара чәчле хаккас егете. Сары чәчлесе—рус егете Александр Николаев. Икесе дә шигырь яза. Проза, драматургия белән дә мавыгалар икән.

Әнә алар икәүләп, чуен капкадан Тверь бульвары ягына чыгып баралар. Берсенең—уң, икенчесенең сул кулы юк. Фронт юлында өзелеп калган. Һәр икәвенең дә күңелләре көр.

Кемдер:

—Кая болай?—дип сораугa, икесе берьюлы көлешеп:

—Универмагка перчатка алырга!—диештеләр. Әйе, аларның икесенә бер пар перчатка да житә хәзер. Үзләре әйтмешли, аз булса да стипендиягә экономия. Ә бу уен-көлкеле сүзләр астында күпме фажига ята...

Мин Килчичаков белән якыннан танышып алдым. Телләребез якын икән. Бер-беребезне тәржемәсез, ягъни уртак рус теленнән башка да аңлыйбыз. Сугыш еллары турында искә төшергәндә, ул миңа бер генә вакыйганы әйтеп куйды. Канлы бинтларга уралган хәлдә, төнгә каршы кыр госпиталендә яткан чагында, Михаил бер шәфкать туташының икенчесенә әйткән сүзләрен ишетеп кала:

—Бу юлбарыс күзлесе йокысыннан айный алмас, ахры, иртәнгә кадәр өзелер...

Килчичаков шуны ишетүгә сискәнеп китә, төне буе күзен йоммаска, йокламаска тырышып, үлем белән тартышып чыга...

Фронтовик дуслар Мәскәүнең Зур театрына да бергәләп баргалыйлар икән. Тамашачы иң гүзәл башкарылган арияләргә шаулатып кул чапканда, болар арттырып жибәрә. Икеләтә авырлык күтәреп өйрәнгән көчле сыңар куллар белән берсенең уң, икенчесенең сул уч төбенә жилләнеп бәргәндә, балконда нидер шартлагандай авазлар ишетелә башлый. Партердагылар, башларын күтәреп, шул якка карый, зал кинәт тынып кала икән...

Әдәбият институтында икесенә бер пар ботинка сатып алып киючеләр дә бар иде...

* * *

Әдәбият институтының штатлы педагоглары юк диярлек. Профессорлар «жыелма команда» булып чыкты. Күбесе Мәскәү университетыннан килеп укыталар. Исем-фамилияләре бик сирәк очрый торганнардан: Ульрих Рихардович Фохт, Валентин Фердинандович Асмус, Симонян, Дынник, Металлов, Бонди... Яһүдләр... Барысы да бөтен илгә танылган профессорлар. Телебез күнеккән Поспелов, Сидорин, Федор Гладков кебек фамилияләр берән-сәрән генә.

Реформацкий лекциягә кергән саен минем якка күз ташлап ала. Әллә шулай тоела гынамы? Рус сүзләренең килеп чыгышларын, тамырларын тикшерү башлангач, без хәтта дуслашып та киттек бугай. Сорауларны гел мина төбәп бирә башлады бу:

—Әйтик, Переделкино юлында сез Арбат мәйданы аша узып йөрисез. Каян туган «Арбат» атамасы, уйлаганыгыз бармы, дуслар?

—«Арба» белән «ат»тан,—дим мин, барысыннан да уздырып.

—Молодец, Маликов!—дигән хуплау сүзен ишеткәч, хәтта кызарынып куям. Татар атамасы турында сүз бара бит. Ничек жаның эремәсен?! Реформацкий сүзен дәвам итә:

—Арбат элек базар мәйданы булган. Атлылар күп килгән. Татарлар бизмән белән арбадан гына сату иткәннәр. Рус лексиконына «базар», бизмен-бизмән», «арба», «дуга», «хомут-камыт», «салам», «товарищ—товарищ» сүзләренең килеп керүе очраклы хәл түгел,—ди ул.

Рус-татар бәйләнешләре турында мин моңарчы бик томанлы гына фикер йөрткәнмен. Лекция барышында күп нәрсәләр аңлашыла башлады. Бөек Болгар, татар һәм рус тарихлары бер-берсе белән бәйләнешеп, чәбәләнеп беткән икән. Кайсысын нәрсәдән аерырга да белмәссең. Әгәр тарихка күз салсаң, Россия—Россия, Украина—Украина гына түгел. Монда гасырлар белән гасырлар маңгайга-маңгай, кылычка-кылыч килгән...

Рус патшаларының да кайберләре татар нәселеннән икән бит: Борис Годунов, Романовлар династиясе. Ә Петр Беренче Нарыш Мирза нәселеннән икән. Хәтта Казан ханлыгын канга батырган Иван Грозныйның да әнисе татар морзасы кызы, аның өч хатыны татар кенәзләре нәселеннән булган. Атаклы полководецлар Михаил Кутузов, Дмитрий Пожарскийларда да татар каны уйнаган. Бөек рус галиме Тимирязевның фамилиясе—кенәз Тимер Газидан, бөек Тургенев—Түргән Морза, шагыйрь Тютчев—Түтчи Морза нәселеннән. Инде Анна Ахматова, Карамзин (Кара Морза) турында әйтәсе дә юк. Татар-Болгар нәселеннән чыккан шәхесләр арасында урыс илендә сигез патша, туксан өч генерал, унике фельдмаршал, алтмыш өч күренекле язучы һәм шагыйрь, илле жиде галим, илле алты илче һәм башкалар бар икән.

Кырып карасаң, һәр урыстан татар каны чыга дип, Наполеон юкка гына әйтмәгән, күрәсең.

Әдәбият институтында зур теләк белән укый башладым. Кирәк-кирәкмәс фәннәр керми. Чираттагы һәр лекцияне бирелеп тыңлыйсың. Тик күршем Федор Сухов мышнап йоклый башласа гына бераз бүленергә, кабыргасына төртеп куярга туры килә. Ул Ватан сугышын жәяүләп тә, шуышып та үткән укчы рота командиры, хәзер бөтен вакытын шигырьгә бирә. Ягъни Переделкинодагы Сельвинский дачасында төннәр буе шигырь язып чыга да, калган йокысын лекцияләр вакытында туйдыра. Ун сыйныфны тәмамлап килгән Наташа һәрчак ярдәм итә аңа—язып барган чиста конспектларын соныннан укырга бирә.

Бервакыт хаккас Килчичаков лекцияләрдән соң мине күреп алды да әйтте:

—Әйдә, Твардовский утыра торган өстәлне күрсәтәм мин сина,—диде,—шаярта дип уйлама...

Ул мине Тверь бульвары белән Горький урамы почмагында, ярымподвалда урнашкан сыра залына алып керде. Эче якты, стеналары пыялалы, уку залындагы сыман акрын гына сөйләшәләр. Буш урыннар күп иде. Миша кайсыдыр театрда пьесасы куела башлавын, бүген гонорар алган булуын сиздерде. Тәрәзә янына утырырга ниятләвемне күргәч, ул мине алгырак почмакка алып китте. Артыбызны урындыкка терәүгә, ак жаймәле өстәлгә кетердәп чәйнәлә торган сары «салам»нар һәм ике кружка күбекле сыра килеп житте.

—Ашыкма,—дип кисәтте күршем,—ял итик бераз... Аның шулай дияе булды, ишек ягыннан түгәрәк йөзле, баһадир гәүдәле берәү күренде. Чаллана башлаган коңгырт чәчен маңгаенын бер ягыннан кашына кадәр

диярлек сыпырып төшергән, кин маңгаенын иkенче ягы түбән таба очлаеп ачык калган. Ул беркемгә игътибар итмәгән сыман, башын югары тотып, бая мин ниятләгән өстәл янына барып утырды. Аның янына инбашына ак сөлге салган пеләш башлы бер абзый килеп иелде. Баһадирның йөзендәге житдилеге кинәт юкка чыкты. Алар күптәнге дуслар сыман, нидер сөйләшеп, көлешеп алдылар.

—Александр Трифонович...

Шулайдыр дип уйлаган идем. «Василий Теркин»ны радиодан күпме кабатласалар да, тынлап туя алганым юк.

Без аны аргы почмактан, үзенә сиздермәскә тырышып кына, күзәткәләп утырдык. Әллә эчте, әллә юк. Ул каядыр билгесезлеккә карап, үз-үзе белән серләшеп, киңәшеп утырды шикелле. Бизәкле сары пәрдә читен ачып, тротуар ягына да карап куя. Өстәлдә кәгазь акча калдырып, салмак, дәрәжәле адымнар белән чыгып та китте Александр Трифонович Твардовский. Аннары бер семинарда безне Твардовский белән очраштырдылар. Ул «Василий Теркин» китабы турында күп сөйләде.

Аннары ул читкә карап, бераз уйланып торды да әйтте:

—Күп кенә классикларны күргән бу тарихи залда әдәбиятыбызның шөһрәте һәм намуслы киләчәге утыра. Шулай дип саныйм. Сезнең каршыгызда ялгышырга Ходай кушмасын, һәр сүзне үлчәп әйтергә кирәк. Әмма минем Теркиным ялгышырга да, алдашырга да ирек бирмәс дип ышанам...

Шул сүзләрдән соң миндә бер кызыксыну туды: ә кемнәр икән алар киләчәкнең бу залда утырган шөһрәтле вәкилләре? Әнә, стена буенда—мин белеп өлгергән өлкән курс студентлары Юрий Бондарев, Григорий Бакланов. Икесе дә артиллерист булганнар. Түбән курстагылар белән аралашмыйлар, безнең ишеләргә бераз өстәнрәк карыйлар шикелле. Янәшәләрендә—Владимир Солоухин. Бөтен килеш-килбәте, сөйләшү рәвеше белән көлсу-сары чәчләренә кадәр—коеп куйган Үзәк Россия урысы. Бер кичәдә «Кое» дигән озын шигырь укыды ул. Аның тавышы тирәннән, кое төбеннән ургылып чыга сыман тоелды. Үзен эчкән коега төкермәскә куша иде шагыйрь.

Миннән алдарак карчыга борынлы Рәсул Гамзатов утыра. Тәржемәчесен еш кына үзе белән ияртеп йөри, гүя жан сакчысы диярсең. Әтисе Гамзат Цадаса классик булгач, Мәскәү үзәгендәге квартирда яши. Институтта сирәк күренә. Безнең шикелле, акчага да өтелеп яшәмидер. Монда тагын яшь шагыйрьләрдән түгәрәк гәүдәле, ине-буе бер диярлек Евгений Винокуров, кытай фамилияле Костя Ваншенкин, очучы гимнастеркасыннан һаман чыга алмаган Василий Федоров, дингезче Григорий Поженян күренә. Әле болары мин белгәннәре генә. Поэзия буенча житәкчем, шомарып беткән кәкре трубкасыннан аерыла алмый торган Евгений Долматовский, елмаюдан, кызыклы мәзәкләр сөйләүдән бушанмаган Михаил Светлов, чиркәү әһелен хәтерләткән Илья Сельвинский, Мәскәү шагыйрьләренең «кенәзе», ярым сүгенеп сөйләшә торган Ярослав Смеляков, бала чагымнан яратып укыган «Белеет парус одинокий» китабының авторы Валентин Катаев...

* * *

1950 елның жәендә безне, беренче курсны тәмамлаган студентларны, ижат командировкасы биреп бергә жыйдылар.

Димәк, жәйге каникулга әти-әниләр янына бер айга соңга калып кайтачакмын. Вакыты житеп, поездга билет алгач, өйгә телеграмма суктым.

Поезд Оркыяды стансасына төнлә барып төшә, анда ике генә минут тора. Мәскәү поезды килүгә, гадәттә, перронда ыгы-зыгы башлана. Шаугөр киләләр, капчыкларын, чемоданнарын күтәреп чабышалар. Барысы да өлгерә тагын. Берәр энемне ияртеп, каршы алырга дип, тынгысыз әти, мөгаен, үзе килеп житәр. Әле төн уртасына кадәр тәгәрмәчләр текелдәвен байтак тынлыйсы бар.

* * *

Утларын анда-санда саран гына жемелдәтеп, таныш стансам күренде. Туктамастай булып, ашкынып чапкан поезд кинәт калтыранып, тартылып куйды.

—Каршылагыз-з-з!—дигән сыман, паровоз монсу гына бер кычкыртып алды. Вагоннар әкренәя башлауга, тамбурга чыгып бастым.

—Ашыкмагыз, туктасын әле,—диде хатын-кыз кондуктор, үз итеп кенә.—Ярый, хәерле юл сезгә!

Баскычтан төшкәндә үк ярым караңгы перронда, каршылаучылар арасында әтигә охшаган бер күләгәне шәйләп алдым. Янында бер малай заты да күренә. Нәкъ мин уйлаганча булып чыкты. Килеп күрешүгә:

—И-и-и, исән-сау кайттыңмы?—дип, аркамнан сөеп куйды әти. Унберенче яшь белән барган энем Ил билемнән кочаклап, күкрәгемә сыенды. Аннары жиргә куйган чемоданымны тиз генә күтәреп алды. Шунда әти көтелмәгән хәбәр әйтеп, күнелемне берьюлы ямансулатып та, яктыртып та жибәрде.

—Сөләйманов кызы Сажидә шушы поезд белән Магнитогорск ягына китеп барды бит...

—Син төшкән вагоннан алдагысында, абый,—дип, сүзгә кысылды энем дә.

—Ә кем озата килгән соң аны?

—Без озаттык, абый, әтисе кайтып китте.

Бераз аптырап та калдым. Шундый яраткан кызын Гаделша абый ничек, вагонга кертмичә, калдырып китте икән? Бик гади генә итеп, бу ягын Сажидә хәл иткән икәнлеге аңлашылды. Барысы бергә күрешеп, бераз сөйләшеп торгач: «Бар, бар, иртән сина эшкә чыгасы бит»,—дип, шоферны, аның белән бергә авыру әткәсен дә «куа» башлаган ул. «Мине Малик абый белән Ил озата»,—дигән. «Ярар, кызым, сине тыңламый булмас»,—дип, Сөләйманов күз яшьләрен сөрткәләгән дә, машинага утырып китеп барган.

—Ә минем кайтасымны белдеме соң Сажидә?

—Ния, белмәйни!—диде энем житдиләнеп. —Сажидә апа синең турыда бездән сорашып та утырды әле. Әдәбият институтында укуына кызыкты. Мин гомер буена укырга риза, диде.

Минем уйларымны еракка, Урал якларына алып китте ул кыз... Поезд тагын ике генә минут торса да, очрашасы булганбыз икән бит. Юк шул, килеп туктавы булды, уфылдап китеп тә барды.

Сажидәнең чемоданын вагонына Ил йөгерткән икән.

—Абыеңа сәламемне тапшыр, диде Сажидә апа. Шундый елмаеп кына тора-а-а. Молодец, үскәнем, диде, чәчемнән сыйпап алды...

Энемнең шулай сөенә белүе мина да күчте. Ни өчен сөенәм соң әле? Юк инде ул хәзер, поездым китте... Адресын белсәң иде!

Өйдә барысы да исән-саулар. Гадәттәгечә, аннан тартып, моннан сузып, очын-очка ялгап, үзләренчә яшәп яталар. Күнелләре шат тагын, зарланмыйлар, ул кирәк, бу кирәк дип, теңкәгә тимиләр. Рух белән яшиләр. Өй тулы хыял.

Марсыбыз Владивосток тирәсендә флотта хезмәт итә. Хатлары килеп тора, кайчагында акча да сала икән. Казанда эшләгәндә өйгә мин дә жибәргәләп тордым. Тик менә Мәскәүдә укый башлагач кына ярдәм кулы суза алмадым. Әни минем студент булып йөрүемә риза түгел шикелле. Сиздереп тә куйды:

—Әтиең мина утыз ике яшендә өйләнде, син дә шуны куарсың микән инде?—диде.

Әйе, 1950 елның августында минем дә яшем утыз ягына авыша. Уйланырлык бар шул.

Әти мина Сажидәнең яңа адресын бирде.

* * *

Әдәбият институтының икенче курсына укырга килүгә, беренче эшем итеп, Башкортстан чигендәге Әбҗәлил районы, Аскар урта мәктәбе адресы белән Саҗидәгә хат язып салдым. Әллә нинди матур сүзләр эзләмәдем. Гыйшык хаты түгел бит әле. «Абыеңа миннән сәлам әйт»,— дигәненә каршы, рәхмәт сүзләре иде бу. Бәлки әле үземчә бер разведка ясау булгандыр.

«Саҗидә!»

Берни кыстырмыйча, шулай гади генә, тыныч кына, иптәшләрчә дәшүем үземә дә ошап куйды. Тагын кабатлыйсы килде шул исемне:

«Саҗидә!

Мин сезне, Аксәет мәктәбенең беренче-икенче сыйныфларында укып йөргән нәни биюче кызны, бик ачык хәтерлим... Аннары, Түбән Тәтешле мәктәбендә күрештек. Хәзер очрашсак, бер-беребезне танып идек микән? Ә мин таныр идем шикелле. Бүлтәебрәк торган иреннәрегездән...»



*Әдип Маликов. 1951 ел.*

Бераз үзем турында язганнан соң, аның тормышы белән кызыксындым. Ахырдан борчыганым өчен гафу үтенгән булдым.

Дөнья әдәбиятына, сәнгатенә, тел тарихларына багышланган мавыктыргыч лекцияләр тыңлау, картина галереяләренә экскурсияләргә йөрү, шагыйрь һәм профессор Евгений Долматовский үткәргән поэзия семинарында студентларның һаваланып бәхәсләшү тәэсирләре, Переделкинога кайтып-килеп йөрү ыгы-зыгылары арасында ике атна вакыт узып та киткән. Каяндыр берәр хәбәр алырга өлгергәнче, Саҗидәдән җавап хаты килеп җитте. Камышлы күлдәге аккош рәсеме төшерелгән зәңгәр конвертны кулыма алуга, тизрәк аудиториягә кереп утырдым. Хат шактый калын иде. Тиз генә күз йөртеп, хатны куен кесәмә яшердем. Переделкинога кайткач, мин аны караватка ятып, иркенләп, тәмен тоеп дигәндәй, укырга тотындым:

«Исәнмесез, Әдип!

Хатыгызны алдым. Бик зур рәхмәт! Монда килгәч, ай буе бер хат та алганым юк иде. Ә аласы бик килә. Мин бит чит-ят кешеләр арасында яшим. Менә Сездән беренче хат. Укытучылар бүлмәсенә керсәм, укытучылар мине шау-гөр килеп каршы алдылар: «Саҗидә, бие, сиңа хат бар,—диләр,—әле кайдан гына—Мәскәүнең үзеннән!»

Хатадыр дип уйладым башта, Мәскәүдә бит минем бер кемем дә юк. Почерыгы да таныш түгел. Шулай да хатны ачтым, иң башта соңгы юлга игътибар иттем һәм кемнән икәнен дә белдем. Әгәр Куеда (Оркыязы) стансасында әтиегезне очратмаган булсам, мөгаен, тиз генә хәтеремә төшерә алмас та идем.

Әйе, Уфа педагогия институтын тәмамлап, эшли башладым. Туганнар һәм дусларымның ризасызлык белдерүләренә карамастан, Башкортстанның иң ерак районын сайладым. Үзебезнең Тәтешледә яки күрше районда калырга да мөмкин иде. Ләкин минем аз булса да сәяхәт итәсем, ят җирләрне, яңа кешеләрне күрәсем, элек күчмә халык булып саналган башкортлар белән танышасым килде.

Ләкин мин уйлаганча һәм кайберәүләр тасвирлаганча, әллә ни романтика тапмадым. Урнашуым да җиңел генә булмады, нервларны байтак талкырга туры килде. Магнитогорск 35 километр гына булуга

карамастан, Аскар шактый карангы, аулак почмак икән. Мин яшәгән район үзәгендә электр да юк, клублары кечкенә. Күл елгасында электр станциясе төзеп маташканнар. Ләкин көтмәгәндә күлнен суы бетә башлаган. Җир астыннан башка юл тапкан, күрәсең. Әле Уфада чакта ук бу яклар күлгә бай дип ишеткәнем бар иде. Шул күнелемне тартып китерде, ахры. Мин бит йөзәргә бик яратам. Имтиханнар житсә, Идел буеннан кайтып та керми идем. Монда килгәч, күлләрнен авылдан ерак булуын күреп, кәефем кырылды.

Монда чын башкортлар яши. Күчмә тормыш үрнәкләре дә саклана. Җәй башыннан ук ишек алдында казан асалар, ачык һавада табын әзерлиләр. Сыер тизәген читәнгә чәпәп баралар, кышкылыкка ягулык. Читәне белән бергә. Каралты-кура бик примитив. Авылнын тирә-ягында биек-биек кыя таулар. Гаҗәеп матур күренешләр! Ләкин анда көне буе барырга кирәк. Кыш житсә, менә чангыда чыгарбыз әле.

Мина иң ошаганы—авыл уртасындагы каенлык. Сагышлы да, моңсу да. Килә-килгәннән бирле ямансулыйм. Андый халәт бәлки Сезгә таныш та түгелдер—кайчагында, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп, үкереп елыйсы килә. Ярый әле һәрвакыт алай түгел. Бәхеткә, мона вакыт калмый. Мәктәптә эш муеннан. Ике смена укытабыз. Дәрескә әзерләнү күп вакыт сорый. Атнага бер йокы туйдыру өчен ял көнен түземсезлек белән көтеп алабыз. Мин башкорт классларында укытам. Бик тырышып башкорт телен өйрәнәм.

Безнен институтны тәмамлаган Зина исемле кыз белән бергә яшим. Димәк, бөтенләй үк ялгыз түгелмен. Башкорт теленнән һәм әдәбиятыннан укытучы Уфа егете дә бар. Аз-маз шагыйрь.

Ярый, үзем турында житәр. Ә, әйе, Тәтешледә каникулыгыз ничек үтте, дип сорагансыз. Бу хакта бәлки язып торасы да түгелдер. Әдәби китаплар укыдым, тегү-чигү белән мавыктым, бакчада казындым. Студентлар белән урманга баргаладык.

Беләсезме, мин Сезне «Пионер Павлик Морозов» спектакле буенча хәтерлим. Сез анда Павлик булып уйнадыгыз. Бер кечкенә генә рольдә мин дә катнаштым. Бу Аксәет мәктәбендә, мин икенче класста укыган чакта иде. Аннары байтак еллардан соң, мин Сезне янадан очраттым. Тәтешле урта мәктәбендә, бишенчеме-алтынчымы класста укыганда, дәрескә яшь кенә җыр укытучысы керде. Бу—Сез идегез. Әле мине җырлатып та карадыгыз. Ләкин берничә көннән китеп тә бардыгыз. Армиягә бугай. Әле дә хәтеремдә: ак чырайлы, ябык кына гәүдәле идегез. Өстегездә карасу-зәнгәр пальто. Хәтеремә шулай сенеп калгансыз. Башкача күз алдына китерә алмыйм. Сезнен китүегез мина бик кызганыч булып тоелган иде. Хәзер очрашсак, Сезне обязательно таныр идем. Теге вакытта, поезд каршыларга төшкән әтиегез Сезнең кунакка кайтасыгызны әйткәч, үзегезне бер күрәсем килгән иде. Ләкин мин утырып өлгерүгә, Сез кайткан поезд кузгалып та китте.

Көнләшәм мин Сездән. Әдәбият институтында укыйсыз. Мин гомер буена укырга риза булыр идем. Мин монда укучыларга Мәскәү һәм Мәскәү дәүләте тарихы турында сөйлим, ә үземнең башкалада булганым да юк. Киләсе җәйгә бару турында хыялланам: музейларын, тарихи урыннарын карап йөрергә, Третьяков галереясе белән танышырга, «Иван Сусанин»ны тыңларга... Болары—план-минимум.

Әдип, Сезнен турыда ишеткәнем дә, укыганым да булмады. Ниләр язасыз? Әдәбият институтында укыгач, басылган әсәрләрегез бардыр дип уйлыйм. Мөмкин булса, языгыз әле.

Хәзергә житәр. Бик чишелеп киттем кебек.

Исегезгә төшереп, хат язуыгыз өчен тагын бер мәртәбә рәхмәт.

Сәлам белән,

Сажидә.

20 сентябрь, 1950 ел».

Матур, тигез хәрефләр, коеп куйган шикелле, тезелеп кенә баралар. Фикерләр үзеннән-үзе агылып тора. Бу хатны ул, мөгаен, бер утыруда, бер тында язгандыр. Шулай тоелды миңа. Үз почеркым өчен оялып та куйдым. Матур язу буенча гомергә «3» алдым. Үзем татар теле укытучысы булырга җыендым тагын.

Шушы хатлар безне гомерлеккә бәйләр дип кем уйлаган ул чагында...

Беренче курска укырга Рәми Гарипов дигән башкорт егете килде. Сажидә әйтмешли, чын башкорт. Кешеләргә гел елмаеп карый. Күзләреннән тирән сагыш, моң сирпелеп торса да, барыбер елмая. Шул сагышлары белән аралаш. Бер күрүдә үк яраттым шул саф җанлы унсигез яшьлек егетне.

Шушы хатны Рәмигә күрсәтергә булдым. Нинди хат икәнен әйткәч, ул кеткелдәп көлеп куйды:

—Минем әле кызларга хат язганым юк, агай,—диде,—оялам бит алардан.

Хатны ул минем яныма, койкага утырып, бөтен игътибарын биреп укыды. Хәтта гәүдәсе, картларныкы сыман, бөкрәя төште. Аннары кинәт, җитди кыяфәт белән башын күтәреп, миңа карады. Йөзендә елмаюның эзе дә күренми, әллә ачуланырга җыенамы, дип торам. Юк икән.

—Агаем, мин ошондай хат алһам, күккә инәр инем,—диде ул.—Яуап язганда башкорт ягына миннән дә һәлам юллагыз!

Рәми Гарипов якындагы Сельвинский дачасында яши иде. Кичләрен минем янга кереп утыра. Күп сөйләшми. Көтмәгәндә берәр кызык кына сүз әйтеп куя. Оялып кына сорый:

—Аскардан хат юкмы әле, агай?

—Булса, нишләрсең?

Тупасрак әйтүемә үзем дә үкенеп, хатамны төзәтергә теләгәндәй, сорап куйдым:

—Ничек соң, ул кызыкай белән хатлашуны дәвам итәргәме миңа?

—Язмаһагыз, үзем язам,—диде Рәми, кинәт үпкә белдергәндәй,—фотоһын һорагыз, агаем.

Сажидә белән хат алышуыбыз дәвам итте.

«...Үткәннәрне хәтерләгәндә, күз алдыннан, экрандагы шикелле, таныш йөзләр чагылып үтә. Берәүләренә карата кызыксыну тойгысы уяна, ә икенчеләре эзсез генә хыял томанына кереп югала. Менә шулар арасыннан ни өчендер Сезгә башлап хат яздым. Шуңа үзем дә төшенә алмыйм хәзер. Бәлки, кайткан юлымны дәвам итеп, Сезнең шул поездга утырып китүегез сәбәпче булгандыр мона? Белмим, белмим...»

Шундый юллар белән башланган икенче хатымда мин бераз институт хәлләре турында яздым, язучы Илья Эренбург белән очрашу кичәсе турында телгә алдым.

Ул дөньякүләм язучы миндә бераз өркү тойгысы уятты. Артык катлаулы шәхес икәнлеге йөзенә чыккан. Ни әйткәнен чамалап тормый алай. Безнең әдәбият институты турында да: «Ябарга кирәк аны, институтта укып, язучы булмыйлар!»—дип әйтеп ташлады. «Сезне тормыш эченә куарга кирәк»,—дип тә өстәде. Урта бер җирдә утырган Килчичаков торып басты да:

—Илья Григорьевич, бәлки, Сез мине янадан сугышка куарсыз,—дип ярып салды,—өзелеп калган укуны дәвам иттерү, Сезнеңчә, ярамаган нәрсә булып чыгамы?

—Мондый урынсыз бәхәсне туктатыйк!—диде арадан икенче бер фронтовик. Анысы Василий Федоров иде.

Ике як та тынып калды. Аннары Эренбург сүзен дәвам итте:

—Миннән дә усалраклар бар икән монда...

... Илья Эренбург үзе чыннан да, бернинди институт та, академия дә тәмамламыйча, академик булган кеше. 1908 елда, Мәскәү гимназиясенең алтынчы сыйныфында укыган җиреннән, революцион хәрәкәтләрдә катнашкан өчен, 17 яшендә кулга алалар аны. Менә шуннан соң

беркемнекенә дә охшамаган катлаулы тормыш юлы башлана: Парижда, Берлинда, Испаниядә, тагын башка илләрдә яши. Үзлегеннән бик күп чит телләрне өйрәнә. Европа башкалаларында шигырь китаплары чыгара, журналистлык эше белән шөгыльләнә. Күп йөри, күп аралаша. Бөтен гомерен сугышка, фашизмга каршы көрәшкә багышлый.

Бөек Ватан сугышы вакытында аның фашизмны хөкем итеп язган утлы, нәфрәтле мәкаләләрен без көтеп ала, землянкаларда, окопларда җыйнаулашып кычкырып укый идек. Явыз Гитлерның: «Ин беренче чиратта Левитан белән Эренбургны асып куярга!»—дигән әмере юкка гына булмагандыр.

Миндә ниндидер аруны, авыруны галәмәтләре сизелә башлаган иде. Апатия. Кинәт күз аллары карангыланып китә, баш, күз авыртырга тотына. Беркөнне институтның өске катында урнашкан литфонд бухгалтериясеннән талон алып, язучылар поликлиникасына киттем. Профессорга эләгә алмадым, шулай да зур табиб кабул итте.

—Арыганлыкныкы бу, егет,—диде, мине тынлаганнан соң,—күбрәк саф һавада булырга тырышыгыз.

—Сугышта катнаштыгызмы, контузия алмадыгызмы?—дип тә сорады.

—Җинелчә контузия булды. Ләкин ул беркайда да теркәлмәгән.

—Ул менә монда теркәлә, яшь егет,—диде табиб, башымнан сыйпап,—еллар узгач килеп чыга...

Уколлар, төрле дарулар язып бирде. Ерак ара йөреп укыган җирдән ничек уколга барасың? Язучы хатыннары, шуларның туган-тумачалары болай да тулып ята анда. Шундый юаннар, симезләр, җитмәсә, пычак телле усаллар...

Бу хәлләрне Сажидәгә сиздермәскә тырышып, аны төшенкелеккә бирелмәскә өндәп, үземчә юаткан булып, хат яздым.

* * *



*Сажидә Сөләйманова. 1950 ел.*

Көтеп алган җавап хаты менә тагын кулымда. Иң әүвәл фотосы килеп чыкты. Чәчләрен иңенә таратып салган, ачык йөзле кыз. Ышанучан караш. Аскы ирене аз гына бүлтәеп тора. Күзләренең зәңгәр икәнлеген бала чагыннан ук белә идем... Кулымдагы рәсемгә бүлмәдәге егетләрнең дә күзе төште. Һәркем үз бәясен бирә башлады.

—Ирене юка түгел алай...

—Миһербанлы кыз булырга тиеш.

—Власть яратучан.

—О, патша кызы бу!

—Ычкындыра күрмә!

Иптәшләргә артым белән борылып, хатны укый башладым:

«Исәнмесез, Әдип!

Ике сүз яздым да уйга калдым—нидән башларга? Кемгәдер түйганчы зарланасым килә, һәм ни өчендер Сезне сайладым. Мәктәптә булган бер очрак кәефемне кырды. Яңа килгән завуч классым белән бергә тарих сәгатьләремне алырга җыена. Бу, бәлки, Сезгә «юк-бар» булып тоелыр. Башыннан ук сөйләсәм, могаен, хәлемә керерсез дип уйлыйм.

1 сентябрь көнне җиденче класста беренче дәресем иде. Ишектән атлап керүгә, ике адым да атлый алмыйча, туктап калдым: укучылар баш өстеннән йөриләр—партадан-партага сикерәләр, кайсысы тәрәзә төбенә менеп баскан, кайсылары почмакта әүмәкләшеп сугышып ята. Мин, ят кыз бала сыман, бер читтә басып торам. Игътибарга алучы да юк үземне. Белмим, күпме торганмындыр, әмма бу газаплы минутлар миңа гасырга

тиң булып тоелды. Нишләргә дә белмәдем: әгәр борылып чыгып китсәң, бу класс белән хушлашуың дигән сүз, башка аяк басмыйсың. Бар көчеңне җыеп кычкырсаң да файда юк—сине берәү дә ишетмәячәк. Шул минутта тау ярырдай баһадир ир буласы килүемне белсәгез иде! Акрынлап утырыша башладылар, әмма тынычланырга исәпләре юк. Өстәл янына кыю гына килеп бастым. Менә бу беренче дәрес минем мәктәптә калу-калмау мәсьәләсен хәл итәчәк, дигән коточкыч уй йөгереп узды башымнан. Үзем дә сизмәстән, класстан дүрт «атаман»ны җилтерәттем дә чыгарып җибәрдем. Калганнарын ничектер кулга алырга, ни беләндер кызыксындырырга кирәк иде. Бәлки, дөрес тә булмагандыр, ә мин тоттым да программаның урта бер өлешеннән, ягъни йөз еллык сугыш, Жанна д'Арк турында сөйли башладым. Методика һәм педагогиканы күрәләтә бозып булса да, үз дигәнемә ирештем: укучыларым тын да алмый, бирелеп тыңлый башладылар. Теге дүрт азгынны алдагы өч дәрескә дә кертмәдем. Директорга ишетелде бу хәл, ата-аналар минем өстән хәтта РОНОга барып житкәннәр. Кыскасы, класста тәртип урнаштырганчы, ох, күңелсезлекләр күп булды. Төннәрен, Зинадан яшереп, юрган астында елый идем хәтта. Ә ай ахырына таба барысы да үз җаена төште, бер тату гаиләгә әйләндек.

Менә шушы классны яңа завуч хәзер алачак. Бу турыда ишеткәч, ни уйларга да белмәдем. Гомеремдә булмаганча, аптырадым да калдым. Бүген анда соңгы дәресемне үткәреп, укучыларым белән саубуллаштым, яңа укытучы каршында аларга яңа уңышлар теләдем. Кинәт күңелем тулып, тавышым калтыранды. Һәммәсе тынып калды. Аннары бер-берсен бүлдереп, шаулашырга тотындылар: «Безне ташлап китмәгез, апа, җибәрмибез Сезне,—диләр,—безгә башка укытучы кирәкми...» һәм башкалар. Арадан бер кыз хәтта елап җибәрде. Мин бу кадәресен көтмәгән идем. Звонок булуга, тизрәк класстан чыгу ягын карадым һәм йөгерә-йөгерә өйгә кайттым (соңгы дәрес иде). Кайтып уйга батып утырдым да, Сезгә менә шушы хатны язарга булдым. Үзем дә аңламыйм, ни өчен именно Сезгә? Институтта бергә укыган һәм хәзер Башкортстанның төрле районнарында укытучы булып эшләгән иптәшләрем дә җитәрлек. Сез әле укытучы да түгел хәзер. Белсәгез иде хәлләремне. Чыннан да, кем беләндер фикер уртаклашасым килә. Өстәвенә Зина авырып йөри. Кичә, мунчадан соң, тау ягына прогулка ясаган идек, салкын тидергән. Шуның аркасында бүлмәбездә тропик климат урнашты.

Радиодан бик матур җыр тапшыралар:

> ...Искә төшә туган ягым,
> Җем-җем иткән карларын,
> Һәр аш саен кул күтәреп,
> Дога кылган картларын.

Беләсезме, Әдип, монда хәзер гаҗәеп матур, күз явын алырдай алтын көз тора. Шундый тын, моңсу, сихри айлы төннәр. Каен яфраклары коелып бетте инде. Агачлыклар арасында коры яфракларны кыштырдатып йөрергә яратам мин. Зур шәһәрләрдә бит мондый айлы төннәр булмый, биек йортлар аша ай күренми. Аннан соң, электр яктысында айның нуры тоныклана. Мондагы табигать миңа бик ошый. Бу хакта инде язган да идем бугай.

Шулай да өйгә кайтасы килә. Бирелә туганнарым, якыннарым юкка күрәдер инде. Ләкин моннан ычкыну авыр, диләр.

Миңа шунысы кызык булып китте, әткәй белән ничек очраштыгыз соң? Башта кем кемне таныды? Неужели Сез? О, әлбәттә, ул минем турыда сөйләмичә түзмәгәндер инде. Шул гадәтеннән һич биздерә алмыйм үзен.

Сезнең җәйге каникул әллә 15 августтан башландымы? Үз чиратымда мин дә сорыйм әле: каникул көннәрен ничек уздырдыгыз соң?

Теге «аз-маз» шагыйрьгә сәламегезне тапшырдым. Нindидер сәер кеше ул. Без аны «америка эшсезе» дип йөртәбез. Якасын һәрвакыт

күтәреп куяр, эшләпәдән йөри. Кулында нindidер таяк булыр. Тарих һәм география укытучылары указкаларын анардан яшереп йөртәләр. Күрмирәк калсан—чәлдерүе ихтимал. Сезгә сәлам анардан.

Фотомны сорагансыз. Ни гаҗәп, район үзәгендә фотография юк. Үзегездән алу шарты белән, элекке фотомны җибәрергә туры килә инде. Тузгыган чәчләремә игътибар итмәссез тик.

Сау булыгыз, Әдип! Языгыз.

Сәлам белән, Саҗидә.

12 октябрь, 1950 ел.»

Бизәми-нитми генә, үз дөньясынын бер кисәген күрсәтеп куйган бу укытучы кыз. Сүз уйнатулар юк. Барысы да чын, ышандыра. Чын хикәядәге сыман. Әгәр хикәя языйм дип утырса, мөгаен, алай килеп чыкмас иде әле.

Мәскәүгә барасы килгәнен әйткән. «Третьяков галереясе» белән танышырга, «Иван Сусанин»ны тынларга...» Третьяков галереясе залларында безне бер атна буе йөрттеләр, шунда лекцияләр укыдылар.

... Мине бигрәк тә сугыш картиналары тетрәндерде. Альбомнар аша аларның кайберләре белән элек тә таныш идем. Ә биредә тәэсир бөтенләй башка. Бөек рәссамнарның үтә сизгер, үткен күз карашлары, нечкә кул хәрәкәтләре, олы җаннары сенеп шунда калган.

Репинның атаклы «Бурлаклар» картинасы, Васнецовның «Өч баһадир»ы тагын! Алар барысы да тере сыман. Экскурсовод хатын кемнеңдер сүзләрен искә төшерә: «Сәнгатьне аркан белән тоярга кирәк... Әгәр Суриковка карап, аркагызда илаһи салкынлык toймасагыз, ул чагында сез... утын яркалары гына».

Россиянен горурлыгы булган бу сәнгать музеенда кырык меңләп экспонат саклана икән. Сәнгатькә гашыйк Павел Михайлович Третьяков аларны 36 ел буе җыя һәм ахырдан Мәскәүгә тапшыра. Бу минутларда мин Саҗидә турында да уйлап йөрдем. Аны үз янымда итеп тоясым килде. Менә килсен иде, күрсен иде ул боларны. «Мин монда укучыларга Мәскәү һәм Мәскәү дәүләте тарихы турында сөйлим, ә үземнен башкалада булганым юк», дигән бит.

«Иван Сусанинны тынларга»... Ә минем Мәскәүдә яшәп тә шуны тыңлый алганым юк әле. Бик теләсән дә, билет алып булмый. Ә алыпсатарлар кулыннан алырга рәт юк. Стипендиягә генә яшәүнен авырлыгы торган саен ныграк сизелә. Союздаш республикалардан килгән студентлар үзләренен Мәскәүдәге илчелекләренә баралар да, күпмедер ярдәм алып кайталар. Акчалары хәтта типтерергә дә кала.

Без, россиялеләр, барыбыз да диярлек ярлы студентларча яшәдек. Мәскәүлеләрне исәпкә алмаганда, әлбәттә. Татарстан Язучылар Союзы рәисе Әхмәт Ерикәй постыннан китү белән, литфонд ярдәме дә таммый башлады миңа. Ә Осетин егете Жора Гагиевның һич исе китми. Алган стипендиясен бурычларын түләүгә өләшеп бетерә дә өч көннән соң тагын бурычка җыя башлый. Көн саен икешәр сумлап. Шулай акча экономияле була, дип көлә генә үзе. Яшь шул, җүләррәк чагы. Кайчакта берәр көн ашамый да тора ала.

Кемнәрдер, институт дирекциясенә сиздермичә генә, Кремльгә, КПСС Үзәк Комитетына хат язганнар. Автономияләрдән килгән студентларга кул куйдырырга китерделәр. Янәсе, сезгә ныграк колак салырлар. Хәтта сүз укыту программаларын яхшырту, схоластикадан арындыру турында барса да, төп фикер студентларның тормыш хәлләрен яхшыртуга кайтып кала: стипендияне арттыру, Мәскәүдә әдәбият институты өчен тулай торак төзү, яхшы әсәрләре булган студентларны югары премияләргә тәкъдим итү... һәм башкалар, һәм башкалар иде.

Без моңардан бернәрсә дә югалтмыйбыз дип, рәхәтләнеп кул куйдык хатка.

—Хатны почта белән җибәрергә ярамый,—диде теге чулак

Килчичаков,—аны юлда ук тотачаклар. Што сез!

Ул үз тәкъдимен кертте:

—Әйдәгез, Ленин мавзолее янында гына, Спасс капкасына әлдерәбез. Пропусклар тикшерә торган урынга бирәбез хатны.

Без өчәүләп шунда киттек: Килчичаков, Жора Гагиев һәм мин.

Кызыл Мәйданга ничә тапкыр гына килсәң дә, дулкынланмыйча булдыра алмыйсың, аның мәһабәтлеген «аркаң белән тоясың». Борынгы чал манаралар, зур ак сарай түбәсендә, җилсез көнне дә җиңелчә генә дулкынланып торган зур кызыл байрак—дәүләт байрагы, сабый чактан ук хыялымда йөрткән мәрмәр мавзолей, күксел чыршылар. Ә Кремль курантларының моңлы итеп, чыңлатып сугулары... Кызыл Мәйдан тулы күгәрченнәр...—боларны сүз белән генә аңлатып булмый.

Мин бит әле Беренче Май демонстрациясендә дә катнашкан кеше. Кызыл Мәйданның шомарып беткән чуер ташларына басып, студентлар колоннасында Ленин мавзолее яныннан узганым бар... Хөкүмәт җитәкчеләрен үз күзләребез белән, аерымачык күрүне бәхеткә саный идек. Без узганда, чү, ни булды? Бездән алдагы колонналар шып туктап калды. Патрульләр, милиция нарядлары борчыла башлады.

—Ша-а-гом ма-а-рш!!!

Юк, кузгалмый колонна. «Сталин! Сталин!» дип кычкыралар. Дулап кул чабалар. Серенә төшендек: Сталин үзе кинәт күренмәс булган икән. Мавзолей канатыннан зәңгәр һавага сыеп төтен бөдрәләре күтәрелә. Утырган килеш, төрепкәсен рәхәтләнеп суырырга тәки ирек бирмәделәр үзенә. Ул күтәрелеп, ялкау гына кул болгауга, мәйдан чайкалып куйды, янадан алга таба кузгалды.

...Спас капкасына таба атлавыбызны күргәч, сакчылар безне бик җитди кыяфәт белән, шып туктаттылар. Кая ул якын җибәрү! Килчичаков конвертны һавада болгап караса да, файдасы тимәде.

—Әйдәгез, егетләр, Кутаховский капкасына киттек!—диде ул, кискен генә итеп.

—Юк!—диде Жора үзсүзләнеп—лутчы Боровицкий капкасына. Анда почта ящигы бар!

Гагиев Мәскәүгә килү белән Кремль әйләнәсен урап, бөтен капкаларны «тикшереп» йөргән, хәтта мәһабәт чыршыларны да бәрәмтекләп санап чыккан икән. Разведчик түгел диң инде син аны! Ул хаклы булып чыкты. Капка диварына беркетелгән зур зәңгәр тартмага хатны төшергәндә часовой кымшанмады да, үрә катып торуын гына белде.

* * *

Берничә ай үткәч, институтка Үзәк Комитеттан комиссия килеп төште. Араларында Александр Фадеев та бар. Хат уңае белән аны Кремльгә чакырганнар. Безнең белән кыска гына әңгәмә вакытында шуны белдерде. Нәрсәдер сорашып, төпченеп тормады. «Хатта барысы да дөрес язылган»,—диде Фадеев.

Озак та үтмәде, уңай нәтиҗәләр күренә дә башлады: Тренев дачасында Переделкинодан йөреп укучы студентлар өчен ябык буфет ачып җибәрделәр. Иртәле-кичле манный яки дөге боткасы бирәләр. Өстәл тулы ипекәй, янына шикәрле чәе дә бар. Ярты хакына гына ашаталар, стипендиянең чиреген генә тотып калалар. Моңа барыннан да бигрәк Жора сөенде. Бүресе улады егетнең. Үзен герой итеп сизде ул. Аның да өлеше кергән бит бу хикмәткә. Бурычка керми башлады. Аннары электричкага түләүсез проезднойлар, метро өчен ай саен күпмедер акча бирергә булганнар. Литфонд оешмасы бай бит әле, Пушкиннар, Толстойлар фонды яшәсен, дибез.

Иң кәттәсе—Мәскәүдә институтның тулай торагын төзү турында Министрлар Советы карары чыкты. Безгә, әлбәттә, анда яшәргә туры килмәс. Институтның әле киләчәге бар бит. Илья Эренбург әйтә дип

кенә, аны ябып куймасларына ышана идек без. Әле студент-язучыларга Сталин премияләре дә бирәләр, имеш. Хат бик үтемле тел белән күңелне кузгатырлык итеп язылган иде шул. Анда «Бөек даһи» сүзләре генә дә берничә урында кабатлана иде.

* * *

Озын походларда йөргәндә бозлы су эчәргә дә, бияләйгә эләктереп кар ашарга да туры килде. Әмма бервакытта да тамагым шешеп йөдәтмәде. Ә сугыш бетеп, инде өйгә кайтырга җыенганда ангина эзәрлекли башлады. Шуны көткәндәй, грипп иярә, бронхит кузгала. Киеренкелек сүрелгәч, әллә организмның иркәләнә башлавымы бу? Шул әрсез «кунаклар»— ангина белән бронхит, бер-берсеннән калышмый, Казанга да ияреп кайттылар, Мәскәүгә дә тагылып килделәр. Литфонд поликлиникасының бер табибы:

—Ангина талкый сезне,—диде һәм операциягә керергә дип, кулыма кәгазь кисәге язып тоттырды.

Бу турыда мин Сажидәгә дә язган идем. Тагын беразга сузып, ярты ай чамасы болганып йөри торгач, октябрь ахырында Мәскәү читендәге бер хастаханәгә кереп ятарга туры килде. Авызны каерып диярлек ачтырып, тамак төбен яру һәм аннары тереләй тунау... Металл элмәккә ияргән бизләр белән бергә, җанны да суырып алдылар шикелле тоелды.

Төкерек тә йота алмыйча, түшәмгә карап, сөттәй ак пәрдә эчендә ятканда, кемдер акрын гына басып, караватт турысына килде.

—Сестра, дару китердегезме?—дип сорауга, ир кеше тавышы ишетелде:

—Әйе, дару китердем, агаем...

Бәй, Рәми ич бу! Каян эзләп тапкан диң җәһәннәм читендәге бу җирдән? Ул пәрдәнең бер читен ачып кына, таныш почеркллы конверт сузды миңа:

—Енгәнән...—дигән булды. Кинәт бите алсуланды үзенең. Ап-ак халат киеп куйган. Авызында ак марля. Елмайганы күзләреннән сизелеп тора.

—Габдулла Әхмәтшин һәлам әйтте,—диде, хатны ачканымны көтәргә ниятләнгән сыман, көттереп кенә—Һеззе һорап, бә-әк сибәр, озын гәүдәле, гарәпкә охшаган берәү килгәйне. «Мостафа Ногман» диде. Ленин турында озын шигырь язган икән. Ошоно укырга тип килгән. Без аны Габдулла агай менән укып сыктык. Ярыйһы болай...

Рәминең кулында бер шешә сөт тә бар икән әле. Сестра анысын бирдермәде. Инфекция кертүдән куркып, ахры, дустымны ул тизрәк озату чарасын күрде.

—Рәхмәт, туганкай,—дип кенә калдым.

Бу егетнең чын кеше икәнлеге, шагыйрьлеге йөзенә чыккан иде. Әле шигырьләрен күрсәткәне юк. Әмма үзендә хисләр ташып торганлыгы сизелә. Күңелемнән бәхет теләп калдым мин аңа.

Монысы инде Сажидәдән өченче хат: әллә шулар белән генә яши башладыммы соң?

«Әдип, исәнмесез!

Эшнең кайнар чагында язам—ыгы-зыгы киләбез, чабабыз, нервларны сыныйбыз. Бүген көне буе бишенче классларым белән бергә булдым. Лозунглар яздык, стена газетасы, фото-газета чыгардык. Стена газетасы шундый әйбәт чыкты, хәтта редколлегия членнары үзләре дә сокланып туя алмыйлар. Йөзләрендә куаныч нуры. Шул миңа күчә. Карикатуралары—«Крокодил» көнләшерлек. Художникның башы күктә. Берәүләр шүрләп тә куя: «Мондый тәнкыйть өчен безгә кемнәндер эләкмәгәе»,—диләр.

Әдип, миңа мәктәп җене кагылды, ахры. Мин балалар белән саташып

яшим. Кайгыбыз да, шатлыгыбыз да уртак. Әгәр бу турыда күп сөйләп, туйдыра башласам, гафу итегез. Бүтәнчә булдыра алмыйм.

Карточкагызны алдым, рәхмәт. Дөресен әйткәндә, Сезне башкача күз алдыма китергән идем. Соңгы тапкыр, мин—укучы, Сез—укытучы чакта күргәндә, бераз оялчан, тыйнак, йомшак күңелле булып калгансыз хәтеремдә. Ә монда—якын барырлык та түгел: горур, кырыс! Дөнья үзгәрткән, күрәсең. Сезнең өчен бүгенгесе юк, гүя киләчәк кенә яшь шикелле. Бәлки ялгышамдыр.

Әдип, кыен булса да, бер үтенечемне әйтәм: шигырьләрегезне җибәрә алмассызмы миңа? Чынлап та. Ризамы?

Теге «аз-маз» шагыйрьне Уфага балалар газетасына чакыралар. Йөзендә кояш нурларын тоныкландырырлык елмаю балкый. Чын кеше булып чыкмады бугай ул. Үзара гына калсын.

Соңга калып булса да, бәйрәм белән котлыйм Сезне! Без Мәскәүдә яшәүчеләрдән көнләшәбез. Бәйрәм парады колоннасында, Кызыл Мәйданнан узу нинди зур бәхет!

Бүген мәктәптә эшләр беткәч, биек таудан чана шудык. Кемнәр белән диегез—бишенче классларым белән! Ат җигә торган олы чанага утырып. Монда үгез җигәләр. Мин, мөгаен, акылдан язамындыр. Белмим, кешеләрдә нинди тәэсир калдырды икән бу җүләрлегем? Башка җирдә булса, бу табигый күренеш саналыр иде. Ә биредә һәр адымыңны сагаеп атларга туры килә. Настроениям шәп: котырып биисем, җырлыйсым, өзлексез сөйләшәсем килә. Чакырылган урыннардан юкка баш тартканмын икән. Бик арылган иде шул.

Сәламәтлегегез ничек, Әдип? Хәзер салкын су эчә һәм морожный да ашый аласыздыр инде. Эх, морожный ашарга! Балага әйләнгән дип, көлмәгез, зинһар.

Иртәгә радиодан Кызыл Мәйдан сулышын тыңларбыз һәм Сезне бәйрәм колоннасында итеп күз алдыма китерәчәкмен. Укуыгызда һәм иҗатыгызда уңышлар телим. Ходай илһам бирсен Сезгә.

Ә миңа түземлелек, түземлелек, тагын бер кат түземлелек теләгез. Бу—адым саен очраган киртәләрне җимерү өчен кирәк. Беренче чиректең нәтиҗәләрен искә төшерсәм, йөрәгем сызлый. Мәктәп буенча өлгереш— 48 %! Коточкыч хәл бу! Комсомол һәм пионер активын хет бауга бәйләп тарттыр. Кире беткән ишәкләр сыман (тупаслыгым өчен гафу итегез), тәрәлеп катканнар. Алга барырга теләмиләр дә. Оятымнан янам: мәктәптә бер генә ударник та юк!

Октябрьнең 33 еллыгын менә шундый «уңышлар» белән каршылыйбыз. Авыр кичерешләр эчендә яшим.

Сау булыгыз, Әдип!

Изге теләктә калам.

Сажидә.

6/XI-50.»

Авыру потлап килә, мыскаллап чыга, диләр. Бер какшасаң, сәламәтлегең тиз генә җүнәми икән. Дөрес, ангина дигәне чигенде. Әмма йөрәк үзенең кайда икәнлеген сиздерә башлады. Баш авырта, күз сызлый. Кулыма китап алсам, күз алларымда сары түгәрәкләр барлыкка килә. Табиблар мине лекцияләргә йөрүдән вакытлыча азат иттеләр. Болар турында Сажидәгә язмый торырга булдым.

Переделкиноны язучылар иҗат урыны итеп юкка гына сайламаганнар. Тирә-ягы урман. Электричка тавышы да артык комачауламый. Үзенә күрә таулары, калкулыклары бар. Саф һава. Төз нарат, ак каеннар арасына төрле яктан бормалы сукмаклар йөгерә. Студентлар лекциягә китеп беткәч, шул сукмакларның берәрсен сайлап, тау ягына юнәләм. Аучыларга йөрергә рөхсәт юк монда. Шуңа күрәдер, аяк астыннан гына диярлек соры куяннар чыгып чаба. Алар хәзер агара, алара башлаганнар. Кыш килгәнен сизәләр. Ноябрь ае бара бит.

Кемнәр генә йөрмәгәндер бу сукмаклардан? Язучылар сукмагы, диләр аларны. Леоновның «Рус урманы», Погодинның «Мылтыклы кеше»се, «Кремль курантлары», Фединның «Беренче шатлыклар»ы, Фадеевның «Яшь гвардия»се шушы урманнар тынлыгында бөреләнә башлагандыр. Хакым бармы минем бу сукмаклардан йөрергә?

Әллә соң институт белән саубуллашып, берәр тынычрак районга китәргә, урман каравылчысы булып урнашыргамы? Сахалин тайгаларында аучы өйләре очрый иде. Шуларны күз алдына китереп йөрим. Ылыс түшәлгән сәкеләр. Аю керә алмаслык кечкенә тәрәзәләр. Ишегендә бервакытта да йозак-мазар булмас. Ачып кер дә ишеген, ялгыз өй эченә сәламеңне бир. Шунда берәр атна яшәсәң дә, сүз әйтүче, килеп эндәшүче юк. Чөнки болар запас өйләр генә. Кабыктан әмәлләп ясаган шүрлектә керосин лампасы, шырпысы, тәмәкесе булыр. Тоз куярга да онытмаганнар. Чәе, шикәре дисеңме, ысланган кызыл балык, сохари... Төп хуҗасы юк аның. Адашкан яки йөреп арыганнан соң, кереп кунарга ният иткәннәр турында билгесез кайгыртучылары гына бар. Кем килеп керә—шул хуҗа. Тайга законы шундый. Ә чыгып киткәндә һәркем булдыра алганча өлеш кертә. Мичен ягарга утын әзерләп булса да калдыра.

Тайгада күп кунарга туры килде безгә. Аска ылыс түшәп, плащ-палаткаларны кайры тун өстеннән бөркәнеп, күз ачкысыз бураннарда кар астында төн үткәргән чаклар да булды. Аю сыман, үз тының белән җылынасың. Җәй көннәрендә тайга безгә күпләп витамин бирә иде. Аның бит һавасы да витаминлы. Ә куакларын сырып алган кара җиләк, күк җиләк, аяк асты тулы мүк җиләге? Зәңгелә авыруына бирешмәс өчен, солдат кружкасына тутырып, ылыс төнәтмәсе эчеп җибәрәсең. Теләмәсәң, командирлар мәҗбүри эчертәләр. Мәрхәмәтле тайга безне дошман күзеннән, үлемнән саклап калды. Әллә соң шул якларга китеп барасымы? Бер-бер кинәш сорасам, Сажидә ни дияр иде икән? Өметсезлеккә тарыганда, сина кул сузардай кешең, киңәшчең булсын икән ул.

Җиде ел нервларны талкый-талкый хезмәт итеп, мин ялның ни икәнен дә белмәдем. Сахалинда яңа өлгергән яшелчә заты күрмәдек. Зур җирдәгечә токмач сыман кисеп киптерелгән бәрәңге, кипкән кәбестә, төрле консервылар, тамактан үтми башлаган манный боткасы, шыр тоз селедка... Ленинград халкы ачтан үлгәндә, тагын ни көтәсең?

Казанга кайткач та, режим дигән нәрсәне белмәдем. Эш белән мавыгып, еш кына ашавыңны да онытасың. Ә радиода эшләгәндә безнең эш көне нормасыз иде. Яшәргә үз почмагың булмагач, кичен тагын каядыр чыгып китәсең. Иҗат турында уйлап та булмый. Ашаудан калса, азлап булса да, өйгә акча җибәреп торуыма хәзер дә сөенеп куям. Ачлы-туклы яшәгән туганнарым торып-торып рәхмәт укыдылар үземә.

Шул кичерешләрдән соң, хәзер студент булып йөрүемне җүләрлеккә саный башладым. Ялгышым булды микән, әллә соң язмышым микән бу? Алдагысын Алла белә, диләр. Борыныңны төшерергә иртә әле, егет.

Бөек Октябрь бәйрәме узуга, һич көтмәгәндә мине СССР фәннәр академиясенең «Сосновый бор» дигән санаториясенә дәваланырга җибәрделәр. «Үзәк нерв системасының арыгаюы» («истощение») дигән диагноз белән. Мәскәүдән шактый еракта, тып-тын нарат урманы эчендә булып чыкты ул урын. Монда инде кар ятарга да өлгергән. Исерткеч саф һава. Чаңгы һәм коньки бирделәр. Катогы да бар икән.

Мәскәүдән килгән мыеклы, кәҗә сакаллы профессорга күрендем. Бөтен ышанычым аңа гына дип кердем янына. Анализларымны карап чыкканнан соң, беренче соравы шул булды:

—Еш тартасызмы, егет?

—Ансыз торалмыйм, профессор...

—Кая, папирос, шырпыгызны чыгарып куегыз әле шушы тумбочка өстенә. Менә шулай... Ә хәзер минем күзләремә туп-туры карагыз. Күзегезне йоммагыз, туры карагыз. Менә шула-а-й...

Җилкә тамырларына баскалап карады да, сестрага язарга кушты:

—Языгыз, сөеклем,—диде ул, бик житди кыяфәт белән.—Чаңгыда ике сәгать прогулка. Кичләрен жәяүле прогулка. Көн аралаш ылыс ваннасы. Күбрәк елмаерга... Төрле чүп-чар турында уйламаска... Языгыз, языгыз, сөеклем...

Мин кинәт көлеп жибәрдем һәм сорадым:

—Ә кызлар турында уйларга ярыймы, профессор?

Ул да елмаеп кына жавап бирде:

—Анысына рецепт юк, яшь егет. Нинди кыз бит тагын?!

Соңгы сүзе итеп, профессор мөлаем сестрага мөрәжәгать итте:

—Тартуын ташлый. Контроль астына алыгыз, сөеклем.

Гадәттә, бераз тәмәке көйрәтми торсаң, үпкәңне тырнардай буласың. Йөрәк кысыла, чигә тамырлары гөлт-гөлт тибә, баш авырая башлый. Сихерләде, ахры, профессор. Бу юлы андый газапларны жиңелрәк кичердем. «Күбрәк елмаегыз»... Анысы да витамин, янәсе. Теләсәм дә, теләмәсәм дә, кешеләр алдында, жүләр сыман елмаеп йөрергә тырышам. Сестраларга да, официанткаларга да, жыештыручыларга да елмаям. Ә папирос пачкасына: «Житте сиңа, булды!..» дип бармак селкеп узам. Эзләнеп, кешедән теләнеп йөрмәс өчен, мин аны юри күз алдына куйдым. Профессор «сөеклем» дигән сестрага күбрәк елмаеп жибәрдемме соң, ул мине үзе белән кечке прогулкаларга алып чыга башлады. Бәлки, «контроль астында тотуы» шул булгандыр... Кыскасы, санаторийдә дөньямны онытып ял иттем. Кәгазь-каләмне күрәсем дә килми башлады. Хәтта Сажидәгә дә хат язып салмадым. Ә соңыннан үкенергә туры килде. Тулай торагыма, ягъни Тренев дачасына кайтуыма, Сажидәдән ике хат ята иде тумбочка өстендә. Бер ай буе дәшмәвемә каршы, ул миңа кызларга гына хас «сюрпризлар» белән жавап биргән. Хатларында шундый юллар:

«Саумысез, Әдип!

Сездән хат алмасам да, язмакчы булдым. Безнең хәзер каникуллар. Буш вакыт күп. Бераз күңелсезрәк тә. Менә бүген көне буе физрук белән чаңгыда йөрдек. Таудан шуып төшкәндә агачка эләгеп чаңгыны сындырдым һәм аз гына маңгайны яраладым.

Унбиш көн инде—Зина Өфедә. Өйдә ялгызыма шундый күңелсез, хәтта куркыныч та. Идән буйлап күселәр чабыша. Ә мин алардан куркып, караватка менеп утырдым да, китап өстендә генә сезгә хат язам. Житдирәк бер эшкә дә тотынып булмый. Әллә нәрсәләр уйлап бетердем инде. Үзем дә гажәпләнәм, шундый куркыныч булып китте—бервакытта да болай булганы юк иде. Моның сәбәбе күселәр генә түгел булса кирәк.

Мин монда килгән вакытта бер максат куйган идем. Беләсезме, сезнең хатларыгыз миңа шул максатымнан тайпылмаска ярдәм итеп торганнар икән. Тик сез: «Мин һәрвакыт хат язып торырга тиеш икән»,—дип уйлый күрмәгез. Югыйсә, миңа бик уңайсыз булачак. Һәм, зинһар, гафу итегез мине шундый таркау хатым өчен. Бүгенге «искитмәле» егылудан соң башым әйләнә...»

Йөрәгемә чәнчеп ала торган сүзләр икенче хатында да кабатлана:

«Беләсезме, Әдип, бер яктан, укытучы булу әйбәт. Ә икенче яктан—бик начар. Укучылар һәр адымыңны, хәрәкәтеңне күзәтеп йөриләр. Урамнан берәр егет белән узганыңны сизсәләр, алар аны жыенаятькә саныйлар. Узган шимбәдә беренче мәртәбә танцыга бардым. Кич буе бер яшь кеше белән биедек. Һәм соңыннан мине озатып та куйды ул. Ял көне, кинодан соң, тагын урам буйлап йөрдек. Менә бүген кайда гына күренсәм дә, пышылдап сөйләшкәннәре ишетелә: «Ташбулат», «танцы» һәм башкалар. Кайберләре, юри мин ишетсен өчен, кычкырып та әйтәләр. Ни дисең аларга? Укытучы неужели монашка яки «футлярдагы кеше» булырга тиеш! Хәзер гел сагаеп, «ул-бу булмагае» дип кенә йөрергәме? Белмим, нишләргә, дөреслек кем ягында соң?..»

Уйланырга, сагаерга мәжбүр итте мине бу хатлар. Бер мәлгә ял итеп, йокымсырап торган йөрәгем, читлегенә сыймыйча, тыпырчына,

хәтта дулый башлады. Әллә соң Сажидә мине сынар өчен, юри генә уйлап чыгарганмы ул «сюжет»ларны? Фантазиясен уйнатканмы, канцеконцов? Юк, бер дә генә белмим шул әле мин элекке укучымны, хәзерге укытучы кызны. Кыю һәм үзсүзле булырга охшый. Якамнан эләктереп алды бит. Иң авырткан урыныма кагылды. Көнләштерерлек итеп. Ул Ташбулат дигәнен хәтта куралмас хәлгә киддем. Аның «физрук» дигәне дә шул үзедер, мөгаен. Башын әйләндереп куймагае.

Ләкин хат язганда боларны сиздермичә, үз биеклегеннән төшмәскә кирәк, дип уйладым. Баштан ук ялынсаң, аннары гомер буена тезләнеп яшәрсең. Ә хәзергә әле син ирекле кош. Минем дә үз горурлыгым бар лабаса.

«...Сезне аңлыйм, Сажидә. Биредә, чыннан да, күселәр генә гаепле түгелдер. Кайвакыт романның тәүге битләре мавыктыра да, аннары артабан күңел еүрелә башлый. Ә сезнең «роман», бәлки, тәмамланып ук киләдер. Шулай да «Ана» булган тойгыларыгызны салкын баш белән тагын бер сынап карау артык булмас, минемчә.

Йә, ни дип әйтим тагын? Ике мең километр ара һәм 12 ел вакыт аерып тора безне. Хәзер генә күрешеп сөйләшү мөмкинлеге юк. Әйе, хат аша гына бер-береңне аңлау кыендыр ул. Әле бит һәркемнең үз «цензурасы» бар. Кайчагында язган хатыңны йомарлап, чүплеккә ташлыйсың да, янадан язарга тотынасың.

Сажидә!

Әгәр Башкортстанның ерак бер почмагында сезнең язмышыгыз, үзегез теләгәнчә, матур хәл ителә икән, нигә куркып торырга! Ләкин, үз бәхетен эзләүче егет буларак, мин башкача да фикер йөртергә хаклы: җәй көне күрешербез, аңлашырбыз, көтә аласың икән—көт, акыллым. Соңгы ике хатыгызны укыганнан соң, мин шуларны гына әйтә алам.

Икенче хатыгыз, ничектер, теләр-теләмәс кенә язылган шикелле. Ә беренчесен кат-кат укып чыктым. Анда билгесез борчылу, ачынып кычкырасы килү... һәм чын мәхәббәткә сусау... Минем дә хәлем шулайрак бит. Әле хуҗерак та.

Беренче хатның авторына ихлас күңелдән иң җылы тойгыларымны белдерәсем килә: бәхетле бул, сеңелем, һәм кемне дә булса тагын бәрәүне бәхетле ит!

Март аенда яшь язучыларның Бөтенсоюз киңәшмәсендә Татарстаннан делегат булып катнашам. Казаннан да, Өфедән дә килергә тиешләр. Тагын ни языйм? Зинага низкий поклон! Егылып, тагын чангы сындыруыгызны теләмим. Түземсезлек белән хат көтәм...»

Менә шундый хәлләр. Сажиданең соңгы хатларын Рәмигә укырга бирмәдем. Күзләремә карап, нидер сизенде булса кирәк, үзе дә сорамады. Нечкә күңелле, бик сизгер егет ул. Барометр шикелле.

Мин юкта институтта әлләни үзгәрешләр булмаган. Шулай да бер яналык сискәндереп җибәрде. Теге, Кремль тартмасына салган хат унае белән, иҗат кафедрасындагы кульъязмаларга, «ревизия» ясаганнар. Укырга кергәндә студент нинди әсәрләр белән конкурс узган—шуларны тикшереп чыкканнар, талант дәрәҗәсен ачыклаганнар. Безнең курстан биш студентны «иҗади булдыксызлыгы өчен» дип, Мәскәү дәүләт университетының филология факультетына күчергәннәр. Өчесе—Мәскәү кызы. Әтиләре дәрәҗәле кешеләр икән. Курста кызларыбыз болай да аз иде.

Санаториядән кайтып, берничә көн үтүгә, мине дә иҗат кафедрасына чакырып алдылар. Бәла ялгыз гына йөрми дип, борчылып кердем мин анда: Сажидәдән килгән хәвефле хатлар, авырып йөрү... Өстәвенә институттан да шудырсалар... Бәлки яхшыга гына булыр монсы? Нигә дип әле көчәнеп укып йөрергә?!

Борчылуым юкка гына булган. Иҗат кафедрасында утырган кызыл иренле ханымнар мине үз итеп, елмаеп каршыладылар. Бишенче курс студенты Василий Федоров (соңыннан күренекле шагыйрь) сүзмә-сүз

тәржемәләремә кыска гына итеп резолюция салган: «Бик теләп укып чыктым, иҗатын хуплыйм. Шулай дәвам итсен.» Тәнәфес вакытында яныма килеп кулымны кысты.

Ә икенче рецензентым—Мәскәү шагыйре Сергей Наровчатов. Ул болай дигән: «...Мин үзем дә шактый вакытлар Сахалинда булдым. Авторның уй-хисләрен рәхәтләнеп уртаклашам. Шул ерак Атау аша Ватан тойгысы калку итеп бирелгән...»

Бер мәлгә кәефем күтәрелгәндәй булды. Ярты семестр өчен имтихан һәм зачетларымны да, бәрелә-сугыла булса да, җилкәмнән төшердем. Әмма шуннан соң бөтенләй аңгыраеп, шиңеп калдым. Төннәрен барбамил дигән көчле дару эчеп кенә йокыга китәм. Үзем әллә нинди куркыныч төшләр күрәм. Шул чагында кинәт борчулы йөз белән Сәҗидә килеп баса каршыма, «бахыркаем» дип, башымнан сыйпап юата, имеш. Соңгы вакытта дөньяны күрәсем дә килми башлады. Юктан-бардан җан үртәлә. Китапларны, конспектларны бер читкә сыпырып куйдым. Чангыда чыккан булам. Санаториядәге профессор әйткәннәрне искә төшереп, «юк-бар турында уйламаска» тырышам.—«Ә кызлар турында»... Сәҗидәдән килгән хатны да укыйсы килми тора. Шулай да кызыксыну җиңде. Йә, минем җавап хатымны ничегрәк кабул итте икән?

«Әдип!

Минем сезгә бер хатны да теләр-теләмәс кенә язганым юк. Киресенчә, һәрвакыт якын кешегә язган тойгы белән һәм артык нәрсә язып ташламагаем дип, сакланыбрак язам. Чынлап та, соңгы хаттагы сүзләрне язарга ни хакым бар иде соң? Ярый әле сез аларны дөрес аңлагансыз һәм ачык җавап язгансыз. Ә бит моның бөтенләй башкача булуы мөмкин иде.

«Тагын нәрсә языйм инде.» «...Тагы бер кат салкын баш белән тикшереп карау артык булмас»,—дисез сез. Ул вакытта мин яраланган баш белән язсам да (между прочим, я повязку сняла недавно), уйламый гына язмадым.

«Тәмамланып килә торган роман» турында сез бераз арттырыбрак язгансыз. Чөнки мин ул «роман»га чын мәгънәсе белән башланып китәргә дә юл куймадым. Тик мин аңа өметләнергә повод биргәнмен—менә шунда инде минем хатам.

Әдип, бәлки минем бу хат та коры, теләр-теләмәс кенә язылган кебек күренәдер. Ә чынында исә бер дә алай түгел, ягъни алай язарга теләмәгән идем, дип әйтәсем килә. Менә хәзер, гомергә беркемгә дә язмаганча итеп, шундый әйбәт, җылы хат язарга дип утырган идем, ләкин...

Гомумән, сез аны аңлыйсыз. Сез бит барын да аңлыйсыз. Алда ни көткәнен ходай үзе генә белә. Уйларымда сезгә бик нык ияләшермен дип курка башладым. Әйдәгез, бу хакта бер сүз дә язмаска дип шарт куешыйк. Болай да инде барсы да аңлашыла. Бу мәсьәләгә карата яшәп килгән элекке карашларым нинди дер чепухага әйләнеп кала кебек. Сезнеңчә ни бу: җинел акыллылыкмы, яки башка берәр нәрсәме?

Мин элек һәрвакыт, кыз белән егет бер-берсен бик яхшы белергә тиешләр дип уйлый идем. Хәзер дә шул уемнан кире кайтканым юк-югын. Күптән түгел мин яшьләр өчен «иптәшлек, дуслык һәм мәхәббәт» дигән темага лекция сөйләдем. Сез тыңласагыз иде мине! Шундый житди, шундый объективно... Әйтерсең лә, ул эшләр минем баштан күптән кичкәннәр һәм хәзер «гыйшык» дип йөргән кешеләргә «мыек астыннан» гына көлеп карап йөрим. (Үземә хәтта көлке булып китте). Лекциядә шул башта әйткән фикеремне үстереп бардым. (Бер-береңне яхшы белү). Ә үзем бөтенләй диярлек белмәгән кеше турында уйлыйм. Бәлки, бу артык хыялга бирелү, фараз кылу нәтиҗәседер. Гомумән, берни дә аңлый алмыйм. Менә шулай. Хәзер нинди фикер каршылыклары турында сүз барганы ачыктыр инде. Тел яшермәү яхшы, диләр дә бит, ләкин аның тискәре

нәтиҗәләре дә булырга мөмкин. Ни булса, шул. Пусть будет все ясно.

Мин хәзер шул турыда уйлый башладым әле: Сезнең белән очрашсам, боларның бөтенесеннән дә соң үземне ничек тотармын икән инде? Кызарырга туры килер, ахрысы. Все же сезнең минем турыда легкомысленныерак кыз дип уйларга хакыгыз бар. Чынлап әйтәм. Ярый, бу турыда бетте.

Менә бүген генә бер укучым яныннан кайттым. Ул бала бөтенләй эштән чыгып бара, ата-анасын тыңламый, кичләрен кайда теләсә, шунда йөри, тәмәке тарта, кайбер фәннәрне бөтенләй укымый. Ә үзе бик сәләтле бала. Гаҗәпкә каршы, ул малайга миндә ниндидер симпатия бар. Минем дәрестән ул һәрвакыт «5»ле ала. Һәм минем алда бер генә әдәпсезлек тә эшләми. Бу вакытка кадәр мин аның житешсезлекләренә артык игътибар итмәгән идем. Ләкин кичә, исереп урамда йөрүдә гаепләнеп, директор янына алып керүләрен күргәч, үзләренә бармакчы булдым. Әтисе райсоюз председателе. Марстан башка беркем дә өйдә юк иде. Караңгы бүлмәдә ике сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Мин ана тавышымны да күтәрмәдем, ләкин ул елады. Минем үземнең дә күзләремнән яшьләр агып төштеләр. Ярый әле караңгы иде. Белмим инде, нәрсә булыр ул бала белән? (Аңа инде 15 яшь). Уңай якка борылыш булыр төсле. Өлкән малайлары да беренче хулиган булган, хәзер армиядә, ди.

Ата-аналар белән укытучыларның тиешенчә игътибарлы булмаулары никадәрле балаларын юлдан яздыралар бит. Мин дә шул игътибарсызлар исәбенә керәм, әлбәттә. Минем класста 36 бала. Аларның һәркайсына аерым подход кирәк. Үткән атнада бер кызым тормышка чыккан. Аңа әле 16 гына яшь. Бу турыда бүген генә белдем (ул башка авылдан). Үз классымдагы баланың нинди интереслар белән йөргәнен дә сизмәгәнмен. Нишләргә инде алар белән? Менә шул инде минем тәрбиянең җимешләре. Педсоветта шулай дип әйтәчәкләр инде. Һәм алар хаклы булырлар.

Әдип, бу—көчсез кешенең зарлары түгел. Тик кайгы-хәсрәтләр белән бүлешәсем килү генә.

Сез каникулыгызны бик яхшы үткәргәнсез. Көнләшерлек бар. Һәм, гомумән, шундый кечке прогулкаларны ешрак ясагыз. Иң беренче рецепт сезгә—тынычлык, саф һава. Сез алай күтәрә алмаслык максатлар куймагыз инде, һич югы хәзергә, укып бетергәнче, үзегезне бөтенләй таза итеп сизгәнче. Бәлки, чынлап та, сез уйлаганча, заочнага күчү кирәктер. Их, карап, кайгыртып торучы житми сезгә.

8 нче мартта новоселье үткәрәбез. Якын булсагыз, сезне дә чакырыр идек. Ә сез килергә теләр идегезме?

Әткәйләрдән хат алып торам. Әткәй озак кына авырып яткан, ләкин миңа сәламәтләнгәч кенә язганнар. Алар һәрвакыт шулай итәләр.

Сау булыгыз, Әдип.

Сажидә.

28/II-51 ел.»

Лекцияләргә йөрү «ирекле»гә әйләнде. Укый башласам, күз алдында сары божралар уйный, күңел болгана. Кинода да ахырына кадәр утыра алмыйм.

Литфонд поликлиникасы исеменнән институт дирекциясенә хат килгәнлеген хәбәр иттеләр. Кабинетына барып кергәч, директор урынбасары профессор Сидоров шул кәгазьне кулында әйләндергәләп, бераз уйлап торды да, миңа сузды. Укыйм: «Студент А. М. Маликовка, сәламәтлеген жайга салу өчен, бер елга академик отпуск бирергә тәкъдим итәбез»—диелгән анда. Диагнозы да күрсәтелгән: «Вегетодистония на почве переутомления центральной нервной системы».

—Нишлибез соң?—дип сорады директор урынбасары, аптыраулы караш белән.

—Үзем дә белмим,—дидем.

Хәзер генә каядыр китәр урыным булмавын, өйдәге гаилә хәлләрен анлатып бирдем. Ике энем—Рәмзи һәм Марс Армиягә алындылар, икесе дә Ерак Көнчыгышта хезмәт итәләр. Әле алардан башка да бит өйдә алты бала. Мин жиденчесе булып кайтырга тиеш. Үзем Сажидә турында да уйланам. Ана бит имтиханнар беткәч, Мәскәүне күрсәтәсем бар. Шулай дип язган идем хатыма.

Уйларымны сизгәндәй:

—Икенче курсны ничек тә түгәрәкләргә кирәк сезгә,—диде профессор, бер карарга килеп,—имтиханнарга кадәр Переделкино дачасында яшәрсез. Теләсәгез, ике-өч айга санаториягә путевка юллый алабыз.

Анысыннан баш тарттым. Нишләп кенә йөрермен сон мин анда шул гомер «эт сугарып?» Бер ае да туйдыра. Ялга сусап килгән адәмнәр арасында үземне «соры корт» итеп сизәргә теләмәвемне белдердем. Кинәт күнелемдә бер уй яктырып куйды. Минем бит әле Казандагы кичке Марксизм-Ленинизм университетын тәмамлау турында дипломым бар. Кирәге чыкса дип, аны үзем белән алган идем...

Партия шәһәр комитеты каршында оештырылган ул университетта мин 1946-48 елларда укып йөрдем. Әдәбият һәм сәнгать бүлегендә (сугыштан сон беренче набор) халыкта кин танылган артистлардан Фәхри Насретдинов, Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатова, театр училищесы директоры—юан һәм көр тавышлы Булатов абый, уен-көлкеле Әхмәт Исхак, тагын кемнәрдер бар иде. Гамир Насрый бер ай чамасы йөрде дә кул селтәде.

Кызыл тышлы дипломым профессор кулына күчте. Имтиханга кергән андагы дүрт фәннең институт курсы өчен дә яраганлыгын әйтеп, минем өчен сөенеп куйды ул.

—Сезнең тагын «Языкознание» (Реформацкий) һәм «Сәнгать тарихы» кала,—диде. Әле вакытыгыз бар, боларын гына жинәрсез...

Безнең курста тагын бер «ирекле» барлыкка килде: шагыйрь Сергей Орлов. Сугышта танкист булган. Һөжүмгә барганда, дөрләп яна башлаган танк эченнән көч-хәл белән коткарып калалар үзен. Бите, мангае, куллары пешеп, озак вакытлар хәрби госпитальдә ята. Битендәге операция жөйләрен яшерү өчен, хәзер ул сакал-мыек үстереп йөри. Бу инде кылану түгел. Сергей Орловның «Его зарыли в шар земной» дигән атаклы шигырен студентлар гына түгел, профессорлар да, жае чыккан саен, телгә алып сөйлиләр иде. Сергей СССР Язучылар Союзында эшли бугай. Ирекле тынлаучы булу ана ярагандыр да. Мин үземне ләкин, «ирекка чыктым» дип, бәхетле санамый идем. Башкалар алдында күз көеге булып йөрим шикелле. Аның бит әле ышанганы-ышанмаганы бар. Акрынлап, иптәшләремнән, дөньядан читләшә башладым.

Март ае житте. Урмандагы кошларга жан өрде кояшлы яз. Кайчагында кичкә каршы Переделкино урманнарына чыгып китәм, таныш сукмаклардан атлыйм. Күк йөзе, янгын шәүләсе сыман, ялкынланып тора. Тирә-юнь яп-якты. Мәскәү шәһәренең миллионлаган утлары шулай офык читләрен алсу нурга мана. Ниндидер дәһшәтле, сихри бер көч тоясың шуларга карап.

Мин хәзер хаттан-хатка гына яши башладым. Хат язарлык жаем бар әле.

* * *

«Исәнмесез, Әдип!

Сезгә кая юл тотарга—шуннан башлыйм сүзне. Минем фикерем хәлиткеч роль уйнар дип дәгъва итмим. Үзегез яхшырак беләсез, әлбәттә, 2-3 айга булса да әти-әниләрегез янына кайтырга киңәш бирер идем мин. Ә сез берәр совхозга барып, эшкә керешмәкче буласыз икән. Анда тыныч булыр дисезме? Бармы соң ул эшнең жинеле, тынычы? Һәркайда

үз мәшәкате табылып тора. Үзегез: «Врачлар укырга, кино карарга да кушмыйлар»,—дисез. Укымый, язмый торган урын кайда бар микән? Бәлки бакчачы булыргадыр? Ләкин анын да бит серләрен белергә кирәк. Туган якка кайтыгыз, Әдип. Җиләк-җимеш бакчасы утыртырсыз, су сибәрсез, чәчәкләр үстерерсез (Мәскәүдә чәчәк орлыклары алырга онытмагыз). Балык тотарсыз, әтиегез белән печән чабарсыз. Сезгә бик нык контроль һәм кайгыртучан кеше кирәк хәзер. Үзегез генә режим саклый алмаячаксыз. Ә моны фәкать аналар гына булдыра ала. Бик күнелсез була башласа, каядыр китеп бара да аласыз бит.

Кичә теге шагыйрь янында булдым (үзенең кайбер этлекләре өчен гафу үтенгәч, без татулаштык). Көне-төне шигырь яза, шигырь китабы хәзерли. Ана сезнең турыда сөйләдем. «Әйдәгез, үзебезнең янга чакырыйк», ди. Бу тәкъдимне бик озак тикшердек һәм, ахырдан, монда сезгә күнелсез булачак, дигән нәтиҗәгә килдек. Ә монда һәммәсе ят-чит. Ә без мәктәпкә китеп югалачакбыз. Санаториягә баруга үзегез дә каршы шикелле. Мин үзем белгән вариантлар турында яздым. Үзегезгә хәл итәргә кала инде. Ә минем ужасно өйгә кайтасым килә. Тагын өч ай көтәсе бар. Мәскәү белән Ленинградны да бик күрәсе килә, бигрәк тә тарихи һәйкәлләрен. Сез хаклы: тарихчы өчен бу зарури. Белмим, хыялларым хыял гына булып калмас микән.

Әле күптән түгел, бишенче классларым белән экскурсиядә булдык, хәрби уеннар уйнадык. Укучылар мина чапаевчылар белән Колчак бандалары сугышып узган урыннарны күрсәтеп йөрделәр. Хәтта шундагы бер зур таш артына яшеренеп, Чапаев пулеметтан дошман яуларын кырган, имеш. Шул тирәдә генә тау куышы бар икән. Ләкин мәгарәнен эченә шуышып кына кереп була. Балалар, бер-берсен бүлдереп, рус наместнигын үтергәч, шушы тау тишегендә качып яткан Биеше турында сөйлиләр. Тау куышының аргы башы моннан йөз чакрым ераклыктагы Баймак тирәсенә барып чыга (анда бакыр табыла) икән. Мавыгып сөйлиләр. Аларны тынлый белергә кирәк, фикерләренә дөрес юнәлеш бирергә. Җәй көне таулар ягына, балаларны ияртеп, походка чыгарга исәп. Сабый чакта биек таулар белән хыяллана идем. Туган якта без андый тауларны күреп үсмәдек.

Бергә басып күмәк төшкән рәсемне җибәрәм (мин сулдан икенче). Шул төшүдән соң, бер сантиметр да үсмәдем шикелле. Буем кечкенә, әйеме? Ә янәшәмдәге кыз—студент елларындагы дустым Рая Черкай. Гаҗәеп әйбәт кыз, бер дигән иптәш. Ул хәзер Туймазыда. Бөтенесеннән гайрәтем чикте, ди. Хыял белән чынбарлык арасындагы күперне кем салырга тиеш соң? Икебез дә зур түземсезлек белән җәйдә очрашуны көтәбез. Зина шикелле, ул да украинка. Планнар тормышка ашса, Мәскәүгә барырга исәп.

Сау булыгыз, Әдип!

Берәр карарга килү белән, хәбәр итегез. Түземсезлек белән көтәрмен.

Сажидә.

18 март, 1951 ел.

Яңа квартирабыз бик әйбәт. Зур һәм якты. Иң мөһиме—каенлыклар янында. Тик менә проблеманы хәл итә алмыйбыз: Мин «җәйгә каләр мич янында йокла», дип үгетлим. Ә Рая теләми. Койкаларыбыз, бәхәс бетүен көтеп, ишек төбендә торалар. Ахыр чиктә икебез дә хат язарга утырдык. Бәлки ул да кемгәдер зарланып язадыр.»

Моннан алдагы хатымда, уен-көлке аралаш, Сажидәнен буе турында сорап язган идем.

Мин туган Югары Чат авылында Арслан исемле оста сунарчы бар иде. Төп шикелле нык, юантык гәүдәле. Ә буйны бирмәгән Ходай. Хатыны исә иреннән ярты метр озын. Каян килеп табышканнар. Арслан абзый Сәхипҗамалын үпкәндә, баскыч куеп менә имеш дип, көлеп сөйлиләр иде. Чыннан да, кызын үзеннән бер башка озын булса, нишләрсен?!

Шул шаян соравыма җавап итеп җибәргән инде бу күмәк төшкән фотосын. «Буем кечкенә, әйеме?» дип раслатырга тырышуына сөендем генә.

Яз үзенекен итә. Табигать күзгә күренеп җанлана. Переделкинода ул бигрәк тә нык сизелә. Әрәмәләрдә, чыршы, нарат урманнарында кошлар үзләрен кая куярга белмичә, агачтан-агачка кунып, и, чөкелдәшәләр—аңласаң иде телләрен. Саҗидәнең соңгы хатлары да быелгы язга аваздаш шикелле. Алар миңа боегырга ирек бирмиләр.

«Правда» гәзитендә басылган Сталин премияләре лауреатлары исемлегендә үзебезнең Татарстаннан Кави Нәҗми («Язгы җилләр» романы), Гомәр Бәширов («Намус» романы) исемнәрен күргәч, башым күккә тиярдәй булды. Бу бит гаҗәеп хәл, моңарчы булмаган тарихи нәрсә әдәбиятыбыз дөньясында.

Шул мәртәбәле документта безнең әдәбият институты студентлары төркмән драматургы Мөхтәр Гусейнов («Алан семьясы» пьесасы), мари шагыйре Миклай Казаков (шигырьләр җыентыгы) исемнәрен күрү дә зур сенсациягә әйләнде. Институт коридорлары корт умарталары шикелле гөжләп тора.

Миклай әле I курста гына укый. Моңа кадәр Мари язучылар оешмасының җаваплы секретаре булып эшләгән. Үтә дә гади, тыйнак һәм кешелекле зат.

Гусейнов та юкка-барга сикереп китә торганнардан түгел. Сабыр һәм салмак адымлы ир уртасы. Өлкән курста укый. Безнең шикелле, институттан кырык чакрым ераклыкта яшәми. Торган җире Мәскәүдә. Лекцияләргә еш кына таксига утырып килә. Ни әйтсәң дә, Союздаш республика вәкиле шул. Ә менә «автоном» Миклай Казаков, премиясен һәм медален алгач, нишләр икән? Алга сикереп әйтәм, ул Переделкинодан, курсташ дусларыннан аерылмады. Безнең шартларда яшәде. Масаю дигән нәрсәнең заты да күренмәде. Әйе, чын кешеләр менә шундый тыйнак булырга тиешләр дияр идем.

Икенче көнне Казан вокзалына—яшь язучыларның бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырылган каләмдәшләремне каршыларга төштем.

Алдан ук хәбәрләшеп торган идек.

Поезд килеп туктауга, вагон ишегеннән Мәхмүт Хөсәен күренде. «Салют!» дип сәламләде дә, җинел генә сикереп төшеп мине кочаклады. Ул да әле шинелен салырга өлгермәгән икән. Битендәге дары эзеннән калган зәңгәрсу сипкелләре дә җуелмаган. Сугыш эзләре йөрәктән дә гомер буена җуелмас инде.

Кояш кебек елмаеп, Ләбибә Ихсанова күренде. Ә аның көлүен чылтырап аккан чишмәгә охшата идем. Хәзер дә үзгәрмәгән. Балалар өчен язылган «Көмеш елга» исемле повестеның шаулап барган чагы иде.

Бер аягын сугышта калдырып, протезга баскан Ибраһим Нуруллинга баскычтан төшәргә ярдәм иттек. Ибраһим исә «әле бөтенесе дә алда», дибрәк йөри торган басынкы, аз сүзле яшь прозаик. Артык дәрәҗәдә тыйнак, оялчан... Ул әле, янар тау сыман, бер уянып китәчәк дип, күңелемә салып куйдым.

Без вокзалга керү белән, Татарстан лауреатларын кайнар котлап, күмәк телеграмма суктык. Ахырдан «Москва, Казан вокзалы» дип тә куйдык.

Мәхмүтнең: «Радиодагы Мөнир Мазуновтан сәлам сиңа»,—дию кинәт үткәннәрне искә төшерде. 1946 елның ахырында иде бугай, Мөнир белән Миңҗамалның туй мәҗлесендә булырга туры килде. Күбесе әдәбият, музыка әһелләре, журналистлар. Шагыйрь Шәйхи Маннур котлау сүзе итеп «Туй» шигырен укыгач, дәррәү кул чаптык. Аннары китте, китте кызып... Радиода чакта янәшәмдә тыныч кына утыра торган Мансур Мозаффаровның да теле «ачылды», хәтта җырлап та җибәрде. Миңҗамалның баянда, ана кушылып, Заһид Хәбибуллинның скрипкада уйнавы үзәкләрне өзгән иде. Фәйзи Биккининның кечкенә гармуннарда уйнавы,

Бари Корбановнын, аю сыман, алпан-тилпән килеп биюе дисенме...

Каләмдәш дусларым белән бергә гүя Казан үзе килгән. Истәлекләр дә янарды. Ул Мәхмүтне әйтим: һәр яктан өлгер булды ул. Туйга барса, шигырь сөйләп, һәммәсен авызына карата, оча-куна бии. Андый мәҗлесләргә кайчакта мине дә ияртә иде.

Каләмдәш дусларым белән бергә булуга сөенеп бетә алмадым. Кәефем дә күтәрелде шикелле.

Кинәшмәдә Татарстан делегаты булып мин дә катнашачакмын. Павел Антокольский семинарында. Авыру нервларым тагын ныграк чуалыр микән инде. Шулай да кульязмаларымны бирергә булдым.

Павел Антокольский йомгаклау сүзендә, бик нигезләп, шигырьләремә карата унай фикерләр әйтте. Мин моны көтмәгән идем. Хәтта тәрҗемә итәргә әзер торуын белдереп, өй адресын да бирде. Бара алмадым шул. «Мескен»легем итәктән тартты, ахры.

Хатларымда Сажидәгә шундыйрак информацияләр язып җибәрәм. Ә анын хатлары тыгыз эчтәлекле була. Үзе өчен дә, сонгы вакытта минем өчен дә борчылып яза башлады.

«Исәнмесез, Әдип!

Инде яктырып килә. Кичтән «Иван Иванович»ны укый башлаган идем, шулай итеп, иртәнгә кадәр утырганмын. Ятарга сон инде, йоклап китеп, мәктәпкә сонга калуын бар. Һәм менә сезгә хат язарга булдым. Башым ап-аек.

Сез кая юл тотарсыз икән дип уйланам еш кына. Төрле вариантларны чагыштырып, күз алдына китереп карыйм. Ләкин берсе дә реаль түгел сыман. Бәлки безнен янга килерсез, дип тә уйлыйм кайчагында. Биредә бик күнелле хәзер. Гайрәтләнеп яз ташып килә. Тиздән апрель, аннары май, ә ул чагында тагы да матуррак булыр. Камал янына бер шагыйрь килгән иде, ана да ошады биредә. Янадан килергә вәгъдә итте.

Сон, ничегрәк хәл иттегез? Кәефегез ничек? Тик рух төшенкелегенә бирелә күрмәгез, Әдип, барысы да әйбәт булыр.

Минем хәлләр искечә диярлек. Балалар кайчагында чыгырдан чыгаралар. Шулардан арыну өчен, һәммәсенә кул селтәп, каядыр китәсе килгән чаклар була. Үзләре үк тагын шул төшенкелек базыннан тартып алалар. Менә бүген (дөресрәге, кичә) класста мәхшәр оештырдылар. Булдыра алганча, ачуландым, кычкырып та карадым. Кайберләрен елатканчы тиргәдем. Аннары, кәефем кырылып, кайтып киттем. Кичке якта укучыларым өйгә килгәннәр. Мин утын ярып маташа идем. Малайлар, кулымнан балтаны алып, үзләре яра, каяндыр пычкы табып, утын кисә башладылар. Эш кайный гына. Ике атналык утын хәзерләп, өеп тә куйдылар. Шуларга карап, сөенечемнән күнелем тулды. Менә нишлиләр бит шайтаннар!

Сонынннан, элек туктап калган урыннан, Лев Кассильнен «Кече урам малае»н укуны дәвам иттердем. Бу китап шундый ошый үзләренә! Күзләрендә гаҗәпләнү, соклану. Тын да алмыйча тынлыйлар. Разведкага йөрүләре көн дә төшебезгә керә, диләр. Ә мин юри, үч иткәндәй, ин кызык урынга житкәч кенә укудан туктап калдым. Алар исә түземсезләнеп, алда ни буласын көтәләр, мөнгерәшеп, ризасызлык авазлары чыгаралар, мине каты бәгырьлелектә гаепслиләр. Сүземдә тордым. «Дәвамы бар», дидем дә, китапны ябып куйдым.

Кайдадыр болытлар өстендә йөзгәнмен икән... Диктор авазы, шушы дөньяда яшәвемне белдереп, мине сискәндереп җибәрде:

—Тынлагыз, Өфе һөйләй! Өфе вакыты менән сте сәгат утыз биш минут.

Мәктәпкә җыенырга вакыт. Башны күтәрәсе дә килми.

Сау бул, Әдип! Гел яхшылыклар гына телим.

Сажидә. 24/III-51 ел.

«Иван Иванович»тан сон никтер йөрәк чәнчеп куйды. Мәктәпкә бармас идем».

* * *

Атаклы драматург Константин Тренев күп тапкырлар атлап узган агач баскычларны шыгырдатып, һәр иртә саен астагы катка—буфетка ашыгабыз. Анда безне якты йөз белән өлкән яшьләрдәге Василиса Андреевна каршылый. Һәркайсыбызга балалар исеме белән «Саша», «Ваня», «Володя»... дип кенә дәшә. Шулар рәтеннән мин дә «Алеша»га әйләндем. Ходайга шөкер, буфетыбыз байый тора. Гадәти боткалар янына сөте, каймагы барлыкка килде. Элекке сыман, коры-сары белән тукланып, коридорда торган коллектив бактагы җылымса су белән хушланып яшәү бетте. Кичен соңгарак калып кайтсаң, үзеңә тигән өлешең өстәлдә, ак җәймә астында көтеп тора.

Василиса Андреевна без ашаган чакта һәркайсыбызның янына килеп, ниндидер җылы сүз әйтеп китә, «өстәмә кирәкмиме?» дип тә сорый. Кайчагында ул «И, балакайлар»... дип, тирәннән уфылдап куя. Ә без шул чагында тынып калабыз. Аның бердәнбер улы Мәскәү янындагы каты сугышларда бомба астында калган икән. Сөякләрен дә җыя алмаганнар. Ире фаҗигале үлемгә очраган. Менә шулай тол хатын булып калган «Василиса-анакай».

—Сан Саныч сезнең ашау-эчүегез белән кызыксынып тора,—диде бер көнне пешекче апабыз.

—Ә без аны белмибез,—дигәч, гаҗәпкә калды ул:

—Соң, борын төбегездә яши бит, Александр Александрович Фадеевны да белмәскә?!

Аннары көрсенеп, өстәп куйды:

—Үзе болай бик кеше җанлы да соң. Зур язучы. Тик бәхете генә юк бичараның.

Ә ни өчен бәхетсез, нигә бичара булырга тиеш әле ул?! «Тар-мар» шикелле классик әсәрләрен без мәктәптә укып үскән, халык мәхәббәтен яулаган язучы бәхетсез була димени? Өстәвенә, күренекле оештыручы-җитәкче дә. Күңелләребездән нидер сизенсәк тә, без бу сорауларга барыбер ачык кына җавап ала алмас идек. Шәхси бәхет, күрәсең, дәрәҗәгә, талантка карап кына килми. Есенинны да, Маяковскийны да күпләр бик бәхетле дип санаганнардыр. Ә тормыш юллары аларның фаҗига белән чикләнә.

Переделкинода яшәүче студентларны тәҗрибәле хатын-кыз врачка беркетүләре дә безнең өчен бер яңалык булды. Кабул итү сәгатьләре, язучылардан бушангач, кичке якта була. Студентлар яшәгән дачаларга да килеп йөри. Бик игътибарлы булганы өчен, без Екатерина Владимировнаны да яратып өлгердек. Монсын да СССР Язучылар союзының генераль секретаре Александр Фадеевның кайгыртучанлыгы дип аңладык.

Саҗидәдән хат килгән көн минем өчен бәйрәмгә әйләнә башлады. Ник болай ашкынып хәбәр көтәм соң әле аңардан? Үзем дә аңлап бетерә алмыйм.

«Саумысыз, Әдип!

Сезнең бу хатыгыз мине кызарырга мәҗбүр итте. Мин Бәшировның «Намус»ын да, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»ен дә укымадым. Гомумән, бер татар язучысының да әсәрен укыганым юк (балалар белән бергә укыган «Җиде көн җир астыннан»ны санамаганда). Бик кызганыч, әлбәттә.

Яшь язучылар киңәшмәсендә Габдулла Әхмәтов белән Нажар Нәҗми дә катнаша, дигәнсез. Икесен дә беләм. Алар бит безнең институтта укыдылар. Танцыларда очрашкан да булды. Нажар Нәҗмине без «Назар Назарович» дип йөртә идек. Модный киенергә ярата. Җырга оста. Кызлар күзе төшәрлек, һәрхәлдә.

«Сездән талантлы педагог чыгачак», дигән юлларны укыганда чәчләремә кадәр кызардым. Алай диясе булмагыз, Әдип, сез бит берни дә белмисез минем мондагы эшем турында. Менә бу чиректә минем 5

классста 13 бала өлгәшми. Ары ташланам, бире чабам, ялым да, йокым да юк соңгы вакытта.

Бүген ял көне. Зина белән киләчәк турында хыялланып алдык. Бик ерак киләчәк түгел: җәй айлары турында. Агыйделдә су коенып булыр микән?—дибез. Хәзер инде Өфе белән ара өзелгәнен искә төшереп, чак кына җылап җибәрмәдем. Монда да якын-тирәдә су юк, Тәтешледә дә юк. Шулай да купальникларыбызны бер-беребезгә күрсәтеп, мактанышып алдык. Зинаның әле купальный баш киеме дә бар икән. Шуннан соң икебез дә хат язарга утырдык. Мондый «мөһим» сүзләрне хатка язмыйча мөмкинме соң?

Соңгы хатыгызда Казанда калган кызыгыз турында сиздереп куйгансыз. «Мине салкынлыкта гаепли иде»,—дигәнсез. Ул сезне, күрәсең, бик яраткан. Сезнең яктан да шундый ук тойгы булуын теләгән. Моңа карап ләкин «мин ярату хисеннән мәхрүм микән әллә?» дигән нәтиҗә ясамагыз әле. Хотя үзегез беләсездер инде...

Минем тормышымда да булды төрле хәлләр. Ләкин берәүне дә гаепләмәдем. Уфада бик чибәр егет бар иде. Бөтен кызлар диярлек «ах!» итә, гашыйк була һәм аның белән танцыга чыгуны бәхеткә саныйлар иде. Ә мин ана фәкать тәрбия предметы дип кенә карадым, шуннан да артык түгел. Бар булган энергиясен, акылын, талантын танцыларда күнел ачуга әрәм-шәрәм итә. Без аның белән якыннанрак танышып, элемтәгә кердек, фикердәшкә әйләндек. Бер-беребезгә нык кына ияләшеп тә киттек (яхшы яклары күп иде аның). Берзаман анардан башка һич тә яши алмам төсле тоела башлады. Ул моны сизенде, әлбәттә. Хәзер ни кылансам да ярый, дигән уй исертте, ахры, үзен. Аның бер кыланышы мине сискәндереп, кинәт айнытып җибәрде. Шуннан соң инде ике арага нокта куйдым. Бик хәтерем калды үзенә, шундый аяныч, авыр кичереш булды бу. Тиздән ул практикага китеп барды, ә мин бер айдан өйгә кайтып киттем. Менә күптән түгел хат килде анардан. Гафу үтенә, дурак булганмын, вакытында бәя бирә белмәгәнмен дип, сабак бирүем өчен рәхмәт әйтә... Мин хәзер моңа, руслар әйткәнчә, «не было бы счастья, да помогла несчастье», дип кенә карыйм. Уйлансаң, бик катлаулы болар, шундыен катлаулы, хәтта бу турыда сүз катасы да килми башлый. Хисләрнең кайчакта йөгәннән ычкынып, акыл авазына колак салмавы тагын да ныграк катлауландыра. Менә шундый хәл булып алды минем тормышта.

Әдип, ә сезнең ул кыз белән ничек-ничек булды соң? Мөмкин булса, языгыз әле. Карагыз аны, режим турында онытмагыз!

Сау булыгыз, Әдип.

Сажидә.

25/III-51.»

Алда ике имтихан бирәсе бар дип йөргәндә, тагын өченчесе чыгып тора түгелме? Сизеп йөрим, төрлечә сынный бу кыз мине. Һаман күнелемә үтеп керә. Шунсына сөенәм: яшермичә, боргаланмыйча, күнелендәгеn яза. Мин дә төшеп калганнардан түгел дип, фараз кылдым үземчә. Үтенечене җавап итеп турыдан «ярдым».

... Татарстан радиосында балалар өчен тапшырулар редакторы вазыйфасын үтәгәндә, мәктәпләрдә еш булырга туры килә иде. Шулай бер татар урта мәктәбеннән матур гына чыгыш оештырдык. Укучылар соравы буенча, аны кабатлап та бирдек. Бу эштә директоры үзе башлап йөрде. Аның белән, әлбәттә, якыннан танышып алдык. Көнен билгеләп, өенә кунакка чакырды бу. Миннән өлкән яшьтәге ир кеше булгач, гаиләсе барлыгын да әйткәч, ихтирам йөзеннән, сөенә-сөенә киттем.

Кыскасы, ирле-хатынлы хуҗалар бар булганы белән кунак иттеләр. Музыка уйнатып та җибәрделәр. Хуҗабикә танцыга чакырды. Аннары затлы мебельләр, спай келәмнәр белән җиһазландырылган, берсеннән-берсе матур бүлмәләрен (ә алар өчәү иде) күрсәтеп йөрделәр. Эчемнән

генә «ник шуларның берәрсе минеке түгел икән», дип тә уйлап куйдым. Буласы булган икән дә. Ләкин...

Шулвакыт каяндыр кызлары кайтып керде. Чибәр, кыю күренә бу. Исәнләшеп, танышканнан соң, саф татарча сөйләшеп тә киттек. Мәктәптә өлкән пионер вожатые булып эшли икән. Укытучылар институтын тәмамлаган. Аннары бергәләп мине киногa чакырдылар. Тагын очраштык, тагын. Горький исемендәге культура-ял паркында икәүдән-икәү генә дә... Сизенеп йөрим, ниятләре—мине үзләренә ияләштерү, кулдан ычкындырмау. Нигә, бик изге теләк. Мин аларны һич кенә дә гаепләргә җыенмыйм. Кемгә зыян моңардан? Минем шикелле, торыр урыны булмаган берәү очраса, шул рәхәт дөньяга кереп кенә чумар иде. Юк шул, күңелем тартмады гына түгел—баш күтәрде кинәт. Ирегемне җуюдан, кешеләр күзенә карап торучы мескен дәрәҗәсенә төшүдән курку шиге чигенергә мәҗбүр итте мине. Хәләл тапкан өлешең булмаган урында синең ни дәрәҗәдә кадерең булыр икән, дип уйладым. Килеп кергәнче, чыгарыңны уйла, диләр бит. Энәдән-җептән башланган гаилә тормышы ныграк та, ышанычлырак та була, янәсе.

Сажидәгә язган җавап хатымда «шәхес ирегe» мәсьәләсендә куертыбрак җибәргәнмен, ахры, хәерлегә булсын.

Бу юлы Сажидәдән бер урынына ике хат алдым. Аллы-артлы язган булган.

«Саумысыз, Әдип!

Бүген миңа шундый күңелле, үземне кая куярга белмим. Беренчедән, балалар шау-гөр килеп утын кисеп киттеләр. Мин аларны чакырмаган идем бит. Киресенчә ярдәмнәреннән баш тартырга тырышып та карадым. Юк, кисәләр генә. «Һезгә авыр бит, апай»,—дигән булалар.Ансын каян беләләр инде, зарланганым да юк бит. Бигрәк тә шунсы мөһим: бер хулиган малай баш рольне уйнады бүген. Кулында бөтен нәрсә уйнап кына тора. Сокланырлык. Безнең бер укытучы кыз аның агасына кияүгә чыкты. Малайлар җингәсе бүләк иткән кулъяулыгын миңа күрсәтергә өнди башладылар. Ул күрсәтми дә күрсәтми. «Апай, безгә үзегез барыгыз әле, тәртипһез вакытымда барып, әсәемне ошакладыгыз да, хәзер бармайһыгыз. Ә әсәем һаман мине тиргәй»,—ди. Кулъяулыкны да шунда күрсәтергә вәгъдә итте. Башкалар киткәч, минем янда торып калды да, бик җитди нәрсә кебек сөйли башлады: «Нимә тиеп дәшәем икән, «апай» тиһәм дә ыңгайсыз, «енгә» тияргә лә оялам»,—ди. Мин аңа «енгә» дияргә киңәш бирдем.

Икенчедән, бүген партия укуы бик уңышлы үтте. Мин башлангыч класс укытучылары өчен оештырылган түгәрәк белән җитәкчелек итәм. Гадәттә алар имтиханга әзерлексез киләләр. Һәм минем нервада гына уйныйлар иде. Ә бүген ике «5», ике «4» куйдым. Ә үзем Ленинның «Две тактики социал-демократии в демократической революции» турында шундый яхшы сөйләдем, үземә дә ошады. Главное, бер мәртәбә дә конспектка карамыйча (ул юк та иде), кулларымны кесәгә тыгып йөргән килеш. (Менә мин нинди мактанчык!)

Менә шуннан кайттым да, сезгә хат яза башладым. Инде сәгать 12, ә минем дәресләр бөтенләй әзер түгелләр әле. Бүген, гаҗәпкә каршы, татарча үзеннән-үзе бик җиңел языла.

Беләсезме, сезнең 29 мартта язган хатыгызга нигәдер мин ачуланган идем. Әгәр дә сез минем күптәнге танышым булсагыз, кайбер җөмләләрегезгә каршы тупас кына җавап та язган булыр идем. Мәсәлән: «...Киңәшләрегез өчен рәхмәт», дигән җөмләгезгә: «рәхмәтегез үзегезгә калсын, мин рәхмәт өчен язмадым»,—дияр идем. «...Очрашсак, сөйләрсез»,—дигән җөмләгезгә: «Очрашсак, имеш, настроениягез бигрәк тиз үзгәрә икән тагын. Элекке хатта гына бит очрашасы килә, дип язган идегез. Очрашу теләге булгач, төрлечә боргаланунын ник кирәге бар»,—дияр идем.

Мондый шелтәләргә хокукым булмаганлыктан, просто, дәшми калырга һәм киләсе хатыгызны күтәргә булдым. Инде килгән хатыгызга карата узган заманны кулланам икән, димәк, үпкәм беткән дип уйлагыз.

Сез, әлбәттә, минем җүләрлегемнән көләрсез. Көлегез, әйдә, көл. Үземнән дә кычкырып көләсем килә. Ләкин төнлә ярамый гына.

Үзегезне ничек сизәсез? Москвадан кайда китәсез? Кайчан? Рәмзи ничек? Ана миннән сәлам әйтегез.

Минем тормышта артык үзгәрешләр юк. Язгы каникул көннәрен Зина Магнитогорскида үткәрде. Мина бер үземә бик күнелсез булды. Гаҗәп, бер ел үтеп бара, минем монда бер якын кешем дә юк икән.

Беләсезме, Әдип, минем сезгә рәхмәт әйтәсем килә. Ни өчен дип әйтим сон инде? Сезнең хатларыгыз мина таяныч булып тора. Морально. Алар мине олы дөнья белән бәйлиләр, ялгызлык тойгысыннан коткаралар. Үземне барлык кешеләр белән бергә итеп сизәм. Зур ихтыяр көченә ия булмагангадыр, мина һәрвакыт таяныч кирәк. Кайчагында хәтта тиргәсәләр дә ярый. Ләкин минем каршымда авторитетлары булган кешеләр генә. Беләсезме, минем өстән власть кирәк икән, ә анын күптән булганы юк. Берәүгә дә буйсынмыйм, берсен дә тынламыйм. Директор белән завучны да. Шул кирелегем аркасында үземә дә эләгә. Валлаһи менә, акылсыз кыз сыман. Әнкәйләр янына кайтсам да үземә урын табалмам төсле. Укыган чакта, шәһәр шау-шуыннан сон авылда ял итү әйбәт иде, әлбәттә. Ә хәзер бөтенләй башка. Бер-ике атна торсам туйдырыр инде...

...Бәйрәм кичәсендә минем бишенче класслар чыгыш ясады. Бер кечкенә пьесаны тәрҗемә иткән булдым да, балалар белән шуны әзерләдек. Белсәгез иде, нинди хәлләр булды аны әзерләгәнче. Балалар урман ясау өчен яшь каеннар кисеп алып кайтканнар. Лесник килеп, штраф салып китте. Балалар шундый яхшы уйнадылар, бөтенләй суфлерсыз-нисез. Шуннан кайттым да, сезгә язарга утырдым.

Әдип, сезне лекцияләргә йөри башлавыгыз белән котлыйм! Тик хәзер имтиханнарны унышлы тәмамлавыгызны теләргә кала. Алла ярдәм бирсен инде.

...Сезнең, «кешене урларга мөмкинмени!»—диюегезгә тулысынча кушылам. Мин дә һәрвакыт шулай уйлый идем. Әйе, мөмкин түгел.

Әдип, «Бер-беребезгә тәрәк булыйк»,—дигән карарга килергә иртәрәк түгелме әле? Сез бит мине бөтенләй белмисез. Ә күрешкәч, башка тәэсир калыр, капма-каршы фикер туар. Сез күзаллаганча килеп чыкмас. Бу мәгънәдә, сезнең «өметләр алдарга да мөмкин» дип, «скептиклык»ка урын калдыруыгыз белән килешәм мин.

Беләсезме, минем характерым, мөгаен, бик чатаклыдыр. Шулай булмаса, мондагы ир затлары белән бәхәскә кереп бетмәс идем. Азмыкүпме якыннан таныш булганнарын да өнәп бетермим. Бер военрук белән генә нормаль мөнәсәбәттәбез. Юк әле, нормаль түгел икән, ни кушсам, шуны үти ул, хәтта мәгънәсезгә әйләнә кайчакта. Һәм мин ана карата еш кына үземнең эгоистлыгымны күрсәтәм. Бу мисаллар минем асылымны ачарга ярдәм итәрләрдер бераз, мөгаен.

Менә шулай, Әдип, андый карарга килергә ашыкмыйк. Соныннан монын икебез өчен дә фаҗига белән бетүе мөмкин.

Ә Мәскәүдә очраша алсак, шулай да кызык булыр иде, әйе бит? Күз алдына китерегез: Башкалага бер авыл кызы килә, ди, биек башняларга, небоскребларга карап, адым саен сөрлегә, ә сез аны, адашып калмасын дип, кулыннан тотып йөртәсез. Анын театрга да, музейларга да керәсе, көне буе шәһәр карыйсы да килә. Менә озак йөрүдән аяклары тубырлый, яки туфли үкчәсе сынып чыга. Әле кунарга урнаштырырга да кирәк үзен.

Икенче күренеш: Сез анын белән театрга бардыгыз, ди. Анда москвичкалар, солидный дамалар озын бальный күлмәктән күз явын алып йөриләр, ә бу «кычыткан чыпчыгы»нын юбкасы тез башыннан гына. Һәм сезгә һәр адымда мәскәүлеләрнең шелтәле, мыскыллы карашлары белән очрашырга туры килә.

Ох, тиз туярсыз бу галәмәтләрдән, яки чакырганыгызга үкенерсез. Шундый хәлләр булу ихтималына карамастан, бик барасым килә Мәскәүгә. Бер карарга килгәч, хәбәр итәрмен.

Сау булыгыз, Әдип! Укуыгызда уңышлар телим. Институтка кайтуыгыз белән котлыйм. Авырмагыз инде. Тиздән очрашу өчен!

Сажидә.

30 апрель, 1951 ел.

«Исәнмесез, Әдип!

Сүземне шуннан башлыйм: имтиханнарым 21 июньдә тәмамлана. 22 июньнән 14 августка кадәр отпуск алам. Әгәр 23 ендә китсәм, 28 июньдә Мәскәүдә булачакмын. Аңарчы сез Мәскәүдә каласызмы? Әгәр көтсәгез, имтиханнар бетү белән, юлга чыгам. Алай туры килмәсә, Уфада тарихчылар өчен оештырылачак экскурсия группасына кушылырга исәп. Ачыклап язуыгызны сорыйм.

Кәефегез ничек? Нинди фәннәрдән имтихан тотасыз? Безнең нибары бер атна дәресебез калды, аннары имтиханнар. Эш кимеде. Бәлки, шуңадыр, кәефем бик әйбәт түгел—эч пошарга вакыт кала. Хәтта үзүземне куралмыйм. Бәйрәмне дә күңелсез уздырдым. Бүген Зина белән көн буе сөйләшмәдек. Бишенче класслар белән дә күңелсезлекләр килеп чыкты. Мин аларны яратмый башладым. Бик сизгерләр шайтаннар, миңа да шуның белән үк җавап бирәләр. Әллә шулай тоела гынамы? Әлерәк кенә мин аларга Е. Кошеваяның «Улым турында повесть»ен укыган идем. Олег белән Нина арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренә барып җиткәч, класс «түрә»ләре чыш-пыш килә, мәкерле елмая башладылар. Минем ачуым чыкты: Олег Кошевой хисләреннән көләргә ни хаклары бар аларның!



*Сажидә Сөләйманова Аскар мәктәбе укучылары белән. 21 июнь, 1951 ел.*

Кичә мәктәпкә беренче тапкыр эшләпә киеп бардым. Шул бишенчеләр, мине тәрәзәдән күреп, мәзәк эзләп каршыма йөгереп чыкканнар. Исәнләшергә дә онытканнар. Мин үземне кыргыйлар арасында йөргән Миклуха-Маклай ролендә сиздем. Гаҗәпләнерлек берни юк, монда күпләр кия торган гап-гади эшләпә югыйсә. Шундый күренешне күз алдына китереп карагыз әле, Әдип! Димәк, алар мине ихтирам итмиләр, санга сукмыйлар. Ничек җылытырга аларны? Балаларны гаепләргә җыенмыйм. Нидер күздән ычкынган. Димәк, үзем гаепле. Ярый әле, күпчелек минем якта. Шуларга таянырга кирәк. Ә класс старостасы, отряд советы председателенең кире йогынтылары аз түгел. Башта эшләр майлаган кебек барды бит.

Сизеп торам, өлкән класслар мине яраталар. Адым саен тоям моны. Их, бу бишенчеләр! Ни гаепләрем бар микән шул очлы күзләр каршында! Үзләре өчен җанымны бирергә әзермен бит. Танцыларга да йөрмим, озаттырып та куймыйм берсеннән дә. Төшенкелеккә бирелеп язсам, гафу итегез, Әдип. Китәсе иде күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга! Тизрәк сезнең белән күрешәсе иде. Чит-ят һәм беренче танышлар кебек кенә булмыйча, якын дусларча, туганнарча. Их, теге вакытта Куеда (Оркыяды) стансасы ник күрештермәде икән безне?! Бу юлы инде без

иң якын кешеләр булып очрашыр идек. Ә бит сезне ничегрәк күзалларга да белмим мин.

Әллә ниләр язып бетердем бугай. Әгәр туктамасам, белмим, тагын ниләр ишетерсез.

Шушы минутта ни теләгәнемне белсәгез иде: иң якын, көчле кешенең күкрәгенә башым куеп, елыйсы иде бер. Ә ул дәшми генә чәчләремнән сыйпасын иде.

Сау булыгыз!

Сажидә.

11 май, 1951 ел.»

«Мин авырганмын икән. Иртән башымны да күтәрә алмадым. Үз гомеремдә беренче мәртәбә авырып дәрес калдырдым. Салкын тидергәнмендер. 10 майда төнлә озак кына яңгыр астында йөргән идем. Юешләнеп беткәнмен. Хәзер үтте кебек.

11 майда язган хатым өчен бүген оялып утырам. Ертып ташларга да уйлаган идем. Әйдә, йомшак якларым фаш ителсен әле, дип, шул килеш калдырырга булдым. Юк, мин әле һаман авыру. Чөнки үземне бүген дә көчле итеп сизмим (һәм рухи, һәм физик яктан).

Җаным үз урынында түгел, нишләргә кирәктер, Ходай белсен.

13 май.»

* * *

...Тәнәфес вакытында Габдулла Әхмәтшин җиңемнән тотып:

—Дежурный посты янында сине энең көтә, хәрби киемнән,—дип хәбәр итте,—бар тизрәк!

Мин ашыгып, ишек катындагы тумбочка янына киттем. Ни күрим, энем Рәмзи басып тора. Елтыравыклы тешләрен балкытып, минем каршыма омтылды ул.

—Исәнме, абый!

—Саумы, энем!

Без ирләрчә, җитез хәрәкәт ясап, кочаклашып алдык.

Рәмзи театр училищесын тәмамлагач, бер ел Минзәлә театрында эшләп, шуннан армиягә китеп барган иде. Мәскәүдә очрашырга язган икән! Иңбашында сержант погоннары. Хәрби формасы, үлчәп текән кебек, ятышып тора үзенә. Җитмәсә, хром итектән...

Звонок чакырса да, мин лекциягә кермәдем. Без тышкы якка чыгып, сөйләшеп алдык.

Ул хезмәт иткән батальонны бик ашыгыч кына Мәскәүгә күчергәннәр икән. Казармалары үзәктә диярлек. Энем музыкантлар взводында хезмәт итә. Ни әйтсәң дә, артист та, иллюзионист та бит. «Трубач» дип, көлеп куйды Рәмзи,—автоматым да бар.

—Молодец!—диюдән башка ни дисең инде. Тагын очрашырга сүз куешып аерылыштык та.

* * *

«Әдип!

11 майда язган хатыгызны алдым. Мин аңлыйм сезне. Юкка гына үзегезне гаеплисез. Озак язмаган булсам, беренче чиратта, мин сездән гафу үтенергә тиеш идем. Ләкин хат яздым мин сезгә, 30 апрельдә. Белмим, нишләп барып җитмәгәндер.

Соңгы хатыгызда язганча, андый халәт миндә дә була. Сөясе, сөеләсе, тормышыңа хуҗа буласы килә. Бу үземнеке дип әйтерлек нием бар минем. Кышларын янган мич алдында, буш әрҗәгә утырып, бөкерәеп китап укыган чаклар була. Арка тала. Шуларны искә төшерәм дә, Зинага үземнең планнарымны сөйлим: «Бер урында оя корсам, йомшак кресло

сатып алыр идем, шунда чумып, мич каршында дәрес хәзерләр идем. Эреп йокыга талсам, ул мине күтәреп ала да урынга илтеп сала.» «Ай-һай, өметең зурдан,—дип көлә Зина,—кем соң бу «бәхетле» зат?»

Кем буласын бит үзем дә белмим. Бер карауга, бик кечкенә теләк. Кемгәдер көлке тоелырга да мөмкин. Бәхет дигәнең шул кечкенәдән башлана түгелме соң? Моңарчы булмаган чын дусны булдырасы килә. Ләкин шунсы бар, ирләр заты белән борчагым пешми минем. Бәхәсләшеп бетәм. Бу ниндәндер, үзем дә белмим. Мөгаен характерым үзгә (Сез язганча, «усаллык та, үзсүзлелек тә житәрлектер» миндә).

Әдип, хыялларым һәм өметләремнең юкка чыгуыннан куркам мин. (Бу турыда ник язам соң әле). Язгы жилкенүгә ышансаң, яз бит ул елның бер фасылы гына. Алай дисәң—яз миңа тәэсир итми. Белмим—бәхеткәме, үкенечкәмедер. Мәктәптә көз. Бай булмаса да уңыш жыябыз. Чәчкән кадәрлесен дә жыеп булмас, ахры.

Кырларга чыксам, табигатьнең гүзәллегенә сокланып туя алмыйм. Ә күңел төбендә билгесез нидер утыра. Шул ахыргача онытылырга, шатланырга ирек бирми.

Әдип, мин сезнең янга барырга карар иттем, көтәрсезме? Юк-бар турында уйламагыз, зинһар, барысы да нормально булыр. Имтиханнарга хәзерләнегез нygытып торып. Поезддан төшеп, яныгызга килүгә, милиционер сыман: «Гражданин, документыгызны рөхсәт итегез!»—дип, зачеткагызга күз салырмын.

Изге теләктә калам.

Сажидә. 17 май, 1951 ел»

Хаттан-хатка яшим, дигән идем. Әйе, мин аның тормышы белән яши башладым. Урал ягындагы Аскар авылы миңа бик якын булып тоела хәзер. Биек таулары, каен урманнары күз алдыма баса. Гүя без бергәләп, табигатьнең гүзәллегенә хәйран калып йөрибез. Мәктәп кичәләрендә катнашабыз. Мин аның дәресләренә кереп утырам шикелле. Хатларда бәхәсләшкән мәлләр дә булды, сүзгә килгән чаклар да.

Сажидәнең иң күңеленә тигәне, «жен ачуын чыгарганы»—көндәлекләр алып бару турындагы киңәшем. Мин бит үземчә, бик изге ният белән: «Педагогик поэма» булырдай көндәлекләр яза аласын, көченә дә, мөмкинлекләренә дә ышанам»,—дигән идем. Шул сүзләр кинәт өркетеп жибәргән аны. «Әдәби интерес»ка гына кайтарып калдырган ул минем үтенечемне. «Балалар язмышы сине кызыксындырмый»,—дип шелтәләгән. Тәнкыйтен кабул иттем. Чыннан да шулайрак килеп чыккан шул.

Үзе турында: «мин эгоист», «характерым ужасный»... диюләре ни өчендер кире тәэсир калдырмады миндә. Чын булса, алай димәс иде, мөгаен. Ә «үзсүзлелеген» күңелемнән хупладым. Димәк, буш кеше түгел. Алга куйган максаты, кыйбласы бар. Күралмыйм умыртка сөяге булмаган ялагай, аумакай кешеләрне. Андыйлардан бөтен әшәкелекне, явызлыкны көтәргә мөмкин.

Хатларында ул турысын, дөресен ярып әйтә. Моның өчен батырлык кирәк. Ә инде беркемгә дә буйсынырга яратмавына килгәндә... бер хатымда мин шаяртып кына: «Борчылма, Сажидә, тормыш йөгәнли ул. Син дә йөгәнсез калмассың»,—дип язган идем. Монысына дәшмәде.

Аскардан килгән хатлар... Тылсымлы хатлар. Рәхмәт аларга!

Бу икесе—соңгылары.

«Саумысыз, Әдип!

Сезнең 17 майда язган хатыгызны алдым. Көндәлек турындагы үтенечегезгә «жиңел» каравым өчен, әлбәттә гафу үтенәм. Ләкин алдагы хатымда мин моның сәбәбен аңлаткан идем инде.

Ә «мәктәп һәм балалар тормышы сезне кызыксындырмый»,—дип, мин һавадан алып кына язмадым. Тормышка чыккан Фәнисә исемле укучы кыз бала турында язган идем, Марс турында язган идем, пионер отряды советы председателе турында язган идем булса кирәк. Әгәр «әдәби

интерес»ларыгызны балалар язмышыннан өстен куймасагыз, мин телгә алган укучылар турында сез бер тапкыр булса да кызыксынып сорап язар идегез. Ә бит эш судка барып житте һәм мина, шаһит сыйфатында, чыгыш ясарга туры килде. Беләсез, минем тормышым балаларга багышланган. Ә сезне бу кызыксындырмый. Бу мине рәнжетә, алар турында шуна башка язмадым да.

Шәхси тормыш көндәлегенә килгәндә, әгәр берәү белән бүлешкән ин саф хисләрен, хыялларын, мәхәббәтен соныннан башкаларга фаш ителсә, бу бик аяныч, күнелсез һәм ямьсез килеп чыгар иде. Сез әйткән көндәлек белән дә шулай булырга мөмкин бит. Бу хакта мин элегрәк тә язарга уйлаган идем, ләкин тупаслык булыр дип, сабыр иттем. Менә хәзер язам. Гомумән, мин тактлылык белән аерылып тормыйм.

Менә сез: «Вакытлы төшенкелек. Соныннан барсы да үз урынына утырыр»,—дип язасыз. Әгәр тиз генә утырып житмәсә? Китапларда гына ул бик тиз үз урынына утыра. Югары советта укытучы булып сайланганнарнын бәлки шулай килеп чыгадыр. Ә мин менә шуна ирешә алмадым әле. Ох, бу әдәби интерес дигән нәрсә! Ник бу сүзне кулландыгыз икән? Мина киләчәктә дә һәммәсе шул «әдәби интерес» өчен генә эшләнә кебек тоелачак.

Башка маршрутлар мине кызыксындырмый. Мәскәүгә барырга булдым. Ләкин мин монын белән сезне иректән мәхрүм итмәячәкмен, әйбәт ял итәргә дә комачауламам, дип уйлыйм.

Сез әйткәнчә, мин үзем дә ирекле кош булуны яратам, һәм ирек дигән нәрсә бар кешегә дә кадерле. Шуна күрә мин бервакытта да башкаларнын бәйсезлегенә комачауларга тырышмадым. Үз ирекләреннән баш тартучыларны ихтирам да итмим.

Бөтен ирләрне дә күралмыйм, дип язмадым ич. Мондагы танышларым турында гына сүз барды. Аларнын үз сәбәпләре бар. Эгоистлыгым турында нәтижә ясарга да ашыккансыз. Шулай да миндә ул бөтенләй юк дип тә әйтә алмыйм.

Ин түземсез кеше булсагыз да, бер минутка гына түгел, хәтта бер көнгә дә түзә алырсыз дип исәплим. Ярый әле бу турыда алдан язгансыз. Әгәр беренче минутта ук миннән качып китсәгез, мина әйтеп бетергесез күнелсез булыр иде. Сез мине каршы алып, урнаштырганчы һәм кайбер күрсәтмәләр биргәнче, бер көнгә «чын мин» булмаска тантаналы төстә вәгъдә бирәм. (Монын нинди газаплы көн булачагын күз алдыма да китерә алмыйм!)

Ә «ужасный характерым» белән ирегегезгә кул сузмас өчен, Мәскәү буйлап бер ялгызым сәяхәт итәчәкмен.

Сау булыгыз.

Сажидә.

23 май.

Минем фәннән әле имтихан булмады. Гомумән, нәтижәләр сөенечле түгел. Тарихтан 26 майда—7 класс, 28 ендә 9 класс имтихан тота. Алар өчен бик дулкынланам. Әгәр имтиханнарга кертелгәннәр арасында бер генә «икеле» чыкса да, акылдан язармын төсле. Һич кемә дә теләмим андый хәлнен булуын. Һәр бала өчен калтырап торам.»

«Әдип!

Моннан элекке хатым өчен, зинһар, ачуланма. Мин аны үзегезнен тондарак язганмын (Бәйрәм ашы—кара-каршы, диләр бит).

Сонгы көннәрдә күбрәк сезнен турыда уйлыйм. Тиздән күрешүебезгә хәтта ышанмыйм да. Ә кинәт очраша алмасак? Килүемә, сез китеп барган булсагыз? Нишләрмен? Шул турыда уйлап кайгырам хәзер. Уйларымда сезгә бик күнеккәнмен, ахры. Хыялымнан сезне чыгарып ташласам, тормыш мәгънәсезгә әйләнер төсле. Белмим, белмим—ни белән бетәр монын ахыры. Ә сез... «Бер минутка да чыдый алмам»,—дип, алдан ук кисәтеп куясыз. Әле күрешмәс, яхшылап танышмас борын. Сез

дә сабыр холыклылардан түгел, ахры. Ни әйтмәс кеше үзе турында.

Мин инде сездән дүрт көн буе хат көтәм, юк та юк. Түзмәдем, тагын язарга булдым. Үзегездән килмичә, җибәрмәм дип торам әле. Йә хатлар белән күмелеп калырсыз. (И, карам начар да инде!)

Әдип, әгәр көтелмәгән сәбәпләр аркасында тоткарлана калсам, мине көтәрсезме, ә? Димәк, туган якка бергә кайту фикереннән кире кайттыгыз, әйеме? Бөтенләй очраша алмау ихтималы да бар булып чыгамы? (Бала-чага сыман, бәйләнепме-бәйләнәм).

Әдип, ә минем хатым өчен хәтерегез калдымы? Ә сездән алгач, минем дә җен ачуым чыккан иде. Сүрелмәс борын, тиз-тиз генә язарга тотындым. Ә соңыннан күнелем сызлап йөрде, хәтта язганыма да үкендем. Берәр көнгә булса да сабыр итәсе калган да бит. Үземне күптән күнектерергә тырышсам да, җитми генә сабырлык.

Бүген 7 «Б» тарихтан имтихан бирде. Биш «бишле», ике «дүртле», җиде «өчле». Ә калган ике укучы имтиханга кертелмәгән иде. Кергәннәре барысы да бирсәләр дә, класстан начар кәеф белән чыктым. Ел буе «4»кә, «5»кә укыган ике кызым чүт кенә батмый калдылар. Мин аларны шпаргалка белән тоттым. Башка билет алдылар. Кәефләре кырылды. Күралмыйм ялган юлга баручыларны! Бөтен программа буенча «кудым» үзләрен. Көч-хәлгә «өчле»гә элгәштеләр. Иртәгә 9 класс тапшыра. Алар өчен бигрәк тә нык дулкынланам. Райкомнан керәчәкләр. (Район житәкчеләренең барысы да диярлек тарихчы). Нәтиҗәсен язармын. Азаматов дигән бик сөйкемле малай бар анда. Бик сәләтле дә. Ләкин соңгы вакытта борынын күтәрде, дәрескә хәзерләнми килә, хәтеренә ышана. Бигрәк тә аның өчен борчылам. Элек гел «5»кә укый иде.

Беләсезме, минем класстагы Мирзагильдина рус теленнән диктантны гел «ике»гә яза иде, соңгы вакытта прогресс сизелә. Педсоветта мин аны имтиханга кертергә кирәк дип, яклап чыктым. Язмадан «4»ле алды! Шунсы кызык, имтиханнар алдыннан укучыларыма уңыш теләп, стена газетасына мәкалә язган идем. Аңа «4»ле теләдем. Һәм шулай килеп чыкты да. Беркемнән дә күчермәде. Коридорга чыккач, шатлыгымнан үбеп алдым үзен. Ә икенче бер кыз, йөгереп килеп, мине үзе кочаклап алды. Ул «5»кә язган! Шул рус теле аркасында классында ике ел утырган иде. Күзләре яшь кенә. Хәзер минем класста бер ударница була.

Әдип, Мәскәүгә килгәч, барсын да төкми-чәчми сөйләрмен, яме. Тик шундый шарт белән: кызыксынуыгыз «әдәби интерес» өчен генә булмасын. Мине әгәр бирелеп тынлаучы булса, берөзлексез сөйләр идем укучыларым турында. Ә язу ягына килгәндә—булдыралмам. Язганда барысын да иңләп булмый.

28/V-51.

Әдип, хәтерегездәме, «Истребитель» фильмендә Сережа профессорга сорау бирә: «Ә телеграммада «сөеклем» дип язарга ярыймы?»—ди. Моны искә төшерүемнең сәбәбе—сезгә ни өчендер шулай дип сүз кушарга теләгәннән булса кирәк. Белмим, шулай ярый микән, юк микән? (Ох, бу язу карасыннан һич унмыйм).

Бишенчеләрем рус теленнән сынатмадылар. Бөтәһе—9 «бишле». Әле башкортча язма һәм телдән имтихан тотасылары бар. Иң курыкканнары шулар...


Имтиханнар ничек бара, Әдип? Үзегезгә көч килерлек булмасын инде, тагын переутомление башланыр.

Әдип, тизрәк очрашасы килә. Нигә шулай икән? Үзем дә аптырыйм. Иң матур теләкләрдә калам.

Сажидә.

29/V-51.»

*Ахыры бар*



## Рөстәм Кутуй

### Китү

*Хәсән Туфан истәлегенә*

**1**

**Туң алмагач. Кара кәүсәсендә**
**сөялләр һәм яра эзләре.**
**Сәер бушлык.**
**Ни эзлим мин монда**
**симез үләннәргә тезләнеп?**

**Бер куышта күке кунып киткән,**
**чытырманда былбыл сайраган,**
**Һәм саескан бытылдаган нидер...**
**Күк күкрәвен йоткан саралан.**

**Тик мин генә хәрәкәтсез ятам.**
**Гөлчәчәкләр килеп сарыла,**
**үләндәге кулларымны үбә.**

**Мин эндәшәм сөйгән ярыма:**
**Төшеңә ни керде?**
**Әйтче, бәгърем,**
**үткән көзнең пәрәвеземе?..**

Рөстәм КУТУЙ *(1936)—шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче. «Яктылык яңгырлары», «Тамырлар», «Күктән болытлар чаба», «Кичке моң» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Рус телендә иҗат итә. Казанда яши.*

«Чәчәк тажы очты,
чәчәк тажы очты өзелеп...»

2

Шагыйрь йорты ятим калды,
ятим калды гөлләре.
Сукырайды өстә кояш,
тынсыз булды җилләре.

Сыкранып ишек ябылды,
сыерчык оялары
аһлады. Урманда ерткыч
тавышын җыялмады.

Сеңдереп көннең нәкышен,
чак сулап оча тожым,—
моңсу төш сыман озын ул,
һич тә табалмыйм очын.

Түбәдә кошлар күренми,
читтә яуды яңгыр да...
Сулкылдады тамырлар.

Ул сагыш йотып яшәде,
шагыйрьләрнең асылы,—
тавышы үләннән дә тын,
карашы—шәмнән җылы:
анда янган, диләр, бик күп
югалтуларның чеме.

Кемнең җитәр түземе?

Тынып калган дөнья. Юк бит
чиртүче сыңар кылга.
Гаепләләр дә юк бугай
бу аяусыз чоңгылда.

3

«Ул сөйләште минем белән...»—ди миләүшә.
«Ул тын торды монда...»—урман ямансулый.
«Мин карашын саклыйм...»—диеп нарат дәшә.
«Таягының эзе...»—сыкрый урман юлы.

«Ул яратты мине...»—диеп, моңсу ландыш
ап-ак энҗеләрен тагын селкеп ала.
Һәм челтери чишмә: «Ул суымны эчте...»,
«Гүләвемне бирдем»,—имән тынып кала.

Пәрәвезләр оча: «Мин төшенә кердем...»
«Юлын яктырттым»,—дип каен күккә аша.
«Күләгәмне аңа мин бирмәкче идем»,—
Караңгылык дәшә хатирәләр аша.

Күкрәп куя күк тә: «Тыңлый иде мине...»,
Яңгыр тамчылары: «Дым өстәдек»,—диләр.
«Санап бетермәдем...»—дип үкенә күке.
«Шигырьләрен аның актардык»,—ди җилләр.

4

Китте шулай җайлы гына,
үләннәргә бераз тиеп.
Наратлар каплады аны,
ылысларын түбән иеп.

Якты гөлләр арасында
чүкте күк хәтта өстәле.
Без шушында аның белән
күпме көннәрне эстәдек.

Булмаган мөсәхабәнең
сүзләре чыкса да истән,—
күбәләктәй куна алар,
яңгырдай коела өстән.

Җилкапкасын бөтенләйгә
ябып китеп баргач мена,
үтәли исәләр җилләр,
гөлләр сагышка төренә.

Үз-үзем белән сөйләшәм,
һәм кул болгыйм
эзләренә.
Күләгәсе шуып үтә,
чык тамчысы—күзләрендә.

5

Туфан бакчасында бүген
әрсез чүп үлән...
Сәхтиян күк кәүсәләргә
чыклар түгелгән.

Китап төсле ач бакчаны,
гөл белән таныш.
Тыйнак карашы биредә—
төкәнмәс сагыш.

Вакыт үтә, үтмәгәе—
җитә калганы:
бу төмсә тәрәзә түгел,
күзләр кәрваны

күкләргә таба сузыла,
аһәңен юллый.
Аны шул базар ягына
өстерәп булмый.

Вакыт үтә, кая таба—
беләсем дә юк,
гөлләр үсә, су челтери,
тормыш шундый ук—
өскә таба гына үрли
нарасый кебек.
Шуңа да кеше үлемсез,
шуңа мәңгелек.

Җисем түгел, төпсез караш
нурлы агымда,
канат җилпеп оча аваз
офык ягына.

Тыгыз алманы кулына
ул алган иде,
гомер бөҗрасына еллар
җыела килде.

Көзнең җимешләре үксез,
җый да авыз ит,—
Вакыттан дәвалар сине—
табигать шул бит.

Сәхтиян тышлы китапны
килә ачасы,—
йорты ябык, әмма яши
Туфан бакчасы.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА *тәрҗемәсе*

## Кымыз

Зәп-зәңгәр сулышлы Ютазыда кымыз
Озын мичкәләрдә ята ап-ак сулап...
Шәрык акылыдай, чүпрәләнеп ята—
Кирмәнгә куйганнар
Стаканнар җылап.

Чүпрәдәй күпергән үләннәр эчендә
Арт санын уйнатып бияләр селкенә.
Аллалар уйлап та тапмаган бу бәхет
Үзенчә селкенә һаман үз иркенә.

Үрләрен бак әле,
Үрләрен кара син!
Төннәрен калкалар атларның сыртыдай.
Зәп-зәңгәр шәрабның зәп-зәңгәр эченнән
Калыкты да чыкты көтмәгәндә ак ай.

Яраттым, диңгезгә сикергән шикелле
Коега сикереп югалган шул айны.
Һәм ике сукмакны... Яшь яңгыр астында
Чайкалып китте дә ике пар котайды...
Ә Әхмәт, үз итеп, миңа дип чәй куя,
Үз ара эндәшеп, сүз ара чәй коя;
—Ярыңны яр итсәң, өйдә син назлама,
Учакка алып чык, төтенгә.—
Тәгәрәп ай ятсын тезеңдә.
Онытсын, оныт, әй, үзең дә.
Китмәслек булсын ул беркемгә!
Әхмәт акыллы ул. Әхмәт карт шулай:
Аның фикерләре акча янчыгыдай!
Һәм ул чынлап килде. Әгәр бирсә әмер,
Кул кисергә түгел, баш кисәргә әзер.
Кайнар кояш тулды
Ут яндырып тынга...
Шул кояшны уып әйләндердем комга.
Ул китеп тә барды...
Ат чабышы тәмам,
Тояк тавышлары, әйтерсең лә, дәвам.
Аңлагызчы хәлне,
Торам үлле-мәлле,
Югыйсә бит җирдә берни үзгәрмәгән!
Аһ, кымыз! Гөбердәп, кайнап күтәрелә.
Сәрхүш җаны аның тапмый, гүя, урын:
Әйтерсең лә күктә козгын бәргәләнә.
Ярсып чаба сыман болын буйлап колын.
Упкын бугазында мине салды суеп.
Тәгәрәдем... Инде юл чыгудан азат.
Иҗат итәм. Татлы булсын
Мин кичергән газап!

Ни дисәң дә Әхмәт, кымыз дисең Хуҗа,
Сөю һәм сөелү аның белән бергә.
Шуңа күрә бугай алып килде миңа
Үз атымның атын,
Салды аны учактагы көлгә.
—Эчәсеңме, әйдә!
Язасыңмы, яз син—тик акылдан язма!
Син кымызны су дип уйлый күрмә берүк,
Эчәсеңме, әйдә!
Тик акылдан язма!
Мин кымызны эчтем акылдан шашканчы,
Зеңләп торды канда, кире кайтты акыл.
Ак тешле акылны ак каен дип белдем.
Ходай дәште миңа: кайрысын да чакыр:
Ютазының күге үзе бөкре сыман.
Болытлары аның—янып торган кымыз.
Пеләш Әхмәт тора кояш кебек балкып.
Көндез дә, төнлә дә баш өстендә йолдыз!

Мин бирегә тагын киләчәкмен әле,
Ютазы вә кымыз ычкындырмас мине,
Белә-белә аңа керәчәкмен әле.

* * *

Корткалар җырлыйлар. Җырлыйлар корткалар.
Яулыклары да бер, үзләре дә бер...
Чип-чиста куллары күкрәкләрендә.
Корткалар җырлыйлар. Сугыш барган дәвер.

Кошлар да тын калган. Корткалар янына
Кешеләр тезелгән түгәрәк җыр булып.
Агыла моң тетрәнеп. Корткалар җырлыйлар.
Гармунга түгел, ә җанга җан кушылып.

Тау бите әргәләп каеннар йөгерә.
Бакчага төтендәй сиреньнәр тезелгән.
Корткалар җырлыйлар—сулышта иркенлек.
Карашларына тик күз яше түгелгән.

Ярым сулыш алып, ярым ыңгырашып
Тынып калган бу җыр дәвам итә әле...
Хөкем ителгәндәй басып тора иде
Хаксыз рәнҗетелгән авыл киленнәре.

Гүргәчә онытмам мин бу күргәнемне:
Корткалар сөялгән йортның нигезенә,
Салам кебек дөрләп көн уртасы яна.
Кырда юл читләп баганалар тезелгән.

Шул юлдан авылга хат ташучы атлый.
Иңендә букчасы хәбәр бирә тосле—
Як-якка «аһ!» итеп өметсез чайкала.
Җыр булып җырның да канатлары төште.

... Төннәрен төшемдә һаман да бер аваз,
Һаман да бер аваз,
Кайдан соң бу оран?
Йолдызлар бәрелеп корткалар җырына
Чәлпәрәмә килде какъ пыяла сыман.

Ишетәм... ишетәм... корткалар җырлый.
Чигешле күлмәкләр төштә дә яна...
Телсезләр сөйлиләр нәрсә турында?—
Баш очымда әнә куллар тармаклана.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ *тәрҗемәләре*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

**Зәки Зәйнуллин**

## ИВАН ДӘДӘЙ

хикәя

–Без сине башкача өстери алмыйбыз инде. Гафу ит, брат. Менә шушы конюшняда калдырабыз...

Сакал-мыек баскан өч солдат ике аягының да тездән түбән сөякләре чарпаланган яралыны ат абзарындагы печән тутыра торган яслегә салдылар да, аңа туры карамаска тырышып, чыгу ягына юнәлделәр.

—Туктагыз әле!—дип ыңгырашты яралы.—Бу хәлдә фашистларга калдырып киткәнче, атып китегез, яисә штык белән чәнчегез. Барыбер үлемгә ташлыйсыз бит...

Чыгып баручылар җавап бирмәде. Тик берсе, ишек төбенә җиткәч, мылтыгын диварга сөяде дә, шундагы ямь-яшел печәнне кочаклап күтәреп яралының өстенә китереп япты, печәнне азрак тигезләгәндәй итте.

—Гафу ит безне...

Мылтыгын алды да йөгерә-атлый иптәшләре артыннан ашыкты...

Авыл читенә кадәр дәшмичә бардылар. Кечкенә, инде туңа башлаган елга аркылы салынган ярым җимерек күперне чыккан чакта, шинель чабулары пулялардан тишкәләнеп беткән карт солдат көрсенде:

—Ташлап китеп ялгыштык. Гөнаһысы... Хет бер патрон булса, атып китәр идем—җәфаланмас иде. Ә штык белән кадарга йөрәк җитми...

Аңа җавап бирүче булмады. Һәркайсысы үз уйларына чумып дәшмичә генә атлый бирделәр.

Ташлап калдырылган солдат ат абзары эчендә аңын бер югалтып, бер ушына килеп ятты да ятты. Ашарына да, эчәренә дә бер нәрсәсе юк иде. «Нужа печән ашата!»—дип дөрес әйткәннәр бабайлар. Кипкән иреннәре белән ялмап алып печән чәйнәштерде. Аяклары, утлы табада кыздыргандай, йөрәккә төшеп сызлыйлар. Шуның өстенә ашказаны сыкрап-сыкрап эчәргә сорый. Ачлыкка, сусаганга түзәргә дә булыр иде. Тик менә ике аякның авыртуына түзүләр бик тә авыр шул. Баш бер туктаусыз чыңлый, кыза. Әллә кемнәр әллә кайлардан чакырган кебек авазлар бирәләр. Ахрысы теге дөньяга чакыралар...

Печән катламы аша сыек кына яктылык төшкәндәй булды. Ике тәүлек ятамдыр ахрысы, дип уйлап куйды ул. Бик күп еллар элек—коммунистлар партиясенә кергәндә онытылган Алласы исенә төште. Чын күнелдән «Отче наш» догасын берничә мәртәбә укып, Ходаеннан тизрәк үлем жибәрүен үтенде. Чукынырга теләде—кулларын күтәрә алмады. Шул ике тәүлек узган чакта әллә нинди саташулар эченә чумып анын югалтты...

Ят телдә сөйләшүләрне ишетеп тагын анына килгәндәй булды, чит сүзләр ишеткәч, йөрәге кысылып куйды: «Фашистлар!» Тагын анын югалтты...

Онытылып күпме яткандыр—азактан да чамалый алмады. Авызына аккан жылымса сыекчаны комсызланып йота-йота күзләрен азрак ачкандай итте. Кемдер ана кофе эчертә иде. Сыек кына томан пәрдәсе аша үзенә иелгән берәүне чамалады, тик анын йөзен аермады.

—Гут, камрад![1]—диде иелгән кеше, тавышында кызгану сизелә иде.—Гут! Тринкен зие битте![2]

Кофе эчергәч, теге кеше анын өстендәге печәнне читкәрәк алып ташлады. Аякларын тоткалап карады. Солдат авыртуга чыдый алмыйча ынгырашып жибәрде.

—Зеер шлехт![3]—диде дә немец чыгып китте.

Озак тормыйча әйләнеп тә керде. Теткәләнгән обмоткаларны, ботинка кисәкләрен, чалбар-ыштан балакларын пычак белән кискәләп, яралы аякларны ачты. Аларны жылы су белән сакланып кына юа башлады. Яралы солдат каты итеп ынгырашты.

—Найн, найн!—дип пышылдады немец.—Кришайт найн! Рус!

Шул көннән башлап немец солдаты яралы кызылармисне ашатты, эчерде, көн саен яраларын юды, йода белән эшкәртте, бинтлар белән урады. Тик яралынын хәле көннән-көн начарланды. Күзләре, эчкә батып, тона барды. Иреннәре ярылып, бите күгәрә башлады. Азрак кофе генә эчкәләде. Немец биргән ипи, колбаса—берсе дә тамактан үтмәде. Ике аяк гөбе кебек шештеләр. Алардан чыдамаслык булып сасы ис анкый иде инде.

—Зеер шлехт, геноссе![4] Плехо ошшень твой ног! Гангрен!—дип анлатты немец яралы солдатнын хәлен.

Кызылармис бик озак уйланып ятты. Янында гына агач түмәрендә немец солдаты утыра. Анын югалтып-югалтып алган кызылармискә ул бер бар була, бер югала. Күзен бер ачканда, кызылармис немец кулында зур хәнжәр күрде. Немец аны үткерли иде.

—Резайт нага!—диде немец, хәнжәр белән кискен хәрәкәт ясап күрсәтте.—Умирайт найн! Резайт! Нага гангрен!

Кыек астына уелып ясалган тишектән төшкән яктылыкка өстәп, ике шәм яндырып куеп, шулар яктысында немец ике аякны да тездән кисте. Операция башланыр алдыннан яралыга ике шешә шнапс эчереп, аны исертте. Солдат исереп хырылдабрак йоклап киткәч, авызын зур сөлге белән бәйләп куйды. Кычкырса, тавышы чыкмасын! Үткен хәнжәр белән теткәләнгән аякларынын сенерләрен кисеп, ике аякны да тездән аерып алды. Агарып торган тез капкачын аякнын түбән өлешеннән калган тире белән төргәндәй итеп урап, нечкә генә сүс бау белән бәйләде. Салынып торган артык тирене кисеп ташлады. Үзе ясаган операциягә үзе сокланып телен шартлатты:

—Гут, Густав! Зеер гут![5]

Ике тездән түбән киселгән сөякне-итләрне бер чүпрәккә төрде, абзар артындагы тирескә алып чыгып күмде. Немец кире кергәндә, яралы ынгырашуыннан туктап, тирән һәм исерек йокыга талган иде. Немец ана карап елмайды да анын өстенә күп итеп печән салды:

---

[1]Гут, камрад—Яхшы, иптәш
[2]Тринкен зие битте—Зинһар, эчегез
[3]Зеер шлехт—Бик начар
[4]Зеер шлехт, геноссе—Бик начар, иптәш
[5]Зеер гут—Бик яхшы

—Гут, камрад! Гут! Шлафен зие![1] Гут!

Икенче көнне өйлә житеп килгән чакта аяксыз калган кызылармис күзләрен ачты. Аның каршында чандыр гәүдәле, кырык яшьләр чамасындагы, соры шинель, башына кырларын аска төшереп пилотка кигән немец солдаты басып тора иде. Немецнең йөзе шатлыктан нурланып балкый. Яралының күзләрен ачканын күргәч, авызы ерылып китте:

—Гутен таг[2], геноссе! Их бин Густав Раухе![3] Гутен таг!

—Гутен таг!—диде яралы, тавышы бик тә хәлсез иде.—Мин Иван булам...

—Йа, йа! Ив-ва-ан! Корошо! Гут! Ив-ван!

Иван күзләре белән аяклары ягына күрсәтте.

Немец аның нәрсә турында сораганын аңлады:

—Нага нит! Их нага резайт. Нага аб!

Абзар идәнендә яткан рюкзактан фляжка чыгарды:

—Эссен! Спиртус! Шлафен зие! Спайт, спайт!

Иван фляжкадан спиртны ике мәртәбә уртлады да йокыга китте...

Шул көннән соң Иванның ярасы төзәлүгә барды. Немец алып кергән эссе кәбестә шулпасын да, боткасын да ашады. Ипи белән колбасаны да читкә куймады. Немец солдатларын әйбәт ашаталар иде...

Караңгы абзар ятлесендә ике аягы да киселгән урыс солдаты Иван немец солдаты Густав Раухе карамагында егерме өч көн яшәде. Немец аның ярасын көн саен чишеп спирт сөртеп тазартты, йод белән буяды, яхшылап бәйләде. Яхшы караганнан, яхшы ашаганнан Иван савыга барды, тазара төште...

Тышта каты ыңгырашып декабрь бураны котырган бер көннең иртәсендә поход өчен ныклап киенгән Густав абзарга автоматын асып килеп керде. Бу инде аның хушлашырга керүе иде. Чөнки немец армиясе Мәскәү яныннан чигенә башлаган көннәр иде. Немец моңсу гына елмайды:

—Гитлер капут, Иван! Дейчланд золдат нах Берлин маршиерт![4]

Хушлашырга кулын бирде Иванга:

—Ти Иван, корошо спи! Шлафен зие! Йа, йа! Бай-бай! Аллес гут! Руссиш солдатен коммен![5] Руссиш солдатен айн-цвай, нах Берлин маршиерен! Йа!—Урысчалап өстәде:—Прощай, Иван!

Яралының баш очына фляжка белән спирт тыкты. Шунда ук бер кирпеч ипи белән бер таяк колбаса да өстәде. Ике кулбашыннан тотып кочаклады, битен биткә терәп хушлашты. Өстенә күп итеп печән өйгәч, тиз-тиз атлап чыгып китте...

Икенче көнне авылга кызылармисләр килеп керделәр...

* * *

Укучым!

Мин бу хәлләрне Иван дәдәйнең үз авызыннан ишеттем. Ике аягы да протезлы Иван дәдәй минем туган авылымда «ат духтыры» булып эшли иде. Минем әти белән бик дуслар иде. Әтигә Иван дәдәй шушы тарихны сөйләгәндә, мин дә исем китеп тыңлап утырган идем...

---

[1]Шлафен зие—Йоклагыз
[2]Гутен таг—Хәерле көн
[3]Их бин Густав Раухе—Мин—Густав Раухе
[4]Дейчланд золдат нах Берлин маршиерт—Немец солдаты Берлинга маршировать итә
[5]Руссиш солдатен коммен—Рус солдатлары килә

## Şigriət
## Шигърият



### Әнәс Исхаков

## САГЫНУ КӨЕН ҖЫРЛЫЙ КҮҢЕЛ

### Миңнурый чишмәсе

*Каршыдагы чишмәбезнең*
*Исемнәре Миңнурый.*
*Чишмә суыдай саф хисем*
*Җырымда урын сорый.*

Халык җыры.

**Исемең калган, инәй, чишмәләрдә,**
**Игелегең безнең йөрәктә.**
**Кайткан саен еллар кайтавазы**
**Дулкын булып кага күкрәккә.**
**Зиярәт кылып китәр өчен генә**
**Без кайтмыйбыз, инәй, янына:**
**Җылы кулың, якты карашларың**
**Гел яңарып китә аңымда.**
**Телем, денем, инәй, синнән күчкән,**
**Әти биргән исем каралмас.**
**Самум җиле исеп актарса да**
**Сездән күчкән хисләр таралмас...**
**Нигезебез каршысында чишмә**
**Исемеңне җырлый балкытып,**
**Уч тутырып эчсәм салкын суын,**
**Бөтен җаным китә яктырып:**
**Безнең күңелләрдә яшәр шулай**

---

Әнәс ИСХАКОВ *(1945) —шагыйрь, «Бу дөнья нигә уйчан?» дигән шигырь китабы авторы. Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы. Азнакайда яши.*

Гомер тынмый торган моң булып,
Биш баласы кебек биш улакка
Көмеш суы агар җыр булып.
Фатихасын биреп озатыр да,
Көтеп алыр безне «Миңнурый»...
Чишмә тамчысында, инәй, синең
Чагыла төсле якты күз нурың.

## Тынлыкта уйланулар

* * *

Хакыйкатьне каплап кара җаннар
Канат җәйгән шушы заманда,
Ак канатлы ак күлмәген җилпеп,
Чәчәк җыя кызчык аланда...

* * *

Төпсез упкынга убыла,
Убыла яшел ярлар.
Бездән соң ничек яшәрләр
Гомерлек газиз ярлар?

* * *

Күңелдә хис, күңелдә шик
Ялкын кебек талпына:
Газиз халкым диючеләр
Газиз микән халкына?

* * *

Текә ярларын Иделнең
Дулкыннар астан ашый.
Нинди көчләр көтә икән
Ашарга... безнең башны?

## Бер сүз әйттең...

Арыган ла җаным,
Авырган ла тәнем,
Кемгә сөйлим икән бу хәлем?
Сихерләгән кебек бер сүз әйттең,
Оҗмахка тиң иде бу мәлем.
Җыр сәйләне тезеп булыр иде
Йөрәгеңнән чыккан сүзләрдән.
Сак була күр инде,
Сакла, зинһар,
Үз-үзеңне—дошман күзләрдән.
Дәваладың тик бер сүзең белән,
Инде башка болай арымам:
Холкым шулдыр,
Матур сүзләр ишетеп,
Кайгы, авырулардан арынам...

## Парлап атлыйк

*Әкълимәгә*

Пар имәннәр, пар каеннар була,
Аккошлар да парлы, казлар да.
Парлы икән ләса фасыллар да:
Җәй пар икән якты язларга...

Парлы булып, җитәкләшеп кенә
Үтик әле гасыр капкасын.
Парлы җаныбызны аерыр өчен
Явыз җилләр ишек какмасын.

## Берәүгә

Авыз ачып сүз әйткәндә
Болыт булып караласың.
Талпынасың өскә менеп
Агу булып яварга син.
Теш артында телең ярсый
Әйтер өчен яман сүзең.
Елан булып чагар өчен
Күптән инде әзер үзең.

Ялгышыңмы, язмышыңмы,
Зәһәрлектән аңың түнгән...
(Яманлыкка нәрсә түзгән?)
Тотам диеп хыялландың
Заманның алтын тоткасын.
Ачма авызың,
Упкын булып
Изге гамәлне йотмасын!

## Уйларым дулкын кебек

Җилләр исми көн бозылмый—
Үзгәрми тора һава.
Зилзиләдәй кубармын күк
Сезнең якларга таба.
Хатлар язмыйм, сөйләмим сүз,
Уйларым дулкын кебек.
Сагыну көен җырлый күңел
Сагышларыма төреп.

## Яңа дуска

*Иске дошман яңа дус булмас.*

Халык әйтеме.

«Елан ята, дигәч, куенында»...
Кабул иттем ялган сүз итеп.
Якын күреп, нәкъ күңелем белән
Йөргән идем сине үз итеп.
Кыен чакларымда серем ачтым,
Гел-гел сиңа барды юлларым.
Үз-үземә аптырыйм, күрмәгәнмен
Яшеренеп ятуын еланның...
Юк, рәнҗемим инде, үпкәләмим,
Пакьлек өчен җаным яралган.
Ә шулай да мин өйрәндем бугай
Аерырга чынны ялганнан...

# Publisistika
# Публицистика



## Индус Таһиров

# ҖИҢҮ ҖИҢЕЛ ЯУЛАНМЫЙ

ТАТАРСТАННЫҢ БӘЙСЕЗЛЕГЕ ӨЧЕН КӨРӘШ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

### СССР юллар чатында

СҮЗ БАШЫН, минемчә, Татарстан суверенлыгының дәүләт декларациясен кабул итүдән башлап китү кирәктер, чөнки кем генә ни генә сөйләмәсен, Татарстанның бүгенге сәяси халәте шул документтан үсеп чыкты.

СССР исән-имин булган дәвердә, татар халкының төп максаты—үз республикасын союздаш итү иде. Әлбәттә инде Союз үзе дә иске рәвештә яшәрлек түгел, ул искергән, тузган һәм инде чыннан да яшәү мөмкинлекләре тәмам беткән. СССРны исән калдыру максаты илдә өстенлек итә иде. Шулай итеп, аны чын мәгънәсендәге федератив дәүләт итү хаҗәте барлыкка килде. Союздаш республикалар, бигрәк тә Россия, аның илбашы Борис Ельцин, бу эшкә ныклап тотындылар. Борис Николаевичның гайрәтле чагы. Аның СССР президенты Михаил Сергеевич Горбачев белән бәрелешүләрен бөтен ил күзәтеп торды. СССРга нибары бер-ике вәкаләт калдырырга, калганнарның барысы да союздаш республикаларга күчәргә тиеш, ди иде Ельцин. Күпчелек союздаш республикаларның җитәкчеләре дә аның ягына авышты.

Гомумән, ул вакытта хакимият башында утырган М. С. Горбачев өчен тарихи мөмкинлек туды. СССР юллар чатында торганлыктан, аның исән калу һәм шулай ук бөтенләе белән юкка чыгу ихтималлыклары бергә буталды. Аның кайсысы тормышка ашасы әлегә билгесез булганлыктан, ул субъектив факторга бәйләнгән иде. КПСС Политбюросы, СССРны саклап калу ниятеннән чыгып, илдә референдум үткәрде һәм

Индус ТАҺИРОВ *(1936)—тарихчы, академик, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе. Казанда яши.*

халыкның күпчелеге аның исән калуын яклап тавыш бирде. Аны чын мәгънәсендә диктатурадан азат итеп, ихтыяри нигездә корылган демократик дәүләт итү мөмкинлеге барлыкка килде. Тик менә Горбачев моңа һич кенә дә әзер түгел булып чыкты. Аны Вильнюска Литва Компартиясенең съездына чакыралар. Әлбәттә, ул анда нәрсә тикшерелергә тиешлеген яхшы белеп бара. Литва Компартиясе КПССтан бәйсез партия булу максатын куя. Гомумән, Литвада 1990—1991 елларда илнең бәйсезлеген кайтару хәрәкәте искиткеч зур колач ала. СССР Халык депутатлары съездының Литвадан сайланган депутатлары искиткеч активлык күрсәтә. Республика галимнәре җиң сызганып бәйсезлек идеясен яклау эшенә керешәләр. Шушы хәрәкәтне Мәскәү мәгълүмат чаралары «профессорлар заговоры» дип атады. Ә бит Литва Компартиясенең җитәкчелеге үз таләбен яки үзенең КПССтан бәйсез булуын компромисс рәвешендә генә алга куйган иде. Бу гамәл Литваны СССР составында калдыру мөмкинлегенең иң соңгысы иде. Ләкин Горбачев моны аңламады. Ул Литва коммунистларын бу ниятләреннән баш тартырга өндәде. Ә аңа болай диделәр:

«Михаил Сергеевич, СССР гимнының: «Союз нерушимый республик свободных навеки сплотила великая Русь»,—дигән юлларындагы һәр сүзне шәрехләгез әле. Бу сезгә әйгә бирелгән эш булыр.»

Шушы «әй эше» белән Горбачев Мәскәүгә кайтып китте. Әлбәттә инде, ул гимнның әлеге сүзләренә берниндди дә аңлатма бирә алмады. Литва коммунистлары моңа мохтаҗ да түгел, алар бер генә империянең дә мәңгелек булмавын һәм халыкларның мәңгелек коллыкта калырга тиеш түгел икәнлеген яхшы беләләр иде. Алар бу хакыйкатьне Горбачев та аңласын һәм СССРны демократик рәвештә үзгәртеп коруның тиешле чараларын күрсен иде, дигән теләктән чыгып кына эш иттеләр. Алай гына да түгел, бу—СССРны теге яки бу рәвештә саклап калырга тырышу иде. Ә бит Литва халкының инде тулы бәйсезлекне торгызу юлына басканлыгын бик тиз үсә барган вакыйгалар тезмәсе раслый торды. Моны 1991 ел гыйнварының беренче яртысында булган вакыйгалар мисалында күреп була. Ул дәһшәтле көннәрдә дистәләгән мең литвалылар танклар белән урамга чыгарылган гаскәргә каршы тигез булмаган көрәшкә чыктылар. Көрәш бәйсезлек символы булган Литва телевидениесен кулга төшерү өчен барды. Кан коелды, үлүчеләр дә шактый булды.

Әйе, республикалар, халыклар ирекке сусаган, алар искечә яшәргә теләми иделәр инде. 1990 елның 12 июнендә РСФСР Советларының съезды Россиянең суверенлык декларациясен кабул итә. Әгәр дә инде СССР составында Россиядә дә ирек җитмәгән икән, ул да азатлыкка сусаган икән, башкалар турында әйтеп торасы да юк. Әйе, алар өчен дә бердәнбер мөмкинлек булып тик суверенлык декларациясе кабул итү генә калган иде. Һәм бу шулай булды да. Республикалар бер-бер артлы үз декларацияләрен кабул итә башлады. Бу процессны «суверенитетлар парады» дип атадылар.

Ә менә автономияле республикаларның хәле мөшкелләнде. Аларга хокук бирергә кирәклеге турында бер генә союздаш республиканың җитәкчесе бер генә сүз әйтсә икән! Киресенчә, аларны элеккеге хокукларында калдырырга кирәк, дигән фикер шактый күп союздаш республикаларның җитәкчеләре тарафыннан әйтелде. Татарлар өчен иң аянычлысы шунда иде, төрки республикаларның лидерлары да шул ук фикердә булдылар. Тугыз союздаш республика лидерлары һәм СССР президенты М. С. Горбачевның уртак белдерүендә бу позиция ачык чагылыш тапты. Бу документны «9+1» дип атадылар. Горбачевның бу документка кушылуының сәбәбе аның шул вакытта Ельцин белән чәкәләшеп торуыннан килә иде. Ул союздаш республикаларның җитәкчеләрен шушы көрәштә үзенә теләктәш итәргә тырышты. Ә аңарга, киресенчә, автономияле республикаларга таянырга кирәк иде. Шулай иткәндә ул Ельцинның мөмкинлекләрен йомшата ала иде. Шунысы кызык, мондый тәкъдимнәр аңа ясалды да. Ни эшләтәсең бит, күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе—ботак тишеге. Ә союздаш республикаларның әлеге тугызы

да бер кайда да китми иделәр. СССРны да бит алардан башка, сорап та тормастан таркаттылар.

Ә татарлар исә Урта Азия республикаларының үсешенә гаять зур өлеш керттеләр һәм инде, һичшиксез, алардан тиешле рәхмәт хисләре күтәргә хаклылар иде. Ләкин рәхмәт урынына тукмак алдылар. Менә шушы ризасызлык тойгылары бер төркем татар зыялыларының газетларда басылып чыккан мөрәҗәгатьләрендә дә чагылыш тапты. Аларның текст авторы мин идем. Документ русча язылган, шунлыктан Горбачевның автономияле республикаларга карата хыянәтенә бәя бирелгән урынын оригиналдагыча кабатлыйсым килә: «Ельцин пошел только на некоторое продление пребывания у власти Горбачева и что, укрепив свой тыл, он пойдет тараном на Союзные власти и, прежде всего, на Президента и Генсека КПСС... Нет, не будет мира под оливами. М. С. Горбачеву еще придется пожалеть, что он предал автономные республики». Һәм бу шулай булды да. Ул ГКЧП вакыйгалары вакытында хурлыклы рәвештә Фороста качып ятты һәм ярык тагарак янында ялгыз калды. Ярый, Горбачев бер читтә торсын, ул безгә, урыс әйтмешли, «не брат, не сват». Татар зыялыларының төп үпкәләре тугандаш халыкларның җитәкчеләренә юнәлтелгән иде. Акрынлап, бигрәк тә СССР таркалгач, бу җитәкчеләр позицияләрен үзгәрттеләр. Моны мин Кыргызстан президенты Аскар Акаев мисалында күрсәтер идем. Без Беренче Бөтендөнья татар конгрессын үткәргәннән соң, башка төрки халыклар да шундый чаралар үткәрә башладылар. Кыргызлар да читтә калмады: гомумкыргыз корылтае үткәрделәр. Анда, БТК рәисе буларак, мин дә чакырылган идем. Акаевка Татар конгрессы символикасы төшерелгән сәгатьне тапшырганда, су үткәрми һәм утта да янмый торган сәгать икәнлеген, татар-кыргыз дуслыгы да шулай ук утта янмас, суда батмас икәнлеген әйттем. Сүземне: «Аскар Акаевич, бу сәгатьне такканда аны дуслык вакытына куегыз»,—дип тәмамладым. Ә инде кунакларны кабул итү мәҗлесендәге чыгышында ул мондый сүзләр әйтте: «Без бәйсезлек юлына бастык. Без ялгыз түгел, безнең белән бергә шушы юлдан Үзбәкстан, Казакъстан, Төрекмәнстан, Таҗикстан, Азәрбайҗан, Татарстан һәм Башкортстан атлый»,—диде. Ә Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаев Минтимер Шәймиев белән булган бер әңгәмәсендә: «Минтимер, ашыкма, вакыты җиткәч, мин сине яклап чыгармын»,—дигән. Һәм ул үз сүзендә торды да. Шәймиев Татарстан президенты булып сайлангач, аның инаугурациясендә катнашты. Казакъстанда Татар Конгрессының ике күчмә утырышын үткәрүдә дә аның турыдан-туры катнашы булды. Гомумән, Казакъстанда татарларга ихтирамлы уңай караш яши. Ә менә 1990—1991 елларда Татарстан, төрки республикаларның ярдәменә мохтаҗ булса да, шактый ялгыз иде. Хәер, үткән эшкә салават, иртәгә дөнья бетмәс, әле алда да кыласы гамәлләр күп. Бердәм булу беркайчан да зарарга түгел.

## Ялгыз батырлык

МИН ТАТАРСТАННЫҢ шушы авыр чордагы гамәлләрен ялгыз батырлык дип атар идем. Аны союздаш республикалар да, автономияләләре дә ачыктан-ачык яклап чыга алмады. Татарстан җитәкчеләренә җиңел булмады. Шуңа да карамастан, алар үз сүзләрен әйтә алдылар. Аларның тырышлыгы аркасында, автономияле республикалар да яңа союз договорын эшләү процессына кушылдылар. Ә инде 1991 елның 12 июнендә РСФСР үзенең дәүләт суверенлыгы турындагы декларациясен кабул иткәч, Татарстан автономияле республикаларның үз хокукларын суверен биеклеккә күтәрү эшен җитәкләде. Әйе, союздаш республикага әверелүнең элеккеге мөмкинлеге, бу эшне өстән төшкән декретка таянып хәл итү мөмкинлеге беткән иде инде. Моны тик Россия мисалына ияреп кенә гамәлләштереп була иде.

Ул вакытта бит әле КПСС исән, ә Минтимер Шәймиев—КПССның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре да. Идеология эшләре

буенча секретарь Рево Рамазанович Идиәтуллин. Ул намуслы һәм халкына җаны-тәне белән бирелгән кеше. Көннәрнең берендә ул мине үз кабинетына чакырды һәм: «Татарстан өчен дә суверенлык декларациясе кирәк»,—диде.

Мин үземнең университеттагы кечкенә кабинетыма Татарстан Югары Суды рәисенең беренче урынбасары Минзәфәр Мәүләтшинны һәм филология факультеты деканы Җәмил Сафиуллинны чакырдым. Алар минем дуслар, эшнең нидән гыйбарәт икәнлеген бик тиз аңладылар. Һәм без декларациянең беренче вариантын эшлидек тә.

Әллә ни күп вакыт үтмәде. Минтимер Шәймиев Кремльдә иҗтимагый оешмаларның вәкилләрен җыеп, декларация кабул итү мәсьәләсен куйды. Берничә проект тәкъдим ителде. Берсе Татарстан халык депутаты, университетның физфак доценты А. В. Штанинныкы иде. Тагын кемнәрнеңдер вариантлары да бар иде. Штанин варианты буенча суверенитет Россия составында, ә безнең вариант кем составында икәнлекне күрсәтмәстән игълан ителергә тиеш иде. Тиздән Югары Советның Президиумы декларацияне рәсми рәвештә язып, аны Югары Совет сессиясенә өзерләү өчен эшче төркем төзеде. Аның составына мин дә кертелгән идем. Газеталар декларация проектын бастырып чыгардылар. Тик шунысы кызык, бу проектта Татарстан Россия составында итеп күрсәтелгән иде. Күрәсең, Югары Совет Президиумы шуның белән ниндидер компромис булдырырга теләгәндер. Бәлки бу үзенә күрә бер маневр булгандыр, анысын әйтә алмыйм. Бу 1990 елның август урталары иде.

Билгеле булганча, Югары Совет сессиясе, шушы проектны бер атна буе тикшереп, ниһаять, 30 август көнне кабул итте. Сессия эшләгән вакытта төрле вариантларны тикшерү өчен килештерү комиссиясе төзелде. Аның рәисе Минтимер Шәймиев үзе иде. Хәтерлим, комиссиянең беренче утырышында ук без бернинди бәхәссез республиканың исеменнән «советская социалистическая» дигән сүзләрне алып аттык. Күпмедер вакыттан соң Минтимер Шәрипович керә һәм өстәлендәге инде өлгереп бетеп килә торган декларация вариантына күз төшерә дә аптырап кала: «Советская социалистическая» сүзләрен кая куйдыгыз?»—ди. Башта ул: «Әйтегез әле, социализмнан да яхшырак нәрсәне кешелек дөньясы булдыра алганмы?»—дип безгә мөрәҗәгать итте. Әлбәттә, ул беркемнән дә нинди дә булса җавап көтмәгәндер. Социализм идеясенең йөзтүбән китүе күпләр өчен сер түгел. Эш бөтенләй башкада: декларациянең кабул ителүе генә түгел, аңа Мәскәүнең дә күнүе кирәк иде. Ә бит әле Мәскәүдә социалистик көчләр хөкем иткән чор. «Сез декларацияне кабул итәрсез дә өйләрегезгә таралырсыз, ә миңа иртәгә Мәскәүгә барырга кирәк. Ярар, вакыты җиткәч, без ул сүзләрне алып ташларбыз, республикабыз бер генә исемле булып калыр»,—диде Шәймиев.

Ике телне, татар һәм рус телләрен дәүләт телләре итеп игълан итү буенча зур бәхәсләр булып, ниһаять, Татарстанны Россия субъекты итеп күрсәтмәү бәрабәренә, шушы ике телне дә дәүләт телләре итеп күрсәткән декларация проекты күпчелек тавыш белән кабул ителде. Юстиция министрлыгында эшләүче, шулай ук килештерү комиссиясе әгъзасы Гаял Мортазинның: «Эх, телебезне саттык бит, егетләр»,—дип уфтануларын һич кенә дә онытасым юк.

Шушы көннәрнең Минтимер Шәймиев өчен никадәр авыр булганлыгын ул тик үзе генә беләдер. Ул, Мәскәүнең төрле кабинетларында декларациядән баш тарттыру таләпләрен ишетеп, аптырап беткәндер, дип уйларга кирәк. Ул беренчеләрдән булып: «Сез Россиядән чыгасызмыни?»—дигән сорауны ишеткән һәм аңа лаеклы җавап эзли башлаган шәхес. Чөнки бер генә автономияле республика да Татарстанныкына охшаш Декларация кабул итмәде. Аларның барысы да үзләрен Россия субъекты итеп таныдылар. Ә бит Татарстан артыннан бару аларның абруен гына арттырачак иде. Татарстан исә теләктәшлек күрсәтүчеләрсез калды. Шулай бервакыт, КПССның реском бюросы утырышына сигезенче катка икәү лифтта менгәндә Минтимер Шәрипович Шәймиев автономияле республикаларның, бигрәк тә Башкортстанның безнекенә охшаш декларация кабул итмәүләренә уфтанды.

—Союзникларсыз калдык бит.

—Алар моның белән берни дә югалтмадылар.

—Ничек югалтмасыннар, ди?

—Шулай, алар заманында үзләренең Россиягә ирекле рәвештә керүләрен танып, шуның 400 еллык юбилейларын үткәреп, орден-медальләр һәм төрле рәвештәге ташламалар алды.

—Ә без?

—Ә без яуланган халык. Шунлыктан 1552 елдан соңгы 438 ел эчендә бер генә татарның да Россиягә ирекле рәвештә керү турындагы документка кул куйганы юк.

—Беркайчан дамы, хәтта совет чорында дамы?

—Әйе. Беркайчан да. Әгәр дә без үзебезне Россия составында икәнлегебезне күрсәткән Декларация кабул иткән булсак, бу беренче шундый документ булачак иде. Сез, Минтимер Шәрипович, бәхетле кеше. Сезнең имзагыз тарихыбызга лаеклы документка куелды.

Шәймиев, хисләрен тирән яшерә белә торган кеше булса да, бу әңгәмә аны, минемчә, нык дулкынландырды. Ул көннәрне Татарстанны төрле рәвештә хурлаулар, куркытулар аз булмады.

Өстәвенә Казанның үзендәге безелдәвекләр республика газеталарына бертуктаусыз суверенитетка каршы материаллар ташып тордылар. Суверенитетны төрле рәвештә яклап килгән Рафаэль Хәкимовка каршы мәкаләләр дә басылды. Февраль аенда «Советская Татария» газетасында аның «Азбука равноправия» исемле мәкаләсе чыккан иде. Шуңа ябырылып, шушы ук газетада 170 кеше исеменнән, нигездә, Авиация институты фәнни коммунизм кафедрасы мөдире Владимир Беляев язган тагын бер материал чыкты. Дәлилләре йомшак, фактлары сыек булса да, кешене бимазалау өчен җитә калган. Мин болай да газеталарда күп басыла идем. Ләкин шушы материал уңаеннан шул ук «Советская Татария»дә «На путях сохранения Союза. О дискуссиии на страницах «СТ» и не только о ней» исемле мәкаләмне язып чыгармый булдыра алмадым. Шуннан соң бервакыт В. Н. Лихачев телефоннан шалтыратып мине үзе янына чакырды. Килеп керүгә үк ул: «Индус Ризакович, яхшы мәкалә язгансыз. Президент Мәскәүдән кәефсез кайтты. Әмма, Сезнең мәкаләне укыгач, җанланып китте, шатланды. Әйдә аңа керәбез»,—дип, мине Минтимер Шәриповичның кабинетына алып керде. Президент чыннан да минем мәкаләмне укыган һәм аннан Мәскәү белән сөйләшүләр алыр бару өчен ныклы дәлилләр алганлыгын әйтте. Шактый озак сөйләштек. Мин Минтимер Шәриповичның фәнгә таянып эш итәчәгенә инанып чыгып киттем.

Менә шушы Декларация Татарстанның Союз договорына, Россия делегациясенә кермәстән, мөстәкыйль рәвештә кул куярга мөмкинлек алуына сәбәп булды. Һәм шушы хакта махсус рәсми белдерү дә ясалды. Мәскәү шактый вакыт тавыш бирми торды. Күрәсең, анда Татарстанның позициясенә нык борчылганнардыр. Ниһаять, 1991 елның август башында Татарстан белән аңлашырга кирәклеге бәхәссез мәҗбүриятькә әверелгән иде инде. Чөнки Союз договорына кул куярга санаулы көннәр генә калып бара.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер. Бу көннәрдә, Татарстанның статусын билгеләү өчен референдум үткәрергә кирәк, дигән фикер киң таралды. Кайберәүләр, республикада татарларның 48,6 процент кына булганлыгыннан чыгып, референдумда Татарстанның суверен статусына тискәре җавап булачагына ышанып эш иттеләр. Менә бер документ китерәм:

## «ДОЛЖЕН ЛИ ТАТАРСТАН ОСТАВАТЬСЯ В СОСТАВЕ РСФСР?»

*Предложения группы представителей научной интеллигенции*

«Вечерняя Казань» 3 июня 1991 г.

Подписание Союзного договора задерживается в связи с особой

позицией, занятой представителем Татарстана, и неготовностью всех остальных республик согласиться с этой позицией.

Какие тенденции по отношению к РСФСР преобладают в Татарстане—центробежные или центростремительные—на этот вопрос наиболее основательный и демократичный ответ может и должен дать только корректно проведенный референдум граждан Татарстана. Вопрос, выносимый на референдум, не должен быть тенденциозно сформулирован, следует избегать также психологической неравновестности ответов «да» и «нет».

Наиболее беспристрастная форма бюллетеня, на наш взгляд, могла быть такой:

Я желаю, чтобы Татарстан вышел из состава РСФСР остался в составе РСФСР

*(Зачеркните ненужный прямоугольник)*

Каждый из нас может иметь свои взгляды по этому вопросу. Нас всех объединяет готовность признать приоритет взглядов большинства граждан Татарстана перед нашим личным мнением. У того, кто не боится, что голос большинства граждан разойдется с его мнением, нет серьезных оснований возражать против нашего предложения. Если же кто-либо ценит свое мнение выше суждения большинства граждан республики, то можно ожидать, что он будет изыскивать поводы для отклонения идеи такого референдума.

Пусть сверенная с голосом большинства граждан подпись представителя суверенного Татарстана в составе РСФСР или вне ее появится под Союзным договором после итогов референдума.

А если все остальные республики не захотят ждать исхода затягивающегося референдума в Татарстане, они могут подписать Союзный договор пока без подписи Татарстана.

Профессора и доктора наук КГУ, КХТИ, КГМИ, физико-технического института АН СССР, биологического института, института им. Н. Чеботарева: А. Александров, А. Александровский, В. Архиреев, Н. Ахметов, В. Барабанов, М. Ганеева, В. Голенищев-Кутузов, Л. Гордон, Н. Гудин, П. Гуревич, Ю. Жигалко, Л. Зиннер, В. Иванов, Н. Ильинский, Р. Кайдриков, О. Кисилев, А. Косарев, А. Костерин, В. Лозовая, О. Маминов, Ю. Молокович, В. Москва, Г. Мухаметзянов, А. Мутрисков, И. Поникаров, Г. Поспелов, Ю. Пустовойт, Р. Сабурова, Р. Сайфуллин, Н. Светлаков, В. Скворцов, Э. Скворцов, И. Фаляхов, Х. Харлампиди, Р. Цейтлин, В. Цивунин, А. Чекалин, Л. Чибрикова, В. Чиков, Е. Шешуков, К. Шангареев, И. Гарифуллин, Н. Мифтахова, Д. Осокин, Т. Толпегина, Е. Штырков»



*Индус Таһиров—Федераль үзәк белән сөйләшү-килешү процессларында актив катнашучыларның берсе*

## Россия белән сөйләшүләрне башлыйбыз

ДИМӘК, җәмгыятьтә Татарстанның суверенлыгына бер төрле генә караш хөкем сөрмәгән булып чыга. Алай гына да түгел, яңа Союз договорына кул куелмый торуны Татарстанның махсус позициясе аркасында дип күрсәтергә тырышу сәясәте туды. Татарстан һәм Россия җитәкчеләре бу мәсьәләгә ачыклык кертергә тиеш булып чыкты.

1991 елның 20 февралендә М. Ш. Шәймиев РСФСР Югары Советы рәисенә түбәндәге мөрәҗәгатьне җибәргән.

«Товарищу Ельцину Б. Н.

Уважаемый Борис Николаевич!

Народные депутаты Татарской ССР единодушно отметили, что предложенный проект Договора противоречит декларации о государственном суверенитете Татарской ССР. Верховный Совет республики Татарстан в принятом постановлении (прилагается) поручил полномочной делегации республики подготовить проект Договора Татарской ССР с РСФСР, решил осуществить его заключение после подписания республикой Татарстан Союзного Договора».

Шул ук вакытта РСФСР Югары Советы Президиумына түбәндәге телеграмма юлланды:

«В связи с рассмотрением на третьем внеочередном Съезде народных депутатов РСФСР вопроса о порядке подписания Союзного Договора Президиум Верховного Совета Татарской ССР доводит до сведения Съезда народных депутатов РСФСР, что III сессия Верховного Совета Республики Татарстан, исходя из Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР, Закона СССР от 26 апреля «О разграничении полномочий между Союзом ССР и субъектами Федерации», приняла решение о непосредственном и самостоятельном подписании Договора о Союзе суверенных республик и о последующем заключении Договора с РСФСР.

Президиум Верховного Совета Татарской ССР просит считать эту телеграмму официальным документом и огласить ее на Съезде.

Руководствуясь правом законодательной инициативы, которая принадлежит Республикам в соответствии со статьей 110 Конституции РСФСР, и принципами проекта Союзного Договора, Республика Татарстан предлагает в Постановлении Съезда о порядке подписания Союзного Договора закрепить возможность его непосредственного подписания Татарской ССР, а также предусмотреть за республиками РСФСР право выбора конкретной формы участия в Союзном Договоре».

### ОФИЦИАЛЬНОЕ ПИСЬМО

Президента Республики Татарстан М. Шаймиева Президенту Российской Федерации Б. Ельцину

Уважаемый Борис Николаевич!

Согласно договоренности с Вами направляю состав официальной делегации Татарской ССР для решения вопроса о порядке подписания Союзного Договора делегацией Татарской ССР и подготовки двустороннего Договора Республики Татарстан и РСФСР.

1. Руководитель:

Лихачев В. Н.—Вице-Президент Татарской ССР, доктор юридических наук, профессор.

2. Газизуллин Ф. Р.—зам. Премьер-министра Татарской ССР, кандидат экономических наук.

3. Железнов Б. Л.—доктор юридических наук, профессор, член Комитета конституционного надзора Татарской ССР.

4. Хафизов Р. Ш.—председатель постоянной Комиссии Верховного Совета Татарской ССР, кандидат юридических наук.

5. Тагиров И. Р.—доктор исторических наук, профессор, декан исторического факультета Казанского госуниверситета.

Одновременно прошу после определения Вами соответствующей группы для этих целей назначить время начала их работы.

Президент Татарской ССР М. Шаймиев.

*30 июля 1991 г.*

Август башларында тагын Кремльгә Президент кабинетына чакырдылар. Анда миннән башка вице-президент Василий Николаевич Лихачев, университет профессоры Борис Леонидович Железнов, Югары Советның комиссия рәисе Рөстәм Шамил улы Хафизов, вице-премьер Фәрит Рәфыйкъ улы Газизуллин бар иде. Президент безгә Ельцин тарафыннан Татарстанның Союз договорына ни рәвештә кул кую мәсьәләсен аныклау өчен сөйләшүләр үткәрү тәкъдиме булганлыгын әйтте. Ике як та делегацияләр төзергә тиешлеген белдерде. Алай гына да түгел, делегацияләрдә бишәр кеше булырга тиешлеген әйтте. Чакырылган кешеләрнең барысы да делегациягә кертелгән икәнлекләрен белдерде. «Делегациянең җитәкчесе Василий Николаевич Лихачев,—диде.—Аның урынбасары итеп мин профессор Таһировны билгелим»,—дип өстәде.

Минем өчен бу көтелмәгән хәбәр иде. Нәрсә әйтергә дә белмәстән, аптырап калдым. Чөнки безнең арада вице-премьер да, Югары Советның комиссия рәисе дә бар. Хәтерлим, Фәрит Газизуллин үзенең кимсенүен яшерә алмады. «Ничек була инде ул, мин вице-премьер гади делегация әгъзасы рәвешендә»,—дип уфтанды ул. Мин бу хакта Президентка әйттем. Тик Президент сүзне кыска тотты: «Нәрсә эшләгәнемне үзем беләм»,—диде. Мин Президенттан делегация составына үз киңәшчесе Рафаэль Сибгат улы Хәкимовны һәм Югары Советның комиссия рәисе Фәндәс Сафиуллиннарны кертүен сорадым. Ул моңа каршылыксыз риза булды. Бу шулай ук дөрес адым иде.

Ничек булса, шулай булсын дип, мин дә яңа ролемә керә башладым. Фәрит Газизуллин исә сөйләшүләр вакытында зур активлык күрсәтте, һәрвакыт курыкмастан бәхәскә дә керде, эшлекле тәкъдимнәр кертте. Без аның белән тиз дуслаштык.Миңа ул үзенең эчкерсезлеге белән ошый иде.

Мин бу көннәрнең көндәлеген алып бармадым. Ләкин шулай да кайбер язуларым сакланган. Аларның берсендә русча язган мондый сүзләр бар. «Лихачев информировал нас о своей беседе с Бурбулисом... У него хорошее впечатление. Думаю, что это эйфория ложная». Чыннан да, сөйләшүләр җиңел булмады.

Ниһаять, 12 август көнне иртән сәгать унда без Мәскәүдә—Ак йортта идек. Без Россия делегациясе белән танышабыз. Аның җитәкчесе—РСФСРның дәүләт секретаре Геннадий Эдуардович Бурбулис. Алда әле бу кеше турында сүз күп булыр. Ләкин баштан ук аның Ельцин тарафыннан үзенә беренче ярдәмче итеп якташы булганы өчен генә түгел, аек акыллы кеше булганы өчен алынган икәнлеген аңлаганлыгыбызны ассызыклап үтәсем килә. Делегация составында аннан башка Россия Президентының киңәшчеләре Сергей Михайлович Шахрай, Сергей Борисович Станкевич, Тышкы эшләр министры урынбасары Шелов-Коведяев, ул вакытта Россия Юстиция министры, бүген Чуашстан президенты Николай Федоров, соңрак Куркынычсызлык Советы секретаре булган Олег Лобов һәм Россия Югары Советында Татарстан депутаты булган Юрий Михайлович Воронинннар бар иде. Воронин сөйләшүләргә бер генә мәртәбә дә килмәде, күрәсең, үз республикасына каршы оппонент буласы килмәгәндер. Федоров безнең белән көрәшүгә үк, эчтән безнең яклы булганлыгын, ләкин ачыктан-ачык безне яклый алмаячагын әйтте. Тәнәфес вакытында ул үзенең Чуашстан Президенты булырга теләгәнлеген дә әйткән иде.

Станкевич соңарып килде һәм инде күп нәрсәләрдән артка калган иде. Ул үз иптәшләренә: «Егетләр, сезгә нәрсә булды, без фикердәшләр түгелмени?»,—дигән ачынулы сүзләр дә ташлады. Күрәсең, бу егетләр баштан ук Татарстан делегациясе белән каты сөйләшергә сүз куешкан булсалар кирәк. Ә ул килгәнче егетләр шактый ук көндәмлек юлына баскан иделәр инде. Чыннан да, Станкевич, хатыны татар булуына да

карамастан, Татарстанга карата шактый каты булды. Гомумән, бу кешедә һәрвакытниндидер катып калганлык сизелеп торды, безгә әллә нинди провокацион сораулар яудырды.

Шулай итеп, делегацияләр озын өстәлнең ике ягына утырыштылар. Сөйләшүләрне котлау сүзләре белән Бурбулис башлап җибәрде. Җавап сүзе белән Лихачев чыкты. Бу кеше турында бер-ике фикер белдерәсем килә. Ул, һичшиксез, үзенең дипломатик сәләтләрен ныклап эшкә җикте. Ә инде башка вакытта зур тапкырлык һәм эрудициясен күрсәтә килде. Ул бу көннәрне Татарстанга турылыклы хезмәт күрсәтә алды.

Без Татарстанның суверенлык декларациясе кабул иткәнлеген һәм шунлыктан Союз договорына мөстәкыйль рәвештә кул куярга теләгәнлегебезне белдердек. Безне баштан ук өзеп һәм кисеп куймакчы булдылар. Имештер, моңа безнең хакыбыз юк. Сезнең арттан башка автономияле республикалар да ияреп китәргә мөмкиннәр бит. Моңа безнең дәлилебез шактый кыска һәм катгый булды: «Беренчедән, бу—республикаларның үз эшләре һәм бу мәсьәләне сез, кирәк булса, аларның үзләре белән хәл итегез. Икенчедән, бу республикалар суверенлык декларацияләрендә үзләрен Россия составында итеп күрсәттеләр һәм шунлыктан алар мәсьәләне безнеңчә итеп куя алмыйлар. «Ярар, монысы да шулай булсын, ә союздаш республикаларга нәрсә дип әйтербез?». «Анысы да сезнең эш, чөнки без сөйләшүләрне гаделлек принципларыннан чыгып кына алып барабыз». Бурбулис безнең декларациянең гадел һәм тирән эчтәлекле булуын да әйтеп үтте. Ләкин: «Әгәр дә сез шушы документ урынына референдум үткәреп, шуның нәтиҗәләре белән килгән булсагыз, бигрәк тә яхшы булган булыр иде»,—диде. Шулай да ул бу турыда башкача сүз кузгатмады. Шушы елларны Татарстан язмышында шактый зур роль уйнаган Геннадий Эдуардович Бурбулис турында әйтеп үтми булдыра алмыйм. Ул Ельцинның якташы, фәнни коммунизм укытучысы булып эшләгән. Аны Ельцин юкка гына үзе белән Мәскәүгә алып килмәгән. Акыллы, яңа идеяләрне бик тиз тотып ала, шул ук вакытта киләчәккә карап эш йөртә белә. Әңгәмәдәшен игътибар белән тыңлый. Энергиясе ташып тора. Каты куллы да була ала. Егор Тимурович Гайдарның хөкүмәте тулаем аның җитәкчелегендә булды. Гомумән, бу кеше Россия җитәкчелегендә Ельциннан соң икенче кеше булып торды. Әгәр дә әңгәмә вакытында дәлилләр өстенлек итә икән, бу аңа ошый. Ләкин инде дәлилсез дәгъвачылыкка җаны-тәне белән каршы. Нәкъ менә шуңа күрә аңар безнең белән сөйләшүләр алып бару бер яктан бик җиңел булды. Ул хәтта безнең шушы беренче очрашуыбызны фәнни семинар белән чагыштырды. Ике делегация бер-берсенә бик тиз ияләште.

Эш җайга салына башлады. Мин, сүз алып, үзебезнең декларациянең тулысы белән 1918 елда Бөтенроссия советларының III съезды кабул иткән «Изелгән һәм эксплуатацияләнгән хезмәт ияләре декларациясе»нә («Декларация прав трудящегося и эксплуатируемого народа») корылган икәнлеген һәм шушы документның Россияне федерация итеп игълан иткән бердәнбер документ икәнлеген әйттем. «Аллага шөкер, ул документларны да искә ала башладылар»,—дип, мине хуплап куйды Шахрай. Бу кеше бик үк гадиләрдән түгел. Акылсызлардан да түгел. Ләкин шулай да әле малайлыгы да чыгып бетмәгән. Ни эшләтәсең, ул да бит әле күптән түгел генә Мәскәү университетының юрфагында лаборатория мөдире булып эшләгән. Ельцин хөкүмәтен «кече фәнни хезмәткәрләр хөкүмәте» дип атыйлар иде. Шахрай да шундыйлардан. Ул шушы фәнни хезмәткәрләрнең иң активларыннан. Соңрак ул Россия хөкүмәтенең Милләтләр эшләре буенча комитетын да җитәкләде, шул сыйфатында, десантниклар формасы киеп, Чечня кырларында танк өстендә Дудаев гаскәрләрен куып йөрде, дәүләт Думасында Президент вәкиле булып та торды. Ләкин болары әле соңрак. Ә бүген исә безнең алда барын да яхшы аңлый торган итеп күренергә тырышкан яшь сәясәтче яралгысы. Мин Шахрайны чын демократ, гаделлек принципларын алга сөрүче кеше, дип әйтә алмас идем. Ул күп вакыт тик шундый булып кыланды гына. Чынбарлыкта исә, һәрвакыт безне

аяктан егарга тырышты. Тик бу эш барып кына чыкмады. Менә бер мисал. Баштарак безгә: «Сез Россиядән чыгасызмыни?»—дип теңкәбезгә тияләр иде. Беренче буларак бу сорауны безгә Шахрай бирде. Аңа җавап урынына мин үзебезнең Президентыбыз белән булган әңгәмәмне искә төшердем. Шуны сөйләп, мин Шахрайга: «Йөгез инде, бүген кайсы татар үз өстенә шундый җаваплылыкны ала алыр икән?»,—дидем. Ул, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлагандай булып, өстәл артыннан чыгып йөри башлады һәм безнең исемнән сөйләгәндәй итеп: «Димәк, без Россиядән чыкмыйбыз, әмма аңа кермибез дә»,—диде. Мин аңа: «Сергей Михайлович, сез безнең позицияне бик төгәл тотып алгансыз»,—дип әйттем. Ул урынына утырды һәм шуннан соң безгә бу сорау шактый вакыт бирелми торды. Әгәр дә тәҗрибәлерәк һәм инде сөйләшүләребезнең кайсы юнәлешкә кереп китәсен аңлап бетерген булса, ул бәлки болай әйтмәгән дә булыр иде. Ә бит берничә минуттан ук аның үзенең дә бу документны ныклап белмәгәнлеге мәгълүм булды. Чөнки аның эчтәлегенең нидән гыйбарәт икәнлеген ачып бирә башлагач, оппонентларыбызга бу документ әллә ни ошамый да башлаган кебек булды. Чыннан да, шушы документ нигезендә Россия ирекле республикаларның ихтыяри союзы итеп игълан ителгән. Минем кулымда шушы декларация басылып чыккан җыентык. Башкаларда ул юк. Мин тиешле цитаталарны да үзем сайлап алып китерәм, безгә файдалы булган урыннарына аларның игътибарларын җәлеп итәм. Сөйләшүләр башланган көннең икенче яртысында Россия делегациясе әгъзасы булган Сергей Борисович Станкевич килеп керде. Ул теге «Декларацияне»: «Бу большевиклар гамәле генә, әйдәгез Русьның меңьеллык тарихына таянып эш итик»,—диде. Әйтеп үтәргә кирәк, Станкевич тарихчы, шунлыктан үзен дә күрсәтмәкче булды. Тик без аңарга: «Меңьеллык тарихның башы—Киев Русе, билгеле булганча, «Повесть временных лет» «Откуда есть пошла земля русская»—дип башлана. Ә җавабы бер: «Киевская Русь». Алай булгач, безгә бәлки сөйләшүләрне дәвам итү өчен Киевка ук китәргәдер, тик менә анда безне ничегрәк кабул итәрләр икән? Юк инде, Сергей Борисович, «Декларация»дән, гомумән, III Бөтенроссия Советлар съездыннан башка бер кая да китеп булмый. «Большевистские штучки»ларны алар, түгелме, Россияне федерация итеп игълан иткән башка документлар юк,—дип җавап бирдек. Риза булды бу кеше, булмый ни эшләсен, аның башка чарасы юк иде бит. Соңрак, сөйләшүләр башлануга бер ел үткәч, Россия делегациясенә башка кешеләр килгәч кенә: «Вы выходите из России или нет?»,—дигән сорау тагын яңгырый башлады.

Хәзер исә шушы сөйләшүләрнең ифрат уңышлы булуын билгеләп үтәсем килә. Алар нәтиҗәсендә кыска гына беркетмә—протокол кабул ителде. Анда: «Моннан соң ни генә булмасын, Россия белән Татарстанның үзара мөнәсәбәтләре тик ике яклы договор нигезенә корылырга тиеш»,—диелгән. Бу протоколны ике як та көне-төне эшләде. Һәр як үз вариантын тәкъдим итте. Вариант артыннан вариант юкка чыгарыла торды. Бер вакыйганы искә төшерми булдыра алмыйм. Сөйләшүләрнең икенче көнендә Геннадий Бурбулис ничектер: «Татарстан хаклы»,—дигән сүзләрне ычкындырган иде. Бу сүзләр, әлбәттә, безгә бик ошаган иде һәм без аларны беркетмәгә кертергә тырышып карадык. Моның белән без Россия тарафыннан үзебезнең декларацияне танытуга ирешеп, шуны кабул ителергә тиешле документта чагылдырырга тырышкан идек. Кая анда, моңарчы сабырлык мисалы биреп торган Бурбулисны әйтерсең лә корт чакты. Аны алыштырып куйдылар диярсең. Ул кызарынды, бүртенде, шартлардай булды һәм үзе әйткән сүзләрдән баш тарткандай: «Нинди хаклы, ди, сез Россия президентын сайлауларны өздегез, сез...» дип, тагын шунда әллә нәрсәләрдә гаепли башлады. Без «артыграк җибәрдек бугай», дип шүрләп тә куйдык. Чыннан да, никадәр эшләнгән эшнең юкка чыгу ихтималы бар иде бит. Без чигендек һәм протоколга декларацияне тану сүзләре урынына аны ихтирам итү дигәннәре керде. Безнең өчен монысы да бик яхшы иде инде.

15 август көнне беркетмә кабул ителеп, ике як делегацияләренең һәммә әгъзасы тарафыннан имзаланды.

Менә беркетмәнең тулы эчтәлеге.

## ПРОТОКОЛ

*по итогам консультаций делегации Российской Советской Федеративной Социалистической Республики и Республики Татарстан, состоявшихся 12-15 августа 1991 года в городе Москве*

В ходе консультаций состоялся обмен мнениями по широкому кругу вопросов политико-правовых и экономических отношений Российской Советской Федеративной Социалистической Республики с Республикой Татарстан.

Принимая во внимание принципы Деклараций о государственном суверенитете Российской Советской Федеративной Социалистической Республики и Республики Татарстан,

учитывая исторические, экономические, культурные и иные связи своих народов,

исходя из понимания необходимости строить свои отношения на новых началах и стремясь к их дальнейшему развитию, делегации согласились о нижеследующем:

1. Понимая и уважая стремление Российской Советской Федеративной Социалистической Республики и Республики Татарстан как участников Договора о Союзе суверенных государств к обновлению и повышению их статуса, ориентироваться на использование договорных форм регулирования отношений Российской Советской Федеративной Социалистической Республики с Республикой Татарстан, учитывающих их приоритетные интересы без ущемления интересов других республик и Союза в целом.

2. Углублять и совершенствовать хозяйственные связи и взаимовыгодное сотрудничество на основе единого экономического пространства, развития рыночных отношений, стимулирования предпринимательства и социальной защиты населения.

3. Гарантировать соблюдение и защиту прав и законных интересов граждан независимо от национальных, конфессиональных и иных различий.

4. Способствовать развитию национальных культур и языков.

5. Признать целесообразным продолжить консультации в городах Москве и Казани.

В консультациях приняли участие:

со стороны Российской Федерации

О. Лобов, С. Станкевич, И. Федоров, С. Шахрай, Ф. Шелов-Коведяев;

со стороны Республики Татарстан

Ф. Газизуллин, Б. Железнов, Ф. Сафиуллин, И. Тагиров, Р. Хакимов, Р. Хафизов.

Руководитель делегации Российской Федерации Г. Бурбулис. Руководитель делегации Республики Татарстан В. Лихачев.

Шуннан соң кич белән Россия делегациясе безнең хөрмәткә банкет оештырды. Ә 16 август көнне без Казанга очтык.

Сөйләшүләр нәтиҗәсендә 19 август көнне нәкъ сәгать 10 да Ак йортта Шәймиев белән Ельцин очрашырга тиешләр иде. Ул көнне Шәймиев Ак йортка килә, ә очрашу булмый кала. Һәм моның сәбәбе Шәймиевтә түгел иде. Иң әһәмиятлесе—шул көнне иртән ГКЧП вакыйгалары башлана.

Хәтерлим, 1991 елның 21 августы көнне сәгать 12 белән 1 арасында мин Президентыбыз белән очрашу өчен аның кабул итү бүлмәсенә килдем. Янында бер кем дә булмаса да, мин аның янына шундук үтә алмадым. Ә инде кабинетына кергәч, аның Россия халык депутатлары съездының ачылуын игътибар белән күтеп торганлыгын күрдем. Мин шуны аңладым, ул Россия һәм Союз җитәкчеләре белән нинди мөнәсәбәтләрдә булырга кирәклеген билгели иде. Мин исәнләшүгә үк: «Инде бар да хәл ителде, тыңлап торасы юк»,—дидем. Ул:

«Ничек?»,—диде. «ГКЧП жиңелде, бетте, Россия житәкчелеге белән мөнәсәбәтләрне яхшыртырга кирәк»,—дидем. Ул моны миңа караганда яхшырак белгәндер белүен, ләкин минем әйтүем дә артык булмагандыр, дип уйлыйм. Безнең сөйләшүнең асылы нәкъ шуңа нигезләнгән иде.

—Минтимер Шәрипович, сез ничек уйлыйсыз, астагы постта торган милиционерның сезне кулга алу мөмкинлеге бармы?

Аз гына уйлап торганнан соң ул:

—Бик мөмкин,—диде.

—Ә бит моны булдырырга ярамый. МВД, Прокуратура, Суд республика карамагына күчәргә тиеш. Менә мондый сценарий булуы мөмкин. МВД тик Мәскәүгә буйсынган, аннан сезне кулга алырга, диган әмер төшә. Шул ук Мәскәүгә буйсынган Прокуратура сезгә карата җинаять эше башлый. Ә суд тиешле карар чыгара һәм шул ук милиция сезне чыгарып ата.

Минтимер Шәрипович моңа да каршы килмәде. Ләкин төгәл генә җавап та бирмәде.

Әйе, без Президентыбызны сакларга, аның иминлеген тәэмин итәргә тиешбез. Чөнки ул—башланган эшләребезнең гаранты, аны житәкләүче. Югары Суд рәисе Минзәфәр Мәүләт улы Мәүләтшин белән шушы ук эчтәлектәге әңгәмә булды. Ул: «Син үз яныңа Татарстан Эчке Эшләр министрының урынбасары Сафиуллинны чакыр, аның белән сөйләш»,—диде. Мин дустыма: «Мин бит тик университетның тарих факультеты деканы гына, ничек итеп аны үз яныма чакырыйм?»,—дидем.

—Син чакыргач, ул килер.

Чыннан да, билгеләнгән вакытта Сафиуллин минем яныма декан кабинетына керде. Мин эшнең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген аңа сөйләдем. Ул минем белән килеште.

—Президент тирәсендә, аның сагында ышанычлы, тик үзегезгә генә буйсына торган кешеләр булырга тиеш.

Бу намуслы, республикага тугрылыклы, аңа җаны-тәне белән хезмәт итәргә әзер кеше. Әгәр дә ул мин әйткәннәргә ышанган икән, димәк, бу чыннан да шулай.

Шикләнүләр юкка булмаган. Дөресен әйтергә кирәк, шомлы көннәр иде ул. Президентыбызны, Татарстан житәкчелеген ГКЧПны яклауда гаепләүләр республиканың үзендә дә шактый көчле иде. «Демократлар», яки нигездә суверенитетка каршы көчләр генә түгел, хәтта татар милли оешмаларының кайберләре дә бу кампаниядә актив катнаштылар. Мин шул көннәрне радиодан Мәскәүдә булган сөйләшүләр хакында, шул исәптән, Шәймиевнең 19 август көнне, алдан сөйләшкәнчә, сәгать 10 да Ельцин белән очрашу өчен Ак йортка килеп, анда Борис Николаевичны очрата алмаганлыгын да әйткән идем. Дөреслекне кабул итәргә теләмәгән кайберәүләргә бу ошамаган. Чөнки алар бит суверенитетны теләсә нинди юл белән буарга әзер иделәр. «Вечерняя Казань» үзенең 27 август санында ниндидер бер Л. Барминның «Как профессор Президента защищал» исемле репликасында болай дип язды: «В минувшее воскресенье немногочисленные слушатели Казанского радио стали свидетелями весьма странного выступления профессора КГУ, декана исторического факультета И. Тагирова, в котором он защищал Президента ТССР М. Шаймиева от нападок со стороны демократических и национальных сил. Последние обвиняют Шаймиева в предательстве своего народа и демократии, а также требуют отставки всего руководства ТССР». Бу кешенең язуына ышансаң, тик Идел буе хәрби округы генералы А. Макашов команда бирмәгәнгә генә, Шәймиев Казан урамнарына танклар чыгара алмаган булып чыга. Ә бит бүген һәммә кешегә Макашовның кем икәнлеге мәгълүм. Ул үзенең демократияне буарга әзер икәнлеген ачыктан-ачык белдерде. Бармин белер-белмәс башы белән Ельцинны яклый, ә Шәймиевне пычрата: «Борис Николаевич в то время был занят несколько другими делами—защищал с народом демократию и свободу. Ну, а Минтимер Шарипович, встретившись с Г. Янаевым, поехал в Казань заниматься своими делами. Какими—вы знаете». Ә бит чынбарлыкта Шәймиев Ак

йортка вакытында килә. Ельцин анда булмый. Юк, халык белән бергә урамда да түгел, ә үзенең дачасында. Ул төнлә белән Казакъстаннан шактый йончып кайткан. Хасбулатовның әйтүенә караганда, хәтта пычранып та беткән була. Анысы дөрестерме, юктырмы—әйтеп булмый. Әмма аны шушы көнне танкка меңгезеп, ГКЧП га каршы көрәш указын укыту өчен Г. Бурбулиска шактый күп көч куярга туры килә. Бурбулис Ельцин дачасыннан Ак йортка шалтыратып Россия Президентының Шәймиев белән очрашырдай мөмкинлеге юклыгын хәбәр итә. Шуннан соң Мәскәүдәге вакыйгаларның нидән гыйбарәт икәнлеген белү өчен Шәймиев, СССР җитәкчелеге белән очрашып, Казанга кайтып китә. Әйе, ул республикада тәртипсезлекләр булдырмауның чараларын күрергә мәҗбүр иде. Ни эшләсен, ул—республика, һәм аның халкының иминлегенең гаранты. Ә инде миңа килгәндә, Татарстан гражданы буларак, аның Президентын якларга бурычлымын.

Әйе, ул көннәрне Татарстанның Россия җитәкчеләре белән мөнәсәбәтләре шактый кискенләште. Монда «Вечерняя Казань» кебек газеталарның өлеше дә зур иде. Генераль Прокуратура Шәймиевкә һәм КПСС рескомының Беренче секретаре Рево Рамазан улы Идиәтуллинга карата, аларны ГКЧПны яклап чыгуда гаепләп, җинаять эше кузгатты. Ә бит бу уен эш түгел. Һәм ул төрлечә бетәргә мөмкин иде. Соңрак бу эшләр туктатылды. Башта Шәймиевнеке. Шактый вакыттан соң Рево Рамазановичның эшен дә яптылар.

Союз договорына кул кую мөмкинлеге юкка чыкса да, СССР таркалса да, Россия белән Татарстан арасын юридик рәвештә аныклау проблемасы кала бирә. Димәк, сөйләшүләрне дәвам итү ихтыяҗы сакланып кала. Ләкин аларны дәвам итү шактый кыенлаша.

## Мөнәсәбәтләр кискенләшә, ә эш дәвам итә

ГКЧП ВАКЫЙГАЛАРЫ сәбәпле, ике ара шактый катлауланса да, икътисади мөнәсәбәтләрне җайлау актуаль була килде. Шунлыктан, Мәскәү һәм Казан арасында бу хакта сөйләшүләр башларга кирәк, дигән фикер ныгыды. Һәм инде озак та үтмәде, Казанда зур икътисади сөйләшү проекты төзелде. Казан сөйләшүләрне шуның нигезендә алып барырга теләде. Ләкин... Хәер, анысы турында соңрак сүз булыр.

Бу сөйләшүләрне ике яктан да башка кешеләр алып барды. Россия ягындагы делегациянең башында Егор Гайдар булса, безнең як делегациясен премьер-министр Мөхәммәт Сабиров җитәкләде. Анда мине дә керттеләр. Сөйләшүләр ноябрь ахырында элеккеге КПСС Үзәк Комитеты урнашкан бинада башланды. Мин соңарыбрак килгән идем. Эчкә үткәндә, инде сөйләшүләрнең пленар өлеше бетеп, тәнәфес игълан ителгән. Коридорда тик Гайдар белән Сабиров кына сөйләшеп тора иде. Аларның әйтүенчә, инде делегацияләр төрле төркемнәргә бүленгән икән. Икътисади, нефть, финанс, банк, юллар һәм башка төркемнәр төзелгән булып чыкты. Алар иртәгәдән эшкә керешергә тиешләр.

Кичен миңа пленар утырышның беркетмәсен бирделәр, ул әлегәчә миндә саклана. Пленар утырыш Гайдар һәм Сабировның чыгышларыннан гына торган булып чыкты. Миңа ул чыгышларның берсе дә ошамады. Гайдарның чыгышында Россия милек һәм башка хокуклар хуҗасы, ә Татарстан сораучы, теләнүче дәрәҗәсенә куелган иде. Аның позициясе «бердәм һәм бүленмәс Россия» принцибына корылган һәм ул катгый иде. Без, ди ул, Татарстан өчен генә ниндидер ташламалар ясарга җыенмыйбыз. Барлык республика һәм регионнар бер хокукта булырга тиеш. Гайдарның позициясе аңлашыла, чөнки ул Россия җитәкчелегенең позициясе. Ә менә М. Сабировның позициясе миндә ни өчен ризасызлык тудырды? Мин Казаннан алып киленгән килешү проектының тамырдан киселеп ташланганлыгын аңладым. Сабировның чыгышы да шуны ук раслый. Ул чыгышының бер урынында « без берсүзсез Россия белән» дип ычкындырган. «Сез нигә мондый белдерү ясадыгыз?»—

дип сорадым мин аңардан. Ул миңа: «Азрак төгәлсезлек киткән»,—дип аңлатты. Шуннан соң мин аңардан делегациябезнең тулы составы алдында беренче көнге сөйләшү нәтиҗәләрен анализларга теләвемне белдердем. Мөхәммәт Галләмович кирәк урында катылык һәм зур таләпчәнлек күрсәтә торган кеше. Ләкин ул шул ук вакытта кешеләр белән йомшак һәм ягымлы сөйләшә белә торган шәхес. Безнең ике ара мөнәсәбәтләр һәрвакыт шундый булып килде. Минем тәкъдимгә ул тулы ризалык бирде. Чөнки делегация әгъзалары Сабировның позициясен дөрес аңларга тиеш иделәр.

Чыгышымда: «Делегацияләрнең кичәге утырышында ике позиция бер-берсе белән бәрелешкән,—дидем.—Аның берсе—Е. Гайдар позициясе. Ул Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы, икенчесе—Сабиров позициясе, ул исә Татарстанның мөстәкыйльлеген яклый»,—дидем. Сабиров мәдәни, рухи һәм икътисади бердәмлек турында сүз алып бара дип, Сабировның әйткән сүзләренә уңайрак төс бирдем. Нигездә ул шушы позициядә тора да иде һәм, чыннан да, сүз ниндидер бер төгәлсезлек турында гына бара иде. Мин делегация әгъзаларының кабул ителгән декларациябез һәм августта булып үткән сөйләшүләр беркетмәсенә таянып эш итүләрен сорадым. «Без монда теләнергә түгел, үз хокукларыбыз белән килдек һәм аларны тануга корылган икътисади килешүне төзергә тиешбез»,—дидем.

Мин моны Мөхәммәт Сабировка карата ниндидер тискәре фикер белдерү йөзеннән әйтмим. Беренчедән, бу—дөреслек, аны мин ялгыш күрсәтә алмыйм. Икенчедән, бу кеше делегация составына мине шундый эшләрне алып бару өчен үзе керткән бит. Шулай булгач, мин үз вазифаларымны дөрес башкарган булып чыгам. Ә аның үз эше болай да муеныннан иде. Тик минә ул һич кенә дә берәүгә дә бәрелмәде, кемнәрдер ниндидер хата җибәрсә, ул аларны йомшак итеп төзәтә белә. Аның фамилиясе холкына туры килә.

Ләкин шулай да баштарак безне, чыннан да, теләнүчеләр итеп кабул иттеләр. Ике-өч көн буе безнең уртак төркемнәрдә эшләгән кешеләребез әйләнеп кайткан саен бернинди нәтиҗә юклыгын бәян итә тордылар.

Бер көнне минем яныма дәүләт милеге рәисе урынбасары Дамир Мансур улы Бикбов килде һәм милек төркеменә ярдәм итүемне сорады. Мин, әлбәттә, риза булдым һәм икенче көнне аның белән төркемнең утырышына бардым. Тик өченче дәрәҗәдәге Россия чиновнигының безнең белән сөйләшерлек бернинди хокукы юк икәнлеген күрдем. Ул инструкция алган һәм шуның нигезендә эш итә. Ул безгә берничә калын китап биреп: «Әнә, сайлагыз үзегезгә кирәген. Аннары сөйләшербез»,—диде. Бу китапларда Россиядәге предприятиеләрнең исемлеге булып, аларның Татарстанда урнашканнары арасыннан безнең карамакка идарә итү хокукы белән кайсыларындыр сайларга мөмкин икәнлеге ачыкланды. Тик теләсә нинди очракта милек Россия Федерациясенеке булып калырга тиеш була. Шул нигездә килешү төзү күз алдында тотыла икән. Мин бу чиновникка: «Сез безгә нинди ксерокопия күрсәтәсез, без мондый документ түгел, ә тигез хокуклык нигезендә төзелгән документ булдыруны телибез»,—дидем. Ул исә үзенә андый вәкаләтләр бирелмәгәнлеген әйтте. Шунлыктан бу көн дә нәтиҗәсез үтте. Бу кешенең соңрак милек бүлүдәге башбаштаклыклары өчен эшеннән алынганлыгы мәгълүм булды.

Икенче көнне сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителергә тиешле документның проектын төзү эше башланды. Безнең яктан монда дәүләт икътисад комитеты рәисе, вице-премьер Филзә Гариф улы Хәмидуллин, финанс министры Дмитрий Нагуман улы Нагуманов һәм инде телгә алынган Дамир Мансур улы Бикбов бар иде. Россия ягыннан бу эшне икътисад министры урынбасары Андрей Шаповальянц алып барды. Бу кеше минем хәтеремә тирән акыллы, логикага таянып эш итүче шәхес булараk кереп калды. Безнең икебезнең арада шундыйрак сөйләшү булып алды. Мин аңа:

—Сезнең белән җитди сөйләшүләр алып барып буламы?—дигән сорау бирдем.

—Сез безне кимсетәсез, без җитди кешеләр һәм безнең белән җитди сөйләшүләр алып барып була.

—Яхшы, алай булгач, сез инде сөйләшүләрдә варислык (преемственность) принцибын танып ысыздыр?

—Әлбәттә.

—Менә сезнең алдыгызда августта булып үткән сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителгән беркетмә ята. Аңа ничек карыйсыз?

—Мин аны яхшы документ дип саныйм.

—Алай булгач, әйдәгез әле аның эчтәлеген карап карыйк.

—Яхшы.

—Анда, ике як та үзләре кабул иткән дәүләт суверенлыгы декларацияләреннән чыгып эш итәләр, диелгән.

—Әйе, шулай булырга тиеш тә.

—Алай булгач, Татарстан декларациясендә, җир һәм андагы милек Татарстан һәм аның күпмилләтле халкыныкы, дип язылган. Шуны танысызмы?

Бу кадәргә киткәч, аңа «таныйм» дип әйтүдән башка юл калмаган иде. Мин исә аңа: «Кабул ителергә тиешле документ та ике якның да үз милке бар, дигән принцип белән билгеләнергә тиеш. Сезнеке ул—сезнеке, ә Татарстандагы барлык милек—«безнеке». Әйдәгез, шулай итеп язып та куйыйк»,—дидем мин.

Ул риза булды. Шушы принцип документка теркәлде. Ул:

—Беттеме?—дип сорады.

—Юк, милекне безнеке икәнлекне тануның никадәр әһәмиятле булуына да карамастан, бу әле эшнең башы гына. Сөйләшүләрдә без шундый логикага таянабыз, әгәр кемнең дә булса милке бар икән, ул аннан үз файдасына салым җыя. Башкалар өчен салым җыярга булгач, ул милекнең нигә кирәге бар? Шунлыктан без,—дип дәвам иттем мин,—бер каналлы мөстәкыйль республика салымын булдыруны алга сөрәбез. Салым ул—акча чыганагы. Димәк, безнең мөстәкыйль финанс системабыз, ягъни үзебезнең бюджетыбыз да булырга тиеш.

—Беттеме?

—Юк әле. Акчаң булгач, аны салырга кесә кирәк бит. Без Татарстанның милли банкы булуын телибез.

Бу логика тулысы белән кабул ителде. Һәм моның өчен миңа нибары 5-7 минут җитте.

Кичке аш вакытында финанс министры Нагуманов: «Индус Ризакович, сез бит тарихчы, ничек итеп шушы җиңүне булдыра алдыгыз?»—дип сорады. Бәлки, бу аңа гаҗәп тоелгандыр, ләкин бит монда эш синең кем булуыңнан тормый. Җавап гади: без дәүләт суверенлыгы декларациясен төзегән вакытта ук анда ниләр булырга тиеш икәнлеген белеп эшләдек.

Нәтиҗә үзен әлләни озак көттермәде. Икенче көнне кичен Нагуманов Сабировка: «Россия мөстәкыйль бюджетка һәм банкка риза»,—дигән шатлыклы хәбәр алып кайтты.

Нефть мәсьәләсе буенча сөйләшүләр аеруча авыр бара иде. Инде безнең шул төркемдә эшләгән М. Гыйниятуллин дә кайтып: «Нефтьнең дә безнеке икәнлеген таныйлар!»—диде. Ә тагын бер көннән нефтьнең яртысы Татарстан карамагына күчүе турында документ проекты төзелде. Мин бу документның эчтәлегенә тукталып тормыйм. Чөнки ул басылып чыкты. Аңарга тик дөрес бәя бирү генә кирәк. Аның тик өнә шул, финанс, салым, банк мәсьәләләре кебек үк, милек мәсьәләсенә принципиальлек кертелгәннән соң гына кузгалып китеп, безгә уңай нәтиҗә биргәнлеген әйтеп үтәсем килә.

Шушы сөйләшүләр вакытында соңгы вакыйганы сөйләмәсәм, ничектер дөрес булмас кебек тоела. Сүз соңгы пленар утырыш турында бара. Монысы да элеккеге КПСС Үзәк комитеты бинасында булды. Политбюро утырышлары була торган бүлмәдә. Өстәлләрдә әле Политбюро әгъзаларының фамилияләре дә шул килеш тора иде. Без утырышкач, Мөхәммәт Галләмович: «Әйдәгез әле, без баштан безнең профессорны тыңлыйк»,—диде. Гайдар каршы килмәде. Һәм миңа сүз бирелеп, мин үзебезнең

декларациянең Россия ягыннан танылган икәнлеген һәм шушы сөйләшүләрдә аңа таянырга кирәк икәнлеген аңлаттым. Гайдар, баштарак, күрәсең, декларацияне әллөни әһәмияткә ия документ түгел, дип уйлаган булса кирәк. Бу аның беренче пленар утырыштагы чыгышыннан да яхшы сизелә. Ул: «Сәясәтчеләр үзара аңлаша торган арада, без икътисад мәсьәләләрен хәл итә торыйк»,—дигән. Тик минә атнадан артык үзара дәгъвалашу мәсьәләнең нәкъ сәяси күзлектән карап хәл кылынырга тиешлеген исбатлады. Шуның өчен булса кирәк, минем сөйләгәнем шактый игътибар белән тыңланды. Мин исә, декларациябезнең нәрсә икәнлеген сөйләгәннән соң, Россия ягын шушы документны формаль рәвештә генә тануда гаепләдем.

—Сезнең бу тануыгыз кериндель тишеген тануны гына хәтерләтә.

Бу сүзләр Гайдарга ошамады.

—Ә сез нәрсә телисез соң?

—Безнең милеккә хуҗа булуыбызны тануыгызны телибез.

—Безгә килешмичә аерылышырга гына каламы?

Мин бу егетнең бу кадәр кызганын күргәнем юк иде, шунлыктан шүрләп тә куйдым: күрәсең, минем аркада сөйләшүләр өзелергә дә мөмкин бит. Ләкин ул тынычлана төште.

—Алыгыз нефтегезне, черек нефтехимиягезне,—дип дәвам итте.—Ләкин сез аларны кая куярсыз?—дип өстәп куйды.

Бу исә иң киеренке мизгелләрнең үткәнлеген раслый торган сүзләр иде. Безнең арадагы әңгәмәгә, ниһаять, Мөхәммәт Галләмович үзе кушылды:

—Казан ханлыгы заманындагы шикелле, сезнең белән сәүдә итәрбез,—диде.

Ул шушы сүзләре белән киеренкелекне бөтенләй диярлек алып ташлый алды. Сөйләшүләр нәтиҗәсендә төзелгән беркетмәнең проекты РСФСР Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатовка җиткәч, ул зур ризасызлык белдереп, банк һәм бюджет мәсьәләсе тик Югары Совет вәкаләтендә генә булып тора, диеп, безнең документка бераз үзгәреш кертен. Гомумән, бу мәсьәлә буенча ике якның да Югары Советлары делегацияләре үзара сөйләшүләр алып барырга тиеш булып чыкты. Андый сөйләшүләр дә булып, анда кайбер уңышларга ирешелде.

## Әбрар Кәримуллин мөнәсәбәте. Сөйләшүләрнең дәвамы

БЕЗНЕҢ СӨЙЛӘШҮЛӘР хакында матбугатта кыска-кыска гына мәгълүмат бирелә килеп тә, аларның эчтәлеге яки нәтиҗәләре турында бернинди хәбәр дә бирелми иде. Бу аңлашыла да. Чөнки нинди дер нәтиҗә турында сүз алып бару әле мөмкин түгел иде. Ә инде әле булмаган эш хакында «булды» дип сөйләү шулай ук мөмкин нәрсә түгел. Ә җәмәгатьчелек кызыксына. Төрле имеш-мимешләр таратыла. Бервакыт урамда миңа Әбрар ага Кәримуллин очрады. Һәм сүзне шактый кырыс башлап җибәрде.

—Йә, сатып бетердегезме әле Татарстанны?!

—Булмаган нәрсәне сатып буламы соң, Әбрар абый?

—Ничек булмаган нәрсә булсын, ди! Без Декларация кабул иттек, барлык милек һәм хокукларны үзебезнеке итеп игълан иттек. Тагын ни кирәк?

Әбрар Кәримуллин турыга сөйли торган ихлас кеше иде. Ул кайвакыт хәтта түземсез сабый баланы да хәтерләтә. Шуның өчен аның белән сөйләшкәндә тик дөресен генә сөйләп котылып була иде.

—Әбрар абый, Декларация бит ул тик ният белдерү документы гына. Без шул ниятебездә бүгенгә кадәр милек һәм хокуклар хуҗасы булган Россия җитәкчелеген күндерергә тиешбез. Ниятебезнең гаделлек принципларына һәм үткән тарихыбызга нигезләнгән икәнлегенә инандырырга тиешбез.

Абзый уйлана төште, шактый суынды. Шуннан соң мин аңа сөйләшүләрнең ни рәвештә барганлыгы турында бөйнә-бөйнә сөйләп бирдем.

—Нигә соң боларның барысын да халыкка җиткермисез?

—Әбрар абый, алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр. Әле тиешле нәтиҗәгә җитмәстән, шапырынып йөрүләр кирәкме икән соң? Әгәр тиешле нәтиҗәгә ирешмәсәк, без халыкка нәрсә әйтербез?

Ул минем белән килеште. Шуннан соң мин аңа һәрвакыт диярлек мөмкин булган кадәресен сөйли торган идем. Гомумән, ул бик милли җанлы, җыр-моңга гашыйк кеше иде. Бу изге җан арабыздан китте инде, урыны оҗмахта булсын. Ләкин аның эшләгән эшләре, гыйльми хезмәтләре, ялкынлы публицистик язмалары аны һәрвакыт искә төшереп торыр.

Бу елларда үзгәрүләрнең яшен тизлеге белән барган вакытлары да булды. Кайбер очракта кыска гына мизгелләр үз эчләренә айлар, хәтта елларны сыйдыра иде. Татарстанның статусын, аның Россия һәм башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен билгеләргә тиешле референдум тарихы үзе ни тора! Республика ул референдумга барырга мәҗбүр иде. Бер яктан, сул милли көчләр Татарстанның тулы бәйсезлеген игълан итүне таләп итсәләр, икенче яктан, шактый көчле агым, шул исәптән, зыялылар Татарстанның статусын билгеләү өчен референдум үткәрүне таләп итә иде. Инде әйткәнемчә, Бурбулис та аның кирәклеген күрсәткән иде. Ничек кенә булмасын, референдум үткәрү турындагы карар Югары Совет тарафыннан кабул ителде.

Мәгълүм ки, референдум алдыннан Татарстанга карата янау һәм кизәнүләр артка期нан-арта барды. РСФСР Югары Советының машиналары Татарстанны иңләп-буйлап референдумга каршы, ә инде ул була калса, анда куелган сорауга «юк» дип җавап бирергә өндәгән листовкалар һәм прокламацияләр таратып йөрделәр. Бигрәк тә РСФСР Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатов котырды. Аның тарафыннан нинди генә уйдырмалар, янаулар әйтелмәде. Акылга утырмаса да, утырмый икән. Бервакыт безнең Декларациягә каршы язган мәкаләсенә җавап итеп, «Советская Россия» газетасында минем Сабиров белән берлектә имзалаган «Позиция или недоразумение» исемле мәкаләм чыккач, ул бер гафу үтенгән иде. Ләкин бу тукран тәүбәсе генә булып чыкты. Шул вакыттагы Россиянең вице-президенты Александр Руцкой да аңардан әллә ни калышмый иде. Ул, Россиянең Югары Советы белән Президенты арасында сугыш мөнәсәбәтләре барлыкка килгәч, Мәскәү өстендә очып йөргән хәрби самолетларга: «Кремльне бомбага тотыгыз!»— дип команда биргән булган. Әгәр дә хәрбиләр аны тыңлаган булса, бүген Кремль, гомумән, Мәскәү нинди булыр иде икән? Әйе, бу кеше һәрвакыт тынычлык вә иминлек дошманы булып килде. Аның Татарстанга да каза китерүе ихтимал иде. Тик, Аллага шөкер, Россиядә әле аек фикерле кешеләр дә бетмәгән.

Форсаттан файдаланып, андыйларның берсе турында әйтеп китү кирәктер дип саныйм. Сүз Юрий Владимирович Скоков турында булачак. Татарстан өчен шомлы көннәрдә ул Россия иминлек Советы секретаре вазифаларын башкара иде. Ельцинның Руцкойга охшаш киңәшчеләре Президентның колагына, Татарстанга гаскәр кертергә кирәк, дип пышылдап торалар. Үзләре хәрби булмасалар да, кайбер вакыт десантник формасын киярга яраталар. Хәер, соңрак берсенең шул формада танк өстенә атланган рәвештә Чечня кырларында йөрүләрен телеэкраннарда еш кына күрергә мөмкин иде. Бәлки, алар Татарстанга да танкка атланып керергә ниятләгәннәрдер. Тик менә Юрий Скоков боларның тәкъдимен катгый рәвештә кире кага. Россия Президентын мондый башбаштаклыкка барудан туктатып кала.

Чыннан да референдум Россия белән мөнәсәбәтләрне ачыклауның бердәнбер юлы булып калган иде. Билгеле булганча, республикада 1992 елның 21 мартында бу референдум үткәрелеп, анда катнашканнарның 61,4 проценты суверенлык статусын яклап тавыш бирде.


31 март көнне Мәскәүдә Россиянең федератив килешүен имзалау

тантаналары булып үтте. Татарстан, үзенең кабул ителгән дәүләт суверенлыгы Декларациясенә һәм аның бөтен халык референдумы нигезендә расланган махсус позициясенә таянып, аңа кул куймаячагын белдергән иде. Бу, әлбәттә, Россия җитәкчелеген бик нык борчыды. Чөнки, Татарстанга ияреп, Саха һәм Башкортстан да килешүгә кул куймау ихтималын белдерделәр. Россия җитәкчелеге аларны Татарстаннан аерып алу максатын куйды. Күрәсең, шуңа ирешү йөзеннәндер, алар Татарстан белән сөйләшүне дәвам иттерү кәнен нәкъ шушы 31 мартка билгеләделәр. Минемчә, аларга моның җисеме түгел, исеме генә кирәк иде. Алар шушы килешүгә кул куярга тиешле республикаларга Татарстанның ультиматив позициядә булмавын, хәтта ничек тә булса, кайчан да булса, аңа кушылачагын исбат итү өчен һәм Татарстанга ияреп, башкалар да бу документны имзалаудан баш тартмасыннар, дип курыкканга күрә, сөйләшүне шушы көнгә билгеләгәннәр булса кирәк.

Менә сәгать 10. Г. Бурбулис әле үз кабинетында утыра. Ишек төбендә—Башкортстан җитәкчеләре. Мин аларны танымыйм. Безнең вице-президент В. Лихачев миңа аларның кайсы кем икәнлеген аңлата.

Ниһаять, без өстәл артында. Бурбулис безнең белән исәнләшә, уч төбе салкын тирдә. Бу аның тыныч түгел икәнлеген күрсәтә. Шулай булырлык та. Россия җитәкчелеге кайбер республикаларның Татарстан артыннан ияреп барып, Федератив договорга кул куюдан баш тарту мөмкинлекләреннән нык шүрләгән. Күрәсең, Бурбулисның безгә: «Татарстан артыннан башкалар да бара»,—дигән сүзләре юкка гына әйтелмәгән.

Инде мәгълүм булганча, моңа кадәр Бурбулис Башкортстан делегациясе белән авыр сөйләшү үткәргән, ике хөкүмәт арасында килешү төзелеп, ул Федератив договорга өстәмә документ итеп танылган. Ә бит бу барып чыкмаска да мөмкин иде. Әгәр дә кайбер республикалар, безнең шикелле үк, Федератив договорга кул куюдан баш тарткан булсалар, кем белә, вакыйгалар, бәлки бөтенләй башка юнәлеш алган булыр иде. Безнең бу очрашу нинди дә булса уңай нәтиҗә бирмәде. Шулай булырга тиеш тә булгандыр, шулай булмаса, беренче очрашудан соң ук Бурбулис үз урынына Россия Фәннәр Академиясенең Этнология институты директоры, Россия хөкүмәтенең Милләтләр Эшләре буенча Дәүләт Комитеты рәисе Валерий Александрович Тишковны калдырып, үзе Федератив договорга кул кую эшләренә чуммаган булыр иде. Ә бит Бурбулисның беренче очрашуда ук белдерелгән Татарстанда референдум үткәрү теләге тормышка ашкан



*Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәгә кул кую вакыты. Мәскәү, Кремль. 15 февраль, 1994 ел.*

иде. Мин Бурбулиска: «Сезнең теләгегез тормышка ашты, без сезнең яныгызга референдум нәтиҗәләре белән килдек»,—дидем. Әлбәттә, ул моңа шатланмады һәм Россия Конституцион судының карары аларның кул-аягын бәйләгәнлегенә ишарә ясады. Ничек булса да булган, бу очрашу вакытында аның урынына Тишков утырды.

Тишков зур белемгә ия профессор. Шул ук вакытта, ул «бердәм һәм бүленмәс Россия» принцибын ныклап һәм нигезләп яклый белүче. Әмма йомшак тавышлы ягымлы кеше. Аның белән аралашу кызык. Бу очрашу вакытында да бер беркетмә кабул иттек. «Анда делегации согласились о нижеследующем: 1.0 необходимости установить особые отношения Республики Татарстан в Российской Федерации» дигән сүзләр бар иде. Мин «в» хәрефен «с» хәрефенә алмаштыруны сорадым. Тишков: «Ярар—диде.—Тик Татарстанның тышкы эшләрдә катнашуы турындагы сүзләрне алып ташлыйбыз»,—диде. Мин моңа риза булдым. Һәм хәрефләр алыштырылды. Аңлашыла ки, бәхәс хәреф турында түгел, Татарстанның статусы турында барды. Моны бу очрашуда катнашкан һәр кеше сизеп торды.

Бу утырышка Мөхәммәт Сабиров та килгән иде. Ул утырыштан соң килеп, минем кулымны кысып рәхмәт әйтте, ә Василий Николаевич Лихачев, ачулы тавыш белән: «Индус Ризакович, сезнең аркада халыкара мөнәсәбәтләр хокукын югалттык»,—диде. Тик безнең өчен Декларациябезнең төп эчтәлеген саклап калу күпкә әһәмиятле иде. Ә инде халыкара мөнәсәбәтләр урнаштыру хокукы Федератив договор һәм Россия Конституциясе аша Федерациянең һәрбер субъектына бирелгән. Шушы урында тукталып, үземнең Василий Николаевич Лихачевка карата мөнәсәбәтемне белдермәсәм, бу һич кенә дә дөрес булмас иде. Бу кешегә карашлар төрлечә иде, мин, аның белән якыннан аралашкан кеше буларак, үз сүземне әйтергә кирәк дип саныйм. Лихачев Казан университетының юридик факультетында төпле белем алып, юридик фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешкән кеше. Ул акыллы, сабыр һәм киң күңелле. Сүзгә оста. Кирәк вакытта фикерен ачык һәм аңлаешлы итеп белдерә. КПСС исән-имин вакытта аны Өлкә комитетына хокукый һәм административ органнар бүлеге мөдире итеп алалар. Ә инде соңрак ул Татарстанның беренче һәм соңгы вице-президенты була. Нәкъ менә шушы сыйфатында ул Россия—Татарстан сөйләшүләре вакытында делегациябезнең җитәкчесе булды. Сөйләшүләр вакытында ул искиткеч зур роль уйнады, чын мәгънәсендә Татарстанның лаеклы вәкиле була алды. Хаталары да, ялгышлары да булмады түгел. Ләкин ул республикабыз тарихының соңгы чорында тиешле урынын алды.

Ничек кенә булмасын, Татарстанның абруе арткannан-арта барды. Минтимер Шәймиевнең исеме Россия һәм БДБ илләрендә генә түгел, дөньякүләм яңгыраш алды.

## Безне Мәскәү таный

РЕФЕРЕНДУМНАН соң, 6 апрель көнне Россия халык депутатларының VI съезды ачылды. Анда Татарстан Югары Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның чыгышы булырга тиеш иде. Аның вазифасы Татарстанның яңа статусын һәм Россия белән мөнәсәбәтләренең нинди булырга тиешлеген аңлатудан гыйбарәт иде. Әлбәттә, үтә җаваплы вазифа иде бу. Шунлыктан съездга Минтимер Шәймиев үзе дә барды. Ә хөкүмәт җитәкчесе Мөхәммәт Сабиров, Россия халык депутаты булганлыктан, съездның эшендә турыдан-туры катнашты. Мин анда киңәшче рәвешендә катнаштым. Безнең белән Әсгать Сәфәров та бар иде. Безне академик Варга урамындагы бер таш койма белән уратылган биләмә эчендәге зур парктагы аерым йортка урнаштырдылар. Менә дигән санаторий. Затлы бүлмәләр, сауна. Ашау-эчү искиткеч! Официантлар сержант дәрәҗәсендәге КГБ хезмәткәрләре икәнлеге ачыкланды. Гомумән, бу объект шушы өч хәрефле органныкы булып чыкты. Кайбер вакыт парктагы агачлар да безне тыңлап торадыр кебек тоела иде. Монда

бездән башка Удмуртия Югары Советы рәисе В. К. Тубылов та урнашкан икән. без Фәрит Хәйрулловичның чыгышын кат-кат бергәләп тикшерә идек. Тубыловны үз иттек, аннан серләребез булмады.

Съездның беренче көннәрендә мин дә житәкчеләр белән бергә көн саен Кремльгә Съездлар сараена бара идем. Чөнки Мөхәммәтшинның чыгышында, һичшиксез, съездның сулышы чагылыш табарга тиеш. Беренче көнне баскыч төбенә килеп туктауга Саха президенты Николаев очрады. Минтимер Шәрипович аны култыклап, читкәрәк алып китте һәм алар анда нәрсәләрдер турында сөйләшеп алдылар.

Көн артыннан көн үтте, ләкин Фәрит Хәйрулловичка һаман сүз бирмиләр. Бер атна үтүгә, Мөхәммәтшинның чыгышын көтә-көтә зарыкканнан соң, Президент кайтып китте. Мин дә аның белән идем. Съездда исә, Фәрит Хәйруллович авырып китү сәбәпле, ул сөйлисе нотыкны Сабиров сөйләгән. Фәрит Хәйруллович: «Иң яхшы чыгышымны Сабировка бирергә туры килде»,—дип уфтанып та йөрде.

Акрынлап Россия һәм Татарстан мөнәсәбәтләре шактый жайлашты. Шул ук елның 3 август көнне безнең зур делегация Мәскәүгә килде. Безне Тишков житәкчелегендәге Россия хөкүмәте вәкилләре каршы алды. Безгә чәчәкләр тапшырдылар. Тишков: «Сез Россия Федерациясе хөкүмәтенең кунаклары»,—диде. Безне почетлы эскорт озатуында Сталинның «Ближняя дача» дип аталган резиденциясенә китереп урнаштырдылар. Сөйләшүләр төркемнәргә бүленү рәвешендә алып барылды. Без Василий Николаевич Лихачев белән статус төркемендә идек. Россия ягыннан бу төркемгә Тишков керде.

Бурбулис белән очрашу өчен Лихачев, Тишков һәм мин Кремльгә килдек. Лифтта менәбез. Коридор буйлап барганда Тишков: «Индус Ризакович, сезгә бу бөеклек дәрәҗәсе басмыймы?»,—ди. Тишковның бу сүзләрне әйтүе өчен нигез юк түгел иде: без моңарчы КПСС ның Генераль секретаре, СССР Президенты Горбачев утырган кабинетка килеп кердек. Бурбулис безне бик жылы каршы алды. Сөйләшүләр дә бик жылы мөнәсәбәттә үтте. Тик шулай да без Тишков белән бәрелешеп алдык. Ул, ничектер, мин сөйләгәндә, мине бүлеп: «Әйтегез әле, сез Россиядән чыгасызмы, әллә юкмы?»—дип сорады. Иң беренче очрашу вакытында ул әле Россия делегациясендә түгел иде. Шунлыктан, ул минем Шахрайның шушы соравына ничек җавап биргәнемне белми. Мин Бурбулиска карап: «Геннадий Эдуардович, бу сорауга җавап бирү кирәкме икән?»—дидем.

Ул минем бу сорауга ничек җавап бирәчәгемне белә. Шунлыктан, ачу белән: «Әйдәгез, Татарстанга башка андый ахмак сораулар бирмик»,—диде. Аның үз чыгышы төпле һәм тирән эчтәлекле булды. Миңа аның бигрәк тә: «Татарстан белән сөйләшүләр алып барган бер ел эчендә без бик нык үзгәрдек һәм хәзер инде Россия конфедерация элементлары булган асимметрик федерация булырга тиеш дип исәплибез»,—дигән сүзләре хуш килде. Миңа гына түгел, Василий Николаевичка да. Урамга чыккач без кул кысыштык. Ул: «Индус Ризакович, әйдәгез бу тарихи көнне гомергә истә калдырыйк»,—диде. Кич белән ике делегация очрашкач, Тишков: «Индус Ризакович—чакматаш!»—диде. Шуңа күрәдер, ул мине делегация составыннан чыгару өчен бик тырышты. Моңарчы биргән бер интервьюсында ул ике яклы сөйләшүләрнең уңай баруын билгеләп: «Тик Татарстан ягыннан сөйләшүләрдә нигәдер җәмәгать оешмасы вәкилләре дә катнаша»,—дигән. Мин, әлбәттә, бу ташның кем бакчасына ыргытылган икәнлеген яхшы аңладым.

Белмим, кем карары нигезендәдер, анысын миңа әйтүче булмады, тик мине сөйләшүләрдән читләштерделәр. Тишковларның тырышлыгы юкка булмады, күрәсең. Моның ничек булуын да белмәдем. Миңа бер кеше дә бу турыда бер сүз әйтмәде. Югыйсә, үз вакытында нинди дер сәбәп аркасында Лихачевка Мәскәүгә бара алмаячагымны әйткәч, Президент минем янга килеп, аркамнан кочаклап: «Мин синең баруыңны бик үтенәм»,—дип тә әйткәне бар иде. Ә бу юлы—ләм-мим. Үпкәләү юк. Әгәр дә эшләгән эшемнән Татарстанга файда булган икән, миңа шул җиткән.

Бу Шартнамә зур чигенү вә югалтулар нәтиҗәсендә барлыкка килгән булса да, искиткеч зур тарихи әһәмияткә ия. Бу хакта да әле күп әйтелер һәм язылыр. Шартнамәнең имзаланырга тиешле тексты мәгълүм булгач, без—аның бөтен тулылыгын булдырырга тырышып йөргән һәм инде Россия ягын конкрет рәвештә шуңа күндергән кешеләр—аптырашта калдык. Мин Президентны күреп, шулар турында әңгәмә кору нияте белән аның янына киттем. Кызганыч, ул урынында булмады. Шунлыктан, мин Мөхәммәтшин янына килдем. Ул минем һәрбер әйткәнемә риза иде. Чигенү мөмкин, ләкин аның чиге бар. Инде яуланган иң әһәмиятле үрләрдән төшү бернинди кысага да сыймый. Безнең сөйләшүләр нәтиҗәсендә Россиягә нибары 7-8 вәкаләт билгеләнгән булса, имзаланырга хәстәрләнгән текстта боларның саны 23кә җиткән иде. Мин, әлбәттә, моның мөмкин түгел икәнлегенә басым ясадым. Тик минә Фәрит Хәйруллович мине җиргә төшерергә, бүгенге чынбарлыкка аек күз белән карарга өндәде. Россия нефтьүткәргечләре безнең нефтьне кабул итми башлаганнар. Шунлыктан безнең резервуарлар тулган, җир астыннан чыгарыла торган кара алтынга урын юк. Нәтиҗәдә промыселлар эшләрен туктата башлады. Нефть районнарында зур тизлек белән эшсезлек артты. Шунысын да әйтергә кирәк, 1994 елның кышы үтә салкын килде. Әгәр дә безгә килә торган газ торбаларының краннары бикләнсә, без нинди хәлдә калган булыр идек икән? Ә бит безнең электростанцияләребезнең күбесе газга көйләнгән. Минә шушы проблемалар хакында бер сәгатькә якын сүз барды. Әйе, ни эшлисең, көчленеке замана. Тик минә безнең сөйләшү Фәрит Хәйрулловичны шул кадәр кыздырган ки, Минтимер Шәриповичның әйтүенә караганда, алар икесе Мәскәүгә очкан вакытта юл буе бәхәсләшеп барганнар.

## Әйтергә тиешле сүзләремнең кайберләре

Ә МИНЕМ исә Шартнамә һәм тагын кайбер сәяси вакыйгалар хакында әйтәсе сүзләрем әйтелми калды әле. Сабан сөреп йөргән үгезне бимазалап торган чебен-черки кебек, бүген «мин дә сабан сөрдем», диючеләр күп. Ә эш барып чыкмаган булса, төрле рәвештәге кисkenлекләр туса, бөтен җаваплылык Президент өстенә төшсә, бу «черкиләр» ни эшләрләр иде икән?

Ләкин әле алда безне бик зур сынаулар көтә. Кемнең кем икәнлеген күрәселәребез әле алда.

Сәхифәләремнең моңа кадәрге өлеше Ельцин президентлыгы чорында язылган иде. Шунлыктан, шушы урынга кире кайтып, Ельцин һәм Шәймиев мөнәсәбәтләре хакында фикеремне белдерәсем килә. Бу ике кешенең тарих битләрендә үз тамгаларын калдырганлыгы бәхәссез. Шунысы да мәгълүм, мондый шәхесләргә беркайчан да бер төрле генә бәя бирелгәне юк әле. Шулай да күзгә ташланганнарның берсе—Ельцин һәм Шәймиев арасындагы махсус мөнәсәбәт. Аларны алдан күрә белү, көчле сизүчәнлек, янаган куркынычны алдан ук тоеп тору сыйфатлары берләштерә булса кирәк.

Шул ук вакытта бу ике шәхеснең икесе ике төрле. Аларның берсенә сөйләмдә һәм гамәлдә үлчәмлелек хас булса, икенчесенә кискен бәяләмәләр бирү, уйланып бетмәгән гамәлләр кылу хас. Шәймиев, теге яки бу эшне эшләгәнче, җиде кат үлчәр, ә Ельцин исә кисеп атканнан соң гына үлчәмгә ябышыр. Шул вакыт аның үкенгәнлеге һәм самимилеге йөзенә чыгар.

Ельцинның кайбер якыннары аны, Шәймиевтән курка, диләр иде. Бу һич кенә дә дөреслеккә туры килми. Чөнки Ельцин гомумән батыр һәм тәвәккәл кеше. Һәм ул үзенең шушы сыйфатын һәрвакыт күрсәтеп торырга ярата. Шәймиев исә хисләрен тирән яшерә белә торган кеше. Ельцин шапырынырга, мактангаларга яратса, Шәймиевтә бу сыйфат юк диярлек дәрәҗәдә.

Бүген Шәймиев элеккеге СССР җирлегендә иң танылган абруйлы

шәхесләрнең берсе. Аны дөнья җәмәгатьчелеге дә таный. «Татарстан моделе» дигән термин халыкара хокук фәнен һәм практикасын баетты. Европа әһелләре Косово проблемасын тикшергәндә Татарстан—Россия мөнәсәбәтләрен өлге итеп алганнар. Чечня проблемасын хәл итәргә тырышучылар да нәкъ Татарстанны мисал итеп күрсәтәләр. Әлбәттә, бу эшләрнең һәрберсендә дә Минтимер Шәймиев сәләте күренә. 1997 елның ноябрендә Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегацияне кабул иткән вакытта, Белоруссия Президенты Александр Лукашенко да:

—Мин Шәймиевкә ышанам. Ул бирелмәс,—дигән иде.

Моның шулай икәнлеген аның Ельцин белән булган мөнәсәбәтләре раслый.

Ничек кенә булмасын, бу ике шәхес уртак тел тапканнар иде. Һәм ул Татарстан белән Россия файдасына булды.

Инде Ельцин сәяси аренадан китте. Аның урынына яшь, энергияле Владимир Владимирович Путин килде. Ни эшлисең, мәңгелек бер генә нәрсә дә юк. Заманалар үзгәрә. Заманалар белән бергә халык та, кешеләр дә үзгәрә. Ельцин хакимлек иткән чорның айлары, хәтта көннәре дә елларның, хәтта дистәләрчә елларга сыярлык вакыйгаларның шаһиты иде. Чыннан да, кыска гына вакыт эчендә дөньякүләм коммунистик хәрәкәт, кызу кояшка чыгарып куелган боз кебек, эреде, юкка чыкты. Дөнья социалистик системасы да беркайчан да булмагандай таралды. Бөтен дөньяны дер селкетеп килгән «сверхдержава» СССР да, дөньяның шактый өлешен үзенә инандырган КПСС та юкка чыкты. Шул ук вакытта Россиянең демократик үзгәрешләр, аның чын мәгънәсендә федерациягә әверелү юлына басуы шактый күп тискәре нәтиҗәләр дә бирде. Моңарчы уртак саналган социалистик милек бетеп, ил малы гаделсез рәвештә аерым шәхесләр кулына күчте. Халыкның шактые хәерче калды. Өстәвенә җинаятьчелек моңарчы күрелмәгән күләмдә артты. Кешегә карата булган социаль гарантияләр бетте. Аның физик исән-иминлегенә дә ышаныч югалды. Менә бу үзгәрешләр кеше йөрәкләре аша үтеп, аларга шом салды. Бу кадәр тиз барган үзгәрешләр Россияне дә чәлпәрәмә китермәсме икән? Бу кадәр гаделсезлекләргә чик кую кирәк түгелме икән? Миләрне менә шуңа охшаш дистәләгән сорау биләп алды һәм илдә шуңа нигезләнгән империалистик менталитет җанланды. Ул хакимияткә каты кул килүен, аның бөтен вәкаләтләрне үзенә бөтереп алуын таләп итте. Иртәмесоңмы мондый вәзгыять барлыкка килергә тиеш иде. Һәм ул килде дә. Социаль заказ рәвешендә чакырылган шәхеснең Путин булуы мәҗбүри түгел иде. Бу кеше тик тиешле вакытта тиешле урында булып чыкты.

Әйе, менә Россиядә хакимият башына Путин килде. Әлбәттә, бу кешенең илдә каты вертикаль хакимият урнаштырасы килә. Аның эшчәнлегендә республикаларны өлкә һәм крайлар белән тигезләү максаты ярылып ята. Татарстанга карата ике төрле мөнәсәбәт. Беренчедән, аның белән санашмау мөмкин түгел, моны Мәскәүдә яхшы аңлыйлар булса кирәк. Икенчедән, аның реаль махсус статусы күпләрне борчый. Шул статусны бетерү максаты да сукыр күзгә дә күренерлек. Ничек булса да Шәймиевне хакимияттән читләштерәсе иде, диючеләр Мәскәүдә дә, Казанның үзендә дә күбәйделәр.

Минтимер Шәймиевның өченче срокка Татарстан Президенты итеп сайлануы өчен барган көрәшнең нечкәлекләрен тәфсилләп сөйләп тормыйм. Ул үзе мөстәкыйль бер мәкалә язуны сорый торган вакыйга.

Соңгы сүз итеп шуны гына искәртик: 2001 елның 25 мартында булып үткән сайлауларда Татарстан халкының сиксән процентка якыны Минтимер Шәрип улы Шәймиевне яклап тавыш бирде. Шулай итеп, ул өченче срокка—яңадан биш елга Илбашы—Президент итеп сайланды.

Алда—Мәскәү белән яңа көрәш еллары...



**Рафаэль Сибат**

# ХӘТЕР ҺӘМ МӘХӘББӘТ

ЭССЕ

## Гаҗәеп халык без

Дөнья халыклары арасында татарлар иң гаҗәеп милләтләрдән. Шундый бер халык инде без.

Үз телләрен саклаган, гореф-гадәтләрен югалтмаган әлеге милләтнең олуг бер өлеше, 500 еллар буе милли-дини-дәүләти изелүгә карамастан, һаман әле үз дәүләтчелеге турында уйлана-хыяллана гына түгел, ә бу эштә күпмедер практик адымнар да ясап карый, әмма арыймы, тиз хәлдән таямы? (Ә бит дөньяда үз урының өчен көрәш беркемне дә аямый!)—Чын Ирекка һич ирешә алмый, һаман Мәскәү табаны астында җан асрап ятабыз.

Кая киткән татардагы Дини һәм рухи бирешмәү—Берләшү, Чын Көрәшчеләр булу—без бит электән сугышчан халык, Максатчан Үҗәтлек, Тырышлык? Әллә безне ялагайлану, куркаклык, үз-үзеңә йомылганлык, сатылу һәм тарлык басып киткәнме? Чарасызлыктанмы бу?

Олуг мәдәниятле, үз дәүләтчелеге булган, күпсанлы, дөнья мәдәниятына үзеннән шактый ук күренерлек өлеш керткән халык юкка чыкса—Киләчәк моны гафу итмәс!

1552 елда Казан ханлыгының Явыз Иван тарафыннан яулап алынуы—татарлар өчен фаҗигаләрнең дә фаҗигасе...

Шуннан соң, татарлар, газиз җаннарын сыга-сыга, үз генофондыннан иң асыл, иң батыр, иң акыллы, иң талантлы кешеләрен Россиягә хезмәткә бирә башлаганнар.

Менә шушы кереш сүздән соң без фәкыйрегез язмасының төп герое булган шәхескә күчә. Ул шәхес—Мәскәүдә яшәүче татар язучысы (әсәрләрен русча яза) Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәров.

---

Рафаэль СИБАТ *(1946)—прозаик, «Исабәт», «Атлар рәнҗеше», «Ялгызак» романнары, дистәдән артык повесть, эссе, хикәяләр авторы. Киров өлкәсе, Түбән Шөн авылында яши.*

Соңгы бер-ике елда аның шактый повесть-романнарын укыдым, сынлы сәнгать буенча гаҗәеп коллекциясе барын, шөгыль-мавыгуларын һәм биографиясен, бәхетле язмышлы иҗат юлын белдем, өйрәндем дә, исем китеп, вә үзебезнең мокытлыкка шаккатып утырдым.

Мактаныйк әле мондый татар белән! Сак кыланыйк—суккаламыйк, бары сокланыйк... «Сөбханалла!» диик. Кирәк икән—талантына, булганлыгына баш иик...

Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәровка быелның 17 ноябрендә 60 яшь тула. Казакъстанның Актүбә өлкәсе Мартук поселогында туган. Әти-әнисе Оренбург татарлары. Хәер, аның кыскача биографиясе, тормыш юлы «Казан утлары» журналында һәм кайбер газеталарда басылды да инде. Шунлыктан, кабатлап тормыйм.

Аның әдәбиятка килүе бераз сәеррәк, әйтик, нәкъ менә Бальзакча яисә Фенимор Куперча. Алар да бит бәхәскә кереп, роман язып күрсәтәләр. Ә Рауль Мирсәет улы бер кинорежиссер белән бәхәскә керә. Бу вакытта инде аңа 30 яшь булган һәм ул үзенең беренче хикәясен яза. «Полустанок Самсона» («Самсон тукталышы») дип атала ул. Менә шулай Рауль Мирхәйдәров язучы була алачагын, моңа сәләте-таланты барын исбатлый. Ул әле профессиональ язучы булып киткәнче, тагы 10 ел төзелештә эшли. Ә «Самсон тукталышы» хикәясе төрле елларда 30 тапкыр басыла.

«Самсон тукталышы»...

Бу хикәянең исемендә үк ниндидер сер бардыр шикелле. Библия буенча Самсон—борынгы яһүди алып-пәһлеван ул. Аның физик көче искиткеч була һәм бу көч батырның озын чәчләреннән килгән. Филистимнәр киңәшесоравына ризалашып, Самсонның сөйгәне Далила әлеге чәчләрне мәгъшугының йокылы башыннан кисеп ата һәм Самсонны көчсезләндерә.

Белмим, Раульнең дә чәчләре җитмешенче еллар башында озын булганмы, әмма язмыш дигән Далила аны әдәби көч-җегәрсез калдыра алмаган, күрәсең. Бәхетле язмыш та аңа көлеп торгандыр, инде 1975 елны яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсеннән соң, ул катнашкан семинар җитәкчеләре белән безнең Зәки Нури аңа СССР Язучылар союзына керергә рекомендация бирәләр һәм Рауль Мирхәйдәров «Молодая гвардия» нәшриятында беренче китабын бастырып чыгара. Бу нәшриятта барлыгы 7 китабы дөнья күрә.

40 яшендә Рауль Мирхәйдәров төзелештән китә, үзен тулысынча язучылык эшенә—иҗатка багышлый. «Художественная литература», «Советский писатель», «Молодая гвардия» нәшриятларында аның 30 дан артык китабы дөнья күрә. Озакламый аның әсәрләре башка телләргә дә тәрҗемә ителә башлый.

Ул—Комсомол премиясе лауреаты (Ташкент, 1981), СССР Эчке эшләр министрлыгы премиясе лауреаты исемен да ала (1989).

Язучы Рауль Мирхәйдәров тормышында гадәттән тыш хәлләр дә була. 1988 елда ул үзенең «Пешие прогулки» романын яза. Аңа хас булганча, тормышны дөрес, ачык итеп сурәтләү үзенең кара эшен эшли, чөнки совет мафиозилары бу әсәрнең геройларында үзләрен күрәләр, һәм аңа—Язучы Кешегә!—үтерү теләге белән турыдан-туры һөҗүм оештыралар. Ул гомерлек гарип булып кала. Менә әдипнең иҗаты һәм фаҗигасе...

## Мәскәү белән сөйләшүләр

...Рауль Мирхәйдәровның фоторәсемнәрен карап утырам. Ни генә димә, кешеләрнең тышкы кыяфәте шактый нәрсәләр турында сөйли вә ишарәли ала бит...

Менә аның 20 яшьтәге фотосы. Бер сүз белән әйтсәк, чибәр егет: ирләрчә-егетләрчә матур йөз, артка таралган куе кара чәчләр. Сизелер-сизелмәс кенә сагыш сирпеп торган җылы карашлы күзләр, өске ирен өстендә юка-тар гына сызылган мыек, костюм, ап-ак күлмәк һәм күбәләк. Әйе, галстук-бабочка. Көяз егет! Әмма...

Миңа иң нык тәэсир иткәне: сизелер-сизелмәс кенә моң-сагыш сирпеп торган күзләре. «Иртәләгән сагыш» бу...

28 яшьтә Ташкентта төшкән фоторәсемендә дә әлеге сагыш аның күзләрендә күпмедер бар. Ул ачык беленеп тә тормый, әмма һәр татарда бабаларыннан кала килгән эчке сагыш, яшерен моң ята шикелле. Татар баласын башка милләт кешеләреннән күбрәк шул моң-сагыш аерыбрак куя да бугай.

Рауль Мирхәйдәров Мәскәүгә күчеп килгәч, башта Переделкинода—язучыларның иҗат йортында сигез ел буена зур бәя түләп яшәп торган. Квартир сатып алып, пропискага кергәнче шулай.

Инде төс-кыяфәте һәм аннан алган тәэсире турында танылган татар прозаигы Флүс Латыйфига сүз бирик. Менә ни дип яза ул «Казан утлары»нда (1998) басылган «Үзебезнеке» дигән мәкаләсендә:

«1997 елның ноябре иде. Язучыларның Переделкинодагы иҗат йорты. Ул елның иртә яуган кары бөтен дөньяны ап-ак юрганга төргән, әнә шул аклык күңелләрдә әллә нинди бер сафлык, пакьлек хисе уяткан көн иде ул. Көтмәгәндә иртәнге якта кемдер тыйнак кына ишек шакыды. Җыештыручылар китеп беткән, коридорда инде тынлык урнашкан бер мәл иде. «Монда танышбелешләрем юк, кем булыр икән?»—дип гаҗәпләнеп куйдым.

Ишектән озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, спортчыларча нык-таза күренүче, шәрекъ кешеләренә тартымрак йөзле бер кеше килеп кергәч, тагын бер кат аптырашта калдым. Уңайсыз тынлыкны кунагым үзе бүлде:

—Сез Казаннанмы? Сез язучы Флүс Латыйфи буласызмы?—диде ул дустанә елмаеп.

—Әйе,—дидем мин тагын бер кат сәерсенеп.

—Мин Рауль Мирхәйдәров булам, танышыйк,—дип кулын сузды кунагым.—Мин шулай иҗат йорты конторына кереп, Казаннан кемнәр килгәнен белешеп торам. Аралашасы, танышасы килә бит...

... Ул хәзерге көндә Русиядә иң күп басылучы һәм иң күп укылучы танылган әдипләрнең берсе... Татар әдибе, ул—үзебезнеке!»

Тагын бер фотосурәткә күз салыйк әле.

1999 ел... Мартукта аның исемендәге урам. Рауль Мирхәйдәров үз исемфамилиясе язылган стелла янында басып тора. Арттарак мәчет күренә. Рауль бу мәчетне төзетүдә нык кына булышлык вә матди ярдәм күрсәткән.

Янсә менә 2000 елның 2 декабрендә, ягъни мәсәлән, гасыр ахырында төшкән рәсемнәре. Аларның берсенә: «60 яшемә атлаган елым; декабрь, 2000. Мәскәү» дип язып куелган. Бу рәсемнәрдә мин 30 еллык иҗат тормышында 30 дан артык китап чыгарган, күп әсәрләре йотылып укыла торган олпат, үзүзенә ышанган, зур тәҗрибәле, дөньяның ачысын-төчесен татыган нечкә күңелле, нахак сүзгә рәнҗүчән, яшьтән үк Йөрәк Хәтерендә татарча моңсагыш йөрткән олуг бер шәхесне күрәм. Күзлек кию аңа җитдилек белән иплелек, ниндидер бер авырлык вә сабырлык та өстәгән. Шулай...

Үткән тормыш еллары һәм юллары, ачы тәҗрибә җиңелешләре вә җимешләре, төрле кавем-милләт кешеләре белән озак кына аралашып яшәү, югалтулар ачысы һәм сагышы аңа күптән инде тормыш кануннары турында үз уй-фикерләрен булдырырга, фәлсәфи гомумиләштерүләргә килергә мөмкинлек биргән. Һәм моның белән мин аны Бәхетле Зат дип саныйм.

Телефон чылтырады...

Мәскәү. Рауль Мирхәйдәров...

Без аның белән шактый озак сөйләштек. Беренче тәэсирләр: йомшак, бәрхет-иплe тавыш. Беренче сөйләшүдә үк тойдым-сиздем: ул—күпмедер дәрәҗәдә трагик шәхес, фаҗига иясе. Ә трагик иҗатчылардан күп вакытта бөекләр чыга.

2 декабрь, 2000 ел...

Мәскәү. Телефон. Рауль Мирхәйдәров.

Сөйләшү барышында ул:

—Беләсеңме, Рафаэль,—ди,—минем турыда күп кенә язып чыктылар. Ләкин мин укучылар өчен генә түгел, хәтта әдәбиятны тирәннән аңлаган тәнкыйтьчеләр өчен дә бары тик детектив язучы гына булып кала бирәм.

«Изобличитель, разоблачитель мафии», имеш. Ә бит ул романнарда, нинди генә формада булмасын, иң беренче, тормыш үзе. Мин хәтта «Пешие прогулки»ны да саф детектив санамыйм. Анда реаль тормыш.

—Кушылам,—дидем.—Сезнең «Игълан буенча танышу» повестен «Казан утлары»нда укыган идем. Менә хәзер—«Иртәләгән сагыш» романыгыз. Ул әсәрләрдә детективлыкның «д»сы да юк. Гомумән, язучыны бер жанр рамкасы эченә генә тыгып кую—үзе ук ниндидер бер мәгънәсез тарлык, җавапсызлык. Әдәби әсәрне барлык чагылышлары белән тирән аңлыйм дисәң: «Башта үзең өчен укы, аннан соң башкалар өчен!»

10 декабрьдәге сөйләшү вакытында сүз татарлык, үз милләтең кешесе булуга килеп терәлде.

—Безнең кебек, Татарстаннан читтә туып-үскән, урыс мәктәбендә белем-тәрбия алган кешеләрдә «татарлык»ны югалтмый торган ике төп нәрсә бар,—диде ул.—Беренчесе—татар җырын, татар моңын җанында саклау, икенчесе—милли горурлык.

## Казанга хатлар

Читтәге—алтын читлектә кебек күренә...

Дөресен генә әйтик, тышкы кыяфәт, матур сөйләшү, чибәр киенү, көяз булу, белемле күренергә тырышу—әле бу кешенең Чын Йөзе түгел, иң-иң мөһиме: Рухы-Җаны дигән сүз түгел. Юк, түгел!

Ачык-гадел, намус-иманлы, денле-миһербанлы инсаннарның чын күңелен, җылы җанын аларның хатлары аша анык чамаларга, шактый ук ачык сиземләргә-тоярга була.

Рауль Мирхәйдәров хатлары...

«Русча язучы татарлар турында да үз сүземне әйтим инде. Рус әдәбиятында рус язучысы булып формалашкан татарлар һәм, рус телендә яза да, татар булып калучылар бар. Болар арасында аерма зур. Мин үзем иҗатымның беренче елларында ук Казанга тартылдым.

Әдәбият һәрчак көрәш булган, бездән соң да бу көрәш барачак, шуңа мин синең язмаңа үз фикерләремне дә кертмәкче булам.

Язучы турында язганда икеләнү начар иптәш, мактыйсың икән—шикләнмә, тәнкыйтьләсәң дә—үзеңә нык ышан!

Тагын бер нәрсә искә төшерәм: болар—минем гамь-борчуларым, җан сызлануларым. Татарстанда барлык татарларның өчтән бере тирәсе яши һәм (Аллага шөкер!) алар татарларның өчтән икесе кебек куылуда, таралуда, качуда, эмиграциядә түгел һәм 99,9% язучылар шул Татарстанда яшәп, әлеге өчтән бер өлеш татарлар турында гына яза. Ә татарларның өчтән икесе турында кем язарга тиеш соң? Рус телендә язучы берничә татар гынамы?

Ләкин аларның язганнарын Татарстанда бөтенләй басмыйлар диярлек, яисә бик-бик аз басылып чыгалар. Татар телендә китаплары юк. Дөрес аңлыйк, сүз монда минем турыда гына бармый, мин инде язасымны яздым, бастырасы әсәрләремне бастырдым. Кирәк икән,—үз акчама!—язганнарымны татарчалаштырып нәшер дә иттерә алам. Ә русча язучы татар коллегаларым нишләргә тиешләр?

Менә шундый эшләр... Ләкин хәзер мине татар әдәбияты арбасыннан алып ата алмаслар инде—китапларым бар һәм татар укучыларым бар...

Беренче тапкыр татар теленә мине 1977 елда Башкортстанда тәрҗемә иттеләр. Моны Мостай Кәрим үтенече белән Айдар Хәлим эшләгән иде. Соңыннан Уфада «Безне онытмагыз» повестемне татарчалаштырдылар. Рәхмәт аларга! «Иртәләгән сагыш» романымда Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» әсәренең тәэсире дә бар...»

* * *

Хатлар—кешенең ишексез, бикләнмәгән җаны, чын-чын ихласлыгы. Монда матур сүз язар өчен генә сүз уйнатып утыру юк. Бу—йөрәгендә кайнаганы, җанын кыйнаганы, күңелне айкаганы һәм—Рухны тоймаганы

өчен кемнәргәдер туган үпкә-рәнҗешләр, намуссызлар эшләгән кара эшләр, моң-сагышлар, үзеңнекеләрнең кагыш ачылары. Әмма, иң мөһиме, аларда каргыш юк! Шуңа алар якты, иркен һәм күңелне ачыклык-ихласлык, якынлык-туганлык белән сугара торган булалар.

... Рауль Мирхәйдәров хатлары да шундыйлар...

## Гаҗәеп шәхес

Рауль Мирхәйдәровның шәхесен азмы-күпме ачу өчен тагы бер ягына тукталып китүне бик мәгъкуль саныйм.

Без аның яшь чагында шәп кенә боксер булуын—Актүбә чемпионы!—һәм футбол яратуын, хәтта җирле «Локомотив командасында уйнавын да беләбез. Бу турыда «Иртәләгән сагыш» романында да язылa.



Рауль яшьтән музыканы яраткан, үзбәкнең атаклы җырчысы Батыр Закировның «Гарәп тангосы»н башкаруына мөкиббән киткән.

Ә балетны яратуын ничек аңлатырга? Поселокта туган, гади генә гаиләдә тәрбияләнгән егетнең балетка таң калуы әллә музыка яратуыннан килгәнме? Ни генә димә, балет музыкасы иң бөек аһәң-көйләргә нигезләнгән. Әллә аның сизгер күңеле Дөнья Сәхнәсенә Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдов кебек балет даһилары киләсен алдан ук сизгәнме? Болар—үзебезнекеләр, безнең татар уллары, халкыбызның бөек вәкилләре ич! Дөньяның Балет Сәхнәсенә иң якты йолдызлар булып менгән, үзләрен үзләре Күккә чөйгән мәшһүрләр.

Һәрхәлдә, аның балет яратуы матурлыкны күрә белүе, матурлыкны тану таланты булуы турында сөйли. Бик сирәк кешеләргә генә бирелә торган сәләт бу. Матурлык вә яхшылыктан Олуг әдәбиятка чирек адым гына, чөнки сүз сәнгатенең мактап җырлаганы да матурлык һәм яхшылык!

Ә менә Раульнең сынлы сәнгатькә булган гыйшкын ничек аңларга? Ул бит егерме яшендә үк беренче картинасын сатып ала. Нәрсә бу? Әлеге дә баягы матурлыкка омтылуымы, Гармония-Камиллеккә ирешергә теләвеме? Каян килгән бу аңа? Ул бит Санкт-Петербург Эрмитажын күреп үсмәгән яисә Мәскәү сынлы сәнгать галереяләрендә булмаган. Бәлки, аның үзе өчен бер Эрмитаж булдырасы килгәндер, француз сүзе «ermitage» русча «место уединения» дигәнне аңлата. Татарча «Ялгызлык Урыны» була инде, төгәл тәрҗемә түгел, әлбәттә. Әмма миңа шулайрак ошый, чөнки язучының, минемчә, һәрберсенең «Ялгызлык Урыны» булырга тиеш, шунсыз чын әсәр тумаска мөмкин. Ә Рауль Мирхәйдәров—иң тәүдә, Язучы Зат, чын талант иясе.

Бу яктан караганда, Рауль Мирхәйдәровның гаҗәеп бер үзенчәлеге дә бар, ул—Россиянең иң атаклы коллекционерларыннан.

Танылган сәнгать белгече Ирина Таратута болай яза:

«Рауль Мирхәйдәров—Россиянең танылган язучысы, утыздан артык китап авторы. Мафия турындагы бестселлерлары аңа киң популярлык китерде. Болар: «Пешие прогулки»,«Двойник китайского императора», «Масть пиковая», «Судить буду я» китаплары. (Боларның исемнәрен, әлегә татарчага тәрҗемә ителмәгәнлектән, русча бирергә мәҗбүрмен. Р. С.) һәм «Иртәләгән сагыш» ретро-романы. Язучы бик күптәннән сынлы сәнгать белән мавыгып яши.

Рауль Мирхәйдәров һәм аның хатыны Ирина Варламова җыйган картиналарның нигезен бүгенге рәссамнарның картиналары тәшкил итә, болар—абстракция, авангард, импрессионизмнан башлап наивлык һәм традицион рус сынлы сәнгате алымнарында иҗат итүчеләр.

Рауль Мирхәйдәровның коллекциясе картиналарының саны буенча да, рәссамнарның күплеге һәм төрлелеге ягыннан да кайбер музейлар һәм танылган рәсем галереяләре белән конкуренциягә керә алалар».

Бармы бездә тагы андый татар? Бар иде, ул инде вафат. Бөек Биюче һәм шәхси коллекцияләр иясе Рудольф Нуриев иде ул.

Рауль Мирхәйдәров дигән русча язучы татар әдибен милләттәшләребез аз белә яисә бөтенләй белми диярлек, ә ул бит Россиядә иң күп укыла торган язучы, китаплары 5 миллион (!) тираж белән чыккан. Безнең өчен ачылмаган Әдәби Америка ул. Колумблар кирәк, Колумблар! Үзебезнекеләрне Үзебезгә Кайтарырга Вакыт!

Безнең татарда тигезләү принцибы, миннән узмасыннар, дигән көнчелек хисе бар. Тарлык-таркаулык әнә шуннан килә инде ул. Рауль Мирхәйдәровка Ташкенттагы үзбәк мафиясе һөҗүм ясаганнан соң, язучыга бер көн дә тыныч яшәргә ирек бирмиләр, гел янап торалар: әле машинасын куып алып китәләр, әле җыелып ятучы китапларын туздырып чыгалар... Инде башкача түзәр хәле калмагач, ул Ташкенттан кузгалып, Мәскәүгә күчеп китә. Әтисе Мирсәет, 1941 елның декабрь аенда Волокламск тирәсендә Панфилов дивизиясе солдаты буларак, Мәскәү өчен барган сугышларда башын сала. Ул улы туганын хат аша гына белеп кала...

Бала туган, ата башын салган...

Гүя шушы тирәләрдә күмелеп, улының яшәве өчен урын сайлаган. Нәрсә дигән әле күренекле француз язучысы Луи Арагон:

—Мин үлгән җирдә Ватаным яңарып туа...

Минем җаныма-күңелемә, «яңа байлар» кебек каударланмый-ашыкмый гына, бәрелми-сугылмый гына Рауль Мирхәйдәров килеп керде. Башта бер повесте һәм бер романы белән. Аннан соң—мин белгән кадәр бөтен булганы белән...

Мәкаләмне язган вакытта минем колакка кемдер гел дә өч исемне пышылдап торды шикелле: Роальд... Рудольф... Рауль... Башта мин моңа артык әһәмият тә бирмәдем, әмма, эштән тукталып, бераз ял иткәндә, бу исемнәр тулысынча аталып күңелемне айкап үттеләр:

—Роальд Сәгъдиев... Рудольф Нуриев... Рауль Мирхәйдәров... Халкыбызның мәшһүр уллары: фикерләвен космос тирәнлекләренә юнәлткән галим, балет-бию сәнгатендә «оча торган татар», русча язып та, татарча яңгырый алган танылган һәм бик популяр язучы.

Башта бер факт: «Иртәләгән сагыш» романы «Казан утлары»нда басылып чыгуга, шагыйрә Иделбикә (Лена Садыйкова) Ульяновскидан баш мөхәррир Равил Фәйзуллинга хат җибәрә:

«P. S. «Иртәләгән сагыш» әсәренең русча язылган булуын сизмисең дә диярлек». Шул ук вакытта монда таякның икенче очын да тотып карарга кирәк: автор романын русча язса да, ул аңа ниндидер бер татар рухын сала алган. Каян килә бу? Ни генә димә, ул бит Мартуктагы татар бистәсендәге татар гаиләсендә тәрбияләнеп үскән. Сигез яшькә кадәр ул бер кәлимә рус сүзе дә белмәгән. Менә аның биографиясеннән бер факт:

1949 елны укытучы Зоя Григорьевна Волянская үз классына җыйган 36 бала арасына бер сүз урысча белмәгән 9 татар һәм казакъ балаларын да ала. Шулар арасында Рауль Мирхәйдәров та була.

Шул мәктәптә рус телен үзләштерә дә инде ул. Үсә төшкәч, Раульнең иң беренче укыган китапларыннан берсе Лев Толстойның «Воскресенье» романы булган. Дөрес, ул вакытта ул аны «Яңадан туу» дип түгел, ә атнаның соңгы ял көне—«якшәмбе» дип кенә аңлаган.

Әмма вә әмма... Китап укый башлау нинди бөек исем белән бәйле ич! Соңыннан ул Иван Бунин белән Валентин Катаевны бик ярата. Тагы бер кызык хәл,—аның иң беренче укыган чит ил язучылары: америкалы Фрэнсис Скотт Фицджеральд һәм япон әдибе Дзюмпей Гомикава. Тагы Герман Гессе, Томас Вулф, Ремарк...

## Без кайдан?..

Хәтәр заман: гасырлар буена җыелган ил-халык байлыгы, янгын чыккан йорттагы кебек, таратылып-туздырылып ташланды.

Сәер еллар: башлары ялганнан чыкмаган кешеләр дөреслек эзләп йөриләр яисә дөрес кешеләр дә ялган көриләр.

Без кайдан?!

Мин кайдан?—дигән атаклы француз язучысы һәм очучысы Антуан де Сент-Экзюпери һәм үзе ук җавап биргән:

—Балачактан!

—Без барыбыз да—балачактан... Әмма нинди балачактан? Берәү әйтер: «Ипиле-иple балачактан...», икенчесе: «Ач-ялангач балачактан»,—дияр, ә Мартуктагы татар бистәсе малае Рауль Мирхәйдәров:

—Кинолы балачактан!—дип әйтергә, әйе, әйтергә мөмкин, чөнки ул малай чакта ук кино карап үскән, сәнгатьнең бу төренә мөкиббән булып яшәгән...

Таптым мин Раульнең бокска, көрәшкә, футболга, гомумән, спортка һәм балетка, театрга, музыкага, сынлы сәнгатькә булган Мәхәббәт Ачкычын. Әнә шул Ачкыч белән Кино дигән ишекне ачып, ул спортка вә сәнгатькә килгән.

Мартуктагы тормыш шундый да бертөрле, вакыт-вакыт күңелсез, эчпошыргыч булган ки, ярый әле кинофильмнар малайны бөтенләй икенче тормышка, шаккаттыргыч хәлләргә, эмоция-хис диңгезенә алып килгәннәр, кирәк икән: хыялда гына булса да, күкләргә алып менгәннәр.

Әнә шулай «кинолы балачактан» ул малай! Зиһенле, кызыксынучан, хыялый...

Хыяллар, хыяллар!

Алар инде хәзер Мартукка гына сыймыйлар. Һәм беркөнне Рауль дигән малай 112 укучы арасыннан берүзе өлкә башкаласы Актүбәгә юл тота. Мәскәү-Ташкент поездының бер вагоны түбәсенә утырып...

Актүбә! Ә анда...

Ә анда 14 яшьлек яшүсмер өчен, Тукаебыз әйтмешли:

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;

Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

Никадәр төгәл тоемлы, анык сиземле ул даһи Тукай! Ул әйткәннәрнең барысы да Рауль Мирхәйдәровны Казанда түгел, Актүбәдә көткән икән. Моның шулай икәне «Иртәләгән сагыш» романында ярылып ята.

Актүбәдә ул вакытта мединститут, культпросветучилище, кооператив һәм тимерюлчылар техникумнары яшьләрдән, студент-шәкертләрдән гөрләп торган. Икенче һәм унберенче мәктәпләрдә үзешчән сәнгать түгәрәкләре бик шәп эшләгән, тимерюлчыларның 44 нче, 45 нче мәктәпләре дә кимен куймаган. Завод клублары, җәйге бакча-паркларда кичләрен барган бию-танцылар! Ул вакытта бит танцыларда джаз-оркестрлар уйнаган.

... Ташкентка килгәч тә Рауль спорт, сәнгать, әдәбияттан аерылмый. Шушы фанатлыкны күргән җитәкчеләр аны хәтта Фирганәнең «Нефтяник» командасына икенче тренер итеп тә чакыралар, ә менә соңрак аның «За все—наличными» дигән романы басылып чыккач, күп кенә газета һәм журнал редколлегия әһелләре, рәсми кешеләр Казан рәссамы Николай Иванович Фешин турында язуын сорыйлар, чөнки Рауль Мирхәйдәровны сәнгать белгече итеп тә кабул итәләр:

—Югары зәвыклы эстет!

Шул Ташкент елларында ук ул каләм чарлап та карый. Юк, әдәби әсәрләр язып түгел әле, ә башкала газеталарының берсендә спорт колонкасы алып барып, атаклы футболчылар Месхи, Метревели, үзбәк «Пахтакоры»ның мәшһүр Абдураимовы белән дус булып йөр дә—футбол турында язма, имеш! Шундый ук кыска-кыска гына мәкаләләр Ташкентта узган төрле концертлар, спектакльләр, симфоник оркестр чыгышлары һәм Мәскәү балеты артистлары биюләрен күргәч тә, язылып торыла.

Рауль Мирхәйдәровның «Пешие прогулки» романы кабат-кабат басылулары белән бездә рекорд булып торадыр. Әйтергә генә ансат: бу романын инде егерменче тапкыр басарга әзерләнәләр!

## «Игълан аша танышу»

Рус телендә булса да, татар повесте, дияр идем мин аны. Чөнки ул Рауль Мирхәйдәровның иң татар рухлы әсәрләреннән берсе. Кыска гына үзе, әмма эмоциональ вә эстетик тәэсире ягыннан зур сыйдырышлы. Бу повесть—нечкә хисләргә, әдәплелек-иплелеккә корылган шигъри әсәр. Башында ук ниндидер эчке бер кискенлек белән рәхәт йомшаклык рәттән атлый.

Район үзәге Хлебодаровка... Исеме үк бик матур бу дала поселогының.

Әкрам Галиевич...

Пенсия яшенә аяк баскан нотариус. Почтальон Дарья Сташова аңа телеграмма тапшыра. «Протест нотасы сыманрак итеп тапшыруы хак». Берничә җөмлә, кызыклы гына башлам: Әкрам Галиевич тә, Дарья Сташова да күз алдына килеп баса. Картаеп килүче ир заты һәм күп балалы хатын. Әлеге хатын казна йортына кушып салынган фатирда яшәп ята. Ә менә телеграмманы «протест нотасы кебек тапшыруы» белән ул ачыла да китә. Әле бит «нәфрәтләнеп»... Әйе, нәфрәтләнеп тапшыра ул телеграмманы. Ә анда ни язылган соң? Менә бу сүзләр:

«Газизем Әкрам Галиевич, Сезне Көньяк Сахалиннан Наталья Сергеевна Болдырева бимазалый. Һич уйламаганда газетада басылган игъланыгызга күзем төште. Миңа калса, без бер-беребезгә тиң булырбыз. Көтмәгәндә ял бирделәр—самолетта очам. Якшәмбе көнне төштән соң сездә булырмын. Күрешкәнчегә хәтле.

Наташа».

Бу телеграмма Дарья Сташовада эчке бер көнчелек тудырса, сугышта да булган Әкрам Галиевичны аптырашта ук калдыра. «Өч тәңкәгә төшкән» әлеге «саллы гына телеграмма» укучыда да зур кызыксыну уята:—«Ә кем ул Наталья Сергеевна Болдырева?» Менә шуннан соң кызыклы бер күренеш башлана—көтү процессы. Әкрам абзый да һәм китап укучы да!—Наташаны көтә:—«Кем ул? Нинди ул?»

Мавыктыргыч башламмы? Һичшиксез, мавыктыргыч!

Әлеге серле хатынның «исеме һәм атасының исеме ошый» Әкрам Галиевич Сабировка. Әнә телеграмманы да ничек башлаган ич:

«Газизем Әкрам Галиевич!»

Әкрам абзый... Беркатлы, чиста рухлы, бераз оялчан, тыйнак, сабыр, ипле Оренбург татары. «Хәләл җефетен җирләвенә ел да тулмаган әле, ай ярым диярлек вакыт калган» көннәрдә автостанция янәшәсендәге базарга сугыла.

Сатучы хатын аңа алмаларны һаман саен «Вечерняя Алма-Ата» газетына төреп бирә икән. Анда нотариус шаккатырлык игъланнар урнаштырылган була. Мәсәлән, менә мондые: «Мин тол хатын. Илле яшьләр тирәсендә, таза бәдәнле, кара чәчле. Ике балам да күптән урнашты, аерым яшиләр. Кырымда йортым, бакчам бар. Эшчән, хуҗалыкчыл, бакча эшләрен һәм чәчәк үстерә белүче ир-атны кабул итәргә теләр идем. Ир-атның таза-сау һәм озын буйлы булуы мәслихәт». Яисә: «Мин 45 яшьтән узмаган, эшчән, мал-туар (сыер, дуңгыз), кош-корт (күркә, каз) асрый белүче таза-сау хатын эзлим» дигән кебеге...

Элегрәк мондый игъланнарны «Крокодил» журналында да укыган икән Әкрам Галиевич. Үзе шул рәвешчә бәхет сынап карарга була. Ләкин... Бу игъланны-белдерүне язу авыр нәрсә икән. Әйтик, хәтта текстын төзү дә...

«Их! Үзем һәм бу йортка үз итеп килергә теләүчем хакында да шигырь белән генә язып бирсәң икән»,—дип хыялланып та ала нотариус. Рифмага салганда эш пешмәде, ниндидер «нотариус—пенсиус» кебек мәгънәсез юллардан ерак китә алмады, бүтәненә башы да, рифмасы да җитмәде, кырыс проза белән генә язарга калды». Һәм.... Әкрам абзый туксан җиде вариантта

язып, туксан сигезенчесен «Вечерняя Алма-Ата» газетына җибәрә. Ул үзе язган игълан текстын шәп санамый, чөнки «булмагач, булмый икән инде»... «Кыш уртасында чәчәкләр үсмәгәч, аларны кызгануың да мәгънәсезлек». Сергей Есенин шигырен дә шулай искә төшереп карый ул. Ләкин бит монда иң мөһиме белдерүдә язылачак сүзләрдә түгел, ә чиста-саф күңелнең олыгаеп барганда үз парын эзләвендә.

Ялгызлык хисе—гаҗәп бер хәл-халәтеңнең чагылышы ул. Бу хис капма-каршылыклар белән тулган. Һәркем, бер яктан караганда, күпмедер ирек-иркенлеккә, ялгызлыкка омтыла. Икенче яктан карасаң, кеше дигәнең һәрвакыт ялгызлыктан куркып яши, артык ирек-иркенлек кирәк түгел дип саный, гади генә әйткәндә, аның кемгәдер яисә нәрсәгәдер бәйле буласы килә. Бәйле булу хисе... Бу хис алга таба үзеңә бурычлар куярга мәҗбүр итә, кешене әхлакый-этик кагыйдәләрдән чыгармый тота ала. Ирек һәм Бәйлелекнең уртасын таба белү зур мәсьәлә, ул ир-хатын, гомумән, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә бик зур роль уйный.

Ә теге шигырь була алмаган игълан-белдерүендәниләр язган соң Әкрам абзый?

«Аның игъланы хәйләкәр, бу эштә остарып беткән коллегасы Загорулько редакцияләгәннән соң түбәндәгечә басылып та чыкты:

«Пенсиягә чыгу алдында торган юрист шәһәрдәге тормышы белән шапырынмаучы берәр ханымны Оренбургның тыйнак бер район үзәгенә чакырыр иде. Көчем, сәламәтлегем, тел-теш тидермәслек абруем, җәмгыятьтә тоткан урыным һәм матди хәлем гаилә корып яшәргә мөмкинлек бирә. Йорт-курам, җайга салынган хуҗалыгым картлык көнеңне мәшәкатьсез генә уздырырга, үзеңне чын хуҗабикә итеп тоярга, тормыштан уңдым дип әйтә алуыгызга инандырыр».

Бу белдерү хаты өчен аның кәефе дә бозыла, «кирәкмәс ният, мәгънәсез эш», дип тә битәрли ул үзен. Ник? «Алдаша белмәгән намуслы Әкрам абзый» бит ул! Әйтик белемен юрист дигән, ул бит университет белеменә ия түгел! Аның юридик факультеты—сугыш булган... Ул сугыштан, ике орден белән бүләкләнеп, офицер булып кайткан, моның белән шапырынып кына йөрми. Игъланындагы «йорт-курам, хуҗалыгым...» дигән сүзләре өчен дә уңайсызлана ул.

Озакламый Әкрам абзыйга ике хат килеп төшә. Берсе Куйбышевтагы укытучыдан, икенчесе Белла—Белочкадан «сөю хаты»:

... «Тәмләп-тәмләп, дәртләнеп-дәртләнеп үбәм һәм кысып-кысып кочаклыйм. Көтәм, сөям. Сөеклем минем, көтә-көтә зарыгып беткән җанкаең янына ашыга күр, озак зарыктырма инде аны».

Менә нинди трагикомедиягә, еласаң-еларлык, уйласаң-уйларлык, көлсәң-көләрлек, елмайсаң-елмаерлык хәлгә тара Әкрам Галиевич.

Наталья Сергеевнаның кайтуына мунча ягып куйсам, дөрес аңлармы дип, шиккә төшеп йөргән ир шундый «дәртле хат» алсын әле! Ә бу «Белочка» хатын уку аңа рәхәт... Әле шундый хатлар тагын килеп тора...

«Артистка» кебек чибәр Нәзифә Әгъләмова Ташкенттан ук язган. Ул Оренбург якларындагы Хлебодаровкада яшәүче Әкрам Галиевич белән тормыш корып җибәрергә риза. Хат тыйнак-тыенкы хисләр белән язылган. Әнә бит: Әкрам абзыйның игъланы басылган газетны да аңа «каралырга кергән сырхау хатын» онытып калдырган икән. «Димәк, таибә»,—дип уйлый Нәзифә турында Сабиров. Ә «Белочка» икенче хатын язган инде: «Янә шул кәгазь, шул ук хушбуй исе, тагын да күркәмрәк һәм дәртлерәк сүзләр».

Инде ул көткәнрәк Наталья Сергеевна да килеп җитә. Әлеге ханым сихерчедәй, әфсен укыгандагыдай итеп кенә верандага мәҗлес өстәле әзерли: «кызыл һәм кара икра, алтындай лимон телемнәре белән бизәлгән тәмле семга балыгы, осетр ите...» Ә өстәл уртасындагы икебана букеты, «Двин», «Дойна» коньяклары! Бу өстәл үзе ук шигырь сорап тора! Әкрам Галиевич үзе дә—Күкләрдә...

Наташа да чая күренә, иңбашыннан кочаклап:

—Йә, Әкрам Галиевич, хатынлыкка аласызмы мине?—дип әйтеп сала.

Ә ул? «Аның күңеле йомшарды, күзләре чыланды, хатынның кулларын үбә-үбә, әкрен генә тын алды:

—Алам, Наталья Сергеевна...»

Әкрам Галиевичның эшләр хутта: Гаджибәковның «Аршин мал алан»ыннан «Рәхмәт инде Сөләйманга»... ариясен җырлап кына йөри. Наталья Сергеевна белән мунча кереп кайткач, күршесе Жолдас аганың: «Бездә, мөселманнарда, туганый апаң белән мунча керү гадәте юк... Үзеңне әдәплерәк тотарга кирәк—француз түгелсең һәм Парижда да яшәмисең!»—дип әрләвенә дә исе китми. Әле бит башка хатыннардан да хатлар килә тора...

Һәм менә...

Чираттагы эштән кайтуына Наталья Сергеевна китеп барган, ә өстәл өстендә хат ята:

... «Тыныч, салмак тормыш минем өчен түгел, күрәсең. Гафу итегез. Үбәм. Наталья Сергеевна».

«Киттең дә мени? Нигә? Ни өчен?»—Әкрам Галиевич шушы сорау-уйларда.

Ә хатлар килә тора. Ленинградтан. Кырымнан...

Әнә «Белочка»дан ничәнче хат инде?!

Наташа китеп барды, әмма хатынлы тормышка өмет-ышаныч уятып югалды. Сабировның күңеле хәзер Ташкент ягында—артистка кебек чибәр Нәзифә Әгъләмовада. Көтә аны һәм очрашалар, ә Нәзифәнең эштие суынган икән инде, кайчандыр чибәр хатыннан әлләни калмаган, вакыт барысын да сыдырып алган һәм ашаган, шуның өстенә үзеннән «Белочка»ның таныш хушбуй исе аңкый. Әкрам эчкәләп кайта башлый һәм нәзакатьле кыланган Нәзифә аннан качып китә.

Кара сана, үзләренең почта бүлеге мөдире Мәрьям дә Нәзифәдән бер дә ким түгел икән лә!

Хәзер Әкрам күңелендә—Мәрьям. Бары Мәрьям генә...

Әсәр тәмам. Бераз моңлы, бераз сагышлы. Татар моң-сагышы бу. Кызыклы повесть, өлкән яшьтәге татар кешесенең соңгы мәхәббәт маҗаралары бу. Сюжет үрелеше матур, укучының кызыксынуын гел көчәйтеп тора. Башка милләт кешеләре арасында (рус, белорус, украин, казакъ) Әкрам Сабиров үзенең татарлыгы белән аерылып тора. Анда саф-чын татар холкы: тырыш, уңган, тыйнак, әдәпле, чиста, пөхтә, ипле һәм үҗәт. Хатыннарның шәл бәйләвенә, ризык әзерләвенә дә ул татар буларак бәя бирә. Әсәрдә—татар рухы! Шуның белән ул безнең өчен кыйммәт вә кадерле дә!

## «Иртәләгән сагыш...»

Дөньяда иң хәтәре—Йөрәк Хәтере булмау...

Йөрәк хәтерең юк икән, син инде маңкорт. Атасын-анасын, әбисен-бабасын оныткан чикылдап торган маңкорт.

Рауль Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш» романы, иң беренче, үткәннәрне күзаллау, шактый еллар узгач, балачагыңа һәм яшьлегеңә мөрәҗәгать итү, еракта калган вакыйгаларга, эш-гамәлләргә анализ ясау, теге якта калган елларга бәя бирү. Мондый әсәрләрне ретро-роман диләр, чөнки алар ретроспектив планда язылган булалар.

Бу әсәргә язган сүз башында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин болай ди:

«Тагын бер мөһим нәрсә, ул—төгәл сурәтләү. Язучы кайдадыр кайчандыр үзе күргән кирәк детальләрне фотографик төгәллек белән кабатлап күз алдына китереп бастыра ала. Мәсәлән, «Пешие прогулки» романында Кырымдагы Куктүбә тирәсен тасвирлаган урыннар бар. Заманында мин үзем дә шул җирләрне күп таптадым. Хәзер дә әзме-күпме хәтердә. Ә менә Раульнең әсәрен укыгач, мин анда әле кичә генә барып күреп кайткандай хис иттем. Кирәк һәм иң характерлы штрихлар шул кадәр осталык белән тотып алынган. Афәрин, молодец!—дияргә генә кала».

«Иртәләгән сагыш»—күп сюжет линиясенә ия полифоник әсәр. Әмма анда ике нәрсә бик көчле сизелә. Болар Хәтер һәм Мәхәббәт. Бу романны үзем төрле төсләрдә күрәм вә әллә нинди аһәң-авазлар, моң сулышлары, сагыш агышлары аша ишетәм. Тормышның үзе кебек үк чуарлык, күп

төслелелек, салават күпере ул. Мин аны вакыт-вакыт роман-калейдоскоп, роман-витраж, роман-коллаж дип тә атыйм.

Әсәрдәге кайбер вакыйга-эпизодлар тетрәндерә. Менә бер коточкыч күренеш: кырыс-ачы, ач-ялангач хәерче тормыш. Землянка, аның эчендә суыкның да суыгы, стеналарда бәс-сыкы. Рушан Дасаевның әнисе Гөлсем, апасы Сания һәм кечкенә малай үзе. Сания инде мәктәпкә йөри, дәрестән әле генә кайтып кергән. Диварларга тешен ыржайтып салкын эленгән...

... Хәтерем еракларга китә. Үткән елларга... Үземнең балачагыма...

Кышкы кич. Кышын без өйнең алгы ягында тормыйбыз, арткы кухня ягында гына тормыш итәбез. Өй эчендә өчле лампа яна, тәрәзәләр кар-бозга каткан. Менә мәктәптән Мөнҗия апа кайтып керә. Ул каткач, озакламас әти-әни дә эштән кайтыр, өй эчендә рәхәт вә талгын, матавыксыз мамыклы җылы иңәр.

Әсәрдәге иң кыйммәтле нәрсәләрнең берсе әнә шул да инде—кеше күңелен кузгату!

Яисә менә тагы бәгырьне телгәләгән күренеш. Рушан Дасаевның әнисе шәл бәйли. Мамык шәл! Данлыклы Оренбург шәле! Ул аны вокзалга барып пассажирларга сатып йөри. Әнә тамбурда хәрби офицер тора һәм аның бик тә кәттә, ифрат чибәр хатыны. Әлеге яшь бикәчкә шәл бик ошый. Гөлсемнең уе бер генә: «Шәлгә 700 сум бирерләрме?»

Менә шунда могҗиза була: әлеге офицерның чибәр хатыны шәлгә 800 сум түләргә куша. Бар бай кешеләр дөньяда! Әмма алар хәзерге «яңа байлар», «яңа урыслар» түгел, комсызлыкның ни икәнен дә белмәгән, ачык-яхшы күңелле, эшләгән эшеңә бәя бирә белгән, матурлыкка табынган, үзләре дә матур кешелекле затлар. Яхшылык вә матурлык ияләре. Бүгенге көндә мондый кешеләрне сагынырга гына кала, сагынырга гына...

Авторның йөзләгән геройлары арасыннан шактыйлары яшьли генә гомер-бакыйга күчеп киткәннәр инде. Алар үзләреннән тирән моң-сагыш, югалту-аерылышуларның искитмәле ачы хәсрәте һәм кара дегет кайгысын калдырганнар. Бу гади сагыш яисә моңсулык кына түгел, ә—нәкъ менә!—иртәләгән сагыш...

Ә йөрәк хәтерендә һаман тере яткан, болганчык сай судагы балык кебек, һаман бәргәләнеп торган мәхәббәт сагышы нинди сагыш ул?

Иртәләгән сагыш...

Бу ике сүзнең кушылып, бер оеткы төсмер-мәгънә биреп, сүзтезмә буларак килүе—ачык тән җәрәхәте кебек. Дөресрәге, ул җан ярасы һәм аннан бертуктаусыз моң саркый. Шунысы күңелгә ямь вә күпмедер рәхәтлек бирә: бу иртәләгән сагышта ниндидер яшьлек җылысы, сизелер-сизелмәс оптимизм, яшәү ләззәте һәм тормышка гашыйклык та бар.

Гомер елларыңны ахыргача санап бетерү өчен бу дөньяда, күрәсең, каный-каный да яшәргә кирәк. Шушы нәрсә, әлеге котылгысызлык Рауль Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш» романында бигрәк тә ачык сизелә.

Балачактан ук кыерсытылулар, авыр тормыш, кырыс-ачы язмышлар...

Мондый күренешне күз алдына китерегез: кечкенә генә малай тимер юл станциясенә күмер урларга бара, чөнки өйне җылытырга—ягар өчен!—берни юк. Әнә шулай ач-ялангач, ярлы-хәерче Рәсәй үз гражданнарын кечкенәдән үк урларга-таларга, юлбасарга әйләнергә өйрәтә. Шунсыз—катып үләчәксең, ачлыктан җан бирәчәксең.

Дөньяда миһербанлы—яхшы кешеләр дә юк түгел. Әнә бит мәктәп директоры Юрий Александрович Кузнецов Рушанның апасы Саниягә киемнәр юнәтергә булыша. «Кар күмеп киткән Мартук» матурланып китә мондый минутларда. Яшәве, чыннан да, күңелле!

... Рауль Мирхәйдәровның прозасын—бигрәк тә «Иртәләгән сагыш» романын!—шәхсән үзем шактый дәрәҗәдә документалистикага, автобиографик истәлекләргә бай әсәр дияр идем. Аларда күпмедер натурализм да бар. Аның теленә Кафкадагы протоколизм да хас. Достоевский сурәтләүдә омтылган тегәллек-тәгаенлык та сизелә, Фолкнерча «җәелеп язу»да юк түгел.

Иң мөһиме, яхшылык-матурлыкка, аның гармониясенә омтылу бар. Чиста-саф әдәбилек тә күренеп тора. Рауль Мирхәйдәровның Рушан Дасаевы

чын мәгънәсендә тулы канлы, үзенчәлекле образ. Аның үз омтылыш-хыяллары, үз көенеч-сөенечләре, үзенең үкенечләре, үзенчә сөя белүе, башкаларга карашы, дөньяны күзаллавы—һәммәсе дә Дасаевча. Ләкин Рушан Дасаев ил-халык эчендә яши, бернәрсәдән дә вә беркемнән дә аерылып тормый, мин менә әйбәт кеше инде, сез генә начар, дип тә лаф ормый. Ул бер үк вакыттарак әдәбият вә сәнгать әһелләрен, мәшһүр спортчыларны күрә. Болар өстенә җирле шагыйрьләр, композиторлар, музыкантлар, спортчылар, сәрхүшләр, сукбайлар, сөйрәлчекләр. Жора Стаин кебекләр...

Рушан Дасаев шундый халык диңгезе эчендә йөзә, аның аларга күпмедер йогынтысы бар, аларның,—әлбәттә!—аңа.

Әсәрнең географик киңлеген дә онытмаска кирәк. Бу да Мирхәйдәров үзенчәлегенең асылы. Мартук, Актүбә, Ташкент, Заркент(Алмалык), Оренбург, Кырым, Мәскәү. Чит илләргә кадәр: Германия, Испания, Кувейт...

Нәрсә ул интернациональ дуслык? Мин аны урыс, удмурт, марилар белән рәттән яшәп тойган идем, ә менә Рауль Мирхәйдәровның «Игълан буенча танышу», «Иртәләгән сагыш» әсәрләрен укыгач, тагын да ныграк аңладым. Юк, романга андый мотив махсус салынмаган. Әмма татар бистәсе татарларының урыслар, украиннар, казакълар, чеченнәр, немецлар, яһүдиләр һәм башка милләт кешеләре белән бер гаиләдәй укмашып (ә яшьләр вакыт-вакыт үзара тукмашып та!) яшәве—менә ул милли киртәләр эчендә генә бүленеп калмыйча, бер-береңең хәл-әхвәлен белешеп, кирәк чакта булышып, чын интернациональ яшәү! Бу—яшәеш, мондый тормышны беркем дә—хәтта Хак Тәгалә Үзе дә!—инкарь итә алмаслык бердәмлек, рухи туганлык. Без—Адәм белән Хаува оныкларының... ерак-ерак оныклары!

Рауль Мирхәйдәровның татарлыгын «Иртәләгән сагыш»та мин тагын татар халык җырларында—милләттәшләребезнең борынгы вә бүгенге үз көйләренә, гүзәл яңгырашлы, матур аһәңле, тирән моңлы җырларына Зур Мәхәббәт тотуда күрдем.

Бер Зур Мәхәббәт—Сөю өчен яшәү—үзе үк бөеклек! Мәхәббәт бар җирдә нәфрәткә урын калмый. Үзеңне яхшы кеше дип санасаң да, башкаларны начар димә, аларны ярата бел, ә ярата белү—үзе үк сәнгать ул...

Романда татарларның үз милли көйләренә мәхәббәте менә нинди урында күренә:

«Кич белән яңадан лампа тирәсенә түгәрәкләнеп утырыштылар да... Әнисе әкрен тавыш белән генә «Кара урман» җырын көйли:

> «Кара да гынай урман, караңгы төн,
> Яхшы атлар кирәк үтәргә.
> Заманалар авыр, еллар ябык,
> Дус-иш кирәк тормыш күтәргә».

Кара урмандай татар күңелен чагылдырган моң, кирәкле-кадерле сүзләр дә син; татар моң-сагышын, хәсрәт агышын, кайгылы ныклыгын аһәңләгән даһи музыкаль аваз-оран да... Мондый көй бары тик безнең җаннардан саркыган илаһилык-камиллек-моңлылыктадыр.

Кыскасы, әсәрнең тукымасында татар рухы ята. Моны Марс Шабаев бик тирән тоеп алган һәм искиткеч шәп тәрҗемә иткән! Чыннан да—гүзәл тәрҗемә!

Әдипнең үзенә турыдан-туры кагылышлы бер як та бар: әсәрдәге милләттәшләрен ул бервакытта да кара яктан гына, хурлап-гаепләп кенә күрсәтми, агын—ак, ди, карасын—кара!

Әсәрнең сюжет линиясендә сындыргалау-сынгалаулар булса да, «Иртәләгән сагыш», нәкъ сагышның үзе кебек үк, тулы бербөтен әсәр. Ярты-порты, сынык-мынык сагыш та булмый бит.

Авторның иң яхшы якларыннан берсе—ихласлык: әйбәте—әйбәт, начары—начар. Әмма яхшылыкта—яманлык, ә һәр яманлыкта яхшылык та ята ич әле! Бу—билгеле нәрсә, Галәми Канун. Шуңа чын ихлас әдип монысын да онытырга тиеш түгел.

«Иртәләгән сагыш». Безнең һәркайсыбызның күңел түрендә утыра ул иртәләгән сагыш. Йокымсырап утыра. Менә шул сагыш бер авыр кичереш,

гаҗәп бер тетрәнү белән уянып китәргә мөмкин. Берәүләрдә—сиздерми генә, икенчеләрдә—җанын көйдереп. Бер адәмнәрдә—бик яшьли, икенче бәндәләрдә—гомер көзенә җиткәч кенә. Сагышсыз кеше булмый, бар икән, димәк, ул җансыз-аңсыз, уй-фикерсез, хиссез-тоюсыз зат.

Фаҗигаләрдән арыну өчен безгә ни кирәк соң? Безгә үз асылыбызга кайтырга вакыт.

Бу—бүген булмаса, иртәгә асылынам дип, үз-үзеңнән йөз чөереп йөрү түгел. Бу—бүген мин үзәндә-түбәндә, иртәгә тауга биеккә күтәрелә̆м, алга таба Күккә менәм—ашам дип яшәү. Күккә Ашу—зур фәлсәфи категория, аңа Күңел Иреге һәм Иркенлеге, Рухи Азатлык, Җанның илаһилыкка ирешүе керә. Бу әле Татар өчен—Татарлык, үз асылына кайту, чын миллилеккә ирешү.

Алыгыз гали олуг халыклардан французларны, инглизләрне, немецларны, испаннарны, итальяннарны, португалларны, гарәп, һинд, бенгал, япон, кытайларны һәм башкаларны... Алар иң беренче үзләренең бөек улкызлары белән данлы-шанлы. Әлбәттә, үз дәүләтләре булу белән дә...

Безгә дә мескен, елак булып яшәүдән ерак качарга кирәк. Кемнедер каргап, кемгәдер үпкәләп-рәнҗеп гомер итү—мескеннәр эше. Халык үзе дә: «Мескенне кем сөйсен?!»—ди.

Мескенлек—елау, әдәбияты—бетүгә йөз тоткан әдәбият ул. Зарлану әдәбияты—югалтуга йөз тоткан әдәбият ул. «Зарланып зәр килми»,—дигән борынгы зәркәннәр. Күз яше дә зәр-алтын булып таммый, ә тоз-кан булып күңелдән бәреп чыга.

Рауль Мирхәйдәров үз әсәрләрендә бервакытта да мескен, бетәшкән, хәсрәткә чумган татарларны күрсәтмәде.

Язган әсәрләрдә «монументаль татар образы»н (тәнкыйтьче һәм язучы Мансур Вәли атамасы) бирү—XXI гасыр язучыларының изге вә төп бурычларыннан берсе булырга тиеш. Мөхәммәт Мәһдиев моны эшли алган икән, нигә әле ул бу яктан безгә үрнәк булмасын, ди?!

Рауль Мирхәйдәровның бу романында дөнья сулышын тоябыз. Бу сиңа төбәк, бетеп барган авыл, деградациягә кергән кешеләр яшәүче караңгы вә шыксыз йорт-алачыктан килә торган томанлы вә тар, авыр һәм шомлы сулыш кына түгел. Роман ифрат оптимистик рухта тәмамлана.

Бу—бетү түгел, ә яшәгәндә яктылыкка, яхшыга, матурга рәхәтләнеп бер күз сирпеп алу гына.

Менә шушы сүзләрне—Бөек Рухлы, Якты Зәңгәр Төсле Сүзләрне!—язар өчен генә дә шәхсән үзем мең битле роман язарга каршы килмәс идем:

«Көннәр үтә—күңелсез, авыр, сагышлы көннәр чиратларда торып, салкын фатирларда яшәп үтә, алда шатлыклар күтәренә ышануы бик-бик тә кыен. Вакыты-вакыты белән гомер бөтенләй бушка үткәндер кебек тоела.

Әмма... әмма...

«Күптән юылмаган, тузанланып беткән тәрәзәсе аша карап торганда, каршы яктагы йорттан кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы кызчык чыгып килгәнен күргәч, Рушанның йөзенә елмаю куна: юк, бернәрсәгә дә карамастан, тормыш дәвам итә, чөнки әле җир йөзендә мәхәббәт бар, әле хәтер тутыкмаган, тоныкланмаган.

Ә хәзергә, мәхәббәт һәм хәтер—кешене биекләргә аккошлар шикелле күтәрүче шул тылсымлы ике канат әле сындырылмаган-имгәтелмәгән вакытта, тормыш чишмәсе кипмәячәк, төтендәй эреп бетмәячәк, таңдагы томандай очып юкка чыкмаячак...

Кипмәс... бетмәс... юкка чыкмас...»

**Вахит Хаков**

# СҮЗДӘН ЧӘЧӘК ЯСАГАНДА...

Сүзнең тәэсир итү көче һәм эстетик функциясе бик киң. Безнең әйләнә-тирәбездәге һәр әйберне һәм күренешне төрле яклап ачыклап килә торган бик күп сүзләр бар. Чынбарлыктагы күренешләрне сәнгатьчә ачыклап килү, аларга поэтик җанлылык бирү һәм предметның бер сыйфатын аеруча калку итеп күрсәтү өчен кулланыла торган сүзләр тасвирый сыйфатламалар булалар. Эмоциональ тасвирлау чарасы буларак, алар әдәбиятның төрле жанрларында кулланыла. Татар телендә күчерелмә мәгънәлелекнең бу төре бик киң таралган. Мәсәлән, иҗтимагый тормыш һәм көнкүрештәге хәлләр, вакыйгалар белән бәйле рәвештә, кешене һәм шәхесне сурәтләү өчен нинди генә сүзләрдән файдаланылмый! Мисалга кешене уңай һәм кире яктан сурәтләгән кайбер сүзләргә мөрәҗәгать итик.

Уңай бәяләү. Кешенең эчке дөньясын, аның гадәтләрен белдерүче сүзләр: чын кеше, юаш кеше, бичара кеше, намуслы кеше, дөрес кеше, җайлы кеше, әйбәт кеше, ышанычлы кеше, житди кеше, тыйнак кеше, кешелекле кеше, яхшы кеше, изге ниятле кеше, басынкы кеше, алтын кеше, рәтле кеше, гөнаһсыз кеше, беркатлы кеше, тәгәл кеше, әүлия кеше, риясыз кеше, олы җанлы кеше, миһербанлы кеше, һиммәтле кеше, мәрхәмәтле кеше, ихлас кеше. Кешенең көче, зурлыгы һәм осталыгы ягыннан ачыклаучы сүзләр: көчле кеше, батыр кеше, дәү кеше, таза кеше, куәтле кеше, курку белмәс кеше, тимер бәдәнле кеше, киң күкрәкле кеше, тимер өзәрлек кеше. Белем, тәрбия, әхлак ягыннан ачыклап килүче сүзләр: зирәк кеше, акыллы кеше, тәрбияле кеше, талантлы кеше, тәҗрибәле кеше, фикерле кеше, абруйлы кеше, авторитетлы кеше, мәдәниятле кеше, сәләтле кеше, белемле кеше, тирән белемле кеше, алтын куллы кеше, хикмәтле кеше һ. б.

Кешене кире яктан сурәтләү өчен кулланыла торган сүзләр дә шактый: начар кеше, мактанчык кеше, начар ниятле кеше, гаепле кеше, алама кеше, коры кеше, ят кеше, шыр кеше, такылдык кеше, каты кеше, яман кеше, вак кеше, кара эчле кеше, ике йөзле кеше, буш кеше, кайнар башлы кеше, таш бәгырьле кеше, шикле кеше, чуар йөрәкле кеше, тонык карашлы кеше, кыска холыклы кеше, чүп-чар кеше, эленке-салынкы кеше, акылсыз кеше, җүләр кеше, комагай кеше, елгыр кеше, һавалы кеше, куркак кеше һ. б.

Сыйфатлау сүзләре язучылар телендә әсәрнең эчтәлеге белән бәйле рәвештә индивидуаль үзенчәлекләргә бай була. Моны матур әдәбият стиле таләп итә. Кайбер мисаллар: «Белми хикмәтсез кеше хикмәт дигән сүз кадрене» *(Г. Тукай. Хале хазир)*, «— Ә син, җүнтәс кеше, шикәр беләнмени чәй эчсән?» *(Ш. Камал. Матур туганда)*, «Шактый ук «бикле» кеше ул безнең арада» *(Ш. Маннур. Чын сөю бармы?)*, «Якты кеше иде бит ул, үзенә тарта һәм яраттыра торган көч бар иде анда» *(Ш. Маннур. Агымсуларга карап)*, «Әллә язучыны мөгезле кеше була дип уйлыйсыңмы?» *(Ф. Хөсни. Минем тәрәзәләрем)*, «Чын дөреслектә бу « төккунмас» кешеләр тирәсендә акча төшереп булмаслыгын чамалап, Сәфәргали аларны ташлап, бөтенләйгә китеп барды» *(Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы)*, «— Мине дә, Лиданы да шул кадәрегә барып җитәрлек хәрт кешеләр дисең инде? Егет, вакыт узган саен, кыза, ярсый барды, ә ярсу—тамгалы кешеләргә начар юлдаш» *(А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын)*, «Үземне өянәкле, үз чирле кешеләр белән бәйләгәнем өчен гаепләдем» *(Г. Ахунов. Йолдызлар калка)*, «Каюм абзый чәүчәләк һәм быткыч бер кеше икән» *(А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?)*, «Күрергә матур, акылга такыр кешеләрдән кызыбызны саклау—безнең бурычыбыз» *(Ш. Хөсәенов. Профессор кияве)*, «Уалы *(бөкре.—В. Х.)* кеше кожанын киеп, бричкасына үрмәләде» (З. Зәйнуллин. Ат караклары), «Шактый өлкән яшьтәге шыксыз һәм шөкәтсез бу кешенең бер сүзе, бер ымы аның киләчәк язмышын чәлпәрәмә китерә ала иде» *(Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет)*, «Инде шундый «тышаулы» кеше хакында да «эчү белән бәйләнгән» ахмак мәзәк уйлап чыгара алганнар икән—бу дөньяда пычратып булмаган кеше юк дип уйларга мәҗбүр буласың» (*(Ю. Сафиуллин)*. «Бу кадәре бежек кеше булырсың икән! *(З. Хәким. Карак)* һ. б.

Мондый сурәтләүләрдә әдәби телнең язма һәм сөйләмә формаларыннан, җирле үзенчәлекләрдән киң файдаланыла. Әйбер һәм күренешләрне ачыклый торган сүзләрнең кулланылышы берүк дәрәҗәдә һәм бер тигезлектә түгел. Бу—сүзнең телдә тоткан урыны һәм

таралышы белән бәйләнгән. Төрле семантик төркемгә кергән кайбер ачыклаучы сүзләрнең таралу ешлыгы киңрәк булганлыгы күзәтелә. Мәсәлән, сүз төшенчәсен ачыклаучы лексик берәмлекләрдә, шул төркемдәге башка сүзләргә караганда, ешрак очрыйлар. Җөмлә эчендә алар түбәндәгечә яңгыраш ала: «Җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз» *(Г. Тукай. Кышкы кич)*, «Сагышларга дәва ширин сүзең дә» *(Дәрдмәнд. Нидер)*, «Синең белән баллы сүзләреңне тыңларга мин әзер, туташ» (К. Тинчурин. Тутый кош), «Рәхмәт сиңа татлы сүзең өчен, күреклем!» (М. Җәлил. Терелү), «Аһ, туганкай, рәхмәт сиңа, Алтын синең бу сүзең» *(М. Җәлил. Бәла)*, «Ана елмая, ягымлы, назлы сүзләр пышылдый: И минем сөеклем, и минем чибәркәем, усалкаем минем» *(Р. Төхфәтуллин. Таныш көй)*, «Бу чандыр чибәр кыз үзенең уенчак сүзләре белән аны эретә язган иде» *(Ф. Хөсни. Икәү—тамаша тәгәрмәчендә)* һ. б.

Юмарт сүз, тәмле сүз, ялкынлы сүз, дәртле сүз, үткен сүз, шома сүз, борынгы сүз, матур көчле сүз, яңгыраулы сүз, җор сүз, акыллы сүз, туры сүз, туган сүз, якты сүз, үзара сүз, утлы сүз, изге сүз, аз сүз, гүзәл сүз, кызык сүз, соңгы сүз, актык сүз, хак сүз, мәзәк сүз, серле сүз, бик гади сүз, иң якын сүз, ямьле сүз, коры сүз, гомуми сүз, капма-каршы сүз, ышандырырлык сүз, нурлы сүз кебек тезмәләр дә шулар рәтендә каралалар. Алар арасында хәзерге тел өчен искергәннәре дә очрый: хәлавәтле (татлы), мөрәүвәтле (кешелекле)—Кол Гали. «К. Й.», сәмави—Г. Тукай һ. б.

Сүз лексемасының да кире төшенчәләрен күзәтергә була. Мисаллар: «Остазларга әллә нинди кискен һәм авыр сүзләр ычкындырган» *(Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр)*, «Китаптан укыган шомлы сүзләрне үз язмышына юрап, һәрнәрсәдә ахырзаман билгесен күрә башладылар» *(К. Нәҗми. Язгы җилләр)*, «Диңгезчеләр телендә булган иң тозлы сүзләр әйтеп ташлады» *(Г. Әпсәләмов. Алтын йолдыз)*, «Мәдинәнең миңа ташлаган үпкә сүзләре артык җитди иде» *(Ф. Хөсни. Бирәү килә, бирәү китә)*, «Аның коткылы сүзләрен истә тотты» *(Н. Фәттах. Сызгыра торган уклар)*, «Ул синең пүчтәк кенә сүзеңне дә җавапсыз, игътибарсыз калдырмас» *(М. Вәли. Мәхәббәт маҗаралары)*. Мондый сыйфатлауларның күп төре кулланыла. Мәсәлән: усал сүз, агулы сүз, салкын сүз, шыксыз сүз, тотнаксыз сүз, юк сүз, пычрак сүз, ачы сүз, әрнүле сүз, хәйлә сүз, дәһшәтле сүз, дорфа сүз, ялгыш сүз, әрнеткеч сүз, хәвефле сүз, буш сүз, тәмсез сүз, ачулы сүз, шапырынкы сүз, мәгънәсез сүз, юк-бар сүз, куркыныч сүз, каршы әйткән сүз, әшәке сүз, начар сүз, яман сүз, чәнечкеле сүз, ямьсез сүз, юләр сүз, сабынлы сүз, арзанлы сүз, купшы сүз, ят сүз һ. б. Аларны һәр автор үзенчәрәк куллана, яңа сыйфатлау сүзләре иҗат итә, шул рәвешчә, әдәби тел туктаусыз баеп тора.

Иҗат эшендә һәм телдән файдаланганда телдәге бөтен сүзләрне дә куллану мәҗбүри түгел. Гадәттә, язучылар (матур әдәбият әсәрләре турында сүз бара) үзләренең бөтен иҗат дәверендә телнең, гомумән, 15-20-25 мең сүзе белән генә эш итәләр. Бу сан телдәге зур байлыкның (100, 200 мең сүзнең) булуын искә алганда, азрак күренә кебек. Статистик анализ, исәпләүләр-тикшеренүләр нәкъ менә шуны күрсәтә.

Әмма язучы иҗатында сүзләрне куллануның сан ягы гына мәсьәләне хәл итми, бәлки авторның бер үк сүзне, тәгъбирне төрле мәгънәләрдә куллануы, ягъни сыйфат ягы аеруча әһәмиятле. Бу яктан караганда, кайбер сүзләр әсәр эчендә, контекстта кулланылганда бишәр, унар, хәтта аннан да күбрәк мәгънәгә ия булалар. Сүзнең күп мәгънәлелеге сөйләме төрле үзенчәлекләр белән баета, телнең киң эчке мөмкинлекләреннән файдаланырга, шуны эшкә җигәргә ярдәм итә.

Мәгънәви һәм стилистик яктан тасвирый сыйфатламалар аерым төрләргә бүлеп каралалар:

**1.** Предмет һәм күренешләрнең төсен белдерә торган сыйфатламалар еш очрый. Сөйләмнең эчтәлеге белән тыгыз бәйләнештә караганда гына алардагы мәгънә үзенчәлекләрен төгәл ачыклап була. Мисаллар: Г. Колахмәтовта кызыл сүзе кучерелмә мәгънәдә: «Кызыл фикер, түгәрәк өстәлгә бер кулы белән таянып, басып тора» *(Ике фикер)*. Моңа контраст мәгънәдә кара сүзе алына: «Кара фикер, бер дә кузгалмыйча, шкаф катыннан Давытка карап тора». Кара сүзе киңрәк кулланылышта: «Бу кара фикерләр озак вакытлар Хәяткә тынычлык бирмәделәр» *(Ф. Әмирхан)*. «Тәненнән кара тирләр ага иде» *(Н. Дәүли)*. «Минем күзләремне кара кан басты» *(Г. Толымбай)*. Г. Ибраһимов, тормыш вакыйгаларын, күренешләрне сурәтләгәндә, төсне белдерүче кара эпитетыннан еш файдалана, аны халык телендәге үзенчәлекләр белән оста кушып бирә: «дөньяны каплаган кара пәрдә», «кара кан юганчы», «мәхәлләнең кара җырлары», «авыр кара өметсезлек», «саташулы кара бер сөрем», «кара хәбәр», «хыялга, өметкә иярми торган кара көчләр» һ. б. *(«Безнең көннәр»)*

**2.** Әйберләрне һәм күренешләрне охшату юлы белән ясалган тасвирый сыйфатламалар да күп очрый. Мисаллар: «Янында тора торган көмеш сакаллы 50-60 яшьләрендәге бер доктор» *(Ф. Әмирхан)*. «Тимер куллы кеше» *(Ш. Маннур)*. «Әгәр син үзең ярдәмгә килмәсәң, врачларның алтын куллары гына берни эшли алмаячак» *(Г. Әпсәләмов)*. Мондый сыйфатламалар исемнәргә

якын тора һәм бу төрки телләргә хас үзенчәлек булып санала.

**3.** Әйберләрнең төрле үзлекләрен (исен, тәмен һ. б.) белдерүче тасвирый сыйфатламалар: «Татлы сүз иясе сүзнең җаен тапмыйча сөйләмәс» *(К. Нәҗми)*. «Мин бит тәмле тормышыңызга тупасча кереп тынычлыкны боздым» *(Г. Исхакый)*. «Син миңа шатлык белән бергә татлы газап та бүләк иткәнсең икән» *(Р. Низамиев)*.

**4.** Искелек-яңалык төшенчәсен бирә торган тасвирый сыйфатламалар: «Куе агачлы карт урман да шул ук сүзләр белән җавап кайтарды» *(Ф. Әмирхан)*. «Хәтта карт йөрәк тә кымырҗып куя» *(Ә. Баян)*. Мондый сыйфатламаларда сатирик-юмористик төсмер дә чагыла: «Их, сез, черек милләт калдыклары!» *(К. Тинчурин)*.

**5.** Әйберләрне һәм күренешләрне төрле яктан ачыклап килә торган сыйфатла-малар да очрый. Мәсәлән: «Бик үткен журнал тарала», «Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел!» *(Г. Тукай)*. «Өй алдында сукыр ут кына, шулай да күрәм» *(Ф. Хөсни)*. «Безнең сынык күңелләребезне юаттың-куандырдың, рәхмәт төшсен үзеңә!» *(Ә. Еники)*.

Төрле стильләрдә сүзтезмәләр рәвешендә киңәйтелеп бирелгән сыйфатламалар да урын ала. Мәсәлән: «Кеше кыяфәтле ерткычлар балаларын каннары чыкканчы суктырганнар» *(Ф. Әмирхан)*. «Ике тиен дә тормаслык җәлладлар, Канга манчылган җир өстен күр дә син» *(М. Гафури)*. «Кычкыралар йөземә тәмсез ачулы сүз белән» *(С. Рәмиев)*. Киңәйтелгән образлы сыйфатламалар, башка сурәтләү алымнары белән бергә кушылып, төрле поэтик-стилистик үзенчәлекләр барлыкка китерәләр. М. Җәлилнең «Балыкчылар» шигыреннән бер мисал: «Алтмыш тоннан балык ул кадәрле Авыр тоелмады беләккә. Йөз тоннадан авыр сагыш хисе Ялкынланып сөйгән йөрәккә». Өзектә сыйфатламалар күренешләрне үз күләменнән зурайту алымы белән тыгыз үрелеп килә.

Контексттагы сыйфатлау сүзләре әйберләрне һәм күренешләрне төрле яктан сурәтләүдә зур урын тоталар, телдәге нечкә төсмерләрне белдерергә мөмкинлек бирә. Вакытлар үткән саен, яңа мәгънәләр дә туа тора. XX гасырга кадәрге әдәбиятта элекке китап һәм сөйләү теле традицияләре нигезендә, сыйфатлаулар шул чорга яраклы рәвештә нормалашалар, соңга таба телне үстерү, фикерне тагы да тулыландыру, эчтәлекне киңәйтү юнәлешендә яңа мөмкинлекләр ачыла. Предметларны һәм күренешләрне ачыклаучы сүзләр дә күбәя. Моны аерым мисалларда ачык күрергә була. Мәсәлән, болыт сүзен ачыклауга караган кайбер сүзләр: «Кояш иңгән як офыкта бөдрәләнеп торган сыек болытлар, алтынлы парчалар төсле, күз камаштырырлык ачык алсу нурга манчылганнар» *(Ш. Камал. Матур туганда)*, «Җилкәннәр кебек юка ак болытлар тиз йөзәләр» *(Г. Гобәй. Каланча)*, «Бистә өстендәге кургаш болытлар, коеп куйгандай, хәрәкәтсез калган» *(Г. Минский. Яшенле яңгыр)*, «Ил өстендә кара болытлар куерып килә» *(Ш. Усманов. Легион юлы)* һ. б.

Соңгы елларда шул күзәтелә: хәзерге телдә болыт сүзен ачыклый торган сүзләрнең мәгънәләре киңәя, аларда чынбарлыкны тасвирлауда яңа төсмерләр арта. Мәсәлән: «Ә кичен, талчыккан гәүдәмне ястыкка таратып ташлауга, күз алдыннан бөдрә болытлар булып, сарык көтүе үтәр» *(М. Галиев. Нигез)*, «Туган якның дымлы болытлары Юешләсен канлы иренне» *(Р. Зәйдулла)*, «Көрәшеп үлгән бабайлар, япь-яшь егет, агай чакта, Хәтерләре ялтырап ята, Ак болытта, яшьле чыкта» *(Б. Рәхимова. Казанда хәтер көне)*, «Җил ул кысыр болытларны офыкка өеп тезеп бара» *(К. Кәримов. Ком сәгате)*, «Хәтта монда бугазына тыгылып, таңны япкан куштан болытлар» *(А. Хәлим. Урланган таң турында баллада)* һ. б.

Ә җил нинди була? Монда да без телнең бик нечкә төсмерләреннән файдаланылганлыкны күрәбез. Җил—ул символ. Татар шигъриятендә бу символ һәр авторның үз алымнары белән баетыла: «кодрәтле җил» *(Ш. Бабич. Язгы җыр)*, «йомшак җил» *(И. Юзеев. Таныш моңнар)*, «кырыс җил» *(И. Юзеев. Китәм, диден)*, «кайнар җил» *(Г. Афзал. Картайсам да)*, «үксез җил» *(Ф. Гыйззәтуллина. Диңгез ярларында)*, «ак җил» *(Р. Вәлиев. Сагынам)*, «тыгыз җил» *(Р. Әхмәтҗан. Туган якка)*, «көмеш җил» *(М. Галиев. Әрем исе әрнүле)*, «гарасат җилләр» *(Г. Афзал. Кичүләр)*, «чәчәк исле җилләр» *(Г. Афзал. Серле күлләр, горур таулар...)*, «канлы җил» *(З. Мәҗитов. Тамчы турында легенда)*, «зәһәр җилләр» *(М. Әгъләм. Яңа гасыр керә)*.

Телебездә хисси сүзләр, предметны, аның нинди леген күз алдына китерми торган лексик берәмлекләр бик күп. Алар татар телендә кулланылышлары ягыннан аерым урында тора. Сүзлекләрдә дә аларның төшенчәләре тулысынча аңлатылып бетми. Дөресрәге, аларны бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп тә булмый. Татар матур әдәбиятында аларны ачыклап килә торган сүзләр—сыйфатларны тикшерү бик мавыктыргыч. Бу—кызыклык өчен генә эшләнми, бәлки телнең эчке дөньясын, сөйләмнең нәфислеген ачыклауны, андагы нечкә төсмерләрне билгеләүне дә төп максат итеп куя. Мондый сүзләр, беренче нәүбәттә, халкыбызның рухи яшәеше, гореф-гадәтләре һәм аның тарихи үсеше белән дә тыгыз бәйләнгән. Шундый сүзләрнең кайберләренә тукталып үтәбез. Моң, уй, күңел, бәхет, җан, хыял кебек күп кенә сүзләр шул төркемне тәшкил итә.

Моң. «Сокландыргыч моң» *(Ә. Ерикәй. Дулкынланып яза шагыйрь)*, «мөлдерәмә моң» *(Ш. Галиев. Бар...)*, «кара моң» *(Р. Фәйзуллин. Кояш тотылганмы?)*, «якты моң» *(Р. Вәлиев. Рамазан)*, «зәңгәр моң» *(Ә. Баянов. Кышкы чәчәкләр)*, «кайгылы моң» *(М.Әгъләм. Болай да бит инде)*, «рухани моң» *(Н. Хисамов. Илаһи моң)*, «назлы моң» *(М. Әгъләм. Дәүләт теле)*, «сәер моң» *(Р. Мингалим)*, «үлемсез моң» *(А. Хәлим)* һ. б.

Уй сүзен ачыклаучы сүзләр аеруча күп: «Чуалчык уй, ахмак уйлар» *(Г. Исхакый. Ул икеләнә иде)*, «зир-зәбәр уй» *(Ш. Бабич)*, «төпле уй» *(А. Гыйләҗев. Тәмәкене ташладык...)*, «давыллы уйлар, гәүһәр уйлар» *(С. Поварисов. Күкнең җиденче катында)*, «башваткыч уйлар» *(Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы)*, «сагышлы уйлар» *(Ш. Камал. Матур туганда)*, «иң-иң мөкатдәс уйлар» *(М. Вәли. Ирекнең кадере)*, «ямансу уйлар» *(Ә. Баянов. Хыялда туган кала)*, «хыянәтчел уй» *(М. Мәһдиев)*, «тәшвишле уй» *(Р. Фәизов. Узган гомер—янган күпер)*, «затлы уйлар» *(Л. Лерон)*, «караңгы уй *(З. Зәйнуллин. Ат караклары)*, «сәер уй» *(Р. Низамиев. Кайтарыгыз!)*, «коточкыч уй, газаплы уй, кайгылы уй» *(З. Хәким. Гөнаһ)*, «җан өшеткеч уй» *(Р. Гариф. Караңгы төшкәндә)*, «начар уй» *(Т. Миңнуллин. Ат карагы)*, «пычрак уй» *(Ә. Баянов. Алтын кашбау)*, «талгын уй» *(Р. Харис. Сәйдәш яры)*, «ихлас, әрнеткеч уйлар» *(М. Вәли. Мәхәббәт маҗаралары)*, «яман уйлар» *(Я. Зәнкиев. Өтелгән мәхәббәт)* һ. б.

Хис һәм күңел сүзләре дә төрле сыйфатлар белән ачыклана ала: «Яман хисләр» *(Ш. Камал. Матур туганда)*, «кайнар хис» *(Ә. Баянов. Кышкы чәчәкләр)*, «ак хисләр» *(М. Вәли. Иртәнге пароход)*, «ачы, кыргый эчке хисләр» *(Н. Исәнбәт)*, «ләззәтле хис» *(А. Шамов. Рәүфә)*, «ташкын күңел» *(Ш. Бабич. Айга мендем)*, «туң күңел» *(Ш. Бабич. Зарлану)*, «хассас *(сизгер— В. Х.)* «күңел» *(М.Гафури. Г. Тукай Уфада)*, «сынык күңел» *(Ш. Маннур. Агымсуларга карап)*, «тутык күңел» *(Марс Шабай. Күңелемә, әткәй, кайтып кер...)*, «алама күңел» *(З. Хәким)*, «таш күңел» *(Р. Зәйдулла)* һ. б.

Җан сүзен ачыклаучы сыйфатламалар да, телдә еш кулланылып, төрле мәгънә төсмерләре белдерәләр. Кайбер мисаллар: «Өмидсезлекләр, усаллык, вәсвәсәләр, зәгыйфь җанны теләләр һәм кисәләр... Мөҗәссәм бер кешелек ул, җылы җан» *(Г. Тукай. Бер мән)*, «Хыянәтсез саф калабыз моңлы җаннар» *(М. Гафури)*, «пошынучан җан, тынгысыз җан, шук җан» *(Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы)*, «Бу түбән, вак җаннар гайбәте» *(Ә. Еники. Кояш баер алдыннан)*, «Алар моңы үзәгемне өзми Сихри җаны булып дөньяның» *(Н. Нәҗми. тагын килде бер яз...)*, «Болытлы көн сүрән җанны талкып» *(Г. Афзал. Болытлы көн)*, «Шундый асыл җанны әрәм итәр идеме?» *(А. Гыйләҗев. Сары чәчәк ата көнбагыш)*, «Уян, уйлан элек, ихлас җаным,— Шәһит җаннар кайткан мәйданнарга» *(Р. Әхмәтҗан. Хәтер көне)*, «Бәдәнгә нурлы җан өреп, Иткәнсең чыдам адәм» *(А. Хәлим. Эчик гүзәл су...)*, «Кайсы кабих җанның этлеге бу?» *(В. Имамов. Утлы дала)*, «Ак җаныңа кире ал ул рәнҗеш-каргышларны!» *(Р. Сибат. Без туганнар бугай)*, «Намуслы җан ничек тыныч йөрсен» *(З. Мәҗитов. Өмет өзелгәндә)*, «Мәңгелек утка кушыла нурлы җаннар, ялкынлы-җырлы җаннар...» *(Ш. Маннап. Әверелү)*, «Табигатьтә бер гыйсьянчы—буранлы җан булганмын» *(Ә. Гадел. Халыкнамә)*, «Азат җаннар! Сез дә коллар булгансыз!» *(Р. Гаташ. Кышкы робагыйлар)*.

Җан сүзе үзенең абстракт төшенчәсен югалтып, турыдан-туры шәхесне, җанлы предметны белдерүгә дә кучә ала. Китерелгән мисалларның кайберләре сүзтезмә рәвешендә тулы бер мәгънәне бирәләр. Бу очракта ул, кеше сүзенең синонимы буларак, сүзтезмә рәвешендә килә һәм тулы бер төшенчә белдерә. Китерелгән мисалларда аның шундый төрләренә дә игътибар ителде.

Гомумән, татар телендә логик һәм метафорик сыйфатламалар сөйләмнең яңгырашын, нәфислеген һәм аһәңен күтәрүдә зур эш башкаралар.

РЕДАКЦИЯДӘН:


***Филология фәннәре докторы, профессор Вахит ага Хаковка бу айда 75 яшь тула. Аны туган көне белән кайнар котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез!***

Tarix
Тарих

# ХАЛКЫН ОЛЫЛАГАН ОЛЫ ГАЛИМ

Халкыбызның тоткан дине хак, тарихы борынгы, милли яшәеш тамырлары тирән. Алар—безнең киләчәктә дә милләт булып яшәр, тормыш арбасыннан төшеп, тарих тузанында күмелеп калмас өчен нигез булып торган, төп таяныч-терәкләребез. Татар халкын тулаем бер милләт итеп саклап, барлап, үстереп торучыларыбыз да һәр заманда булган һәм булыр, иншалла.

Язмамда мин шундый милли җанлы, тирән белемгә ия милләттәшем, тарихчы-галим, археолог Фаяз Шәриф улы Хуҗин турында сөйләмәкче булам. Җырласа—күңелләр тулып җыларлык, аңлатса—дәлилләре белән инандыра алырлык шәхес ул. Кайчакта мин, кем генә булып эшләсә дә, аннан менә дигән үз эшенең остасы чыгар иде, дип уйлап куям.



Фаяз әфәнде Зәй районының Карман авылында моннан 50 ел элек туып үскән. Әти-әнисе—Әхмәтшәриф абый белән Фәгыйлә апа—гади авыл кешеләре, алты бала тәрбияләп үстерәләр. Иң өлкәне—безнең каһарманыбыз.

Фаяз башлангыч белемне авылда ала, аннан соң күрше Бигеш урта мәктәбендә укый. Бигрәк тә тарих һәм әдәбият фәннәрен ярата. «5-6 нчы сыйныфларда укыганда туган як тарихы түгәрәгенә йөргән идем. Укытучым Мөнәздәһә апа Кәримова миңа авылым тарихын язарга кушты. Картлардан сораша-сораша истәлекләр җыя башладым. Бер ел дигәндә тәки ерып чыктым бу эшне. Бер дәфтәрлек хезмәтемне Мөнәздәһә апа бик мактады. Югарырак сыйныфларда укыганда да Фәхрази абый Ситдыйков бу эшемне ташламаска күндерде. Шуннан китте бугай тарих белән җенләнүем»,—дип искә ала Фаяз әфәнде.

Ул үзенең киләчәк профессиясе турында озак уйлап тормый укытучыларына булган ихтирамын чагылдырып, балачактан укытучы булу теләге белән яна. «Аның тарих белән тирәнтен кызыксынуын белә идем инде,—дип сөйли Фаязның элеккеге сыйныф җитәкчесе Фәгыйлә Хаҗи кызы Вәлиева.—Тик минем аны, үзем телче-әдәбиятчы булгандыр күрәсең, университетка журналистика яисә филология буенча укырга җибәрәсем килә иде. Тарихны сайлады. Казанга имтиханнар бирергә киткәч, борчылып-дулкынланып тордык—егетебез бик тә тыйнак һәм оялчан иде.»

1968 елдан Фаяз Хуҗин—Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультеты студенты. Группада татар мәктәбен бетереп килгән бердәнбер студент. Башта бик авыр була, хата җибәрермен дип, русча сөйләшергә дә оялып йөри. Укытучысы Елена Александровна Халикова, җәй көне борынгы Биләр шәһәрлеген казырга «практикага» барырбыз дигәч, аптырап кала: безнең Татарстанда да болгар бабаларыбыздан шундый мәшһүр истәлекләр сакланып калган микәнни? «Бигрәк тә надан булганмын икән инде,—дип көлә Фаяз әфәнде ул елларны искә төшереп.—Хәер, шул «наданлыгым»

мине, бәлки, археологиягә алып килгәндер дә инде.» Әйе, 1969 елда Фаяз Хужин беренче мәртәбә Биләрдә бара торган археологик казу эшләрендә катнаша һәм менә шул вакыттан бирле бу «эштән» аерылганы юк.

... XI-XII йөзләргә караган мөселман зиратын казып яталар болар. Болай берни дә күренми кебек. Берән-сәрән чүлмәк китекләре генә очраштыргалый. Казылган җирне бик тигез итеп чистартып куйганнан соң студентлар янына яшь профессор Альфред Хәсән улы Халиков килеп җитә. «Күрәсезме,—ди ул үткен күрәк кыры белән җиргә әллә нинди сызыклар сызып,—менә бу борынгы кабер эзе. Янәшәсендә икенче каберлек, әмма ул беренчесенә караганда, соңгырак чорга карый. Яхшылап чистартырга кирәк булыр хәзер аларын.» Студентлар игътибар белән укытучылары күрсәткән урынга иелеп карыйлар, әмма берни дә күрмиләр. Әллә нинди таплар бар анысы, ә кайда соң каберлек, профессор аларны нинди билгеләрдән танып белә соң? «Шушы мәлдә,—дип искә ала Фаяз әфәнде,—Альфред ага миңа чып-чын тылсымчы кебек тоелды. Минем дә тизрәк археология серләренә төшенәсем килде, күңелемдә, йөрәгемдә аның кебек җир астында калган тарихыбызны аңларлык гыйлем иясе булырга теләү хисе уянды.»

Борынгы биләр шәһәрлеге, егетебезне магнит кебек үзенә тарта башлый. Эштән соң ашханәгә барып, бераз ашап алгач та, ул шәһәрлеккә чаба. Җир өстендә аунап яткан чүлмәк китекләрен, тагын әллә нинди табылдыклар җыя. Җыя һәм өйрәнә...

Бер айлык археология практикасы үтеп тә китә. Каникуллар башлана. Биләрдән алып кайткан чүлмәк китекләре белән башка табылдыкларны Фаяз әти-әнисенә, туганнарына, дусларына күрсәтә, аларга рухланып бабаларыбызны—Олуг шәһәр Биләр турында сөйли. «Менә бу чүлмәк китекләренә ким дигәндә мең ел,—ди ул тыңлаучыларына.—Безнең тирәләрдә дә очрарга мөмкин ич алар. Тапсагыз, берүк миңа күрсәтегез, яме.» Икенче көнне җиденче сыйныфка күчкән сеңлесе Гөлфирә күлмәк итәгенә тутырып әллә никадәр чүлмәк китекләре алып кайта абыйсына. Зичә белән Аулаш елгалары кушылган җирдә, ферма тирәсендә алар тулып ята, ди. Нindидер бик тә сәер чүлмәк ватыклары. Мондыйларны аның күргәне дә юк әле. Стеналары калын, тупас, бизәкләре әллә нинди серле. Нинди чор, кайсы халыкларга карый соң болар? Студент егетебез, булачак археолог, сеңлесен ияртеп, әлеге табылдыклар очраган урынга чаба. Җир өстен җентекләп тикшереп чыгалар. Чүлмәк китекләреннән тыш өч бронза урак, сөзге очы һәм хәнҗәргә охшаш пычак табып алалар. Әйе, бик борынгы авыл урыны булырга охшый бу. Бәлкем бронза чорына карыйдыр? Тик ничек белергә соң моны? Фаяз Казанга, китапханәләргә ашкына.

Яна уку елы башлану белән студентларның бер өлеше колхоз эшенә, калганнары яңадан археологик экспедициягә китеп баралар. Бу юлы Фаяз таш гасыры чорын өйрәнүче археологлар Марк Косменко белән Рөстәм Габәшевка ияреп китә. Кабат әллә ничаклы яңа ачышлар. Яңа тәэсирләр. Аңлашылмаган һәм әлегә җавапсыз кала биргән сораулар. Шул рәвешле, археология егетне бөтенләе белән үзенә тарта. Хәерлегә булсын!

Укулар башлана. Лекцияләр, семинарлар. Фаязның күп вакыты хәзер китапханәләрдә үтә. Максатчан эшли, мөстәкыйль рәвештә, китаплардан укып, үз авылы янында сеңлесе тапкан борынгы әйберләрнең датасын билгеләргә тырыша. Һәм үзенә күрә беренче ачышка ирешә: табылдыклар чыннан да бронза чорына карый икән. Биредә безнең эрага кадәр XIII-XII гасырларда бура кабиләләре яшәгән булган. Фаяз үзенең беренче фәнни хезмәтләрен язып, тарихка кертә. Кышын укулар, җәен экспедицияләр белән студент еллары үтеп тә китә. Фаяз Хужин—Зәй районы Кадер сигезъеллык мәктәбенә тарих укытучысы булып эшкә кайта.

Максатка ирешелгән дә кебек. Әмма күңеле дә тыныч түгел. Аның профессионал археолог буласы килә. Җәйге ялы вакытын һаман экспедицияләрдә уздыра. Аны бигрәк тә таш гасыр чорына караган истәлекләр кызыксындыра. Фаязның омтылышларын күреп алган археолог Рөстәм Габәшев бервакыт аның янына килә дә: «Фаяз, син татар егете, мин сиңа киләчәктә таш

гасыры белән түгел, болгар чоры археологиясе белән шөгыльләнергә тәкъдим итәм. Уйлап кара әле, безгә бит әйбәт болгарчылар кирәк»,—ди. Уйлана егет һәм тәҗрибәле археологның киңәше белән ризалаша. Казан археологларының остазы Альфред Халиков аны Биләргә чакыра. 1974 елдан Фаяз Хуҗинны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә алалар. Менә шулай мәктәптән, яраткан укучыларыннан аерылу аңа бик авыр булса да, күңелендә ныклап урнаша килгән археолог булу теләге җиңеп чыга.

Биләрне очраклы рәвештә сайлап алмады ул. Заманында бар җиһанны шаулаткан әлеге гигант каланы озак еллар буена археологлар нигәдер үз итә алмады. Казыну эшләре һаман Болгар шәһәрлегендә үткәрелде. Ниһаять, 1967 елда Альфред Халиков җитәкчелегендә Биләр археологик экспедициясе оештырыла. 1970 еллар башында биредә, Олуг шәһәрдә, эшләр гөрләп бара. Җәй айларында эшләүче студентларның, лаборантларның һәм гыйльми хезмәткәрләренең саны йөздән артып китә. Профессор А. Халиков үзенең ярдәмчесе, ягъни экспедиция җитәкчесенең урынбасары итеп Фаяз Хуҗинны билгели.

Май аеннан башлап октябрьгә кадәр экспедициядә. Шәһәрлекнең үзендә казулар, аның тирә-юнендә яисә Чирмешән буйлап язын-көзен разведкалар үткәрелә. Һәм яңадан-яңа ачышлар. Биләр дә шул кадәр бай археологик истәлек булыр, болгарларның монголларга кадәрге тарихын яңабаштан язарга мөмкинлек бирердәй материал тупланыр дип Альфред Хасановичның да башына килмәгәндер, мөгаен. Идел буе мөселманнарының иң борынгы, Ибн Фазланнар чорына караган җәмигъ мәчете, аның янында гына ханнар зираты, кәрван-сарай хәрабәләре. Боларны тикшерүдә Фаяз Хуҗин да актив катнаша. Ә шәхсән үзе җитәкчелек иткән казылмаларда килеп чыккан һәм болгар археологиясендә әле һаман да бердәнбер исәпләнгән юрта калдыклары, бизәнү әйберләре ясаучыларның остаханәсендә табылган 6 килограмм чамасы гәрәбә, олуг кенәз Всеволод Зур Ояның кургаш мөһере, чүлмәк тоткасына уеп төшерелгән рун язмалары... Саный китсәң, бик күпкә җыела алар. Борынгы каланы уратып алган биш катлы саклау ныгытмаларын да Фаяз Хуҗин бик җентекләп тикшерә һәм туплаган материаллары нигезендә Олуг шәһәрнең тарихи үсешендәге төп этапларны билгели. 1987 елда Ленинградта (Санкт-Петербургта) зур уңыш белән яклаган кандидатлык диссертациясе Билярдәге 15 еллык казу эшләренә нигезләнгән була.



*Археологик казу эшләре вакытында*

Биләрдә ике дистә ел эшләү дәверендә (1974—1994) Фаяз Хуҗин фәндә үз урынын таба, коллегалары арасында, Казанда һәм Россия күләмендә, бәхәсләрдән курыкмый торган, үз фикерен һәрвакыт ышандырырлык дәлилләр белән расларга омтылучы кыю һәм принципиаль галим буларак таныла. Аның бу сыйфатлары фәндә әле дә бәхәсле (әмма Фаяз өчен түгел!) булып калучы Биләр-Болгар, ягъни болгар бабаларыбызның монголлар һөҗүменә кадәрге башкала проблемасын өйрәнгәндә бигрәк тә ачылып китәләр.

1980 еллар ахырында, бигрәк тә 1990 еллар башында Фаяз Хуҗин фәнни тикшеренүләренең диапазонын, тематикасын киңәйтеп җибәрә. Юк, Биләргә тугрылыклы булып кала ул. Әмма әлеге шәһәрнең тарихи язмышын тагын да тирәнрәк аңлау өчен башка болгар шәһәрләрен дә параллель рәвештә казып өйрәнергә кирәклеген сизеп ала. Коллегаларын үз тирәсенә җинел тупларга

сәләтле, тырыш, тәҗрибәле һәм кызыксынучан галим 1990—1994 елларда археологлар тарафыннан күптән инде онытылган Сувар, Җүкәтау һәм Чаллы (Балык Бистәсе районы) калаларына чыгып китә. Болгар чоры археологиясенә яңадан-яңа ачышлар өстәлә.

1994 елда остазы Альфред Халиков вакытсыз вафат булганнан соң әле яңа гына Казан Кремлендә башланып киткән экспедициягә җитәкчелек итү өчен кандидатуралар эзләгәндә дә иң беренче булып Фаяз Хуҗинга мөрәҗәгать итәләр. Аның кебек бай тәҗрибәле, коллегалары белән һәрвакыт яхшы мөгаләмәдә була алган тыйнак һәм таләпчән, шул ук вакытта Мәскәү, С. Петербург археологлары арасында да абруе булган галимнәр сирәк шул ул. «Аның белән эшләве җиңел. Масаймас, сүзендә торыр, авырлыкны һәрчак үз өстенә алырга тырышыр». Болар—аның коллегалары белән аралашканда еш әйтелә торган сүзләр.

Фаяз әфәнденең Казан кремлендәге эшчәнлегенә тукталсак, аерым китап язарга кирәк булыр иде. Шуңа күрә бу эшчәнлекнен—татарның йөзек кашы—нурлы Казаныбызга 1000 яшь булуын исбатлау белән тәмамлануын искә төшерү дә җитәр, дип уйлыйм. Ә моны дәлилләү өчен ярты дөньяны айкап чыгарга, архивларда, китапханәләрдә эшләргә, атаклы галимнәр белән очрашып сөйләшергә туры килде аңа. Һәм бер кечкенә генә ялгыш адым да ясалмады кебек. Ә аны көтеп торучылар, җае килеп чыгу белән изеп-сытып китәргә торучылар да юк түгел иде. Хәер, һәрберебез кайсы заманда, нинди илдә һәм җәмгыятьтә яшәвебезне беләбез ич.

Биредә мин Фаяз Хуҗинның гыйльми эшчәнлегенә төпле анализ ясауны максат итеп куймадым. Аның археология фәнендәге төп казанышлары Биләр һәм Казан белән бәйле булуы аңлашылгандыр дип беләбез. «Биләр культурасы» (Мәскәү, 1985), «Чирмешәндә Олуг шәһәр» (Казан, 1995), «Борынгы Казан замандашлары һәм тарихчылар күзлегеннән» (Казан, 1996), «Биләр—Олуг шәһәр» (Яр Чаллы, 1997), дигән китаплары шуны куәтлиләр. Әмма, шул ук вакытта, Суар, Җүкәтау, Алабуга, борынгы Чаллы һәм, гомумән, болгар археологиясенә багышланган күп санлы хезмәтләрен дә онытырга ярамый. Республикабыз территориясендә урнашкан археологик истәлекләрнең алты томлык җыелмасын төзүдә дә ул актив катнашты, бу хезмәте өчен, коллегалары белән берлектә, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек булды.

Галимнәр тормышында төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә катнашу, командировкаларга йөрү гадәти күренеш. Фаяз әфәнде дә эреле-ваклы конференцияләрнең берсен дә калдырмаска тырыша. Аның Мәскәү, Санкт-Петербург, Дүшәнбе, Казан, Уфа, Ижау, Самара, Пушкинские Горы (Псков өлкәсе), Суздаль кебек шәһәрләрдә ясаган чыгышлары тирән эчтәлекле, яңа фактларга бай булулары белән танылган Русия археологларының да игътибарын җәлеп иттеләр.

Табышларының әһәмиятен ачыклау, яңа фикерләрен, ачышларын дөньякүләм танылган галимнәргә ирештерү өчен чит илләрдә дә еш булырга туры килә аңа. Чехия, Германия, Австрия, Франция, Италия, Голландия, Венгрия, Болгария кебек илләрдә булып, Болгар-Казан тарихын һәм, димәк ки, үз халкыбызның тарихын олы бер дәрәҗәгә күтәргән галим ул.

Мәктәп укытучыларына Фаяз Хуҗин дәреслекләр авторы буларак таныш. Аның Г. Дәүләтшин һәм И. Измайлов белән берлектә язылган «Татарстан тарихыннан хикәяләре»н (Казан, 1993, 1994) укытучыларыбыз яратып кулланалар. Быел шулай ук югары уку йорты студентлары өчен «Татарстан археологиясеннән очерклар» дөнья күрәчәк. Бу дәреслекләрне әзерләүдә Фаяз Хуҗинның да өлеше зур.

Кыскасы, бик бәхетле археолог ул Фаяз. Әле берәүнең дә моңарчы үз гомерендә Биләр, Сувар, Җүкәтау, Чаллы, Казан кебек мәшһүр болгар калаларын берьюлы диярлек тикшергәне юк иде. Изге гамәлендә аңа гел уңышлар юлдаш булды.

**Нурулла ГАРИФ**

## Фаяз Хуҗин

# БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ— БЕЗНЕҢ МИРАС

Соңгы вакытта кайбер галимнәребез, Алтын Урда тарихы белән артык мавыгып китепме, монголларга кадәр яшәгән болгарлар турында онытып җибәрделәр кебек. Халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләсен тикшергәндә дә өстенлек безнең якларга монгол яугирләре белән килеп урнашкан татарларга бирелә, болгарларның ролен төрлечә киметеп күрсәтергә тырышалар. Имештер, алар, болгарлар, Алтын Урда чорында ук инде татарлар тарафыннан йотылып беткәннәр. Ә үзләре «килмешәк татарларның» чынлыкта кем булулары турында әлегә кадәр төпле фикергә килә алмыйлар. Берәүләр, аларны монгол телендә сөйләшүче халыктыр, диләр; икенчеләре, төрки телле кабиләләрдән оешкан, дип тәкърарлый. Татарлар борын заманнардан көчле халык булган, хәтта үзләренең мөстәкыйль дәүләтчелеген дә төзегәннәр диючеләр дә бар. Шулайдыр. Әмма бу фактларның берсе дә болгар чорын нindидер бер очраклы, эпизодик күренеш формасында гына карап, тарихыбыздан сызып ташларга нигез бирми.

Татар халкының килеп чыгышын өйрәнүчеләр кайвакыт мине «болгар теориясе тарафдарлары» исемлегенә кертеп куялар. Чынлыкта исә мин «алтын урталык»та торам, чөнки халкыбызның этногенезында болгарларның беренчел ролен таныган хәлдә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында килеп чыккан этник үзгәрешләрне дә инкарь итеп булмый. Болгар җирлегенә соңрак үтеп кергән татар, кыпчак, ногай, урыс һәм җирле фин элементларын (элементлар гына булса икән әле!) күрмәмешкә сабышу хакыйкатькә берничек тә туры килми. Әмма ләкин, ивануымча, болгарлар безнең, ягъни Урта Идел һәм Урал буе татарларының, төп бабалары булып кала. Болай дип әйтү заманында бөтен дөньяны дер селкетеп торкан, гаҗәеп дәрәҗәдә югары мәдәнияткә ирешкән Алтын Урда мирасыннан баш тарту дигән сүз түгел. Хак анысы, бу мирас бары тик безнеке генә түгел, дибез без (киләчәктә аны әле бүлгәли дә башларлар). Ә менә болгарлардан калган мирас—башлыча безнеке, татарларныкы.

Болгарлар тарихы белән нисбәтле рәвештә «цивилизация» төшенчәсен галимнәр бик сирәк куллана. Цивилизацияле халык, димәк, дәүләтле, матди һәм рухи культура үсешендә югары казанышларга ирешкән халык. Болгар халкы һәм аның культурасы бу билгеләмәгә туры киләме соң?

Узган гасырның икенче яртысы болгар фәнендә, бигрәк тә археологиядә, олы ачышлар чоры булды. Бу ачышлар, галимнәр тарафыннан тупланган яңа чыганаклар тарихыбызны тагын да тирәнрәк һәм объективрак итеп өйрәнүгә этәргеч бирделәр. Тарихчыларыбыз Болгар дәүләтенең Евразия илләре арасында тоткан урынын тулырак итеп күзаллый башладылар. Чыганакларны урта гасыр цивилизацияләре яссылыгында чагыштырмача планда өйрәнү «цивилизация» төшенчәсен бер дә шикләнмичә болгарларга карата да куллану мөмкинлеген күрсәтте.

Үзенең барлыкка килү моментыннан башлап диярлек, Болгар— замандашлары әлеге дәүләтне һәм аның башкаласын шулай атап йөрткәннәр— урта гасырлар цивилизациясенең иң атаклы һәм бай бер өлеше сыйфатында гарәп-фарсы географларының, урыс елъязмачыларының, Аурупа сәяхәтчеләренең һәм сәүдәгәрләренең игътибар үзәгендә торган. Бу бик яхшы аңлашыла, чөнки иң төньякта урнашкан мөселман дәүләте—Болгар иле тиз арада

халыкара сәүдә үзәге буларак таныла башлый. Әмма бу танылу һич тә Идел-Кама юлындагы уңайлы геополитик шартлар исәбенә генә түгел. Дәүләтнең халыкара сәүдәгә бик актив һәм чагыштырмача җиңел кереп китүенә, беренче чиратта, аның нык үскән икътисады, бигрәк тә авыл хуҗалыгы һәм һөнәрчелеге сәбәп булып торган. Шунысын да истә тотыйк: халыкара сәүдәдә катнашучы илләрнең икътисады, мәдәнияты, социаль-политик үсеш дәрәҗәсе бер-берсенә якын торганда гына дәүләтара мөнәсәбәтләрдә тигез партнерлык һәм үзара файдалы хезмәттәшлек хөкем сөрә ала. Болгар иле һәм аның сәүдә партнерлары (тауар ишләре), һичшиксез, бу җәһәттән бер-берсеннән калышмаганнар.

Эреле-ваклы шәһәрләре булу һәр цивилизациянең төп билгеләреннән санала. Безнең якларга 1235 елда ерак Венгриядән килеп киткән Юлиан исемле миссионер-монахның язмаларында, «Идел Болгарстаны—бай шәһәрләре белән данлыклы, көчле һәм бөек дәүләт», диелгән. Бу сүзләрдә бернинди арттыру да юк. X гасыр башларында ук инде болгар бабаларыбыз бик актив рәвештә шәһәрләр һәм хәрби ныгытмалар төзү эшенә керешәләр. Соңгы археологик ачышлар Болгар илен шәһәрләр цивилизациясе дип атарга җирлек бирәләр. Урта Идел һәм Кама буйларында, хәзерге административ бүленеш буенча караганда, Татарстан һәм Чувашия (биләмәләрендә) территориясендә, Ульяновск, Самара һәм Пенза өлкәләрендә табылган болгар шәһәрләренең саны 170 кә җитә. Аларның өч дистәдән артыгы чын, олы шәһәр калдыклары. Зурлыклары, димәк, халык саны буенча да, алар Русь һәм хәтта Аурупа калаларын узып китәләр.

Урта гасырлар цивилизациясенең гигант шәһәрләре арасында Биләр, һичшиксез, иң атаклыларыннан санала. Күренекле сәяхәтчеләрне, туристларны гына түгел, күпне күргән археолог-галимнәрне дә, иң әүвәл, борынгы каланың искиткеч зур мәйданда урнашкан булуы шаккаттыра. Ул үзенең төзелеше, планлашуы ягыннан караганда, нигездә ике өлештән торган. Озынлыгы 5 чакрымнан арткан биек үрләр һәм шул үрләр өстенә куелган агач стеналар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт диварлар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләгән. Ныгытмаларның озынлыгы 10 чакрымга сузыла. Аннан соң әле тышкы шәһәрне бөтен яктан диярлек «кочып» алган күп санлы бистәләр дә Биләрнең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән. Менә шуларның барысын да бергә кушып исәпләсәк, борынгы каланың гомуми мәйданы 800 гектардан да артып китүен күрербез. Биләрнең урыс елъязмаларында теркәлеп калган атамасы—Олуг шәһәр (Великий город). Исеме җисеменә бик тә туры килә. Әйе, күрше илләрдә дә зурлыгы ягыннан Биләргә тиң бер генә шәһәр дә булмаган.

Болгар хакимнәре яшәгән административ үзәк эчке шәһәрдә урнашкан. Биредә казып тикшерелгән архитектура ядкарьләре арасында иң кызыклысы, әлбәттә, Җәмигъ мәчете хәрабәләре. Аның агач өлеше (мәйданы 1400 квадрат метр чамасы) тарихи 922 елда төзелә башлагандыр, дип уйлыйбыз. Бераз вакыт үткәннән соң мәчетне киңәйтәләр, элеккесенең көнчыгыш ягына терәтеп ярым колонналар белән матур итеп бизәлгән, биек манаралы тагын бер мәһабәт таш бина торгызып куялар. Шулай итеп, мәчетнең гомуми мәйданы 2300 квадрат метрга җитә. Михраб ягы нәкъ кыйблага караган. Намаз укый торган залда 6 рәткә тезелгән 24 колонна булган.

Мәчеттән ерак кына түгел ике катлы кирпеч йорт урнашкан. Биредә болгарларның берәр атаклы дин әһеле, мәсәлән, шул ук мәчетнең имам-хатибы үз гаиләсе белән яшәп яткандыр, күрәсең. Читтәрәк тагын бер кирпеч бина—җәмәгать мунчасы. Шундый ук мунча «караван-сарай» тирәсендә дә казып тикшерелде. Алар идән астыннан үткәрелгән махсус каналлар аша килүче эссе һава белән җылытылган. Белгечләрнең фикеренчә, әлеге биналарның барысы да Шәрекъ илләреннән килгән осталар катнашында төзелгән.

Шунысын да әйтеп үтик: Биләрнең 1973 елда төшерелгән аэрофоторәсемнәрендә (сурәтләрендә) әле тагын утызлап кирпеч йорт урыны ачык күренеп тора. Күпме байлык үзенең тикшерүчеләрен көтеп ята!

Әмма Биләр үзенең матур архитектурасы белән дан тоткан бердәнбер кала түгел. Суварда, мәсәлән, 1930 елларда ук инде кирпечтән салынган бай феодал йорты табылган иде. Кирпеч биналарны археологлар республикабызның Тәтеш районында урнашкан Хулашта, Самара өлкәсендәге Мөрәндә, Ульяновск өлкәсендәге Кызыл Сөндек шәһәрлегендә дә казып тикшерделәр. Үзләренең 1000 еллык юбилейларына әзерләнүче борынгы Казанда һәм Алабугада исә хәрби ныгытмалар XII гасырда ук инде таштан салынган булган.

Боларның барысы да Болгар илендә шәһәр төзелеше культурасының югары үсеше турында сөйләүче фактлар.

Сүз дә юк, урта гасырлар цивилизациясенең икътисади нигезен шәһәр һөнәрчелеге тәшкил итә. Бу өлкәдә дә болгарлар күршеләреннән калышмаганнар. Алай гынамы соң?! Тимерчеләр һәм бакырчылар, ювелирлар һәм күнчеләр, пыяла ясаучылар һәм кирпеч сугучылар, чүлмәкчеләр һәм башка һөнәр ияләре җитештергән югары сыйфатлы тауарлар дөнья базарында дан тоткан! Биләрдә тимер коючылар бистәнең бер гектар, чүлмәкчеләр бистәнең өч гектар җирен биләп торуы, XI гасырда ук инде тәрәзә пыялалары ясый башлау, металл эшкәртүдә, ювелирлык эшендә бик күп катлаулы ысуллар куллану һ. б. шундый күп санлы фактлар болгар һөнәрчелегенең үз вакыты өчен гаять югары дәрәҗәдә торуын дәлиллиләр.

Болгар бабаларыбыз рухи культура ягыннан да югары баскычта торганнар. Бу өлкәдәге казанышлар—урта гасырлар цивилизациясенең үзенчәлекле күренеше. Нәфис итеп сөяктән ясалган язу каләмнәре, кара савытлары, асылташлар белән бизәлгән китап тышлыгы, язулы йозаклар, тормыш-көнкүреш әйберләре, шахмат-шашка фигуралары—болары шул цивилизациянең археологиядә чагылыш тапкан бик кечкенә бер өлеше. Язма чыганаклардан исә, болгарларның әле X гасыр башларында ук мәчет-мәдрәсәләре, мәктәпләре барлыгы билгеле. Бу мәктәпләрдә ислам нигезләрен генә өйрәнеп калмыйча, математика, география, тарих, астрономия, медицина буенча да башлангыч мәгълүматлар укытылган. Сәләтле яшьләрне Бохара, Сәмәрканд, Нишапур, Балх, Багдад һәм башка шәһәрләргә җибәреп укытканнар. Биредә алар исемнәре Шәрекъ дөньясында киң танылган олы галимнәрдән белем алганнар. Шул яшьләр арасыннан үсеп чыккан Әбү Хәмид ибн Идрис әл-Болгари, Борһанетдин ибн Йосыф әл-Болгари, Сөләйман ибн Дауд әс-Саксини әс-Сувари, Таҗетдин ибн Хөсәен әл-Болгари кебек атаклы галимнәр дин һәм хокук белеме, медицина, фәлсәфә буенча күләмле хезмәтләр язып калдырганнар. Бу хезмәтләренең бер өлеше әле дә Таһран һәм Истанбул мирасханәләрендә саклана.

Кайбер чыганаклар күрсәткәнчә, болгарлар тарихка караган трактатлар да язганнар. Әбү Хәмид әл-Гарнатый исемле Андалусия сәяхәтчесенең китабында, мәсәлән, Йакуб ибн Ногманның «Болгар тарихы»ннан өзекләр китерелә. Монголларга кадәрге Болгар чоры әдәбиятының безнең көннәргәчә килеп җиткән җәүһәре—Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы—әлгәрге цивилизациябезнең чын көзгесе. Мондый әсәрне иҗат итү өчен шартлар урта гасырлар чорының бөтен яктан да югары үскән җәмгыятендә генә булырга мөмкин.

Табигый ки, матди һәм рухи культураның барлык өлкәләрендә диярлек шундый югарылыкка ирешелгән Болгар дәүләте үз кабыгына гына бикләнеп яши алмаган. Язма чыганакларга мөрәҗәгать итеп, Болгарстанның Азия-Аурупа мөнәсәбәтләре системасындагы урынын ачыкларга мөмкин. X гасырга караган Ибн Фазлан «Рисалә»сеннән болгарларның Гарәп халифәте белән бәйләнешләре турында һәм исеме билгесез Венгр тарихчысы язмаларыннан Биләр кешеләренең Дунай якларына китеп, анда Пешт шәһәренә нигез салулары, дәүләт хакимиятендә финанс эшләре белән җитәкчелек итүләре турында кызыклы мәгълүматлар алырга мөмкин.

XI гасырдан калган Скандинавия сагаларында «Вулгария» Гардарика-ның («Шәһәрләр иленең») бер өлеше буларак телгә алына.

XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Бәйхаки китабында болгар әмире Ибраһимның Хорасан патшасына Себзевар һәм Хөсрәүҗәрд шәһәрләрендә ике мәчет төзү өчен акча һәм бай гына бүләкләр җибәрүе турында язылган.

Шушы ук гасырның урталарында югарыда телгә алынган сәяхәтче әл-Гарнатый, Болгар илендә булып, аның шәһәрләрен, халкын, башыннан кичергән хәлләрне тасвирлап китап язып калдыра.

Ниһаять, монгол яулары алдыннан гына Биләргә Венгриядән Юлиан исемле монах килә. Язмаларыннан күренгәнчә, аның максаты болгарлар арасында яшәп ятучы кардәшләрен табып, аларны католик диненә күндерү була.

Әлеге чыганаклардан башка болгарлар турындагы хәлләрне Ибн Рөстә, әл-Истахри, әл-Масуди, Ибн Хаукал, әл-Мөкаддәси, әл-Марвази, әл-Идриси кебек шәрекъ язучыларының әсәрләреннән һәм дә борынгы урыс елъязмаларыннан күпләп табарга була. Әмма Болгар иленең күрше дәүләтләр белән багланышларын күрсәтүче язма чыганаклар аз. Шулай да багланышлар эпизодик характерда гына булган икән дип нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Өстәнөстән генә булса да археологик материалларны күздән кичерик.

Болгарстан һәм Шәрекъ илләре. Көньяк халыклары белән бәйләнешләр. Бу темага караган материаллар бик күп. Алар арасында очраклы рәвештә һәм казу эшләре вакытында табылган гарәп тәңкәләре, VIII-X гасырларда сугылган күп санлы көмеш дирһәм хәзинәләре, Урта Азиядән (Үргәнеч, Сәмәрканд, Мерв), Ираннан (Кашан, Рей), Һиндстаннан, Сүриядән, Византиядән китерелгән кыйммәтле савыт-сабалар, муенса төймәләре, бизәнү әйберләре ясаганда кулланыла торган лазурит, сердолик, гранат, тау хрустале кебек асылташлар һәм башка табылдыклар бар.

Биләрне һәм Мөрән шәһәрлеген казыганда килеп чыккан төсле витраж пыялалары, лампалар, савыт-сабалар Грузиядә, Әрмәнстанда, Византиядә эшләнгәннәр. Херсон һәм Таврия остаханәләрендә ясалган амфоралар да еш очрый. Пыяла савытларга салып ислемайлар һәм дарулар, амфораларда зәйтүн мае һәм төрле эчемлекләр алып килгәннәр. Шуны да әйтеп үтик: югарыда саналып киткән табылдыклар йөзләп, хәтта меңләп исәпләнә. Күрәсең, бу илләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре бик тыгыз булган. Моннан тыш әле язма чыганакларда әрмән келәмнәре, Византиядә һәм Әзербайҗанда җитештерелгән тукымалар, Сәмәркандтан китерелгән язу кәгазьләре телгә алына. Бу тауарларны зур-зур кәрваннар белән дөяләргә төяп ташыганнардыр, чөнки археологлар, кайсы гына болгар шәһәрен казымасыннар, дөя сөякләренә юлыгалар.

Болгарлар үзләре бу илләргә нәрсә сатканнар? Хәрәзмга чыгарыла торган кайбер тауарларның исемлеген әл-Мөкаддәси китерә, болар: эшкәртелгән тире, балык, бал, балавыз, сугыш кораллары, кыйммәтле җәнлек тиреләре, коллар һәм терлек.

Болгарстан һәм Аурупа илләре, Балтыйк буе, Скандинавия. Археология материаллары арасында Көнбатыш илләреннән китерелгән әйберләр чагыштырмача аз. Бу исемлектә Германиядә, Даниядә, Чехиядә сугылган акчалар бар. Казан Кремлен казыганда килеп чыккан 930 елгы чех акчасы уникаль табылдыклардан санала. Германиядә, хәзерге Бонн шәһәре тирәсендә X-XI гасырларда ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар (викинглар, норманнар) аша килеп кергәндер дип фаразлана. Бу кылычларга ULFBERHT дип остаханә хуҗасының исемен уеп язганнар, мәңгеләштер-гәннәр. Сирәк кенә булса да археологлар Скандинавиядән кергән бизәнү әйберләре табалар. Балтыйк буеннан китерелгән гәрәбә еш очрый. Әйтик, Биләргә килеп заказга эшләп яткан бер урыс ювелирының остаханәсеннән генә дә 6 килограммнан артык гәрәбә җыеп алган идек.

Шул ук Биләрдә һәм Пенза өлкәсендә табылган әйберләр арасында Лотарингиядә Аквитаниядә эшләнгән бакыр-көмеш савытлар бар. Аурупа илләрендә исә Болгарда җитештерелгән әйберләр мәгълүм түгел (дөресрәге, бу мәсьәлә белән махсус кызыксынучы да юк). Шулай да Швециядә, Норвегиядә, Финляндиядә, Даниядә, Польшада һәм Балтыйк буе дәүләтләрендә X гасырда сугылган болгар акчалары табылган. Профессор Иштван Федор мәгълүматлары буенча, мондый акчалар Венгрия музейларында да саклана икән.

Болгар иле һәм Русь дәүләте. Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып өйрәнгәндә, Киев Русендә һәм борынгы урыс кенәзлекләрендә ясалган әйберләр

бик күп очрый. Христианнарның муенга асып йөри торган тәреләре һәм иконалары, беләзек-йөзек ише бизәнү әйберләре, шифр дип атала торган шәмәхә төсендәге йомшак таштан ясалган орчык башлары, савыт-саба, йозаклар һәм башка төрле тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары урысларның болгар шәһәрләрендә күпләп яшәгәнлекләрен күрсәтәләр. Биләрдә, мәсәлән, христианнар өчен махсус зират та булган. Урыслар, күбесенчә, сәүдә эшләре белән йөргәннәр. Сугыш белән дә килгәннәр, әлбәттә.Элек-электән урыска җир җитмәгән. Болгарлар яшәгән бай һәм матур табигатьле Идел-Кама буйлары аларны гел кызыктырып, үзенә җәлеп итеп торган. Шундый талау сугышларының берсендә, 1183 елда Биләргә яу чапканда Владимир-Суздаль кенәзе Всеволод Зур Оя үзенең кургаштан ясалган мөһерен төшереп югалта. Без аны сигез йөз елдан соң 1978 елгы казу эшләре вакытында табып алдык.

Сугыш белән йөрергә болгарларның вакытлары булмаган, чөнки алар көне-төне тырышып иген иккәннәр, һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр, сәүдә эшләре белән дөнья иңләгәннәр. Менә болгар әйберләре табылган урыс шәһәрләренең тулы булмаган исемлеге: Киев, Новгород, Псков, Суздаль, Владимир, Мәскәү, Ярапольч, Залесский, Муром, Городец, Переяславль, Серенск, Вышгород, Гомель, Ростов, Белоозеро һәм тагын да ераграк Вычегда-Печора якларындагы дистәләрчә шәһәр-авыллар.

Эрерәк шәһәрләрдә болгарлар сату итеп кенә ятмаганнар, һөнәрчелек тауарларын урында җитештерүне дә җайга салып җибәргәннәр. Владимирда, мәсәлән, чүлмәк ясау осталары яшәгән. Биләрдән махсус чакыртылган төзүчеләр хәтта Владимир-Суздаль җирендә урысларга чиркәүләр дә салып биргәннәр. Һава шартлары аркасында уңышлы килмәгән елларны (ә андый еллар Русьта нишләптер еш кабатланып торган) болгарлар үзләренең ут күршеләренә корабларга төяп ашлык озатканнар һәм аларны, елъязмачы сүзләре белән әйтсәк, «күп тапкырлар ачлык һәм үлем тырнагыннан йолып калганнар».

Менә шулай. Язганнарымны тагын бер кат күңелеңнән үткәреп уйлап кара әле, хөрмәтле укучым! Сүз бит моннан 850—1000 еллар элек чәчәк атып яткан болгар цивилизациясе һәм аның казанышлары турында бара! Тезислар формасында тыйнак кына санап кителгән, һәм әйтер идем, барыбызга да таныш гап-гади фактлар. Әмма аларның һәрберсе зур мәгънәгә ия. Горурланырлык түгелмени болгар бабаларыбызның тарихы белән?! Без борын-борыннан дәүләтле халык ич! Мондый халык һич тә эзсез югала алмый. Әллә нинди империяләр составында яшәсә дә, тарихында күп төрле фаҗигале вакыйгалар кичерсә дә... Болгар цивилизациясеннән җимерелгән манаралар, аянычлы тарих кына калмаган, аның эзләре шул җирлектә яшәп калган халыкның геннарына күчеп дәвамчылык алган. Башкалабызның, аның белән бергә барлыкка килгән Алабуганың 1000 еллык юбилейлары гына да болгар мирасының әле бездә никадәр көчле икәнен күрсәтеп тормыйлармыни?

Баш тартырга хакыбыз бармы безнең шул бөек мирастан?

# ӘМИР МАМАЙ КЕМ БУЛГАН УЛ?

Урыслар, еш кына, татарларны Мамай токымы дип атарга яраталар. Гәрчә бу сүздә күбрәк сәяси төшенчә ятса да (ягъни, без урыслар, Мамайны җиңдек, татарны да җиңдек, имеш). Мамайның, татар урта гасыр тарихында, тирән эз калдырганына шөбһә юк.

Әмир Мамай, чыңгызлылар (бу очракта Жужи) нәселеннән булмаса да, Дивандагы дүрт бөек әмирнең берсе, һәм, шулай ук, бәкләрибәк, ягъни сугыш вакытында бөтен татар гаскәренең башлыгы булган. Алтын Урдада бәкләрибәк вәзирдән дә өстен саналып, ханга иң якын әмир исәпләнгән. Шуны өстәп әйтергә мөмкин, Әмир Мамай Бәрдибәк ханның кызына өйләнгән була. Шулай ук, Мамай, Алтын Урданың Кавказ, Кырымнан алып, бөтен көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш олысларын саклау вазифасын да башкарган.

Әмир Мамайның асыл нәселен, ыруын безгә бер генә чыганак та ачыкламый. Тик Э. С. Кульпин гына, бер нинди чыганак та күрсәтмичә, Мамайның бабаларын Чиннан килгән ниндидер хановин дип күрсәтергә тырыша. Әмма Глинский һәм тагын башка татар шәҗәрәләрен тикшергән А. А. Шенников, Мамайны Алтай якларыннан, монгол яулары белән килгән, төрки меркит ыруы белән бәйләп аңлата. Без А. А. Шенниковның фикеренә каршы килмичә, шулай да Мамайның асылын кыпчак бәйләренә дә бәйле булуы мөмкин, дибез.

Ничек кенә булмасын, XIV гасырда, Алтын Урдада төрле төрки кабиләләре татар исеме астында берләшеп, бер халык булып оешып килгән була. Шуның өчен, чыганакларда Алтын Урда халкы **татарлар** дип кенә исемләнә башлый. Татарда искелекне белдерүче, һәр кем белгән, «Мамай заманыннан калган» дигән бер гыйбарә дә сакланып калган. Димәк, бабаларыбыз халкыбызның бу бөек шәхесен онытмаганнар, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Билгеле булганча, Алтын Урдада IV гасырның 60 елларында фетнәчуалышлар көчәеп китә. Бу вакытта Алтын Урданың үзара көрәшүче ике «ханлыкка» бүленүендә Мамайның да роле зур була.

1359 елда Бәрдибәк хан үлгәннән соң, Алтын Урдада чуалышлар башланды, дигән фикер, Хаммер-Пургштальның җиңел кулы белән башлатылып җибәрелсә дә, дөреслектә, чуалышлар бераз соңрак, Хызыр хан үтерелгәннән соң башлана. Шулай да, Бәрдибәк ханнан соң җуҗиларның Бату тармагы «тәмамлана». Ханлыкка Җуҗи нәселенең башка тармаклары омтыла. Әлбәттә, фетнәләр өчен бу җитди бер сәбәп булып тора.

Бәрдибәк ханнан соң Көлнә, Нәүрүз һәм Хызыр ханнар идарәчелек итә. Бу ханнарны бөтен Алтын Урдада кабул итәләр. Алар исеменнән Хәрәземдә, Сарайда, Азак һәм Гөлстанда акча сугалар. Көлнә һәм Нәүрүз турында чыганаклар безгә исемнәреннән башка бер нәрсә дә теркәмәгәннәр. Безнең фикеребезчә, алар икесе дә Сарай шәһәрендәге әмирләр арасыннан чыккан булырга тиешләр. Ә менә Хызыр хан Күк Урдадан чакырып китерелгән, һәм Җужи (Урда-ичен) нәселеннән килгән хан була. Әмир Мамай бу ханнарның өчесенә дә буйсына, итагать итә.

Тик, 1361 елда Хызыр хан үтерелгәннән соң гына, тәхет өчен барган ыгы-зыгы Әмир Мамайны татарның эчке сәясәтенә кысылырга мәҗбүр итә. Аның кебек зур көчләргә ия булган, бөек әмир, башка төрле гамәлләр кыла да алмаган була.

Сарайдагы татар аристократиясе эчендә бердәмлек булмый. Үз араларыннан сайланган Көлнә белән Нәүрүзне үтерәләр. Тәхеттә көчле хан күрергә теләүчеләр Җуҗиның Урда исемле улыннан килгән Күк Урда идарәчеләрен ханлыкка чакыралар. Әмма, Сарай әмирләренең бер өлеше, Күк Урдадан килгән ханнарга буйсынырга теләмиләр. Шул ук вакытта, Алтын Урданың Ак Урда олысында да, башкалада да көчле хан булырдай чыңгызлы табылмый.

1361 елда Хызыр хан үтерелә һәм чуалышлар башлана. Әнә шулай ханнар тәхеттә озак утырмыйлар: йә үтерелә, йә куып җибәреләләр. Олыс

әмирләре Сарайдагы ханнарга буйсынмау юлын эзлиләр. Алтын Урданың Хәрәзем олысы акчаларына тик ислам символикасын гына басарга керешәләр. Сарай әмирләре чуалышларда актив роль уйный. Тәхет өчен Күк Урда һәм шәйбанилар олысындагы Җүжи нәселеннән килгән угланнар көрәш башлап җибәрә. Ак Урда олысында исә көчле Җүжи нәселе булмый. Шуның өчен Ак Урда әмирләре Мамай әтрафында берләшәләр. Ул заманны тасфирлаучы гарәп һәм фарсы чыганаклары вакыйгаларны бик буталчык аңлаталар. Ә урыс елъязмалары чуалышлар заманында барлыгы 10 ханның гына исемен «беләләр». Урыс елъязмалары белгән соңгы хан—Азиз хан. Шуна күрә бу вакытның сәяси тарихын реконструкцияләү өчен төп чыганаклар булып—татар нумизматика материаллары санала. Бөтен бу чыганаклардагы мәгълүматны тикшергәннән соң, вакыйгаларның барышы болайрак була. Хызыр хан 1361 елның язында үтерелгәч, бик кыска гына вакыт Тимер Хуҗа хан булып тора. Урыс елъязмалары «Тимер Хуҗаның ханлыгының җиденче көнендә төмән башлыгы Мамай гыйсьян итте» дип язып калдырганнар *(ПСЕЛ.—Т. 8.—С. 11)*. Урыс елъязмаларына Мамай шушы вакыйга белән килеп керә. Сәбәбе, безнеңчә, Тимер Хуҗаның Хызыр ханны үтереп, гаделсезлек белән тәхеткә утыруы булса кирәк. Фикеребезне моннан соңгы булып узган вакыйгалар да раслый. Тимер Хуҗадан соң, Урда Мәлик ханлык итеп күтәрелә. Аның исеменнән Азакта да акчалар сугалар. Моннан аңлашылганча, Мамай Урда Мәликкә итагать иткән. Урда Мәлик, шулай ук, Күк Урдадан килгән була. Әмма ул да тәхеттә озак утыра алмый. Аның урынына, үзен мәрхүм Җанибәк ханның улы дип игълан иткән Килдебәк утыра. Мамай Килдебәк ханны да кабул итә. Әмма Сарай әмирләре Килдебәккә каршы көрәш башлап җибәрәләр һәм Хиҗри белән 763 (31.10. 1361—20.10.1362) елда аны Сарайдан куалар. Урыс елъязмаларында бу хакта: «Сарай әмирләре Мурат исемле ханны игълан иттеләр»,—дип язып үтелә. Акчаларыннан күренгәнчә, Килдебәк Азак шәһәренә кача. Мурат хан 1362 елның җәендә, дошманының гаскәрләрен тар-мар китереп, Килдебәкнең үзен үтерүгә ирешә. Аңлашылганча, әмир Мамай бу сугышларга катнашмый. Әмма бераздан Мамай Мурат ханга буйсынудан туктый. Ул үзенең олысында яңа Алтын Урданың ханы буларак Абдулла исемле ханны игълан итә. Чыганаклар Абдулланы Мөхәммәт Үзбәк ханның нәселеннән дип күрсәтәләр.

Мамай әмирнең бу адымы, безнеңчә, Морат ханның алып барган сәясәтенә бәйле. Беренчедән, Күк Урдадан килгән ханнарга буйсынырга теләмәгән әмирләргә каршы, Морат ханның репрессив сәясәте Мамай әмиргә дә куркынычлык тудыруы мөмкин. Икенчедән, сарай әмирләренең фетнәчел сәясәте илне тарката башлый. Өченчедән, Ак Урда олысындагы әмирләр, үзләренең арасыннан берәрсен тәхеткә хан итеп утыртырга телиләр.

Бөек әмир, зур җирбиләүче, шулай ук чикләрне саклаучы буларак, әмир Мамай Алтын Урдада һәркем тарафыннан кабул ителгән, көчле ханның тәхеттә утыруын теләгән була. Фетнә, чуалышлар аның кебек әмирләрнең зарарына гына эшли.

Гаскәрен җыеп, Мамай Сарай шәһәренә юнәлә. 1362 елда сарайдан Моратны куып чыгара һәм Абдулланы хан буларак игълан итә. Әмма Абдуллага Сарайда озак утырырга туры килми һәм ул сарайны калдырып, кире Мамай олысына китә. Аннан соң тәхеттә, сугылган акчаларыннан күренгәнчә, Әмир Булат, Азиз Шәйх, Толынбәк ханым, Каганбәк, Туктамыш, Ырыс, Гарәп Шах һәм яңадан Туктамыш хан утыра.

Мамай берничә тапкыр Сарайны кулга төшерә, әмма озак кулында тота алмый. Нигә? Юкса, Ак Урда олысын тулысынча үз йогынтысында тота. Урыс кенәзлекләре, шулай ук, Мамай урдасындагы ханнарга буйсынып торалар. Мамайга каршы көрәшкән Күк Урдадан килгән угланнарның да бит гаскәре зур булмый.

Безнеңчә, монда Мамайның гаскәре аз булуда, йә исә Мамайның начар гаскәр башлыгы булуында түгел. Мәсьәлә бераз катлаулырак торган күрәсең. Мамай, татар дәүләтенең чикләрен дә сакларга тиеш булган. Моңа өстәп, Ак Урданы да идарә итү, урыс олысын һәм Кырымдагы итальян колонияләрен контрольдә тотуын да онытмыйк. Ак Урданың чикләре Кавказ, Кара диңгез һәм Көнбатышта Мажарстан, Польша һәм Литва белән чиктәшлек иткән була. Нәкъ менә шушы көнбатыштагы христиан дәүләтләре, Алтын Урдада чуалышлар башлангач, татарларга каршы золым, басып алу сәясәте үткәрә башлыйлар.

Бигрәк тә, көтүчелек белән көн күрүче валаш-молдован кабиләләре вәхшилекләре белән аерылып торганнар. Мамай аларга каршы аяусыз көрәш алып бара. Шуның өчен, Мамай әмирне Такиәддин Әл Мухибби: «Сугышучы, ярдәмче, кайгыртучы, житәкче, мөэминнәрнең кылычы, исламның һәм мөселманнарның даны, гази һәм жихад итүче, гаскәрләрнең башлыгы» *(СМИЗО.—Т. I.—С. 350)* дип олылый.

1362—1363 елларда Литва кенәзе Ольгерд Киевны ала һәм Подолиядә өч татар әмиренең гаскәрен тар-мар итә. Берничә ел каты көрәштән соң, татарларны Днестр һәм Прут елгалары буеннан да кысрыклап чыгаралар. Татарлар күп сугышлар белән тик Дунай елгасының түбәнге өлешләрен генә саклап кала алалар. Литвалылар һәм молдованнар басып алынган жирләрдә татарларны кырып бетерәләр. Чәчәк атып утыручы татар шәһәрләре урынында жимерек харәбәләр генә кала. Бүгенге көндә, ул берничә татар исемнәре йөрткән жирләрдә шәһәр һәм Добружада татар авыллары гына сакланып калган.

Тәхет өчен көрәштә көндәшләр күп булганлыктан, Мамай үз олысын ныгытырга керешә. Бөтен Ак Урда әмирләре аңа буйсына. Аларны берләштерер өчен, Мамай башта Абдулланы хан итеп тота, ә соңыннан Мөхәммәт исемле угланны хан итеп игълан итәләр. Вакыйганы урыс чыганаклары да теркәп калдырганнар. *(ПСРЛ.—Т 33,—Л.: Наука, 1977.—С. 86).* Абдулла ханның исеменнән сугылган акчалар Хижри белән 770 елда (16. 08. 1368—4. 08. 1369) бетә. Шушы ук елда Мөхәммәт хан тарафыннан сугылган акчалар да бар. Димәк, Мөхәммәт хан Абдулланы 1369 елның жәендә алыштырган. Акчаларыннан күренгәнчә, Мөхәммәт хан Мамай урдасында хижри белән 777 елга (2. 06. 1375—20. 05. 1376) чаклы идарә иткән *(Федоров-Давыдов Г. А. Клады джучидских...—С. 143—163).*

Мөхәммәт ханнан соң Мамай олысында кемне хан итеп күтәргәннәре хакында һәм язма һәм нумизматика чыганаклары безгә беркемне дә белдерми. Фәндә моны төрлечә тасвирлаучылар бар. Эш шунда ки, кайсыбер ярлыкларда Тулунбәк исеме телгә алынган, ә берничә елъязмаларда Теләк исеме теркәлгән *(Егоров В. Л. Золотая Орда перед Куликовской битвой // Куликовская битва.—М.: Наука, 1980—С. 208, 209).*

Безнең фикеребезчә, Мөхәммәт ханнан соң, Мамай беркемне дә хан итеп күтәрми, ә үзенең хатыны (Бәрдибәк ханның кызы) Тулунбәк ханым исеменнән идарә итә башлый. Алдарак Сарай ханнары арасында Тулунбәк ханымны искә алган идек инде. Безнең фикеребезчә, монда бер шәхес турында сүз бара.

Бу сәяси үзгәрешләрнең сәбәпләрен чыганаклар, шулай ук, ачыкламыйлар. Сарайны кулда тота алмаган, әмир Мамай үз урдасында акча бастыра башлый. Ана чаклы татар ханнары һичбер заман урдада акча сукмаганнар. Мамай ханнары турында без менә шушы урда акчалары булганга яхшы беләбез дә инде. Тик менә, Мөхәммәт ханнан соң Урдада, ни башка Ак Урда шәһәрләрендә дә яна хан исеменнән акча сугылмый. Моның сәбәпләре, безнеңчә, Ак Урдада көчле жужи нәселе булмавына бәйле. Бердибәк ханнан соң Бату хан нәселе бетә. Ә ниндидер Мөхәммәт Үзбәк ханга, йә Җанибәк ханга кардәшлектә булган угланнар татарлар тарафыннан кабул ителмиләр. Ә Мамайга Алтын Урданы берләштереп булмаса да, Ак Урданы таркатмаска кирәк була. Чөнки әгәр Ак Урда таркалса, көнбатыштагы дошманнар татарларны басып алырга тырышачаклар.

Алда күргәнебезчә, Мамай Күк Урдадан килгән беренче ханнарны кабул итте, әмма соңгыларының үзара көрәше һәм Ак Урда әмирләре тарафыннан кабул ителмәүләре Мамайны татарның эчке сәясәтенә катнашырга мәжбүр итә. Әмма ни Абдулланы, ни Мөхәммәтне Сарай әмирләре дә, Күк Урда һәм Шәйбани олысларының әмирләре дә кабул итми. Ихтимал, Ак Урда халкы ул ханнарны кабул итеп бетермәгәннәрдер. Шуның өчен, Мамай Сарай шәһәре өчен көрәшне 1376 елдан соң тулысы белән туктата *(СМИЗО.—Т. I.—С. 391).* Ә Ак Урдада, элекке ханнарның авторитетына таянарак, Бәрдибәк ханның кызы исеменнән идарә итә башлый.

1374 елда Хажи Чәркәс Мамайны жинә һәм сарайдан куып чыгара. Моннан соң Мамай тулысы белән урыс олысы мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Эш шунда ки, Мамай Хажи Чәркәстән жинелгәннән соң, урыс кенәзләре әмирнең ханнарына буйсынмаска омтылалар. Мамай, урыс олысында башбаштаклыкларга юл куймаска кулыннан килгәнне эшли.

Баскак институты бетерелгәч, Мөхәммәт Үзбәк хан заманыннан башлап,

татарлар урыс олысында таяныч буларак, Мәскәү кенәзлеген алга чыгара башлыйлар. Бөтен бөек кенәзләр арасыннан, Мәскәү кенәзенә «урыс олысынын бөек кенәзе» дигән ярлыкны күпчелек вакытта бирәләр. Шунын өчен, Мәскәү кенәзенә татар ханынын легитим булуы бик мөһим булган. Ә Мамайнын ханнары Урдада яши, Урдада акча суга.

Бу вакытта татар аристократиясе эчендә яна идеология ныклап утыра. Илне берләштерергә, башбаштаклыкны, фетнәләрне туктатырга, тәхеткә көчле Жүжи нәселеннән килгән кешене утыртырга кирәк дигән фикер үзара көрәшүче татар углан-әмирләрен берләштерә башлый. Бу вакытта Алтын Урдада, Жүжи династиясенә караган Урда-ичән, Тука-Тимур һәм Шәйбани нәселләре иң алдынгы карашлы вә көчле саналган булалар. Шулай да, беренчелеккә Урда-ичән нәселе чыга. Сарай әмирләре дә бу Күк Урда идарәчеләрен яклый, һәрхәлдә, бу процесс башка татар олысларында да, шулай ук Ак Урдада (бигрәк тә шәһәрләрендә) тамыр җибәрә һәм урыс олысына да ныклап тәэсир итә башлый. Бу идеология, аеруча Ырыс ханга һәм Туктамыш ханга хас була. Туктамыш хан, хиҗри белән 777—779 елларда, Сарайда хан булып утыра. Шулай ук, Мамайнын Хаҗи Чәркәстән җиңелүе дә бик көчле булырга тиеш. Чөнки, бу җиңелүдән соң, Мамай Сарай өчен ныклы көрәш алып бара алмый. Әлбәттә, болар барысы да анын авторитетын төшерә, һәм иң авыры, Мамайның сәясәтендә легитимлык юк диеп, анын белән эш итәргә теләмәүчеләрнең санын арттыра.

Туктамыш хан 777 (1376) елда тәхеткә утыргач, Мамай Мөхәммәт хан исеменнән акча суктыруны туктата. Чыганаклардан күренгәнчә, Гарәп шах та Туктамыш ханга ярдәм итә *(Марков А. К. Инвентарный каталог мусульманских монет императорского Эрмитажа.—СПб.—1986.—С. 479).*

Моны ничек аңларга соң? Туктамыш хиҗри белән 779 елда Сарайны калдырып китәргә мәҗбүр була. Ырыс хан белән сугышта яраланган Туктамыш ханны, Аксак Тимергә алып киләләр, һәм ул янадан көч җыеп, бөтен дошманнарын җиңеп, 782 елда (1380) бөтен Алтын Урданы берләштерүгә ирешә. Шулай ук, Ак Урданы да үз кулы астына ала. Ә Мамайның гаскәрләре сугышмыйча, Туктамыш ягына чыгалар. Мамай үзе үтерелсә дә, анын улы Туктамыш ханның әмирләре эчендә йөри. Соңыннан да, Ак Урдада Мамай токымы бөек татар аристократлары арасында яшәвен дәвам итә. Боларны ничек аңларга? Безнеңчә, бөтен мәсьәлә идеологиядә.

Үзенең урдасындагы ханнарның татарларны берләштерә алмаячакларын, татар аристократиясенең киң катламы, Ырыс хан, ә соңыннан Туктамыш хан янында тупланууларын күргән әмир Мамай, Ак Урданы таркатмаска, дошманнардан җирләрне сакларга, урыс олысын йогынтысыннан ычкындырмаска бөтен көчен куя. 1375 елдан соң, Мамайның Сарай ханнарына, башка татар олысларына каршы көрәшүен күрмибез. Ә 777 елда Мөхәммәт ханнан да баш тарткач, без шуны аңлыйбыз: әмир Мамай татарның эчке сәясәтеннән чыга һәм бәкләрибәк башкарырга тиеш булган эшләрне дәвам итә.

Әлбәттә, Мамай лидер була. Ак Урда лидеры. Шуның өчен, ул башка көчле лидер чыккач, яшәмәскә тиеш була. Куркыныч, әмма гадел канун. Чөнки дәүләтне саклап калу әһәмиятлерәк. Тик шәхесләр үзләрен милләтенә, диненә, Ватанына, халык кабул иткән лидерына корбан иткәндә генә дәүләтләр бөек көчле була. Бу тәгълиматны безнең бабаларыбыз яхшы аңлаганнар. Бөек әмир Мамай да моны яхшы белгән. Кем анын үткәргән сәясәтен татарга каршы дип әйтә ала?

Юк. Киресенчә, без Мамайның сәясәтен өйрәнгәннән соң, анын ничек иленә, халкына тугры булганлыгын аңлыйбыз.

Үзләрен гел татардан кыерсытылган (димәк, татар хаксыз имеш!) итеп аңлатучы урыс, молдован һәм башка тарихчылар тасвирлаган Мамай, бөтен гомерен Бөек татар дәүләтенең мәнфәгатьләренә хезмәт итүгә багышлаган. Анын алып барган яулары татар дәүләте күзлегеннән караганда, гадел һәм изге саналган һәм саналырга тиеш тә!

Бу бөек татар каһарманы, гаскәр һәм дәүләт эшлеклесе бөек шәхесләребез арасында үз урынын алыр дип өмет итәбез.

**Илнур МИРГАЛИЕВ,**
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*Тарих институты аспиранты*



Qərən tatar telendə
Коръән татар телендә

# 12—ЙОСЫФ (ЙОСЫФ) СҮРӘСЕ

**(Йосыф сүрәсе 111 аятьтән тора. Мәккә-и Мөкәррәмәдә иңгән. Сүрәнең башыннан ахырына кадәр Йосыф пәйгамбәребез турында сөйләнгәнгә күрә, шушы исемне алган.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

**1.** Әлиф. Ләм. Ра. Болар Китапның ап-ачык аятьләредер. **(2)** Сез аңласын дип, Без аны гарәп телендә, Коръән буларак, иңдердек. **(3)** *(Ий, Мөхәммәд)* Без сиңа бу Коръәнне вәхий итеп, яшәп узган кавемнәрнең хәлләре турында гүзәл сурәттә аңлатабыз. Шунысы хактыр ки, син моңа чаклы *(башкалар кебек үк, аларның хәлләре турында)* белми идең.

**4.** Бервакыт Йосыф атасына *(Ягъкубка)* әйтте:

—Атакаем, мин төшемдә унбер йолдыз белән Кояшны вә Айны күрдем. Алар миңа сәҗдә итте.

**5.**—Углым-балам,—диде атасы.—Сак бул! Төшеңне абыйларыңа сөйли күрмә. Юкса, алар синнән көнләшерләр, сиңа тозак кора башларлар. Чөнки шайтан *(көнчелек)* кешеләргә хәтәр дошман. **(6)** Болай булгач, Раббың сине сайлаячак, сиңа төш юрау хикмәтләре өйрәтәчәк һәм ике бабаң: Ибраһим белән Исхакка биргән нигъмәтләрен сиңа да биреп бетерәчәк икән. Раббың барысын да бик яхшы белеп торучы хикмәт ияседер.

**7.** Хактыр ки, Йосыф һәм аның абыйлары белән булган бу вакыйгада гыйбрәт-сабак алырга теләгәннәр өчен хикмәтләр бар. **(8)** Абыйлары әйтте:

—Йосыф белән төпчек энебезне *(Бинияминне)* атабыз бездән артык сөя. Гәрчә, без күбрәк һәм көчле булсак та. Чынында атабыз бик нык ялгыша *(ул безгә гадел түгел).*

*(Йосыф белән Биниямин бер анадан, абыйлары бүтән анадан туган иде.)*

**9.**—Йосыфны үтерергә кирәк яки аны ерак җиргә илтеп ташларга, адаштырырга кирәк. Шуннан соң атабыз йөзе белән безгә генә карап торыр. Ахырда *(тәүбә итәрбез дә),* игелекле кешеләр булып китәрбез.

**10.** Арадан берсе: «Әгәр бу эшне башкарырга булсагыз, сез Йосыфны үтермәгез, коега ташлагыз. Узып баручы *(кәрвандагыларның)* берәрсе аны табып алыр»,—диде.

**11.** Әйттеләр:

—Ий, атабыз! Син ни өчен Йосыфны безгә ышанып тапшырмыйсың? Без аңа бары тик игелек кенә телибез. **(12)**

—Иртәгә син аны безнең белән *(сәхрәгә)* җибәр: рәхәтләнеп *(ашап-эчеп),* уйнасын. Шикләнмә, без аны *(бәла-казадан күз карабыз кебек)* саклarбыз,—диделәр. **(13)** Ата кеше әйтте:

—Аны алып китсәгез, миңа читен булыр. Сез абайламаган чакта аны бүре ашап китсә, дип куркамын. **(14)** Әйттеләр:

—Без куәтле жегетләр *(шушы кадәр дә күп кеше)* була торып, аны бүре ашап

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

китсә, әлбәттә, бу зур кимчелек булыр иде *(ояты гына ни тора!)*

**15.** Аны алып китеп, кое төбенә салырга карар кылганнан соң, Без Йосыфка вәхий күндердек:

—Һичшиксез, син кайчан да булса, аларга бу кылмышлары турында сөйләп бирерсен, ләкин алар сине танымас,—дидек.

*(Күлмәген салдырып, абыйлары Йосыфны коега ташлый.)*

**16.** Кич җиткәч, елый-елый аталары янына кайттылар. **(17)**

—Ии, атабыз,—диделәр.—Без әйберләребезне Йосыф янында калдырдык та, ярышка-узышырга киттек. *(Әйләнеп килсәк, ни йазык ки)* аны бүре ашап киткән. Дөресен сөйләсәк тә син безгә ышанмассың инде.

**18.** Йосыфның бүтән төрле канга буялган күлмәген ата кешегә тоттырдылар. *(Ягъкуб канга буялган күлмәкне алып йөзенә каплады: «Моңа чаклы шушындый да рәхимле бүрене күргәнем булмады. Улгымны ашаган, күлмәген ертмаган да»,—диде. Алдаганнарын ул шуннан сизенде һәм әйтте):*

—Сезнең мәкерле нәфесегез яман эшне яхшы итеп күрсәткән. Хәзер миңа олпатлык белән сабыр итәргә генә кала. Сез миңа төшендереп бирдегез: миңа ярдәм *(сезнең тарафтан түгел)* бары тик Аллаһтан гына киләчәк.

**19.** Бер кәрван туктады; су алып килергә хезмәтчене коега җибәрделәр. Ул чиләген коега төшерде. Йосыфны күргәч:

—Сөенче! Менә сиңа бер углан!—диде. Аны сатып җибәрер өчен, хәзинә кебек саклап алып киттеләр. Аллаһ аларның ни кылганын бик яхшы белә иде. **(20)** Аны арзан гына бәягә, берничә дирхәмгә сатып җибәрделәр. Сатулашып тормадылар. **(21)** Аны сатып алган Мисыр кешесе хатынына әйтте:

—Моңа игътибарлы ул! Яхшылап бак!—диде.—Күнелем сизә, без аннан файда күрәчәкбез. Һич югында без аны уллыкка алырбыз.

Менә шулай итеп, Без *(Мысырда гаделлек белән идарә итсен өчен)* төшендә күргәннәрне тормышка ашыру өчен, төш юрау хикмәтләрен өйрәтер өчен, аны шундый җиргә урнаштырдык. Аллаһ үз әмерен җиренә җиткезеп үтәрдәй кодрәт иясе. Ләкин кешеләрнең күбесе бу турыда белми.

*(Риваятьләргә күрә, хәзрәти Йосыфны үзенә алган зат Мысырның мал белән сәүдә итү эшләренең башлыгы иде. Ул Йосыфның зиһенле һәм сәләтле бала икәнен сизенә. Алга таба ул аны дәүләт эшләрендә файдаланырга уйлый иде. Балалары булмау сәбәпле, сөекемле Йосыфны бу гаиләдә бик сөеп каршылыйлар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**22.** Балигъ булганына чаклы аңа хөкем эшләрендә уңыш казанырлык гыйлем бирдек. Менә шулай итеп, Без гүзәл холыклыларны бүләклибез. **(23)** Өйнең хуҗабикәсе нәфесен Йосыф белән канәгатьләндерергә теләп, ишек-капкаларны бикләтте һәм:

—Яныма кил,—диде.

Йосыф әйтте: —Аллам сакласын!—диде.—Ирегез минем хуҗам. Ул миңа яхшылык кылды. Хактыр ки, кәферлек кылганнар бәхеткә ирешмәс. **(24)** Хатын тәкатьсез рәвештә Йосыфны тели иде. Раббының *(зина кылуның зур гөнаһ икәнен)* дәлилен күрмәгән булса, аны явызлык һәм нәҗес гамәлләрдән коткарырга теләвен сизенмәгән булса, бәлки Йосыф та бу хатынны теләгән булыр иде. Шик юк ки, ул ихлас колларыбыздан иде. **(25)** Икесе дә ишеккә таба йөгерде. Хатын аның күлмәгенең арткы итәген ертып төшерде. Ишек төбендә алар хатынның ире белән очрашты. Хатын әйтте:

—Синең гаиләңә зыян салырга теләгән кешенә нинди җәза кирәк? Зинданмы, әллә чыдап булмас җәзамы?—диде.

**26.** Йосыф: —Ул мине аздырырга теләде,—диде.

Хатынның туганнарыннан берсе шаһитлек итте:

—Әгәр аның күлмәге алгы яктан ертылган булса, хатын дөресен әйткән булыр. Бусы исә ялганлаган булыр,—диде. **(27)**—Әгәр күлмәк арткы яктан ертылган булса, хатын ялганлый. Бусы исә дөресен әйтә. **(28)** Күлмәкнең арткы тарафтан ертылганын күргәч, *(хаким)* хатынына:

—Шик юк ки, бу сез—хатыннарның мәкерле тозагыдыр. Чыннан да, сезнең тозак иң шәп каптыра торганнардан була,—диде. **(29)**—Әй, Йосыф! Син моны башкаларга сөйләмә. Ә син, хатын, гөнаһың өчен гафу үтен. Чөнки син

гөнаһлы булдың. **(30)** Шәһәр хатыннары әйтте:

—Газизнең хатыны егетне аздырырга уйлаган. Ул Йосыфка муеныннан гашыйк икән. Ул, чыннан, да мәхәббәтеннән тилергәндер,—диделәр. **(31)** Шәһәр хатыннарының гайбәтен ишетеп, хуҗабикә аларны кунакка алдырды: янтаеп, *(терсәкләр белән таянып)* истирахәт кылыр өчен, ястыклар-мендәрләр әзерләтте. Аларның һәрберсенә пычак бирдертте. *(Хатыннар пычак белән җимеш кисә башлауга ук, хуҗабикә Йосыфка):*

—Бар, алар янына чык!—дип боерды.

Йосыфны күргә, хатыннар аның мәһабәт икәнен аңладылар.

*(Үзләрен белештерми)* бармакларын турыйлар иде. Һәм әйттеләр:

—Йа, Раббым, сөбхәналла, бу адәми зат түгелдер, бу мәһабәт бер фәрештәдер,—диделәр. **(32)** Шуннан соң хуҗабикә әйтте:

—Менә, шуның аркасында сез минем гайбәтемне саттыгыз. Әйе, мин нәфесемне аның илә канәгатьләндерергә уйлаган идем. Ләкин ул бу эштән катгыян баш тартты. Әгәр дә ул минем теләгемне үтәмәсә, һичшиксез, зинданга атылачак; һәм, әлбәттә, мәсхәрә кылынып *(сарайдан)* сөреләчәк,—диде. **(33)**—Йа, Раббым,—диде Йосыф.—Минем өчен зинадан зиндан яхшырак. Әгәр дә алар корган хәйләләрдән мине коткармасаң, мин аларга тартылып, акылдан *(юлдан)* язганнар арасында калырмын. **(34)** Раббы аның догасын кабул итте. Тегеләрнең хәйләсен җимерде. Аллаһ барысын да ишетеп, яхшы белеп тора. **(35)** *(Гаепсез икәнен белсәләр дә, гайбәтчеләрнең авызын томалар өчен, хуҗабай хатынының күңеле булсынга, дип)* Йосыфны вакытлыча зинданга ташларга булдылар. **(36)** Аның белән бергә зинданга тагын ике егетне утырттылар. Шуларның берсе әйтте:

—Мин төшемдә шәраб ясаганымны күрдем,—диде.

—Мин баш очымда ипи күтәреп барам икән дим. Ипиемне кошлар чукый, имеш,—диде икенчесе.—Төшебезне юрап бир. Без сине бик игелекле кеше, дип уйлыйбыз. **(37)** *(Йосыф)* әйтте:

—Безгә һәр көнне китерелә торган аш килеп җиткәнче, мин, һичшиксез, төшегезне юрармын,—диде.—Бу—Раббымның өйрәткәннәреннәндер. Хактыр ки, мин Аллаһка ышанмаган халыктан еракка киттем. Ахирәт көнен инкарь итүчеләр дә алар. **(38)** Бабаларым Ибраһим белән Исхак һәм атам Ягъкуб тоткан динне тотамын. Һичбер нәрсәне, һичбер кемне Аллаһ белән тиң күрергә ярамый. Бу—Аллаһның безгә—инсаннарга биргән бәрәкәтедер. Тик кешеләрнең күбесе *(Аллаһка)* шөкер итми. **(39)** Әй, зиндандашларым, төрле уйдырма тәңреләргә ышану яхшымы, әллә беркемнең дә көче җитәлмәс, бердәнбер Аллаһка инануммы? **(40)** Аллаһтан башкаларга табынуыгыз сезнең аталарыгыз уйлап чыгарган берничә исем генә бит. Аллаһ аларга бернинди дә вазифа бирмәде. Хөкем бары тик Аллаһ ихтыярында. Ул Аллаһтан башкасына гыйбадәт кылмаска әмер итте. Менә, иң дөрес дин шул булыр. Ләкин инсаннарның күбесе моны белми. **(41)** Әй, зиндандашларым, *(төшләрегез турында әйтим)* берегез *(баштагы кебек ук)* хуҗабайга шәраб эчерәчәк; икенчегезне исә асып куячаклар һәм козгыннар аның башын чукып, тамак туйдырыр. Сораганнарыгызны юрау шушының белән тәмам булды. **(42)** Зинданнан котылачагына ул әйтте:

—Хуҗабаең янына кайткачтын, син мине исенә төшер *(бәлки ул мине зинданнан коткарыр)*,—диде. Ләкин шайтан *(ул әйткәннәрне)* онытырды. Шуңа күрә, Йосыф берничә елга зинданда кала бирде.

**43.** Бервакыт Мысыр падишасы әйтте:

—Мин төшемдә җиде арык сыерның җиде симез сыерны ашаганын күрдем. Аннан соң җиде яшел башак белән җиде коры башак күрдем. Яраннарым, юрый алсагыз, төшемне юрап бирегез,—диде. **(44)** *(Юраучылар)* әйтте:

—Болар төш түгел, бары тик саташу гына,—диделәр.—Без мондый буталчык төшләрне юрый алмыйбыз.

*(«Өч төрле төш була икән. Аллаһ тарафыннан җибәрелгән төш, киная, читләтеп кисәтү төше. Нәфес теләге чакырган төшләр. Шайтан тарафыннан төшкә кертелгән котырту, юлдан яздыру, саташулар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**45.** Зинданнан котылган кеше байтак вакыттан соң Йосыфны исенә төшереп әйтте:

—Мин сезнең төшегезне юрата алам,—диде.—Мине зинданга алып барыгыз. **(46)** *(Зинданга кергәч, ул)* әйтте:

—Әй, Йосыф, син тугры сүзле кеше. Җиде арык сыерның җиде симез сыерны ашавы турында, җиде яшел башак белән җиде коры башак турындагы төшне юрап бирсәнче,—диде.—Юравыңны кайтып кешеләргә сөйләрмен, бәлки, алар да *(синең изге икәнеңне)* аңлар. **(47)** Йосыф әйтте:

—Җиде ел тоташтан гадәттәгечә иген игегез. Аз микъдарда гына ашап, калганын башакта *(эскертләрдә)* калдырыгыз. **(48)** Шуннан соң җиде ел рәттән ачлык булыр. Эскерттәге ашлыкны орлыклык кына калдырып, җиде ел буена ашагыз. **(49)** Шуннан соң тагын бер ел киләчәк, ул елда инсаннарга *(Аллаһтан)* мул яңгыр явачак һәм ул елда *(җимеш сутлары белән үсемлек мае)* сыгып, *(сыер, кәҗә, дөя, сарыкларны)* савыгыз.

*(В. Пороховада: и будут выжимать (и масло, и вино себе на благо.) И. Крачковскийда: они будут выжимать, дип кенә язылган. Ш. Ногманида: җимешләр сыгып, шәраблар ясарлар. Т. Кочигит, Х. Караман тәфсирләрендә исә фәкать җимеш суты сыгу, ширбәт алу турында гына әйтелә. Мәүланә М. Алидә: давить виноград, диелгән. Х. Чантайда киңрәк аңлатыла. Без Х. Чантай тәфсирен мәгъкуль күрдек.)*

**50.** Бу юраманы сөйләгәч, падишаһ әйтте:

—Аны минем янга алып килегез,—диде.

Йомышчы зинданга кергәч, Йосыф әйтте:

—Падишаһ янына кайт: бармакларын пычак белән турый башлаган хатыннарга ни булды?—дип сора. Шик юк, Аллаһым аларның хәйләсен бик яхшы белеп тора. **(51)** Падишаһ хатыннарга әйтте:

—Йосыф белән ләззәт кичәргә теләгән чагыгызда сез нинди халәттә идегез?—диде.

Хатыннар әйтте:

—Аллам сакласын, без аннан һичбер яманлык күрмәдек,—диделәр.

Газизнең хатыны әйтте:

—Бүген дөреслек уртага чыкты. Мин аны аздырырга маташтым. Шик юк ки, ул—гадел кеше,—диде. **(52)** Йосыф әйтте:

—Газиз өйдә юк чакта аңа хыянәт итмәгәнемне вә Аллаһның чын хаиннәр корган хәйләсен юкка чыгарачагын барысы да белеп торсын,—диде. **(53)** *(Хатын әйтте):*

—Мин үземне акларга тырышмыймын, чөнки нәфесеңне тыя алмау яманлыкка этәрә, әгәр дә Аллаһ сакламаса. Шик юк ки, Раббым ярлыкаучы, гафу кылучы. **(54)** Падишаһ әйтте:

—Аны монда алып килегез,—диде.—Мин аны үз яныма аламын.

Аның белән сөйләшкәч:

—Бүгеннән син янымда югары дәрәҗәле һәм ышаныч казанган вазифалы кеше саналырсың,—диде. **(55)** Йосыф әйтте:

—Мине өлкәнең җир байлыкларына *(иген басуларына)* башлык ит. Мин аларны яхшы сакларымын, чөнки мин бу эшләрне яхшы беләм,—диде. **(56)** Менә шулай итеп, Без Йосыфны үзе теләгәнчә гамәл кылырлык вазифалы иттек. Үзебез ихтыяр иткән һәр кешегә рәхмәтебезне бирдек. Игелек кылганнарның игелекләрен заяга чыгармыйбыз. **(57)** Иман китереп, яманлыклардан сакланганнар өчен Ахирәт бүләге тагын да хәерлерәк. **(58)** *(Ачлык елны Ягъкубның уллары икмәк сорап, Мысырга килде.)* Йосыфның кардәшләре килеп, аның хозурына керде. Йосыф аларны таныды. Алар аны танымады. **(59)** Йөкләре төялеп беткәч Йосыф әйтте:

—Бер атадан туган энегезне минем янга алып килегез,—диде.—Күреп торасыз бит, мин сезгә дөрес үлчәтеп бирдем. Мин кунакчылларның иң юмарты. **(60)** Әгәр аны минем янга алып килмәсәгез, кабат мин сезгә бер үлчәм дә *(ашлык)* бирәчәк түгелмен. Кабат килеп йөрисе булмагыз! **(61)** Әйттеләр:

—Аны атабыздан сорап алырга тырышырбыз. Әлбәттә, без моны эшләячәкбез,—диделәр. **(62)** Йосыф буйсынар егетләренә әйтте:

—Ашлык өчен биргән тауарларын *(акчаларын)* йөкләре эченә яшереп куегыз. Өйләренә кайтып җиткәч, алар шул тауарларны табып алыр да, бәлки, янадан *(икмәк сатып алыр өчен)* монда килерләр,—диде.

*(Тәрҗемаләрдә дә, тәфсирләрдә дә күбрәк «мал», «тауар» сүзе кулланыла. Ягъни, Ягъкуб балалары икмәккә алмаштырыр өчен Йосыфка акча урынына соңгы зиннәтле әйберләрен алып килгән. Акча сүзе күчермә мәгънәдә генә йөри булса кирәк.)*

**63.** Ата кеше янына кайтып җиткәч, әйттеләр:

—Ий, атабыз, икмәк алу юлы безгә ябылды. Энебезне *(Биниаминны)* безгә ияртеп җибәрсәң генә, безгә икмәк бирерләр. Без аны яхшы сакларбыз,— диделәр. **(64)** Ягъкуб әйтте:

—Моннан алда да кардәшегезне ышанып тапшырганым кебекме?—диде.— Монысын да шулай итеп сезгә ышанып тапшырыйммы? *(Мин аны фәкать Аллаһка гына ышанып тапшыра аламын.)* Аллаһ иң ышанычлы саклаучы. Хәсрәттәгеләргә иң мәрхәмәтле—Аллаһ.

**65.** Йөкләрен чишкәндә алар үзләренең тауарларын таптылар. Һәм әйттеләр:

—Ий, атакаебыз, нишлибез? Тауарларыбыз кире үзебезгә ияреп кайткан. Бу акчаларга тагын бер дөя йөге икмәк сатып алып кайтырбыз. Алып кайткан икмәгебез бик тә аз микъдарда бит. Энебезне саклап кына йөртербез,—диделәр. **(66)** Ягъкуб әйтте:

—Бәлагә юлыктырмаенча, аны сау-сәламәт килеш алып кайтачакбыз, дип, Аллаһ исеме белән ант итмәсәгез, мин аны сезгә биреп җибәрмәм,—диде.

*(Ул теләгәнчә)* ант иттергәннән соң, тагын әйтте:

—Безнең сөйләшүгә Аллаһ шаһит,—диде. **(67)** Аннан өстәде:—Угылларым, шәһәргә бөтенегез дә бер капкадан кермәгез. Аерым-аерым, төрле капкалардан керегез! Юкса, мин сезне берничек тә Аллаһның җәзасыннан коткара алмам. Хөкем Аллаһтан башкага бирелмәгән. Шуңа күрә, мин бары тик Аңа гына ышанамын. Тәвәккәл итүчеләр бары тик Аңа гына баш орсыннар.

**68.** Алар, аталары кушканча, төрлесе төрле капкадан керде. Ләкин бу *(саклык чаралары)* Аллаһтан киләчәкләрдән коткарып калалмады. Бу эш *(төрле капкалардан керү)* бары тик ата хәтере калмасын өчен генә башкарылды. Чынлыкта, ул *(Ягъкуб)* гыйлемгә ия кеше иде. Чөнки Без аны өйрәттек. Ләкин кешеләрнең күбесе моны белми. **(69)** Кардәшләре Йосыф янына кергәч тә, ул энесен үз хозурына алдырды.

—Беләсенме, мин синең кардәшең бит,—диде.—Аларның кылмышлары өчен син бик кайгырма.

*(«Риватьләргә күрә, кардәшләрен сыйларга дип, хәзрәти Йосыф табын әзерләтә. Аларны табын янына икешәр-икешәр итеп утырта. Биниамин ялгызы—так кала да, елап җибәрә: абыкаем Йосыф исән булса иде, без бергә утырган булыр идек,—диде. Хәзрәти Йосыф аны үз табынына ала. Ашап-эчкәннән соң, хәзрәти Йосыф кардәшләрен икешәр-икешәр итеп фатирларга урнаштыра. Биниамин тагын ялгызы кала. «Сиңа пар юк, алайса, син минем янда калырсың»,—диде. Биниамин әйтте: «Синең кебек кардәшең булса иде ул. Ләкин бит сине атам Ягъкуб белән анам Рәхилә тапмаган». Моны ишеткәч, хәзрәти Йосыф елый башлый. Биниаминне кочаклап ала һәм: «Мин синең абыең»,—ди».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**70.** Йөк төягәндә *(Йосыф)* энесенең әйберләре арасына затлы савыт яшерде. Юлга кузгалгач, Йосыфның йомышчысы:

—Һәй, кәрванчылар, сез угрыларсыз!—дип кычкырды. **(71)** *(Кәрванчылар борылып)*:

—Сез ни югалттыгыз?—дип сорадылар. **(72)** Болары әйтте:

—Хакимебезнең ширбәт эчә торган затлы савытын эзлибез; аны табып китергән кешегә бер дөягә төярлек ашлык бирәчәкбез. Бу эшкә мин җаваплы,— диде йомышчы.

**73.**—Валлаһи, без угры түгел!—диделәр кәрванчылар.—Безнең гауга-фетнә чыгарырга килмәгәнебезне сез бик яхшы беләсез бит. **(74)** *(Куа чыгучылар)* Әйтте:

—Ярар, алайса, ялганыгыз тотылса, ни булачак *(сез шуны беләсезме)*?— диделәр. **(75)** Аның җәзасы, югалган кувшин кемнең йөгендә табылса, шул кеше үзе түләү булачак. Без гаделсезләрне шулай җәзалыйбыз.

*(«Карак, югалган әйбернең хуҗасына кол булып, бер ел хезмәт итәргә тиеш».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**76.** Йосыф шуннан, энесенең йөген түгел, башкаларныкын актара башлады. Аннан соң гына энесенең йөгенә тотынды һәм югалган савытны тартып чыгарды. Менә шулай итеп, Без Йосыфка бер хәйлә өйрәттек. Юкса падишаһның кануннары буенча, ул энесен, Аллаһ рөхсәтеннән башка, алып кала алмаган булыр иде. Кемгә ихтыяр итсәк, Без шул кешене дәрәҗәләргә күтәрәбез. Чөнки

гыйлемгә ия һәр кешенең өстендә аннан да яхшырак Галим тора. **(77)** *(Кардәшләре)* әйтте:

—Ул урлаган булуы да бик ихтимал, аның абыйсы да карак иде,—диделәр. Йосыф һични сиздермәде, әмма эченнән генә уйлап куйды: сез әле һаман да шундый ук яман затлар икәнсез. Аллаһ сезнең ни сөйләгәнегезне бик яхшы ишетеп тора. **(78)** Әйттеләр:

—Әй, Газиз, чыннан да, аның бик карт атасы бар. *(Төпчеген югалтуга карт түзмәс)* монын урынына безнең берәребезне алып кал. Чөнки без сине игелек кылучы, дип беләбез. **(79)** Ул әйтте:

—Әйберебезне йөгеннән тапкан кешедән башкасын алып калудан Аллам сакласын. Шулай итсәк, без, чыннан да, гаделсезлек кылган булыр идек.

**80.** Өметләре өзелгәч, алар бераз читкә китеп киңәштеләр. Олыракларыннан берсе *(Яһүдә)* әйтте:

—Атабыз безне Аллаһ исеме белән ант иттерде. Узганында да Йосыф белән ничек итеп гаделсезлек кылганыгызны онытгыгызмыни? Атабыз рөхсәт иткәнчегә чаклы яки Аллаһ үзе хөкем чыгарганга кадәр, бу җирдән китмәмен. Аллаһ хөкем чыгаручыларның иң гаделе. **(81)** Кайткач, атабызга әйтегез: ий, атакаебыз, шик юк ки, ул угрылык кылды. Без күргәнебезгә генә шаһитлек итәбез. Күрмәгәнебезне белмибез. **(82)** Без булып кайткан шәһәргә барып, үзең белешә аласың. Яки шуннан килә торган карванчылардан сораштыра аласың: без дөресен сөйлибез, дип әйтегез, зинһар. **(83)** Ата кеше *(Ягькуб)* әйтте:

—Ышанмыйм!—диде.—Нәфесегез сезне шушы яман эшкә *(ялганга)* этәргәндер. Миңа тагын сабыр итәргә генә кала. Өмет итәмен ки, аларның һәрберсен Аллаһ миңа кайтарып бирер. Аллаһ барысын да белүче хикмәтләр иясе. **(84)** Алардан читкә борылды һәм әйтте:

—Аһ, Йосыфым!—дип сызлана башлады. Ул хәсрәтен көчкә тыеп тора иде. Елый торгач, аның ике күзенә дә ак төште. **(85)** *(Угыллары)*:

—Син әле һаман Йосыфны оныта алмыйсың. Валлаһи, болай булса, сине бөтенләй чир басар яки кайгыңнан үлеп тә китәрсең,—диделәр. **(86)** *(Ягькуб)*:

—Дөрес, кайгымны бары тик Аллаһка гына сөйлимен. Сез белмәгәннәрне мин Аллаһтан килүче хәбәрләр аша беләм,—диде.—(87) Ий, угылларым, барыгыз, Йосыф белән энесен яхшылап эзләгез. Аллаһның ярдәменнән өметегезне өзмәгез. Кяферләрдән башкалар Аллаһ ярдәменнән өметен өзмәс.

*(Ягькуб угыллары тагын кәрван белән Мисырга, Йосыф янына киттеләр.)*

**88.** Йосыф янына кергәч, әйттеләр:

—Ий, бөек аксөяк, илебезгә кытлык килде. Без аз гына акча белән килдек. Тиешлебезне тулы үлчәп бир, зинһар. Безгә юмарт бул. Шик юк ки, Аллаһ хәер биргәннәрне бүләкләр. **(89)** Йосыф әйтте:

—Сез томаналыгыгыз аркасында, Йосыф белән энесен нишләткәнегезне беләсезме?—диде.

**90.**—Син әллә, чыннан да, Йосыфмы?—диделәр.

Ул да:

—Әйе, мин Йосыф буламын,—диде.—Монысы минем энем *(Бинияминн)*. Бер-беребез белән кавышуны Аллаһ хәзерләде. Кем Аллаһ каршысында гөнаһ эшләүдән курка, кем сабыр итә, шул, һичшиксез, Аллаһ тарафыннан бүләкләр алыр, игелек кылганнарның игелеге заяга китмәс. **(91)** Әйттеләр:

—Валлаһи, чыннан да, Аллаһ Тәгалә сине бездән өстен куйды. Хак, без гөнаһкяр булдык. **(92)** Йосыф әйтте:

—Бүген мин сезгә үпкәләмим инде, Аллаһ сезне гафу итсен иде. Ул, миһербанлыларның да миһербанлысыдыр. **(93)** Минем шушы күлмәгемне алып кайтыгыз да атамның йөзенә каплагыз, ул күрә башлар. Һәм бөтен гаиләгезне монда алып килегез,—диде. **(94)** Кәрван Мисырдан киткәч, ата кеше әйтте:

—Бу инде саташа башлаган, димәгез. Әйтәмен ки, мин Йосыф углымның рухын сизәм.

**95.**—Валлаһи, бу синең электән килгән саташуың гына,—диделәр өйдәгеләре.

**96.** Сөенечле хәбәр китерүче *(Яһүдә)* аның йөзенә күлмәкне каплауга ук, *(Ягькубның)* күзләре күрә башлады. Ул:

—Мин сезгә: Аллаһ тарафыннан килгән хәбәрләр аша сез белмәгәннәрне беләм, дип әйттемме, юкмы?—диде.

**97.** Әйттеләр:—Ий, атабыз, безне гафу итсен дип, Аллаһка догалар укы, зинһар. Чөнки без, чыннан да, гөнаһлы булдык.

**98.**—Сезнең өчен Раббымнан ярлыкау сорап, ялварачакмын. Аллаһ ярлыкаучы, гафу итүче,—диде Ягъкуб.

**99.** *(Йосыфның ата-анасы—бөтен кардәшләре Мисырга килә)* Йосыф янына кергәч, ул ата-анасын кочаклап алды:

—Аллага тапшырып, Мисырга иминлек белән, төкле аягыгыз белән керегез,—диде.

**100.** Ата-анасын ул абруй тәхетенә утыртты, кавышу сөенеченнән аларның барысы да *(Йосыфның шәһрәте алдында)* баш иде, намаз укыды. Йосыф әйтте:

—Ий, атакаем, менә бу эшләр әллә кайчан күргән төшемнең юралуы булыр,—диде.—Раббым аны, ниһаять, тормышка ашырды. Дөресе шул: Аллаһ миңа рәхмәтен яудырды. Мине зинданнан чыгарды. Кардәшләрем белән минем араны шайтан бозганнан соң, сезне чүл аша имин чыгарды. Шик юктыр ки, Раббым ихтыяр иткән колына мәрхәмәтле. Хактыр ки, Алла барысын да белеп торучы хикмәт иясе. **(101)**

—Йа, Раббым, милкеңнән миңа *(насыйбын)* бирдең вә *(төштә күрелгән)* вакыйгаларның ничек юралачагын өйрәттең. Ий, күкләрне һәм Җирне яралткан, Син дөньяда да, Ахирәттә дә минем остазым. Мөселман булган хәлемдә җанымны ал, зинһар. Һәм мине изгеләр рәтенә куй.

*(«Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, хәзрәти Ягъкуб Мисырда, улы Йосыф янында 24 ел яшәп вафат була. Васыятенә күрә, җәсәде Шамда, атасы Исхак янына җирләнә. Хәзрәти Йосыф та атасыннан соң 23 ел яши, 120 яшендә вафат була. Аның җәсәден Мисыр халкы мәрмәр сандыкка салып, Нил елгасына батыра. Байтак еллар узгач, хәзрәти Муса сандыкны алып, Ягъкуб (галәйһиссәлләм) янына җирли».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**102.** *(Мөхәммәд)* менә сиңа таныш булмаган хәбәрләрдән Йосыф кыйссасы шушы булыр. Аны сиңа вәхий итәбез. Алар фетнә эшләргә җыенганда син алар арасында түгел идең. **(103)** Син никадәр генә тырышсаң да, кешеләрнең күбесе иман китермәячәк. **(104)** Гәрчә, син бу эшләрең өчен алардан түләү сорамыйсың. Коръән халыклар өчен үгет-нәсихәттер. **(105)** Күкләрдә, Җирдә *(Аллаһның барлыгына, берлегенә, гыйлеменә, кодрәтенә, Аның хикмәт иясе икәнлегенә)* күпме дәлилләр бар, алар бу дәлилләрдән йөз чөереп китәләр. **(106)** Аларның күбесе Аллаһка гыйбадәт кылып та, Аллаһка тиңдәш итеп, әллә нәрсәләргә табыналар. **(107)** Аллаһ тарафыннан убылып килә торган һәлакәттән яки абайламастан Кыямәт көне килүдән котылып калырбыз, дип өмет итәләрме икән алар?

**108.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт:

—Менә бу—минем юлым,—диген.—Мин сезне ачык күз белән Аллаһ тарафына чакырдым. Мин үзем һәм миңа ияргәннәр якты юл табачакбыз. Әлхәмдүлилләһ, мин мөшрикләр белән бергә түгелмен. *(Аллаһның тиңдәшләре юк)*,—диген. **(109)** Синнән элек тә *(пәйгамбәр итеп)* җибәргән илчеләребез *(әллә кайдан түгел, үз араларындагы)* шәһәр кешеләреннән сайланган иде. Шул ир кешеләргә вәхий күндергән идек. *(Ни гаҗәптер)* әллә соң *(мөшрикләр)* Җир йөзендә ил гизеп, дөнья күреп йөрмиләрме, үзләреннән әүвәл яшәгән *(мөшрикләрнең)* кара тәкъдиренең ничек тәмамланганын белмиләрме? Ахирәт йорты *(нәҗестән, гөнаһлардан)* сакланганнар өчен, әлбәттә, иң яхшысы булыр. Сез әле һаман шуны аңлап бетермисезмени соң?

**110.** Һәй, пәйгамбәрләрем! Инде өмет киселде, безне ялганчыга чыгардылар, дигән вакытта сезгә ярдәмем килде вә Без теләгән кешебезне коткарып калдык. Ләкин гөнаһлы халык өстеннән җәзабыз алынмас.

**111.** Хактыр ки, бу кыйссаларда акылы булганнар өчен бик күп гыйбрәтләр бар. Бу *(Коръән)* уйлап чыгарылган гына нәрсә түгел. Аннан элек килгәнне *(башка китапларны раслаучы)* дөресләүче, һәр нәрсәне ачыклаучы *(Китап буларак иңдерелде)*. Иман китергән халык өчен мәрхәмәтле һәм тугры юл күрсәтүче ул *(Коръән-и Кәримдер)*.

## *Ибраһим Салаховның тууына 90 ел*

# Язмыш хатасы микән?..

...Мөмкинлеге чыккан саен Ибраһим ага Салахов ерак араларны якын итеп Казахстанның Күкчәтау төбәгендәге Кызылтъяр авылыннан Казанга ашыкты. Әйе, башкача мөмкин дә түгел: бирердә аның иң матур, кабатланмас яшьлек еллары узган, иҗат белән бәйле беренче тәэсирләр, иҗат очкыннары, Агыйдел сылуы Зәйтүнәгә булган беренче мәхәббәт тә шушында кабынган. Ниһаять, тәүге китабы да монда дөнья күргән...

Казанда аны яраткан укучылары һәм хәтта үз вакытында сөргенлек еллары газапларын башларыннан кичергәннәр—дуслары да көтте. Күрәсең, үзенең «Йөрәктәге яралар» исемле истәлегендә әдип юкка гына: «Казан—минем рухани бишегем, йортым. Мин анда язучы буларак тудым һәм «үлдем»,» дип язмагандыр *(Соц. Татарстан, 1989 ел, 16, 18, 20 июль саннары).* Чыннан да, ни аяныч, әдип язмышындагы фаҗига дә нәкъ менә Казаннан башланган.



Ибраһим Салахов байтак газап һәм җәзалар күрсә дә, озын гомер юлы узган әдип. Өч ел элек мәрхүм булган язучыга быел 30 августта исә 90 яшь тулган булыр иде...

И. Салаховның нәсел шәҗәрәсе Татарстанның Балтач җирлеге белән бәйле булса да, (аның әти-әнисе Низами белән Маһижамал ачлык елларында Казахстан далаларына бәхет эзләп чыгып китә), ул гомере буе читтә яшәде. Әмма аның әсәрләре татар әдәбияты дөньясында өйрәнелде, киң катлам укучылар да бу иҗатны җылы кабул итте, әдәбиятыбызда аның үзенә аерым бер урыны да формалашты. «Колыма хикәяләре» («Тайгак кичү») фаҗига-хроникасы һәм әдәбияттагы уңышлары өчен 1990 елда олы бүләк—Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелү—бу әдипкә булган зур хөрмәт, иҗатын югары бәяләү буларак кабул ителде.

1998 елның 8 апрелендә, үләренә берничә генә ай кала, Ибраһим ага тормышында тагын зур, истәлекле вакыйга булып узды. Казахстанның башкаласы Астанада Президент Нурсолтан Абиш улы Назарбаев аны «Парасат» («Алтын дуслык») ордены белән бүләкләде.Әдипкә бу орден бирелү—зур мәгънәгә ия иде. Президент үзенең чыгышында аны: «Казахстан халкы өчен зур хезмәт, татар һәм казах, рус әдәбиятлары арасында ныклы күпер салудагы эшчәнлеге өчен» дип билгеләде. *(Степной маяк, 1998 ел, 1 май)*

Татар халкының күренекле язучысы Мөхәммәт Мәһдиев тә «Үз илендә пәйгамбәр юк» исемле мәкаләсендә аны: «Ибраһим ага Салахов—татар белән казах әдәбиятын, мәдәни табышларны тоташтырып торучы бер шәхес», дип бәяләгән иде *(Соц. Татарстан, 1991, 27 ноябрь).*

Шулай итеп, әлеге бүләк белән Казахстан халкы да әдипкә булган хөрмәтен, аның ике җөмһүрият язучысы да булуын исбатлады.

Әйе, мондый олы бәяләргә И. Салахов, чыннан да, лаек иде: тормышы белән дә, иҗаты һәм эшчәнлеге белән дә. (Ибраһим ага озак еллар дәвамында Күкчәтауның татар мәдәнияты үзәге җитәкчесе вазифасын да башкарды бит әле.)

Иң куанычлысы шул: Ибраһим ага якты дөнья белән үзенә булган зур хөрмәтне белеп хушлашты. Сабыр, акыллы булды әдип, беркайчан һәм һичкемгә авыр сүз әйтмәде, булганына канәгать иде ул. Ә иң әһәмиятлесе— катлаулы тормыш юлы кичсә дә, тоталитар системаның барлык җәза этапларын узып сәламәтлеген югалтса да, әдип кешеләргә булган ышанычын һәм мәхәббәтен югалтмады, аның рухы сынмады. Бер әңгәмәбез вакытында мин аннан авыр елларда аңа гаеп тагучылар турында, аларның соңгы язмышы турында кызыксынган идем. Ул кешеләргә начарлык эшләүчеләрнең тормышта да бәхетсез булуларын әйтте һәм үзенең гомер буена: «Яхшылык эшлә дә, суга сал—халык белмәсә, балык белер» мәкаленә таянып яшәвен әйтте. Күрәсең, яхшылык, кешеләрне ярату хисе аны иң авыр вакытларда да саклап калгандыр.

«Дөресен әйткәндә, мин үзем бу елларга хәтле килеп җитәрмен дип хыяллана да алмый идем,—дип язды ул миңа 1996 ел башында җибәрелгән бер хатында—Колыма алтын приискаларында 50-60 градуслы суыкларда 10-12 сәгать забойда эшләгәндә, сменаның ахырына кадәр җитәмме, катып үләмме дип кенә уйлый идем... Күпләр шул забойда калдылар. Ә мин... Бу язмышның бер хатасы, могаен».

Әдипкә язмыш мәрхәмәтле булдымы, мәрхәмәтсезме—кистереп кенә әйтүе кыен. Әмма бер нәрсә ачык: күргән газапларын, чор хаталарын, олы дөреслекне күпләргә ачып салу өчен исән калды ил агасы. Һәм шушы хәл, шушы максат белән яшәү, язу аны киң катлам укучыларга таныткы.

«Минем исемсез улыма хат» шигырендә автор үз тормышы турында түбәндәгечә язган иде:

Минем тормыш кояш төсле якты,
Май аедай матур башланды,
Ләкин...
Кара болыт басты аның күген,
Аякларга богау ташланды.

Дәһшәтле, куркыныч 1937 еллар... Кешеләр бер-берсенә ачылырга, сөйләшергә куркып йөргән дәвер. 1928 елда үги анадан качып диярлек, ашкынып һәм зур өметләр баглап Казанга килгән егет, бу шомлы елларга кадәр педагогия техникумында белем ала, «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр», «Пионер каләме» һ. б. матбугат органнарында шигырь, хикәя, мәкалә һәм очерклар белән катнашып, каләмен шактый чарлап өлгерә. Әле алай гына да түгел: яшь кенә булуына карамастан, чорның атаклы шәхесләре—Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, С. Рафиков, М. Җәлил, Ф. Кәрим һ. б. белән аралаша. Актив журналистлык эшчәнлеге һәм әлбәттә, актив иҗаты нәтиҗәсендә үзе дә шул чорның талантлы язучылары рәтендә йөртелә башлый. Аның бер-бер артлы «Ярату» пьесасы (1936), «Дуэль» (1937), «Мәхәббәт һәм өмет» (1937) повестьлары, «Постта» (1937) шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. «Кызыл Татарстан», «Кызыл Армия», «Совет әдәбияты» һ. б. матбугат органнарында аның әсәрләрен уңай яктан бәяләп мәкаләләр басыла.

Әмма үсеп, танылып килгәндә генә ул 1937 елда репрессиягә эләгә һәм 58 статья белән гаепләнеп, аның 10 елдан артык гомере «халык дошманы» исеме белән төрмә һәм лагерьларда үтә, биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителә. Димәк, төрмәдән азат булгачтын да әдипне җиңел тормыш көтмәгән. «Колыма хикәяләре» фаҗига-хроникасында И. Салахов әлеге елларны, кешеләрнең аңа мөнәсәбәтен гаҗәп дәрәҗәдә тәэсирле, оста тотып алынган сәнгать чаралары ярдәмендә укучыларга җиткергән иде инде. Хәтта үзенең иң якын кешеләре—әтисе, үги әнисе, бертуган сеңлесе тарафыннан да кимсетелә, рәнҗетелә әдип. Хатыны, кечкенә малае белән өйдән куып чыгарылгач, ниһаять, Кызыл Яр авылы сельпосының ашханәсенә буфетчы-сатучы булып эшкә урнаша ул. Маһинур белән үзләренә бер куыш— өй җиткергәч тормыш бераз җайланып киткәндәй булса да, биредә аны әле бик күп сынаулар көтә.

1956 елның янгырлы, суык, шыксыз бер көне күп газаплар кичергән И. Салаховка, ниһаять, әйтеп бетергесез зур шатлык—аклану кәгазен китерә. СССР Верховный Советы Президиумы Председателе К. Е. Ворошиловка бер-бер артлы язылган хатлар үзенекен эшли. СССР Югары судының Хәрби коллегиясе язучының эшен янадан карап, 1937 елгы хөкем карарын юкка чыгара.

Ундүрт ел буе зарыгып, өметләнеп һәм өметсезләнеп көткән соңгы таяныч, «Әбелхаят—яшәү кәгазе» анда кабат кешеләргә ышаныч, мәхәббәт уята. Ин зур шатлыгын уртаклашу өчен автор Казанга, яшьлеге үткән шәһәргә ашкына. Бераздан биредә иң якын дуслары—Хәсән Туфан һәм Сөббух Рафиков белән очрашуны тасвирлаган «Сагыну» истәлеге языла.

1937—56 еллар аралыгында әдәбияттан аерылып торырга мәҗбүр булган әдип, акланганнан соң ныклап иҗат эшенә керешә. Аның тиз арада «Дала дулкыннары» (1957), «Күкчәтау җырлары» (1961) дигән шигырь җыентыклары, «Төн кызы» (1971) исемле хикәяләр, очерклар, легендалар җыентыгы, «Мәхәббәт картаямы?» (1980) повесте, Фәхретдин бине Мифтахетдин, Г. Ибраһимов, С. Атнагулов, Р. Алкин, Г. Мөхәммәтшин, Г. Гали, Г. Нигъмәти кебек күренекле шәхесләр турында истәлекләре, әдәбият тарихына караган материаллары, балалар өчен хикәяләре дөнья күрә.

И. Салахов ирекккә чыкканнан соңгы әсәрләрен нигездә үзенең шәхси биографиясенә, күргән-белгәннәренә таянып иҗат итә. Аны зур язучы итеп таныткан «Күкчәтау далаларында» (1965), «Имәннәр тамыр җәйгәндә» (1986), «Колыма хикәяләре» (1989) әнә шулай дөнья күрә.

«Колыма хикәяләре»—И. Салахов иҗатының иң биек ноктасы. Биредә алтмышынчы еллар шартларында ачыла башлап та, ахыргача фаш ителеп бетмәгән сталинизм чоры, тарихтагы «ак таплар», шәхес культы елларында ил кичергән фаҗига тулысы белән ачылган. «Күкчәтау далаларында» (1965) романында автор бу чор турында беркадәр мәгълүматлар биргән иде инде. «Колыма хикәяләре»н язарга алынуны исә ул намус эше дип саный, ул кысынкы елларда качып-посып булса да, иҗат итәргә алына.

Автор бу әсәрен кечкенә хикәя һәм новеллалардан төзи, язу эше өзелгәндә дә бөтенлеген югалтмый торган әдәби алым сайлый. Чөнки тормышлар үзгәреп, язуны тапсалар—кабат төрмә һәм лагерь юллары башланачак ич. Әсәренең язылган хәтлесен тимер әрҗәгә салып, алмагач төбенә күмә бара ул. Бу турыдагы бер истәлегендә автор соңрак: «... бәлки тоелган гынадыр: төбенә кульязмамны күмгәч, алмагач ачы алмалар бирә башлады кебек. Язларын бакча шау чәчәккә төренгәндә, алмагачым мина хәсрәттән чәче агарган кеше булып күренде», дип, образлы итеп искә алды *(«Ялкын, 1989, 6 сан)*.

Утызынчы еллардан алып Х. Хәйри, Г. Гали, К. Нәҗми, һәм алга таба, С. Әдһәмова, С. Рафиков, Н. Арсланов, С. Актаев, Е. Мырзәхметов, З. Нури һ. б. тарафыннан иҗаты уңай бәяләнгән бу әдипнең «Колыма хикәяләре» басылганнан соң әсәрләре янабаштан өйрәнелә, бәяләнә башлады. Мисалга, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин «Калыпларга сыймый ул» мәкаләсендә хәтта: «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре»)—хәзерге татар әдәбиятының горурлыгы», дип язды. Шушы ук мәкаләсендә тәнкыйтьче бу иҗатка гомуми бәя дә бирде: «Бу күп кырлы, күп темалы иҗат турында кыскача гына әйтүе шактый кыен. Лирик шигырьләрдән алып ил язмышы турындагы романга кадәр булган киңлек бик аз әдипләр өлешенә генә туры килә. Моның өчен, сүз остасы булудан тыш, Ибраһим Салаховныкы кебек мәгънәле тормыш, гражданлык батырлыгы да кирәк» (Тат. яшьләре, 1991, 19 сентябрь).

Үзе дә шәхес культы җәзасын татыган А. Гыйләҗевнең әсәргә бәясе түбәндәгечә булды: «... әсәре, авторның йөз аклыгы булу белән бергә, татар халкының горурлыгы да, казанышы да. ... Эчтәлеге белән гаять үзенчәлекле, документаль төгәллек белән язылган бу әсәр—Сталин чорының роман-хроникасы да, илебез халыкларының тирән фаҗигасе дә ул. Шуның белән бергә, бик күп миллионнар арасыннан могҗиза белән исән калган Ибраһим ага Салаховның җан авазы да» *(Җан авазы. Китапта. И. Салахов.—Колыма хикәяләре.—К, 1989.)*

Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин исә «Илебез тарихында партиянең XX съезды ниндиерәк роль уйнаса, безнең өчен И. Салаховның әсәре дә

шундыерак роль уйнаячак», дип бәяләде. *(Затлылык. К. 1989.)*

Тәнкыйтьче Ә. Сәхәпов фикеренчә, «Тайгак кичү» кырыс реалистик рухы белән Хәсән ага Туфанның лагерьда әрнеп язган шигырьләренә аваздаш: «Ул чын мәгънәсендә дөреслекне тудырырга тырыша. Һәм үз максатына ирешә дә» *(Алтын тамырлар. К. 1990).*

Кыскасы, җәмәгатьчелек әсәрне хуплап каршы алды һәм аны, гомумән алганда, «шәхес культы корбаннарына куелган һәйкәл», дип бәяләде *(Г. Ахунов. Соц. Татарстан, 1991, 9 сентябрь).*

1991 елда әсәр рус телендә дә дөнья күрде. Аерым мәгълүматларга караганда, фаҗига-хроника Станбулда—төрек, Казахстанда—казах телләренә дә тәрҗемә ителгән.

Инде әйтелгәнчә, романның сюжет һәм композициясе шактый үзенчәлекле. Әсәрдә әйтергә теләгән төп фикерне, конфликтны бер ноктага җыеп торучы—ул авторның үз образы. Романда автор шәхесен күз алдында тотып М. Әгъләмов та: «И. Салахов исеме рәнҗетелгәннәр авазы булып яңгырады. Рәнҗетелгәннәр... Бу сүз безнең хәтергә мәңгегә сеңеп калырга тиеш», дип язган иде *(Шәһри Казан, 1991, 7 сентябрь).*

Рәнҗетелгәннәр авазы үз вакытында сәхнәдә дә яңгырады. Казан Татар дәүләт яшьләр театры үзенең 1995-96 нчы елгы сезонында фаҗига-хрониканы «Тайгак кичү» исеме астында сәхнәгә куйды. Төп фикерне, үзәк конфликтны бирү ягыннан әсәр шактый йомшак сәхнәләштерелгән булса да, спектакльдә әдипнең үзенең дә катнашуы зур бер вакыйгага исәпләнергә хаклы. Тамаша азагында «Яшь Ибраһим»ның һәм 85 яшьлек әдипнең, ягъни образның һәм прототипның сәхнәгә бергә менүләре, Ибраһим аганың чыгышы ул вакытта тамашачыларга нык тәэсир ясады. Чөнки чынлык, хакыйкать иң битараф күңелләрне дә тетрәндерерлек иде. Әлеге күренешне «тапталган яшьлек белән очрашу» дип, бик мәгънәле итеп атавы белән тәнкыйтьче Ф. Галимуллин мең кат хаклы иде.

Инде мәгълүм булганча, 1994 елның октябрь аенда Тел, әдәбият һәм тарих институты Казахстаннан әдипнең архивын алып кайтты. *(Алып кайтучы—шушы институтның фәнни хезмәткәре Зөфәр Мөхәммәтшин).* И. Салахов үзе исән вакытта ук архивы турында кайгыртты, аның киләчәге турында борчылды. Аның аерым хезмәтләре безнең шәхси архивта да саклана, беркадәрен инде матбугатта да бастырдык. Бу нисбәттән, авторның язган хатыннан өзек китереп үтәсе килә: *«Бүген Марсель Әхмәтҗановтан архивны алулары турында хат алдым. Син, Ләйлә сеңелем, институтка барып Марсель һәм Юзиев Нил белән сөйләш—архивны нишләтергә уйлыйлар? Син инде ул эштә минем күз-колак бул һәм актив катнаш. Мин барыннан да сиңа гына ышанам—бәлки ниндидер практик чаралар күрелер, дип. Бу хатны алу белән институтка барып минем теләкләрне әйт, бу хатка салып җибәргән тәкъдим-искәрмәләрне күрсәт, аннан миңа хат яз.*

*24 октябрь, 1994 ел. Кызыльяр авылы».*

Үз вакытында әдиптән шушындыерак эчтәлекле хатлар, ышаныч кәгазьләре алынса да, архивка кереп эшләү рөхсәте безгә авыр бирелде. Зур күләмле әсәрләрнең каралама вариантлары, истәлекләр, очерк, шигырьләр, илнең төрле төбәкләреннән килгән хатлар—бирердә әле өйрәнәсе материаллар байтак. Ләкин, ишетеп белүемчә, И. Салахов архивы әле бүгенге көнгә кадәр тасвирланмаган икән—кызганыч.

Соңгы елларда безгә әдипнең туганнары, якыннары белән дә хат алышырга туры килгәләде. Алар аерым архив материалларының Казахстан музей һәм мәктәпләрендә саклануын, әле байтак өлешенең өйдә булуын яздылар. Димәк, әле бу юнәлештә эшләү мөмкинлекләре алда да зур.

И. Салахов үзенең бер мәкаләсендә: «Мин халык трагедияләренен—кайгы, горурлык һәм куркаклык, кешелеклелек һәм вөҗдансызлык картиналарының тере шаһиты», дип язган иде *(Казан, 1994, № 5-6).* Бүген ул инде—мәрхүм. Тик, шулай булса да, аның исеме, иҗаты һәм, димәк шаһитлыгы да әле һаман да күпләр күңелендә яши.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ОЯ ТОЙГЫСЫ

Сөенечле хәл: яна гасырга, яна меңьеллыкка безнең татар әдәбияты үзенә бер төрле күнел күтәренкелеге белән килеп керде. Замандашларның хис-кичерешләрен чагылдыруда бер генә чорда да алдынгылыкны бирмәгән шигърияtne инде әйткән дә юк, әле бит хәтта әдәбиятның авыр артиллериясе саналган проза тармагы да, туксанынчы еллар уртасындарак күпмедер дәрәҗәдә хәлсезлек кичереп алганнан соң, гасыр ахырына таба янадан да җанлана һәм үзенең элеккеге еллар традициясенә лаеклы мәртәбәле урынына күтәрелә башлады. Шулай ук публицистиканың да киң даирә авторлар көче белән көн таләпләренә авазлаш кайнар рухлы язмалар биреп баруын хупларга кирәк. Соңгы елларда театрларда куелган аерым спектакльләр уңаеннан үз адресына байтак кына тәртмәле сүзләр ишетсә дә, нигездә, драматургиябезнең хәлен дә начар диярго тел бармый—чөнки анда даими рәвештә яңа авторлар күренеп тора, кызыклы яңа әсәрләр еш пәйда була. Әдәби тәнкыйть тармагында да күпмедер җанлылык күзәтелә диярго мөмкин сыман. Сирәк кенә булса да бирелә дә яшь көчләр күзгә ташлана, алдагы елларда әдәбият мәйданында ат уйнаткан һәм аннары бер мәл пассивлашып алган тәнкыйтьче кадрлар соңгы арада янадан иҗади яктан активлаша төште.

Бу елларда төрле нәшриятларда басылып чыккан әдәби китаплар санының һаман арта баруы да безне сөендерергә тиеш дип уйлыйм. Әйе, анысы сер түгел: сыйфат ягыннан алып караганда алар бер-берсеннән җир белән күк кебек аерыла—бирелә безнең әдәби тәнкыйтьне иге-чиге күренмәгән «эш фронты» көтеп тора! Әмма, мәсьәләгә икенче яктан күз салсаң, бүген татар телендә әдәби китапларның шактый ук мул басылуы ул—милләттәшләребезнең китапка, басма сүзгә булган зур ихтирамы дигән сүз дә бит әле. Димәк, безнең замандашлар үзләренең иң кадерле уй-кичерешләрен, гомерләре дәвамында үз башларыннан кичкән гыйбрәтле хәл-әхвәлләрне китапка ышанып тапшыралар дигән сүз бит әле бу! Димәк алар китапның, әдәбиятның киләчәгенә зур өмет баглыйлар дигән сүз! Шулай икән—димәк аларның рухи дөньялары, күнел омтылышлары дөрес юлдан бара.

Менә шушындый оптимистик уйлар яна гасыр башында барыбызны да дәртләндерә, канатландыра. Һәм, әлбәттә, гасыр башында басылып чыккан китапларга без бүген бигрәк тә игътибарлы. Чөнки беренче ел китаплары бит алар! Алар хәтта, күпмедер дәрәҗәдә киләчәктән—алда торган еллардан—килгән яна мәгънәләрне, серле аһәннәрне дә үзләрендә чагылдыра сыман.

Шулай итеп, алдыбызда яна гасырның—беренче елның—беренче китабы ята. Шигырь китабы ул. Бу хакта аның исеме үк әйтеп тора: «Ярату яралары». Ә авторы—инде хәзер танылып өлгергән шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова. Алдыбыздагы китап—аның беренче китабы. Димәк, әнә шул яктан да игътибарга лаек бу җыентык.

Кемгә ничектер, ә минем үземә бу шагыйрәнең исемен әйтү белән менә шушы җыр сүзләре хәтергә килә:

Алкаларым сынар-сынар,
Йә югала, йә сына...

Алкалар... Татар хатын-кызының тулы, түгәрәк бәхете һәм әнә шул бәхетнең кояш сыман битләрдә, йөзләрдә балкуы булып гәүдәләнә ул алкалар... Ә инде шуңа ияреп килгән икенчерәк мәгънәле сүзләр: «сынар-сынар», «югала», «сына»... Табигатьтәге һәм тормыштагы бөек бер гармония булган парлылыкны юксыну, шуны тансыклау тойгысы бирелә сизелер-сизелмәс киная, тел

төбендәге уй, әкерен генә исеп киткән жил рәвешендә генә—скрипканың нәфис моны сыман гына ишетелеп куя түгелме? Әйе, шагыйрәнең талантлы күнеле бирелә бик матур һәм укучыда тирән ассоциацияләр уята торган образга юлыккан. Шушы ук шагыйрәнең тагын менә мондый жыры да бар бит әле:

Күзләреннән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

Бирелә беренче ике юлда сүзләр бик матур, ягымлы булса да, аларда әлләни яналык юк, ә менә инде өченче-дүртенче юллар үзләрендәге мәгънә яналыгы, үзенчәлеге белән ничек балкып, яктырып тора. «Үзем яраткан кадәрле» дигән өч сүзгә бу дөньядагы бөтен гашыйкларның нурлы күз карашларының яктысы, йөрәкләренең һәм жаннарының кояштай балкулы, барча өмете һәм темпераменты сыйган шикелле. Чыннан да, гашыйк кешенең йөрәк психологиясе ничек төгәл һәм нечкә тотып алынган әнә шул «үзем яраткан кадәрле» дигән сүздә! Бирелә инде мәхәббәтнең бөтен көче һәм шул ук вакытта субьективлыгы да, фажигаи ялгызлыгы да—кыскасы бөтен-бөтен язмышы... Әнә шуңа күрә ул сүзләрнең укучы, тыңлаучы күнеленә тәэсире дә бик зур.

«Ярату яралары» дип исемләнгән бу китапта менә шушы жырлар шикелле тирән һәм үзенчәлекле хискә ия шигырьләр күп. Алар укучыга өч бүлеккә бүлеп тәкъдим ителгән: «Гамь», «Гөлләр сере», «Алма бакчасы».

Беренче бүлекнең нинди эчтәлеккә ия булуы турында инде исеме үк әйтеп тора—бирелә бүгенге тормыш чынбарлыгы китереп чыгарган рухи-әхлакый проблемалар, аларның нечкә күнелле кешеләргә булган тәэсире һәм яшен уты кебек балкып-балкып китүче яшәеш фәлсәфәсе.

Тулаем шушы бүлекнең нигезе булырдай, шагыйрәнең үзе өчен дә программ характердагы әсәрләр дә бар. «Оя» дигән шигырьне мин, мәсәлән, шулай кабул иттем.

Көннең бүген күнеле тулган
Яшь коя да яшь коя.
Качар идем бу сагыштан
Тапсагызчы бер оя.

Әйе, оя... Кошлар өчен генә түгел, кешегә дә оя кирәк. Ә инде хатын-кызга бигрәк тә! Аның өчен оя бигрәк тә мөһим. Оя ул—жил-яңгырдан ышыкланырдай коры һәм ышанычлы почмак та. Оя ул—гаилә кору һәм балалар үстерү, бергә-бергә яшәү бәхетен тату жирлеге дә. Оя ул—сөйгәненнең жан һәм тән жылысы тоела торган бердәнбер кадерле нокта да...

Әмма ни кызганыч: якынча алганда егерменче гасырның икенче яртысында әнә шул кадерле жирлекне, ышанычлы нигезне табу һәм тапканнан соң аны саклый алу, озак яшәтә алу яшәешнең иң зур проблемасы булып әверелде. Кешеләр тормышының бик кызу темплар белән шәһәрләшүе, фән-техника һәм сексуаль революция нәтижәләрендә хәзер гаилә адәм баласы өчен кирәкле, әмма бик тә дефицит булган күренешкә әверелеп китте.

Замананың бу фажигаи тенденциясе тормышта төрле чагылышларда, вариантларда яши. «Иске өй» дип аталган шигырендә Ф. Мөслимова аны болайрак күрсәтә:

Балалары үсеп, канат ярган
Жылыдан да жылы оя бу.
Дулкын каккан, давыл искән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу.

Әнә шул өйне хәзер сүтеп яталар... Бирелә шагыйрә күзе бик зур фажига күрә, аны замананың бер начар чагылышы дип кабул итә, шуңа күрә шагыйрә жаны кайта-кайта өзгәләнә:

Карлыгачлар оя корган нигез,
Үрмә гөлләр үскән бакчасы.
Ишегалларында яшел чирәм—
Юкка чыга менә барчасы!

Күрәсезме, шагыйрә югалып баручы гармонияне ничек итеп күз алдына китереп бастырды. Менә шундый гүзәллекне югалтуны бары тик үз әниенне югалтуга гына тиңләргә мөмкиндер! Хәтта әле бирелә аннан да зуррак фажига турында сүз бара бугай: ничәмә-ничә буын кешеләрне тудырып үстерәчәк Ана—Табигать-Ана хакында сүз бара ич монда!

Шул ук рухтагы «Күчә комнар...» шигыре исеме белән Дәрдемәндне искә төшереп алса да, бирелә инде чын безнең заман фажигасе күренә:

Ишәлтауның инде яртысы юк,
Бульдозерлар һаман кимерә.
Шул тавымның ком бөртеге итеп,
Жилпеп атты язмыш мине дә.

Әйе, безнең чор тормышының иң зур тетрәнүе—адәм баласы өчен ышанычлы ояның югала баруы—

шагыйрәнең күп әсәрләрендә чагыла. «Капка», «Ике фәлсәфә», «Бу заман» шигырьләре дә әнә шуңа мисал була ала. Ә инде «Китәләр...» әсәре боларның һәммәсенә лирик-фәлсәфи сөземтә сыман янгырый:

Нигә соң һаман да югалтам?
Нигә соң китәләр, китәләр?

Бу юлларны укыгач Э. Хемингуэйның «Кем рухына чаң кагалар?» әсәрендәге тирән мәгънәле мондый сүзләр дә искә төшеп куя: «Кем рухына чаң кагалар дип сорама, синең рухыңа да чан кагу бу».

Шулай шул—барыбыз бергә уртак Оябызны, Табигать диган бердән-бер һәм ышанычлы җирлегебезне югалта барабыз шул! Әнә шундый фаҗигаи хәлләр уртасында калган бүгенге шәхеснең жан трагедиясе менә бу рәвештә дә ачыла:

Калып булмый, китеп булмый,
Йөзмичә дә юк чара.

Шушы юллардагы шикелле хисси киеренкелек, рухи һәм психологик тирәнлек әлеге әсәрләрне укучыга кадерле, кызыклы, кирәкле итә. Шуның белән тулаем китапның да рухи-эстетик кыйммәте арта, ул безнең күңел сердәшенә әверелә.

Инде баштарак әйтеп үтелгәнчә, бу китапның икенче бүлеге бик тә мәгънәле рәвештә «Гөлләр сере» дип исемләнгән һәм ул үзенә тупланган шигырьләре белән бүгенге көндә очынып-дәртләнеп тә, еш кына вакытларда сөю утларыннан янып-газапланып та яшәүче Гашыйк Йөрәкнең үз сөйгәненә атап язылып, ни сәбәпледер җибәрелмичә калган ялкынлы хатлары кебек кабул ителә. Бер шигырендә шагыйрә хәтта бу хакта болай дип әйтеп тә уза:

Айлы төндә шигырь генә язам
Хат язарга сина оялып...

Әйе, хатка языласы иң кадерле сүзләр, иң садә-керсез кичерешләр, күңелнең иң-иң тирән катламнарындагы, иң төбендәге аеруча кадерле тойгылар, омтылышлар, күңел җилпенүләре-талпынулары биредә. Әлеге шигырьдә әйтелгәнчә, шагыйрә турыдан-туры сөйгәненә ачылырга ояла, кыенсына (биредә без тагын бер мәртәбә татар хатын-кызының рухи чалымнарын тоеп алабыз, танып алабыз), ләкин ул, шигырь язам диеп тотынгач, сөйгәненә булган бөтен-бөтен хисләренең үзләреннән-үзләре түгелгәнен, елга-ташкын булып агылганын, ташып китүен сизмичә дә кала... Шуның кадәр дә тулган-тулышкан икән алар йөрәк түрендә—кечкенә генә тамчы тамса да кичерешләрнең галәмәт зур буасын ерып, ачып, агызып җибәрергә генә тора:

...Кочаклармын елап
Очрый гына күрмә!

Ләкин күп чагында Фәйрүзә Мөслимова гашыйк Йөрәкнең холык-табигатен бу рәвештә түгел, ә шигъри ишарә, матур киная, тирән мәгънәле ымнар белән белдерә:

Бәйләмә инде кара атыңны
Капка төбенә, су өчен генә.
Үзем дә беләм: көям дә кибәм
Юк өчен генә, юк өчен генә.

Шигырьдән өзеп алынган менә шушы дүрт юлда да матур әчке мәгънәле бер шигъри күренеш килеп туды түгелме? Капка төбенә бәйләнгән ат инде ул—кызлы өй өчен бик зур ишарә, димәк бу тирәдә бик хикмәтле «кунак» йөри дигән сүз... Әле ул «кунак»ның йөрәге дә яна икән, югыйсә су эчәргә туктар идемени?! Ә соң кыз? Ул да әнә «көям дә кибәм» дип әйтеп тора—димәк аның да күңеле су юлына таба тарта... Бик якын көннәрдә (яисә инде матур кичләрдә) беренче очрашу булачагы да сизелеп тора—чөнки ике йөрәкнең дә омтылышлары уртак ич! Ләкин, шул вакытта, татар кызына хас оялчанлык, хәтта кырыслык та сизелеп куя: ул боларның барысын да «юк өчен генә» дигән булып бәяли. Ә чынлыкта монда без хатын-кызның бөтен язмышын хәл итәчәк мәсьәлә—Мәхәббәт турында сүз барганын бик яхшы белеп торабыз.

Әйе, безнекеләр хис-тойгыларын сөйгән кешесенә турыдан-туры ачарга ояла инде алар. Әчкә, күңел түренә җыя бара, туплый, тутыра инде алар! Әллә соң әнә шуңа күрәме безнең татар хатын-кызларының мәхәббәте көчлерәк, куәтлерәк һәм... бөтен нәрсәне (шул исәптән үзара татулыкны да!) бөтереп агызып китәрдәй дәһшәтле агымга әверелә микән?

Синең өчен, синең хакка
Күңелләрем кубәләктер.
Белмәсәң дә, сизмәсәң дә
Бәхетләрем түгәрәктер.

Бу юлларны укыгач, хәтта шагыйрь Тукайның кызларга булган оялчан, ләкин көчле әчке мәхәббәте искә килеп төшә.

Ләкин Фәйрүзә Мөслимованың бу

китабы бер дә юкка гына «Ярату яралары» дип аталмаган—аның иң зур өлешен мәхәббәт, сөю драмаларына багышланган һәм үзләреннән вулкан аткандагы сыман ут, ялкын чәчеп торган чын мәхәббәт шигырьләре тәшкил итә. Биредә безнең еллар мәхәббәтенең киң гаммадагы чагылышы яши.

Синең—минсез,минем синсез үтәр
Киләчәккә калыр бер хатирә.

* * *

Җан авазым йолдызларга аша:
—Авыр булыр сиңа миннән башка-а!

* * *

...Елларынның елап агышымы...

* * *

Күлдәй тыныч һәм... куркыныч!

Әле генә күреп киткән менә бу юллар инде Мәхәббәт белән саубуллашканнан соңгы күңел халәтен белдерүче көчле ут көлтәләре. Якындагы янгынның безне дә пешерә, куыра, яндыра торган ялкыннары алар! Китаптагы әлеге шигырьләр безгә шулай тәэсир итә. Биредә ирексездән Мостай Кәримнең:

Әмма мине шагыйрь ясадылар
Югалтулар белән сагышлар,—

дигән классик юллары да искә төшә. Французчалап: «Си ля ви...» дип тә әйтеп куясы килә... Чыннан да, яшәү әнә шундый бәхетле очынулары һәм газаплы тетрәнүләре белән—барысын бергә алганда гүзәл бер симфония булганга күрә матур һәм тәмле шул инде ул! Бу китап яшәүнең әнә шундый киң диапозондагы гүзәллеген әйбәт, тулы чагылдыра.

Ә инде китапның соңгы бүлеге—«Алма бакчасы»—алдагы ике бүлектә без кичергән бөтен хисләрне, тойгыларны бергә бәйләүче, берләштерүче аерым бер поэма сыман кабул ителә. Гүяки алмагач һәм алма образы аша шагыйрә кешеләр, гашыйклар язмышын бирә. Алмагачның язын балкып чәчәк атуы да, алмасын үстерә-үстерә куануы да, ә инде көзләр килгәч алмаларның коела, ботакларның сына, яфракларның коела башлавы да—биредә һәммәсе дә кеше башыннан кичә торган сөенечле һәм көенечле, әмма тәэсирле тормыш күренешләре булып кабул ителә.

Алдарак китерелгән шигырь юлларыннан укучы инде үзе дә күргәндер, аңлагандыр: шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова әсәр иҗат иткәндә шигырь тукымасын матур-матур сүзләр белән, купшы-купшы телбизәкләр белән, истә кала торган поэтик детальләр белән әлләни бизәп, чуарлап тормый. Шигырьләрне укыган чагында бик тиз күзгә ташлана торган әнә шул тышкы билге шагыйрәнең шәхсән үз холкын да һәм әнә шуңа бик тә бәйләнгән иҗади табигатен дә сиздереп тора. Әйе, дисең—бу шагыйрә халыкта кайсыбер иҗатчыларга карата әйтелә торган «тел бистәсе» дигән төшенчәгә һич кенә дә туры килми. Бу шагыйрә тәмле-тәмле сүзләр белән сыйпап-юмалап һәм шул ук вакытта... алдашып та яшәүче түгел. Ул—ихлас кичерешләр, җитди, тотрыклы, тирән һәм көчле хисләр кешесе!

Язган чагында да шагыйрә үзенең төп игътибарын хис-кичерешнең үзенә, аның асылына, чын табигатенә юнәлтә. Әнә шул кичерешне, шул давылны тәгәл һәм тулы итеп, бар катлаулыгында һәм тирәнлегендә ачып салырга тели, шуңа омтыла. Һәм аның бу төп теләге уңышлы рәвештә тормышка да аша. Китаптагы күпсанлы уңышлы мисаллар шуны раслап тора.

Әлбәттә, тормыш булгач, җанлы иҗат процессы булгач—әсәрләр бер югарылыкта гына килеп чыга алмый. Йөрәктәге хисләр дә төрле чакны төрле кайнарлыкта, төрле экспрессиядә була ич! Бу китапта да ара-тирә тиешле кайнарлыкка ирешеп үк җитмәгән әсәрләр очраштыра... Аннары, урыны-урыны белән, артык шәхси үпкә хисләре дә күренгәләп ала. Укучы өчен аларның зур әһәмияте юк, билгеле.

Ләкин андый шигырьләр бу китапта бик аз. Шуңа күрә алар шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың шигърияттәге уңышына һич кенә дә күләгә төшерә алмый.

...Менә без шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың беренче китабын укып чыктык. Әйе, мона кадәр газета-журналлар аша таныш булган бу иҗат, чыннан да, җитди, тирән дөнья икән! Ул безне җан, рух өчен бүген бик тә мөһим булган хәзинәләр белән баетты, безне әхлакый һәм рухи яктан көчәйтте. Ә иң әйбәте—бу шигырьләрне укый-укый безнең күз алдында бүгенге көн татар хатын-кызының рухи портреты хасил булды. Фәйрүзә Мөслимованың бу китабындагы күпчелек әсәрләр укучы күңелендә гаилә, оя тойгысын көчәйтүгә, шуны ныгытуга булыша дип әйтәбез икән—хәзерге иҗат өчен бу зур казаныш, мәртәбә.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

*Nənilərgə uqığız*

# İlgizər Soltan

## Yaratam

Yaratam almanın
Qızarıp peşkənen;
Ciləknen sikerep
Qulıma təşkənen.
Yaratam yılğanı —
Dulqınnar uzışın:
Alar belən kilə
Çabışıp uynıysım.
Yaratam urmannı —
Çəçəkle alanın.

Urmanğa şuŋa min
Şatlanıp baramın.
Yaratam, yaratam...
Nigə gel yaratam? —
Urmannan qaytqanda,
Şunı uylap qaytam.
Aŋladım, aŋladım,
Aptıramam bütən:
Alar da bit mine
Yaratalar ikən!

## Ə min nigə qızaram?

İslam nigə qızarğan?
Eləkte şul qızlardan:
Bersen ürtəgən ide,
Qızlar cıyılıp kilde,
Tarttılar qolağınnan,
Yıqtılar ayağınnan...
Əy eləkte İslamğa,
Çaptı tübən uramğa...

Almaz nigə qızarğan?
Tağın «ikele» alğan:
Məs'ələ çişə belmi
Ul matematikadan...

İrek nigə qızarğan?
«Berle» aldı yazmadan.
Əygə birelgən eşnen
Bersen də ul yazmağan...

Alsu nigə qızarğan?
Oyala malaylardan:
Yumağan qolaqların,
Kisməgən tırnaqların...
Ə min nigə qızaram?
Minme, min bit alarnı
Sezgə ələkləp toram.
Şuŋa, bəlki, qızaram?!

## Kələ genə seŋelem...

Aygəl konfet yarata,
Matur konfet qəğəzləren
Minem alğa
Tarata.

İrek kitap yarata.
Kitaptağı rəsemnərne
Miŋa buşlay
Qarata.

Alsu yoqı yarata.
Miŋa kürsətə yoqısın:
Gel yata —
Karawatta...

Nəfis şiğer yarata,
Məktəptən ul kən sayın
Ber şiğer
Yatlap qayta.

...Ə min qızıq yaratam,
Kən də nəni seŋeləmə
Ber qızıq
Totıp qaytam.

Kələ-kələ, seŋelem
Üzenə cıya bara —
Bəten qızıknı
Minem!..

# Uqucı süze
# Укучы сүзе

Хөрмәтле редакция!

Былтыр журналыгызны мактап хат язган идем инде. Аны бастырырсыз дип көтмәгән идем, бераз тәнкыйть тә бар иде анда. Бу юлы сезгә бик күптәннән уйлап йөргән бер фикеремне житкермәкче булам. Татарлык турында ул. Чит җирләрдә яшәүче кайбер татарларда үз милләтеннән, үз теленнән оялу тойгысы бар. Мин моны Явыз Иван Казан ханлыгын басып алганнан соң, гасырлар буе татар халкын җәберләү, көчләп чукындыру, йотарга тырышулар нәтиҗәседер дип беләм. Әмма хәзерге татарны хәзерге урыс җинмәгән дә, буйсындырмаган да бит. Шулай булгач, ник туктамый соң ул «оялу» һәм «бытовой» шовинизм? Минемчә, урыс та үзенең тарихи гаебен аңлый, буйсындырылган халыкларның күтәрелүеннән шүрли, курка (мәсәлән, Чечня), шуңа күрә янадан-яңа явызлыклар эшли. Безгә икенче сортлы халык булу тойгысыннан арынырга кирәк, татар исеме белән горурланырга кирәк!

Русиянең 80% артык мәйданы «вакытлы басып алган» җирләр (халыклары белән бергә). Шуңа күрә аларны буйсындыру, талау өчен воеводалар, наместниклар, губернаторлар билгеләнгән. Хәзерге «вертикаль хакимият» тә нәкъ шуны хәтерләтә түгелме?!

Татар халкының җырлары моң-зар белән тулы. Әдәби әсәрләрдә дә шул. Ә бит бар икән бүтән җырлар да. Мәсәлән, И. Шакиров башкаруындагы «Каръят батыр». М. Гайнетдиновның «XVII йөздә татар яңарыш хәрәкәте» әсәрендә *(«К. У.» № 7, 8, 1992)* зур йөрәкле татар уллары турында күп язылган. Андагы вакыйгаларны укыганда йөрәк ярсый. Ш. Маннап мәзәкләре арасында татар үҗәтлеге Зәйнуллин берәмлеге белән үлчәнә икәнен укыдым *(«К. У» №1, 1999).* З. Зәйнуллинның «Агыйделнең аръягында» әсәре дә бик ошады. Мин үзем дә армиядә 37 ел хезмәт иттем. Татар хәрбиләренә караш К. Шәйхетдиннең «Кышлар узар...» дигән язмаларында бик дөрес сурәтләнгән. Кайчагында миңа: «упрямый татарин» диләр, ә мин: «упрямый булмасам, әллә кайчан урыслашкан булыр идем» дип җавап кайтара идем. Ф. Сафинның «Җаек буе—яу җире» язмаларындагы *(«К. У.» №8, 2000)* «чикылдап торган татар» турында рәхәтләнеп укыдым. Менә шундый «чикылдап торган татар» саклап кала да инде безнең милләтне, ул беркая да югалмый, таралмый, сер бирми!

Журналыгызда күбрәк шундый әсәрләрне укыйсы иде, чын татар рухы, татар теле белән язылганнарын. Үрнәк итеп Батулланың «Алып батыр мажаралары»н китерер идем. Шул ук, М. Гайнетдинов тикшеренүләрендә «Урал буеннан Кашгаргача араны кылыч уйнатып гизгән, рыцарьлыгы, галимлеге белән хәтта дошманнарын таң калдырган, күп санлы мәкерле дошман тозагына төшмәстән, тарих сукмакларында эзсез югалган милли-азатлык көрәше батыры Карасакал» (Гарибальди!) турында язылган. Моннан бит менә дигән тарихи роман чыгар иде (кая Н. Фәттах, кая яшь язучылар?). Мондый үрнәкләр булса, оялмас иде татар, яшь буынга нинди шәп мисал! Татар төзүчесе турындагы К. Кәримов романы—«Ком сәгате»—чын безнеке. Хәзер әдәбиятта татар халкын таркау итеп сурәтләү бик киң җәелде. Я. Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» романында бер бригадир төп геройның тенкәсен корыта. Г. Гыйльмановның хыялый романы «Албастылар» исә ике исерек аркасында бик аяныч бетә. Кемгә кирәк ул мескенлек? Кая безнең батырлар, киң күңеллелек, кешелек сыйфатлары? Гомер буе зарланып, фәкыйрьлектән баш чыкмас. Ник соң әле без алай куркабыз? Бездән курыксыннар! Сер бирмик әле! Сезнең барчагызга да уңышлар телим.

**К. К. НАСРЕТДИНОВ,**
*Мәскәү шәһәре*



İctimağí-mədəní tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХӨРМӘТЕНӘ

1 июльдә бөек язучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы публицист Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә (Чистай районы) беренче мәртәбә Исхакый укулары булып узды. Бирегә Татарстанның күп төбәкләреннән делегацияләр килде. Күренекле язучылар, артистлар, укытучылар, җәмәгать оешмалары вәкилләре...

Тантананы Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан халык депутаты Фоат Галимуллин ачып җибәрде. Аннары Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Роберт Миңнуллин чыгыш ясады.

Билгеле булганча, моннан дистә ел элек Гаяз Исхакый исемендәге премия гамәлгә куелган иде. Тантанада Исхакый премиясе лауреатлары Рабит Батулла, Әхмәт Рәшит, Газинур Морат, быел бу бүләккә лаек булган язучы Фәүзия Бәйрәмова чыгыш ясады.

Күренекле каләм ияләре Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзиев, Кояш Тимбикова, Лена Шагыйрьҗан чыгышлары да тантананың күркәм бер бизәге булды. Соныннан бәйрәм Яуширмәнең үзәк мәйданында дәвам итте. Бирегә әдәбият һәм сәнгать әһелләре чыгышлары Г. Исхакый һәм башка драматургларның әсәрләреннән өзекләр күрсәтү, татар эстрадасы йолдызлары башкарган җырлар белән аралаштырып алып барылды.

Гаяз Исхакый бәйрәмен уздыруда Камал театры директоры Шамил Закировның өлеше аеруча зур булды.

## САБАДА—«КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

18-19 июньдә Сабада «Казан утлары» көннәре уңаеннан әдәбият-сәнгать бәйрәме булып узды. Районга Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, сатирик язучы, журналның бүлек редакторы Камил Кәримов һәм драматург Рәдиф Сәгъди килде.

Алар башта Саба урта мәктәбендә булып, югары класс укучылары белән очраштылар. Килгән кунаклар белән Сабада яшәп иҗат итүче каләмдәшебез язучы Тәлгат Нәҗмиев таныштырды.

Очрашуда катнашучыларны халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары Нурислам Насыйбуллин, мәгариф бүлеге мөдире Шамил Зиннуров уку елы тәмамлану белән тәбрикләп, һөнәр сайлауда уңышлар теләделәр.

Шул ук көнне кичен Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры артистлары Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек» спектаклен Саба тамашачыларына күрсәтте. Язучыларны һәм сәнгать осталарын сабалылар аягүрә алкышлады, җылы сүзләр әйттеләр.

Язучылар шулай ук район хакимияте башлыгы Рәис Миннеханов белән очраштылар, эшлекле әңгәмә кордылар. Язучылар район китапханәсендә, музейда да булдылар. Балалар иҗат үзәгендә узган очрашуда район мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханә мөдирләре катнашты. Шунда ук Гөлчәчәк Галиеваның башта «Казан утлары» журналында басылган, соңыннан китап булып чыккан «Тулгак» повестен тәкъдир итү булды. Бу театральләшкән чарада автор үзе дә катнашты.

## ҖӘМӘГАТЬ СОВЕТЫ

Июнь ахырында Татарстан Эчке эшләр министры каршында төзелгән җәмәгать советының беренче оештыру утырышы булды. Совет составында республиканың 40 абруйлы гражданы—предприятие һәм оешма җитәкчеләре, дини конфессияләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре бар.

Совет рәисе—эчке эшләр министры Әсгат Сәфәров республикада бүгенге оператив хәлгә бәя бирде, яна органның максатларын, бурычларын аңлатты.

Эчке эшләр органнары хәзер дини конфессияләр, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре белән килешүләр төзеделәр инде. Ә. Сәфәров фикеренчә, Советны төзү—җәмгыятьнең барлык сәламәт көчләрен туплауда тагын бер адым. Советның төп бурычы җинаятьчелек белән көрәштә ТР ЭЭМ сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүдә, тормышка ашыруда Эчке эшләр министрлыгына ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт.

Президиум советы сайланды. Аның составына Әсгат Сәфәров (рәис), министр урынбасары Александр Вайда (урынбасар), министр киңәшчесе Сергей Кириллов (җаваплы секретарь), Түбән Кама шәһәре хакимияте башлыгы Илсур Метшин, «Мелита» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Алексей Пахомов, КФЭИ ректоры Наил Хәйруллин, Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов керә. Шулай ук бу абруйлы Совет соста-

вында «Казан утлары» журналының бүлек редакторы, язучы Камил Кәримов та бар.

## ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН—ФӘН ДОКТОРЫ

Мәскәүдә Русия Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясе диссертация советында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин сәяси фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклады. Диссертация яклау уңышлы үтте. Ф. Мөхәммәтшин үзенең диссертациясендә Русия Федерациясе субъекты булган Татарстанның социаль-сәяси үсешен яктыртты. Аның фәнни консультанты—Казан дәүләт университеты профессоры, философия фәннәре докторы М. Фарукшин.

## ВЕТЕРАННАР ОНЫТЫЛМЫЙ

Хәтер һәм кайгы көнен Татарстан Язучылар берлегендә билгеләп үттеләр. Бөек Ватан сугышы инвалиды, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Хисам Камалов**ка күптән түгел 75 яшь тулган иде. Күренекле әдипкә «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем дә бирелде.

Сугышның башыннан алып, аның соңгы көннәренә кадәр алгы сызыкта булган язучы Геннадий Паушкинның ил-ватан алдындагы хезмәтләре Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән билгеләп үтелде.

Шул уңайдан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары шагыйрь Роберт Миңнуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәм аның урынбасары Шаһинур Мостафин 22 июнь көнне фронтовик язучыларның өйләрендә булып, аларның хәл-әхвәлләрен белештеләр, югары бүләкләргә лаек булулары белән котладылар.

## ТУКАЙ МУЗЕЕНДА

Күптән түгел Казанда Габдулла Тукай музее ачылуга 15 ел тулуга багышланган чара булып узды. Анда Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Моннан 15 ел элек музейга беренче экспонатны Америкада яшәүче милләттәшебез Шәмсия Апакай китергән була. Ул Габдулла Тукай тарафыннан әзерләнеп, Җамал Вәлиди мөхәррирлегендә 1914 елның 14 маенда Япониядә нәшер ителгән китап. Шул вакыттан бүгенге көнгәчә музейда йөзләрчә материал, шагыйрьләрнең шәхси әйберләре тупланды. Быел исә музейда Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек булучыларның бүлмәсе дә булдырылды.

Шулай ук эшлекле кинәшүләрнең берсе—музей директоры Мөнип Низамиев инициативасы белән үткәрелгән музей хезмәткәрләренең Тукай премиясе лауреатлары белән очрашуы булды. Бу кинәшмәдә Татарстанның халык шагыйрьләре Илдар Юзиев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Тукай премиясе лауреатлары Әхсән Баянов, Роберт Миңнуллин, рәссам Абрек Абзгильдиннар катнашты. Соңыннан музейның баш рәссаме Фаил Зыязов кунакларга үзенең картиналарын бүләк итте.

## ХАЛЫКАРА СЕМИНАРДА

21-22 июньдә журналыбызның редколлегия әгъзасы, «Мәгариф» нәшриятының директоры, язучы Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) һәм Татарстан Министрлар кабинетының бүлек мөдире Ким Миңнуллин Уфада булып, анда Европа Советы булышлыгында үткән «Төбәк телләре турында Европа Хартиясе» буенча халыкара семинар эшендә катнаштылар. Моннан тыш алар Башкортстан премьер-министры урынбасары Х.Х. Ишморатов белән очраштылар, Башкортстан халык мәгарифе министрлыгында, «Китап» нәшриятында, «Кызыл таң» газетасы редакциясендә һәм Башкортстан дәүләт университетында фән, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында фикер алыштылар.

## ЛИТВА ТАТАРЛАРЫ ХӘЛЛӘРЕ

Вильнюста бизнес белән шөгыльләнүче, шәхси предприятие һәм фирма хуҗалары булган татарлар Литва мөселманнары белән очрашу үткәрделәр һәм анда «Ориент-2001» не оештыру мәсьәләләре каралды.

«Ориент» дип Польшада үткәрелеп килүче татар тарихына багышланган фәнни-популяр конференцияләр атала. Мондый чаралар Белоруссиядә дә гадәткә кереп бара. Литвада исә алар беренче мәртәбә үткәреләчәк.

«Ориент-2001» июль башында үтәчәк. Шул ук көннәрдә Каунас мәчете ачылуга 10 ел тулу уңаеннан тантаналар да уздырылачак.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен шагыйрь, «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге редакторы **Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы**на «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Төнге Казан вокзалы.

*Н. Исмәгыйлев фоторәсеме.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Факил Сафин (Факил Әмәк).

# ЯҢА КИТАПЛАР

ТАГИРОВ И. Р. **История национальной государственности татарского народа и Татарстана.** Казан: Татарстан китап нәшрияты.—2000. 312 б. Тиражы—2000 данә.




Күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарихчы академикның бу житди хезмәте татар халкының һәм Татарстанның милли дәүләтчелек тарихына багышланган. Ун бүлектән торган китапта халкыбызның өч мең еллык дәүләтчелек тарихы бар дип раслана. Һуннар дәүләте, Төрк каганаты, Хазар каганаты, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы... Китапның шактый өлеше үткән гасыр ахырында Татарстанның мөстәкыйльлек өчен шактый ук нәтиҗәле көрәш сәхифәләренә багышланган. «Мондый хезмәтләр тарихи хакыйкатьне һәм тарихи гаделлекне торгызуга ярдәм итә» дип яза кереш сүз авторы профессор М. Фарукшин. Бу китап галимнәр, укытучылар, студентлар, гомумән, татар халкының этнополитик тарихы белән кызыксынучы һәммә кеше өчен дә кызыклы булачак.

Сара САДЫЙКОВА. **Идел суы ага торыр** (җырлар). Казан: Татарстан китап нәшрияты. —2000. 80 б. Тиражы —3000 данә.



Бу басмада күренекле композитор Сара Садыйкованың төрле елларда иҗат ителгән, әмма киң җәмәгатьчелеккә чагыштырмача аз билгеле булган утызлап җыры тупланган. Бу җырлар Х. Туфан, С. Хәким, Н. Дәүли, И. Юзиев, Г. Зәйнашева, Л. Шагыйрьҗан һ. б. шагыйрьләр белән иҗади хезмәттәшлектә туган әсәрләр.

«Сара Садыйкованың киң катлам укучыларга тәкъдим ителгән бу җырларында аның Ходай биргән уникаль мелодик сәләте, артистлык табигате, чынбарлыкны самими бер чисталык һәм ихласлык белән кабул итүе—кабатланмас моңы тулы чагылыш таба»,—дип яза китапның редакторы—композитор Леонид Любовский. Кереш сүзне «Композиторның серле сәхифәләре» дигән баш астында музыка белгече Клара Тажиева язган.

Индекс 73210



Факил Сафин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)